ISSN 0206—4189

# Казан утлары

9. 1984



# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

9

1984

## Бу санда

Н. АРСЛАНОВ. **Учларымда кояш.** Шигырьләр . . 3
М. ХӘБИБУЛЛИН. **Кубрат хан.** Роман . . . . . 9
К. СИБГАТУЛЛИН. **Пошилар.** Шигырьләр . . . 139

«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

Д. ВӘЛИЕВ. **Мәрхүмнәр кояшы.** Хикәя . . . . 144

З. МАНСУРОВ. **Акка күчерү.** Шигырьләр . . . 156

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ЗУЕВА. **Казанда Тукай урыннары** . . . . . 161

**Сүзебез мәктәпләр турында.** Түгәрәк өстәл янында сөйләшү . . . . . . . . . . . 162

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

С. МАННАПОВ. **Чынлап та шулаймы соң?** . . 171

БИБЛИОГРАФИЯ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. **Ихлас хисләр гәүдәләнеше** . . 181

УКУЧЫ ФИКЕРЕ

З. ГАЗИЗҖАНОВ. **Әсәрне чын иткән нәрсә** . . 184

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

М. ӘХМӘТҖАНОВ. **Г. Кандалыйның яңа табылган әсәрләре** . . . . . . . . . . . . . 185

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

**Каләмдәшләребез — СССР Язучылар союзының яңа әгъзалары (Р. Вәлиева, Г. Кашапов, Хәйдәр)** . . . . . . . . . . . . . 188

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . 189

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 191

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия:*
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ *(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Роман **М. Хабибуллина** «Кубратхан» (продолжение).
На конкурс «Подвиг продолжается»: рассказ **Д. Валеева** «Слава — солнце мертвых».
Стихи **Н. Арсланова, К. Сибгатуллина** и **З. Мансурова.**
«К 100-летию Г. Тукая»: рис. **Т. Зуевой** из цикла «Тукаевские места в Казани».
За круглым столом — разговор о проблемах современной школы.
В рубрике «Литературная критика» статья **С. Маннапова.**
Отклики на новые повести **М. Магдеева** и **А. Хасанова.**
«К истории культуры». Публикация **М. Ахметзянова.**
«Занимательные истории» (из жизни выдающихся деятелей татарской культуры). «Дневник культуры». «На наших обложках» — творчество художника **Ш. Шайдуллина.**

Техник редактор *Р. Сөләйманова* Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*

Производствога бирелде 25.6.1984 ел. Басарга кул куелды 28.8.1984 ел. ПФ 09025. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64049. Заказ К-251. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

# Нури Арсланов

## Учларымда кояш

Әллә кояш бөтен җиргә кереп
Бер ялтырап калыйм ди микән,—
Табигатькә яңадан җан өреп,
Балкып чыккан әнә таң-иртән.

Агачлардан сары яфрак ява,
Җил җаена биеп, кыйгачлап.
Зыңлап-чыңлап тора зәңгәр һава,
Коен нурда, йөз син колачлап!

Учларымда кояш бу чагында,
Җирем — палас, күгем — бер дәрья.
Бөтен дөнья гүя кочагымда,—
Миннән дә бай җирдә кем бар, я?!

Җан иясе бәхет өчен туа,
һәрни татый яшәү шатлыгын.
Кеше генә дөнья куа-куа
Сизми кала михнәт — шартлыгын...

Зилзиләләр, туфаннарны үткән,
һәлакәтләр, яулар кичергән:
Кырылмаган!— Язмыш аңа күптән
Абелхәят суы эчергән.

Кешелек шулай дәвам итә җирдә.
Хәзер инде мендек айларга!
Ә һаман да тимер кием иңдә,
Тынгы йөри әллә кайларда...

Яшәү кадерен якын белгәнгәме
Ышанасы килми сугышка:
Афәт гаме бер көн бетәр әле,
Тынычлык бер җиңәр тормышта!

Мин ышанам, учымдагы кояш
Иңәр бер көн илләр җанына,
Бәхет кенә булыр дөньяга баш!—
Мин фәкать шул язмыш ягында:

Тынычлыкта чөнки яшәү чыны!
Ә яфраклар ява-тирбәлә,
Көйләп тора көзнең алтын чыңы,
Мин шатланам тыныч иртәмә.

## Шигырь төзәткәндә

Фортепиано телләредәй чыңлап,
һәрбер сүзе җырлап торса да,
Шигырь әле чыкмаган дип чынлап,
Кызганусыз күңел кул сала.

Пушкин да бит үзенең язмаларын
Биш-алтышар тапкыр төзәткән:
Шуңа балкый хәзинәсе аның
Халкы бүләк иткән бизәктән.

Мин телемне ачтым Тукай белән,
Пушкин белән чыктым зур юлга;
Үз юлымны ләкин анык беләм! —
Борылмаска булып уң-сулга.

Намусым белән бергә атладым мин,
Юллар борма-борма булса да,
Халкың белән бергә тар юл да киң,—
Үз йортыңда изге бусага!

Сөрткән саен алтын балкыгандай,
Тигән саен шигырь тылсымлы:
Күз яшьләре сыгылып саркылганда
Тел сурәтле була, тел сынлы!

Сурәтлән син, бас син бар гәүдәңә,
Ил турында изге уйларым!
Җирләгәч тә, дөнеп бер шәүләңә,
Бәлки мәңге җырлап туймамын...

Һәр бизәгең, шигырем, камилләшсен,
Күз нурларым шунда түгелсен,
Ләйсән булып тамсын кайнар яшем,
Сүзләреңнән гөлләр үрелсен!

## Егетлек турында

Борынгыда мактар булса аксакаллар
Егет белән атын бергә мактаганнар,
Ир-егетләр, Кули-Чурдай, сиксәндә дә
Егетлек салтанатын саклаганнар.

Вәгъдә бирсәң, икеләнми үтәүне бел,
Егет сүзен аклар өчен әзер тор гел,—
Бабаларның гадәт-йолаларын бозу
Әманәткә хыянәттән һич ким түгел!

Егет эше — хәрәкәттә-кузгалуда:
Уңыш фәкать яз — чәчүдә, көз — алуда,—
Тарихыңны онытсаң — юк киләчәгең,
Яшәү сере узганнарга күз салуда.

Бабаларың язган аны ташка, тузга:
Әверелмәсен нәселнең дип җаны бозга,—
Шуңа игеп, урып икмәк үзең пешер,
Берәү куйган әзер нанга кулың сузма.

Ир икәнсең — илгә тапшыр язмышыңны,
Сөйлә, шагыйрь, үз халкыңа хакны-чынны;
Бүген күрсәт фидакарьлек, изге юлда,
Һич шикләнмә, ил төзәтер ялгышыңны!

Ишетерләр микән, Нури, тавышыңны,—
Киләчәккә таба җилләр авышырмы?
Ил түренә менеп, килер буын белән
Синең дә бервакыт рухың табышырмы?!.

## Аяз иртә

Тәрәз төбендәге агачлардан
Үтеп кояш төшкән пәрдәмә:
Яфракларны нәкыш итеп салган
Пәрдәмдәге алтын шәүләгә.

Ал болытлар оҗмах кошы төсле:
Каурыйлары яшел, сарыдан...
Шатлык белән тулган җирнең өсте,
Җанга хәят рухы сарылган!

Салмак кына оча иртәнге җил,
Шаян бизәк уйный пәрдәмдә.
Бу чагында миндәй шат микән ил,
Бик бәхетле микән һәр бәндә?!.

## Берәү уйный

Берәү уйный әнә татар көен,
Тәрәзәсе айга караган;
Кем бизәгән космонавтлар илен,
Йолдызларын кемнәр санаган?

Күңелнең иң нечкә кылларында
Өзелеп-өзелеп сызыла бу моңнар:
Искә төшә Идел буйларында
Чәчәк аткан гүзәл урыннар...

Көйләр көйләп уйчан сагышлана,
Көйләр көйләп көләч шатлана,
Бөекләргә җырлар багышлана,
Узганнарың җырда саклана...

Чын безнеңчә итеп берәү уйный,
Йолдызлар да тыңлыйлар сыман.
Тыңлый күңел, хыяллана, уйлый...
Уянгандай тәнге моңсудан.

## Китап

Китап — хикмәт: битен ачкан саен
Күңел күзем минем ачыла,
Көндез кояшым ул, төндә аем,—
Китап илтә таңнар каршына!

Кысыр китаптан да, алыйм дисә,
Ала гыйбрәт адәм баласы.
Тик бер генә адым бит югыйсә
Юләрлек һәм хикмәт арасы.

Киштәләрем минем, күр, сыгылган,
Китаплар сер сөйли тирәмдә:
Мин тышаусыз җибәргән ат сыман
Яшел кырга — язгы чирәмгә.

## Дустың булса иде...

Дөнья күтәрләргә эш муеннан,
Тырышларга бәхет җитәрлек.
Зур бәхет шул җирдә —
Очрый алсаң тиңгә
Шул бәхетне уртак итәрлек,
Сандугач та сайрый
Гөлен сайлый-сайлый,—
Сайраулары җанга үтәрлек.
Без тормышка килгән кунак кына,
Гомер кыска — исләр китәрлек!
Ул бер йомгак ише,
Юк хикмәтле кеше
Аның серен белеп сүтәрлек.
Хәят — тылсым иле...
Дустың булсын иде
Чөкердәшеп гомер итәрлек.

## Сугыш теләүчеләргә

Ятаган ятсын кынында,
Юкса — чабасы була...
Гел усаллык кылуның да
Чиге-чамасы була.

Ике башлы, диләр, таяк,
Ятаган — ике йөзле:
Син гайрәтләнүгә карап
Каршы як чүкми тезне.

Сират күпере ул сәясәт —
Өзелердәй тартылган кыл.
Кирәксез дисәң һәлакәт —
Кирәкле салкын акыл!

Яңа сугышмы, уйнама,
Ул — сугыш түгел — БӘЛА!—
Җиңеп чыгам дип уйлама —
Җиңү юк беркемгә дә...

## Герострат өрәгенә

Герострат ул белгән дан киләсен,
Гасырларны таңга калдырган:
Изге Артемида кәлисәсен
Ут төрткән дә исәр яндырган.

Шуңа охшап инде син дә әллә
Мәңгеләшсен димсең атыңны?—
Атом янгынында исән хәлдә
Күрермен дип һәр Штатыңны,

Хыялланасыңмы? Дөнья янса —
Яшәү бетсә җирдә артыңнан:
Ниткән дан ул! — көлләр генә калса
Үзеңнән һәм яманатыңнан.

# Исмәт акынның соңгы сүзләре

*Казакъ шагыйре Олҗас Сөләйманов әсәренә тәкълид.*

Яшь хатынын акын Әзербайның
Урлап качкан Исмәт далага.
Озын телләр сөйли: «Ике ярның
Булган икән гыйшкы арада».

Язмышлары тора Әзербайдан,—
Качкыннарны куып тотканнар...
Арканланган Исмәт җиргә ауган,—
Ат өстеннән тартып екканнар.

Егет көчкә аягына баскан.
Усал итеп көлгән Алибәк,
Балдакланып төшкән богау аркан —
Пычак белән телгән Алибәк.

Тиргә баткан атлар өй янында
Утлап йөргән сирәк үләнне,
Алар гына гамьсез... Дошманыңа
Күрсәтмәсен Исмәт күргәнне.

Исмәт акын каушамаган бер дә,
Уа-уа оеган кулларын,
Тыныч тавыш белән, әкрен генә
Җырга салган соңгы уйларын:

«Булды суларга батканым,
Талчыкканым...
Үкенмимен.
Бер эштән дә баш тартмадым,—
Ач йокладым,
Үкенмимен.
Күбрәк яхшыдан яманга
Ризык куйдым,
Үкенмимен.
Битләремне ай-далада
Карда юдым,
Үкенмимен.
Булмады юлга юнәтер
Хатыным да,
Үкенмимен.
Булмады дустым дип әйтер
Якыным да,
Үкенмимен.
Сөеп тирбәтмәдем олан
Тезләремдә,
Үкенмимен.
Төшәлмадым бәхет-болан
Эзләренә,
Үкенмимен.
Бакты үлем — кара томан —
Күзләремә,
Үкенмимен.

Тик бер генә үкенечем бар:
Инде дөньям ләхеттәй тар,
Бер дәм генә гомер арам,
Җирдән җилдәй үтеп барам,
Инде авыру-сырхау күрмәм,
Сагына-сагышлана белмәм...
Яшел чирәмгә ауганда —
Соңгы йокыга талганда
Бер үкенечтән күңелем китек,
Тик бер генә инде кайгым:
Кочалмадым ярым итеп
Хатынын акын Әзербайның».

Ул җырлаган моны өзлекмичә,
Бер тоташтан, салмак һәм сабыр,
Каш карайган, шомлы булган кичә —
Бөтен дала гүя бер кабер...

Көндез матур булмаса да Исмәт
Матурайткан моңлы җыр аны.
Җырда икән тылсым, бөтен хикмәт,—
Балкып киткән аның сыннары.

Тавышы тибрәп эңгер күккә менгән,
Тәне янган-пешкән, тирләгән...
Кинәт киез япма күтәрелгән,
Карт Әзербай чыккан тирмәдән:

— Алибәк! — дип ул эндәшкән улына.
— Тыңлыйм, ата,— дигән Алибәк.
— Бирегез атлар, китсен үз юлына
Ике качкын.
— Бу соң ни димәк?!.
— Китсен алар, тимә.
Киез өйдән
Атылып килеп чыккан чибәр дә;
Исмәт тотып аны туптай чөйгән,—
Атландырган шундук ияргә.
Алибәкнең атына менгән үзе:
Тояк тавышы озак яңраган.
Алибәкнең тәмам беткән түземе,
Гарьлегенә чыдый алмаган,
Ул җылаган.
— Алай булгач, тынып
Тыңла, улым! Сез дә тыңлагыз!
Исмәт мине хурлады ир булып;
Ә акынга үчлек кылмагыз.
Акын булып Исмәт минем эшне
Дәвам итәр, яңрар киң илләр!
Ит пештеме?
— Пеште, ата, пеште! —
Дип кайтарган җавап киленнәр.

— Узыгыз, я, олылап ризык хакын,
Аштан авыз итеп күрмәгә,—
Дип бөек карт, олы җанлы акын
Кереп киткән диләр тирмәгә.

1983

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# КУБРАТ ХАН

РОМАН

## 9



Сөрән салучылар халыкны бик тиз бер төбәккә җыйдылар. Багатыр мәетләрне күмү хәлен, шунсыз җыен булмавы турында аңлатты. Кирмәндәге греклар да кабер казырга чыктылар, аю-бүредән калган мәетләрне күп тә үтми бер кабергә ташыдылар, теге дөньяда аякланып киткәнче дип, өч көнлек ризык куйдылар.

Бары тик шул эшләр беткәч кенә халык, бәйрәмчә киенеп, елга буендагы тугайга җыела башлады. Аксакаллар үз даирәләре белән багатыр утырасы төбәккә чатыр кордылар. Багатыр уң кулы Ташбулатка багучы алыпларның башы Адайны алып килергә кушты. Адайны шундук китереп житкерделәр. Уң кулы итеп ниндидер төрки алыбын билгеләүгә, аны исә багучы алыплар башы итеп җибәрүенә Адай мәргән багатырга үпкәле кебегрәк тоелды. Ул арада кызлар килделәр, алар бик матур итеп киенгәннәр, үзләреннән күз алмалы да түгел иде. Багатыр Адайга карады. Әйе, үпкәле. Юк, үпкәле түгел, борчулы. Нигә микән?.. Багатыр Адайны үз янына чакырып алды, янәшәсеннән урын бирде.

— Кыз куасыңмы, Адай мәргән?

— Куам, багатырым.

— Кайсын куарга исәбең соң? Монда барысы да чибәр, барысы да яшьләр...

— Мангыш тархан кыз Айгөлне, багатыр.

— Кайда соң ул, кайсысы?

— Ул килеп җитмәде әле, багатырым. Егълый да егълый.

— Үлгән артыннан үлеп булмый. Китер син аны, Адай.

— Баш өсте, багатырым.

Ул арада кызлар берсе артыннан берсе тасмага баса башладылар, кызны куарга ниятләгән егет чыгып басуга, алостаз Дәян яулык селтәде. Сәере шул иде: кызлар барысы да диярлек елга буена җитмәс борын егетләрдән тоттыра бардылар. Ниһаять, тасмага Мангыш тархан кызы Айгөл килеп басты. Күрде дә кызны, багатырның йөрәге кысылып куйды. Кыз төс-йөзе белән генә түгел, гәүдә-сыны белән дә Чәчкәгә охшаган иде. Багатыр уйланып утырганда, Адай кызны куып тоткан да икән инде. Егет белән кыз кулга-кул тотынышып, оластаз Дәян янына килде, алостазга багатыр нидер әйтте, Дәян кулын күтәрде.

---

Дәвамы. Башы 8 нче санда.

— Халаек, багатыр сүз әйтә,— дип оран салды.
Тын калдылар, елга шаулавы ишетелә, еракта-еракта кәккүк кычкыра.
— Болгарлар, Субашлар, грек кардәшләр. Айгөлнең атасы Мангыш тархан угры Чалбай хан белән алышта башын салды. Гүзәлләрнең гүзәле Айгөл үзенә минем иң батыр алыбымны сайлады. Мин, Кубрат хан багатыры Илбарыс, Адай батырны Эске кирмәндә тархан итеп калдырам. Кубрат хан исеменнән әйттем.
— Ур-ра! Адай, ур-ра!— дип кычкырдылар, «ур-ра» тавышы Этил елгасы ярларына барып бәрелде, кайтаваз булып әйләнеп, кирмән өстендә яңгырап торды.
Эске кирмәнгә тархан итеп билгеләнгәч, кирмәннең иң олы аксакалы аңа тимер очлым кигерде, аннары Адайны киезгә салып, кирмәнгә таба алып киттеләр. Кирмән капкасын кергәндә аңардан ант эчертәчәкләр, шушы мәлдән Адай Эске кирмән тарханы, кирмәндәге һәркем аңа буйсына, аның боерыгын үти.

Икенче көнне кояш чыгар-чыкмас йөзбашлар үз алыплары белән елга буендагы тугайлыкка җыелдылар. Багатыр да килеп җитте. Алыпларның кулында таш, алар аны багатыр үткәндә бер төбәккә ташлап китәргә тиешләр. Соңыннан алостаз Дәян ташларны санады. Дүрт йөз дә җиде алып иде алайда. Йөз алыпны багатыр кирмәндә калдырды. Кояш күренде. Барысы да көнне каршы алдылар, матур көн теләделәр. Шул чак кирмән капкасыннан хатын-кызлар чыкты. Болгар алыплары атларыннан төштеләр, бер төнлек хатыннары кулыннан бер чокыр кымыз эчтеләр. Аннары саубуллаштылар. Багатыр алыпларына кузгалырга боерды. Алыплар атларына атлангач, хатыннар аларның иярләренә тотынып, тарлавыкка кадәр озата килделәр, аннары хатыннар ирләренә тагын кымыз салып бирделәр, ирләр аттан төшми генә кымызны эчтеләр, шулай ук атларыннан төшми генә хатыннарының кайнар иреннәреннән үбеп алдылар. Шуннан соң да хатыннар ирләреннән тиз генә аерыла алмадылар, урманга кереп киткән юлга кадәр кадерлеләренең өзәңгеләренә тотынып, саубуллаша, сөйләшә, вәгъдәләшә бардылар. Килерләрме сайлаганнары кайчан да булса Эске Кирмәнгә, язганмы тәңре аларга ир-канат белән очрашырга? Хатыннарның берсе дә моны белми иде. Язмыш аларны һәрчак үз диңгезенә ташлады.
Елга кырт борылды, урман башланды, юл агачлар арасына кереп ятты. Шунда моңа кадәр ирләренең өзәңгеләренә тотынып, сабыр гына сөйләшә-сөйләшә килгән хатыннарның кайсысы елап җибәрде, кайсысы дәшми-тынмый гына ирнең ат ялыннан берничә кыл өзеп алды. Шул кыл аның йөрәген ире йөрәгенә бәйләп тотачак, кыл ирне янәдән аның янына алып кайтачак, бик сагынганда баш астына кылларны салып ятканда, ир-канаты сөйдереп төшенә керәчәк.
Алыплар атларын юырттырып, урман юлына кереп киттеләр, хатыннарның кайберләре ирләре артыннан берара йөгереп барды, кайберләре сулкылдап елап калды, кайберләре дәшми-тынмый гына китеп барган сөйгәненең аркасына, җилкә аша ташлаган җәясенә, тимер очлымына карап, сабыр гына кул изәде.
Грек Агасике атта төркиләрдән ким йөрми иде. Төптимерче атын матурлаган, бизәгән. Ат күкрәгендә каплагыч, маңгаенда таҗ төшерелгән япкыч, йөгәненә көмеш тәңкәләр тезгән. Болгарлар тәңрегә табына, тамгалары — кояш, греклар христиан диненә, тамгалары — тәңре. Тәңрене тамга итеп алган Агасикене алостаз Дәян ошатмады, аны күргәч, күзе-кашы җимерелде.
Фанагүргә исән-имин кайтып җитсәләр, алостаз боларның барысын да Кубрат ханга түкми-чәчми сөйләп бирер. Нинди мәкер күрә микән Дәян бу төптимерче грек йөзендә? Тормышы белән шаярып, орышлар-

да катнаша... Юк, Агасике шикле кеше түгел, аны Төн илләре халыклары кызыксындыра. Ләкин ул аларны күрмәячәк, хәтта арадаш Субаш кардәшләрне дә күрми китәр. Ул бары тик угорларны күрер. Ә угорлар үзләре Төн халыклары белән Субашлар аша, сәүдә итәләр... Әйе, Агасике үз кеше, ә менә Илтотар шаманны һич кенә дә аңлап бетермәле түгел иде. Кичә Кызкуыш туе булыр алдыннан теге убырлы карчыкны яклап маташты. Бүген дә әнә бер читтәрәк бара, багатырга якын да килми. Багатыр Илтотарны калдырырга кушмады, үзе белән алды. Дөрес, кичә төптәңре җибәргән балдакны күргәч, шаманның күзләре әллә нишләп китте, багатыр алдына килеп баш орды... Алай да шикле кеше иде шаман. Ни өчен, әйтик, заманында Илтотар шаман Алатыр буйтурны ташлап, Чалбай ханга күчкән?.. Багатыр чыгып киткәндә уң кулы Ташбулатка әйтте: «Шаманны бер мизгелгә дә күзеңнән яздырма»,— диде.

Юл елга яры буйлап өскә күтәрелә. Шаманга да, алостаз Дәянга да юл таныш бугай, бара бирәләр. Хәер, бу җәйләүләр — Алатыр буйтур биләмәләре, Кубрат хан калдырган алай башыныкы. Кубрат хан буйтур Алатырны Төн илләре халыклары белән Эске Кирмәндә арадаш итеп калдыра. Алатыр буйтур дөнья куйганчы Кубрат ханга тугрылыклы булып кала. Угланы Чанай да Болгарда яхшы яктан гына телгә алына.

Ниһаять, куе урманны чыктылар, туктап, атларны утлауга җибәределәр, үзләре дә ашап алдылар.

Көне буена бардылар, бер генә кеше дә очрамады. Бары тик кечкә таба гына зур болынга килеп чыктылар, болын тулы мал-туар иде. Көтүчеләр, ят кешеләрне күреп, качып киттеләр. Ике алып аларны тотарга итте, әмма тапмадылар. Шунда багатыр ике сыерны суярга, казан асарга кушты.

Ашап-эчкәндә дә, аннан соң да багатыр дүрт якка да каравыл алыплар җибәрде. Йөзбашлар җыелышып, мәзәк сөйли башладылар. Берчиттәрәк алостаз Дәян белән гр.к Агасике үзара әңгәмә итәләр, шаман моңлы итеп курайда уйный, уң кулы Ташбулат ярымтавышка гына җырлап утыра.

Багатыр болын буйлап китте. Аяк астыннан төрле-төрле чәчкәләр, адым саен чикерткәләр сикереп чыга, янәшәдә кошлар сайрый. Илбарыс багатыр тархан Адай турында уйлады. Күрде бит багатыр, сизде бит: курыкты Адай аңа Мангыш тархан кызын күрсәтергә, үзенә алыр дип курыкты. Ләкин Адай белми иде Илбарысның йөрәген кем биләгәнен, белсә алай итмәс иде. Илла ни генә булмасын, Мангыш тархан кызында Чәчкә чалымнары бар иде.

Кызкуыш туена Адай бик матур киенеп килгән иде. Өстендә җофар тиресеннән теккән күлмәк, аякларында җиңел итекләр, маңгаен уратып зәңгәр тасма бәйләгән. Айгөл өстендә кара күлмәк, башында кызыл калфак, аякларында җиңелчә күн чүәкләр иде. Кыз рәтләп йөгермәде дә, егетне күтәп алгандай итте, аннары алар борылып килделәр. Кызның күзләреннән нурлар тама кебек иде. Чибәр иде кыз. Әллә соң Чәчкәгә охшавы белән артык чибәр күренде ме ул Илбарыс багатырга?

Кызкуыш туеннан соң бераз гаҗәпләнә калып, багатыр уң кулы Ташбулаттан сорап куйды: «Син нигә берәүне дә кумадың?» Ташбулат бер тын зәңгәр һавага карап торды, шуннан соң гына: «Бездә кыз куып өйләнмиләр, багатыр»,— диде.

Эске кирмәнгә китәр алдыннан Кодрак илхан багатырга әйтте: «Төн илләре халыкларыннан сак бул, багатыр. Башта илбашлары белән сөйләш, кирәк икән баш ор, ничек тә күңелләренә юл тап. Киләсе җәйләүгә, Эске кирмәнгә ыруым белән үзем күчеп килем. Сине дә ала китәрмен, атам сине миңа бәйләде».— диде.

Матур икән табигате, Кодрак илханга бәйләнүенә мыскал да үкен-

мәде Илбарыс. Мәгәр күчеп килә-нитә калса, Чәчкә нишләр... Нишләр? Тиле түгел диген инде үзеңне. Хан кызы ла ул... Кем бирсен ул кызны сиңа?... Кубрат ханмы?!

Куе үләннән дымсу хуш ис килә, төрле төстәге чәчәкләрдә бал кортлары очына, ак, кызыл, сары күбәләкләр биешә. Күрче, үлән-чәчкәсе дә, агачлары да — бар нәрсә биредә үзгә, берсе дә Фанәгүрдәгечә түгел.

Йөри торгач, багатыр зур булмаган көрбәпкә[1] тап булды. Бу көрбәпкә кемне күмделәр икән?.. Кубрат хан бу якларны буйсындырып йөргәндә һәлак булган болгарлар көрбәбеме әллә? Түгәрәкләп, өеп менгергәннәр... Бик мөмкин хәл ич. Төптәңре Ирсан, үлгән кеше бу дөньяга яңадан әйләнеп кайта, дип бара. Ничек әйләнеп кайта икән? Бүгенге хәлендәме, әллә яңадан туамы?..

Илбарыс бу турыда бер тапкыр гына уйламый. Чынлап та, кемне күмделәр икән? Бәлкем бу көрбәптә бабабыз Әти, янсә аның оныгы Әтиолан ятадыр!.. Алай дисәң, Әтиоланны ерак көнбатышта үлеп калган дип сөйләде төптәңре.

Кинәт Илбарысның күз алдына Мангыш тарханның көрбәбе килде. Мангыш тархан белән болгарлар алыпларын да бик кадерләп, яннарына коралларын, ризыкларын куеп, хәтта атларын да куеп күмделәр. Теге дөньяда да ат кирәк бит кешегә. Җәяү йөрмәс бит анда, ди, төптәңре.

Багатыр урман кырына җитте, ап-ак каеннарны күрде дә таң калды. Матур булып тезелеп киткән иде каеннар, түзмәде багатыр, урманга кереп, берничә каенны сыйпап карады. Әтил буенда яшәгән төркиләр бу агачны каен диләр, ә кайберләре аккаен, ди. Аккаен, Аппак. Матур исем. Әллә соң ханшаның исемен шушы агачтан алганнармы?.. Кубрат хан сараенда Аппакка ияреп килгән җитен чәчле кызлар булды. Соңыннан ханша аларны берәм-берәм кара чәчле болгарларга кияүгә биреп бетерде. Кызкуыш туе булган саен өч-дүрт көтригур кызы йөгерер иде.

Борылды да багатыр алыплары янына китте. Шунда ул елга буена килеп чыкты. Елга буенда ике-өч хатын кер чайкый иде. Багатырны күрделәр дә чырылдап, куаклар арасына кереп киттеләр. Багатыр адымын кызулата төште. Хатыннар кер юа, димәк якын-тирәдә генә җәйләү, я торак өйләр.

Шунда аның янына Ташбулат йөгереп килде.

— Синең Кашкаң утлап йөри әнә, багатыр.

— Мин атым эзләмим, Ташбулат. Әйт әле, Ташбулат, нинди халык яши бу төбәктә?

— Багатыр, шуны да белмисезме. Без Алатыр буйтур җәйләүләрендә. Арадаш кардәшләргә керәбезне, туры маҗарларга китәбезме, багатыр?

— Безгә Субашка керергә кушылмады, Ташбулат. Боерык бир, атларны иярләгез, кузгалабыз.

Багатыр Кашкасына кычкырды: «Бах-бах! Кашкам! Фию-ю!» Хуҗасының сызгыруын ишетүгә, Кашка томырылып иясе янына чабып килде.

Кузгалып киткәч, Дәян белән рәттән баручы шаманны куып җитте багатыр.

— Илтотар шаман, нигә бу якта күп төрле агач үсә икән? Җәйләү чоры узгач, Субаш кардәшләр малларына ни ашаталар?

— Үлән чабалар, аны киптереп, җыеп өяләр, багатыр. Субашлар моны угорлардан өйрәнде, багатыр. Угорлар ашаган үләннәр күп төрле: кузгалак, әче какы, суган, кәбестә, балтырган, тагын әлләниләр

---

[1] Көрбәп — курган.

шунда. Урман-әрәмәләрдә күп төрле җимешләр, җиләк була. Шомырт, балан, миләш, гөлҗимеш әллә ниткән җир гөмбәсе... Үләсе килми, багатыр, кешенең.

— Шаман, Төн илләрендә җәй бик кыска була, диләр. Алар ни ашыйлар соң?

— Болан, сыер ите, балык. Кан эчүчеләр дә бар.

— Канны нигә эчәләр? Ант иткәндәме?

— Канны тешләре коелмасын өчен эчәләр, багатыр. Кан эчмәсәләр аларның тешләре чери.

— Хатын-кыз ни ашый?

— Ир-ат ни ашый, шуны ашый, багатыр.

Багатыр аръякта пошн күрде, пошины шаман да күреп алды.

— Тиздән кичүгә җитәбез, аръякка чыгабыз, анда күп очрый урман сыеры, багатыр. Мажарларның җәйләүләре аръякта.

— Шаман, синең белмәгәнең юк. Шаман түгел син, чәчән. Әйт әле, шаман, син миннән куркасыңмы?

— Хаким иткән — хөкем иткән, тели икән адәм затын ятим иткән, багатыр.

— Син шаман гына түгел, Илтотар, син чәчән-шаман. Мин сине хөкем итәргә җыенмыйм. Киресенчә, мин синең ярдәмеңә мохтаҗ, шаман. Бу яклар минем өчен ят. Биредәге кешене урман-сулар урап алган. Ә мин далада үскән кеше, шаман. Далага чыгуга, мин шашам, эчемлек эчкәндәй исерәм. Биредә мин үземне начар хис итәм, шаман.

— Өйрәнерсең, багатыр. Әнә Субашлар да өйрәнде. Килгән мәлдә Алатыр буйтур да зуррак аланга килеп чыгуга, күкрәген тутырып сулыш алыр иде дә җилләнеп бер чаптырып килер иде. Соңга таба урман-болыннардан кайтып кермәс булды, һавасы шифалы ди торган иде. Әнә, әйбәтләп тирә-ягыңа кара әле, багатыр. Очар кошлар бала чыгара. Көзен җылы якларга китсәләр дә, яз янә әйләнеп кайталар. Мин сине аңладым, багатыр. Сагышланудан бу. Илеңдә сөйгәнең калгандыр, шуңа күңелең барысын да күрә. Тынычлан, багатыр. Ул бары тик бер сине ярата. Беләм, куркуың бар. Үтәр ул. Уйла, уйла, багатыр, җирең турында, кызың турында, илең турында уйла. Чалбай хан әнә кая күзе карый — шунда яу чапты. Чапты-чапты да әнә эзләгәнен тапты. Җире барның — иле бар, иле барның өе бар, өе барның көе бар, көе барның җөе бар, җөе барның туе тулыр, туе барның улы булыр, улы барның кызы булыр, кызы барның тозы булыр, тозы барның йөзе булыр, йөзе барның күзе булыр, күзе барның сүзе булыр, сүзе барның теле булыр, теле барның сере булыр, сере барның уе булыр, уе барның юлы булыр, багатыр. Нык басып йөр, җәйләүләр Кубрат ханныкы.

— Бу җәйләүләрне олуг хан икенче угланы Кодракка бирде. Тиздән ул үз ыруы белән бире күчеп киләчәк. Кубрат хан мине Кодрак илханга бәйләде. Кал син безнең белән, шаман.

— Багатыр, шаман алып түгел, ул бары тик төз агач янәшәсендә утырган кәкре агач кына. Кояш та аңа бик аз тия, жим-су да. Шаман ул ханнар күләгәсе, багатыр. Мәгәр агач күләгәсез булмаган кебек, хан да шамансыз яши алмый.

Алар янына албагучы алып чаптырып килде.

— Багатыр, кичүгә җиттек.

— Ташбулат, боер кичүдән чыгарга!

— Багатыр, минем мажарларга күренәсем килми. Калдыр мине Субашлар җирендә, миңа күп яшисе калмады инде.

— Юлдашың тәңре булсын, шаман. Син теләсә кая китә аласың.

— Инде киңәшем тыңла, багатыр. Мажарларның юлбашлары гаять холыксыз кеше. Кубрат ханга хөрмәте зур булса да, колач җәеп каршы алмас. Алтын-көмеш савыт-саба ярата. Бүләк кызганма. Угор князе олыгаеп килә. Мажарлар белән Кубрат хан килешә алды, ә менә угор-

лар белән орышты. Князь баш иде, әмма орышны онытып бетергәне юктыр. Сак бул. Ак юл сиңа, багатыр. Юлдашың тәңре булсын!

Шаман шулай диде дә атын чаптырып китеп барды. Шундук багатыр янына алостаз Дәян килеп җитте.

— Багатыр, ник җибәрдең шаманны?

— Игелекле шаман, китә бирсен. Субашларга китте, туган җәйләвенә.

— Ышанып җитмим мин аңа, багатыр.

— Шаман хан түгел, аның куләгәсе генә, алостаз.

— Кайчак куләгә дә яман эшләр эшләп ташлый, багатыр. Ярый, олага бирсен. Мине шаманнан битәр Агасике кызыксындыра... Әйдәгез, багатыр, алыплар елганы кичтеләр инде. Аръяктан мажарлар җәйләве башлана.

— Алостаз Дәян, мажар юлбашына ни бүләк итәбез?

— Хан биргән көмеш табакны, багатыр,— диде Дәян, кичүне чыгуга, албагучы алыплар янына чаптырып китте.

Кичүне чыгып, күп тә үтмәделәр, еракта мажар җайдаклары күренде.

Багатыр атын чаптырып, алга чыкты, аны алостаз Дәян куып җитте.

— Инде нишлибез, алостаз Дәян. Албагучылар җибәрәбезме, үзебез барабызмы?

— Мажарлар юлбашы Кубрат хан белән солыхта, үзе килеп Кубрат ханга баш орды. Үзебез барыйк, багатыр, шиккә калдырмыйк.

Багатыр күккә карап алды. Баш түбәсендә генә ак болытлар йөзә, болытлар арасыннан бер чыга кояш, бер кереп кача. Багатыр төптимерче Агасике ягына күз төшереп алды. Төптимерче дә ни сәбәпледер болытларга карап тора иде.

Төптимерче Агасике әрәмә буендагы мажар җайдакларын беренче булып күрде. Ул һәрбер елганы, һәрбер халык яшәгән төбәкне куенындагы картага төшереп бара иде. Яшь бозау тиресе элпә калынлык итеп кенә иләнгән, бөкләсәң учка сыярлык, ә бөтен илләрне үз эченә ала иде. Мажар алыпларының башларында җәйпәгрәк очлым, атлары карсак, елгыр күренә. Орышырга ниятләре юк кебек. Агасике биредә яшәгән һәр халыкны исендә нык калдырырга тиеш. Илгә кайту белән базилевс барысын да сорашыр. Димәк, Әтил елгасының аръягында мажарлар, төркиләр яши. Бу якта яшәгән барлык халыклар турында мәгълүматлар җыярга тиеш ул. Базилевс аңа шул бурычны йөкләде. Һәрбер варвар халкы турында базилевста мәгълүматлар булырга тиеш. Төптимерче ярты юлны үтте инде. Кубрат хан ышанычына керде, багатыры белән Әтилнең югары җәйләүләренә килде. Базилевс шымчысы өчен аз түгел иде бу. Бирегә алар Эске кирмән аша килделәр, аннан угорларга барырга исәпләре бугай, көтригурлар аша кайтырлар. Роська кермиләр булып чыга. Бирегә килергә ниятләгәндә базилевс, әлбәттә, су юлын сайлар. Корабларга грек утын куяр да...

Болгар алае мажар алыпларына җитәр-җитмәс туктады.

— Мин монда аларның юлбашларын күрмим, алостаз,— диде багатыр.

— Әнә ул, җәяүләп килә. Син дә, багатыр, атыңнан төш, җәяүләп каршы кит. Калканың, коралларың калдыр, хан хан каршына корал тотып бармый.

Багатыр аттан төште, уң кулы Ташбулатка калканын, коралларын салып бирде һәм әкрен генә болгарларга таба килүче мажар юлбашына таба китте. Мажар юлбашы багатыр белән кул сузып күреште, баш иде, багатыр да аның хәрәкәтләрен кабатлады. Мажар төркине белә икән.

— Кубрат ханның мәргән багатыры Илбарыс!

— Олуг юлбашы, мин сине күрүгә бик шатмын. Болыннарыгызда үлән мул булсын, малларыгыз көр булсын, ир балаларыгыздан игелек китмәсен.

Юлбашы бөтен йөзен тутырып елмайды, багатырны үз алыпларына таба алып китте. Шунда гына күрде багатыр, әрәмә артында болгарлардан өч-дүрт мәртәбә зур алай тора иде.

— Багатыр, ни өчен җәйләвемә килдең дип сорамыйм. Кунагым бул. Йомышың соңнан әйтерсең. Аз-маз ишетеп беләм, житкерделәр. Чалбай ханны җиңеп, Эске кирмәнне кайтаргансыз икән. Мангыш тархан әйбәт кеше иде. Исегез китмәсен, багатыр, кирмәндә минем дә кешеләрем бар иде. Чалбай хан эзләгәнен тапкан. Минем түбән җәйләүдән ике йөздән артык кызларым җыеп, әсир итеп алып киткән. Жирсез, илсез угры ханга башкача үлем кызганыч булыр иде. Алаең дәш, багатыр, кунак итмичә җибәрмим. Кайткач Кубрат ханга әйт: мажарлар сәүдәгәрләрен Эске кирмәнгә җибәрә калдылар, диген.

* * *

Мажарларда кунып, өч көн юл баргач кына угорлар җиренә життеләр. Угорлар җәйләүләренә житкәч, алостаз Дәян:

— Багатыр, угор князе заманында Кубрат хан тарафыннан рәнжетелде. Кичкә каршы җәйләүләренә бармыйк. Моннан ерак түгел төп ыстаннары булырга тиеш. Аларның безне сагалап торулары бар.

— Алостаз Дәян, кунарга урын эзлә, туктыйбыз. Атлар да ял итәр.

— Багатыр, бер киңәшем бар. Җибәрик алдан грек Агасикене? Угор князе корал ясаучыларга тими, корал ясаучыларны изгеләр дип йөри.

— Угорлар аюга табыналар, багатыр,— диде Ташбулат. — Атка табынучылары да бар. Шуның өчен аларда кыргый атлар күп була.

— Ташбулат, боер, төнгә тукталабыз.

Кич белән ашап-эчкәч, тирә-якка каравыл куйдылар. Ташбулат шаманнан кураен алып калган икән, курайда уйнап җибәрде. Берничә алып җыр башлап җибәрде.

Туктаулары кечкенә инеш буенда иде. Инеш буйлап бераз барсаң, урман башлана. Ташбулатның сүзләре чынга аша бугай, урман буенда җиделәп ат күренде. Атларны күрүгә, Ташбулат кураен ташлап, сикереп үк торды.

— Кыргый атлар, багатыр! Тотыйм берсен. Арканым да үзем белән, багатыр?..

— Ярамас, Ташбулат. Атка табынучылар да бар диден бит.

— Төп ыстандагылар аюга табыналар, багатыр. Атка табынучылары төньяктарак яшиләр. Атны алар башта суялар, тиресен тунап итен ашыйлар, аннары тире эченә үлән йолкып тутыралар, аннары шул атка атланып чыгалар. Янәсе, шулай оҗмахка керәләр. Аннары ул атка ут салалар, әче бал эчәләр дә бии-бии күңел ачалар. Төньяк угорларның колга башында ат башы күрденме, димәк, алар атка табыналар, аю башы күрдеңме — аюга. Багатыр, тотыйм бер атларын. Бергәләп өйрәтербез, күңелле булыр.

— Килешерме соң, Ташбулат. Иоанн Фасиан бер генә халыкның да йоласын мыскыл итәргә ярамый, ди.

— Алыплары җәяү орыша, болын тулы кыргый атлар йөри. Нинди йола булсын ди ул. Бер ат кына тотам, багатыр?!

— Барсын,— диде Агасике алар янына килеп.— Тотсын. Тота алса. Ат куян түгел.

Ташбулат мәргән артыннан барысы да карап калды. Урман буендагы атлар күздән язганнар иде инде. Соңгы мәлдә генә уң кулы Ташбу-

латны җибәрүенә үкенеп куйды багатыр. Менә караңгы төште, күктә йолдызлар җемелди башлады. Ташбулат кайтмады да кайтмады. Багатыр бик озак йоклый алмый ятты.

Ул таң алдыннан уянып китте. Дәртләнеп кошлар сайрый, утлауда йөргән атлар пошкырып куя, каравыл алыплар бер-берсенә дәшеп, кычкырып торалар. Күп тә үтми таң нурлары чыңлый-чыңлый күккә үрләде, яктыра башлады. Үлән-чәчкә кыякларына төшкән чык тамчыларына тиеп нурлардан җиз кыңгыраулар зеңләп тора шикелле иде. Тиздән кояш чыгар, көн туар, чык тамчылары кибәр һәм бертуктаусыз зеңләп торган чык тамчылары юкка чыгар.

Багатыр торып утырды, тирә-ягына күз ташлады. Грек Агасике үзе белән алган кол янында йоклый. Кол алып иясе яныннан бер генә минутка да китми. Ташбулат юк, кайтмады, тота алмадымы атны, әллә тотып ерак киттеме... Болгар алыплары кайсы баш астына ияр, кайсы ат япмасы куеп яткан, кайсы үлән йолыккан да хуш исле печән исен иснәп исергән — саташып куялар, төшләрендә кычкырып ук җибәрәләр. Алостаз Дәян да йокламый икән, багатыр янына килде.

— Ташбулатны җибәрмәскә иде, багатыр. Агасике кушты дип. Ул грекка мин ышанмыйм. Ташбулат бит башта Агасикене җибәрергә кушкан иде, ә ул, хәйләкәр грек, күрәсеңме эшне ничек борып җибәрде. Беләсеңме кичә нәрсә диде ул миңа. Мәргән Ташбулатның угорлар шымчысы булып куюы бар, ди. Чөнки мәргән бар нәрсәдән дә хәбәрдар иде, ди.

— Бу мөмкин түгел, алостаз.

— Ярты түмән алай белән яу чапмыйлар. Угорлар безне эх дигәнче турап бетерәчәкләр. Кубрат ханны оныта алмыйлардыр әле. Угорлар белән Сура елгасы тула.

— Без аларга орышырга түгел, изге ният белән килдек, алостаз. Кубрат ханны мәҗбүр иткәннәрдер... Тәңре болгарны ташламас, алостаз.

— Тәңре күктә, без угорлар җирендә, багатыр. Уң кулың Ташбулатны көтмә, багатыр. Угор урманда мәче кебек орыша. Әйе, аны әсир иткәннәр. Алар әле дә бездән ерак түгелләр, сагалыйлар...

— Багатыр, кузгалырга ярамас. Мин елга башында угор алыплары күрдем. Сөңге башларында ат коерыгы.

— Багатыр кояшка карады, көнне каршы алды, тәңредән игелекле көн теләде. Юындылар, ашадылар да юлга җыена башладылар.

— Багучылар җибәрикме? Кем бара!?

— Мин, багатыр,— диде Дәян.— Мин барам. Үзем белән ун алып алып барам.

— Ал. Без сезне биредә сабыр итәбез. Алыплар, атларыгызны тышауламагыз. Ял итегез.

Алостаз Дәян ун алып белән ыстан яклап китеп барды. Менә алар да күздән яздылар. Мәргәннәрнең эчләре поша башлады. Арадан берәүсе: «Алышабыз!»— диде. Тиз арада мәйдан оешты, мәйдан уртасына батыр чыгып басты.

Алыплар көрәш башлап җибәрделәр. Егылган бер алып, мәйдан читенә барып утырды, екканнары мәйданда калды. Менә башта сабыр гына карап утырган Агасике дә мәйдан эченә керде. Кем чыга дип, өстендәге күн сырмасын салып ташлады. Агасике батыр чыккан өч көрәшчене эх тә итми бәрде. Мәйданны түгәрәкләп утырышкан алыплар сикерешеп үк тордылар.

— Ай да, төптимерче, күр әле моны!..— диештеләр.

Батырга карсак кына бер алып чыкты. Күрер күзгә таза да түгел иде алып. Агасике аңа көлемсерәбрәк карап алды.

— Кил!— диде.

— Кил түгел, әйдә, грек дус,— диде алып.

Батырга чыккан алып белән грек Агасике көрәшен багатыр да карарга килде. Көрәшчеләр билләреннән алыштылар, бер урында әйләнәтулгана башладылар. Агасике карсак буйлы алыпны күтәрергә итте, әмма шул мәлдә көтелмәгән бер хәл булып алды. Карсак алып Агасике астына кереп китте, грекны күтәрде һәм гөрс итеп сыртына салды.

Алыплар моны көтмәгән иде, сикерешеп үк тордылар. Тордылар да карсак буйлы алыпны кулларында күтәреп сикертеп алдылар. Шуннан соң гына Агасике алып янына килде, кулын кысты һәм үзе ясаган әнҗе саплы хәнҗәрен бүләк итте.

— Ал-ал, багатыр. Грек Агасикене берәүнең дә екканы юк иде әле, ал,— диде.

Көрәшеп тә туйдылар алыплар, кайсы-кая таралышып, сөйләшеп утыра башладылар. Кайсысы атын карады, кемдер коралын үткерләде.

— Төптимерче Агасике, нишлибез, киңәш бир?

— Көтәбез, багатыр. Мәргән егет үзе кайтмаса, угорлар үзләре килерләр, түзмәсләр.

— Агасике, ун-унбиш алып белән мин үзем эзли китәм Ташбулатны. Мин аны табармын, Агасике. Табармын да шымчы булса башын кисәрмен.

— Ташбулатны эзлисе түгел, багатыр. Ул угорлар кулында.

— Ярый, төптимерче, тапшырдык. Тәңре безнең белән. Алайга син ия, Агасике.

Төптимерче Агасике тамагына нидер тыгылгандай ык итеп куйды, әмма кайтарып сүз әйтмәде.

— Алыпларым, боерам: минем белән ун алып китә. Кемнәр бара, җыеныгыз. Алай башы булып Агасике кала. Аның боерыгы — минем боерыгым!

Ун алып белән багатыр да китеп югалды.

Көн уртасы җитте. Агасике уйланды. Угорлар килеп чыксалар, күп тә үтмәс аларның башлары сөңге очына эленгән булыр. Дөрес аңысы, болгар алыплары тиз генә бирешмәсләр, әмма ахыр чиктә барыбер җиңүне сан хәл итәр.

Төптимерче Агасике үз кул астында калган алыпларга күз йөртеп чыкты. Алыплар тик тын торалар, бу — болгар халкы өчен гадәти хәл. Алар өчен баш итеп калдырылган кеше җавап бирә, ул ни әйтте — шуның әмерен үтәргә, үлгәнче орышырга әзер алар.[1] Ерактанрак китереп уйлаганда, бу очракта Агасике аларны болгарларга кардәш булган Субашларга яисә Тугрыхан җәйләүләренә дә алып китә алган булыр иде. Әмма моның өчен ул иң әүвәл алостаз белән багатырның башларын колга очында күрергә тиеш. Башкача эшләсә, тегеләр исән-сау Фанәгүргә әйләнеп кайтсалар, Кубрат хан аның башын кистерәчәк. Ә базилевс шымчысы Агасикенең андый ахмак үлем белән үләсе килми иде. Ул иң әүвәл базилевска Төн илләре, аларның халыклары турында мәгълүматлар алып кайтырга тиеш. Юкса аны базилевс та гафу итмәс. Төн илләре, Төн халыкларыннан җыйган кыйммәтле тиреләр беркайда юк. Әйе, Болгарларның Төн халыклары белән бәйләнеше базилевска кирәк, бик кирәк. Болгардан кайткан мәгълүматларга таянып, базилевс Кубрат ханга карата үз политикасын корачак. Илендә яшәгәндә үз алласына рәтләп табынмый иде Агасике, ул аңа монда килгәч кенә чынчынлап табына башлады. Аңа монда курку килде. Курку аны изге Гайсә каршына китерде. Һәр көн булмаса да, көн аралаш Гайсә сурәте каршына тезләнеп, аннан мәрхәмәт сорады. Гайсәсе аны әлегә саклап килә, угры Чалбай хан кадәр Чалбай ханнан исән калды. Инде угорлар сөңгесеннән дә исән-имин калса, яңадан туган кебек булыр иде төптимерче Агасике. Инде исән калмый икән, базилевс аның семьясын

ташламас, сөйләшү шулай иде. Базилевс белән шулай дип сөйләшүен сөйләште Агасике, Византия императоры вәгъдәсендә торырмы?.. Соңгы мәлдә күбрәк Кубрат ханга тартыла иде Агасике. Әллә соң гаиләсен Фанәгүргә чакыртып, бөтенләйгә монда калыргамы?— дип тә уйлады Агасике. Уйлап кына калмады, хәтта олуг хан белән киңәште дә. Олуг хан аңа ышандырып ук җиткермәде, әмма тырышып карармын, диде. Шикләнебрәк калды бугай Кубрат хан. Болгардан төптимерче бик күп мәгълүматлар алып китәчәк — шуңамы шикләнә калды. Әйе, Болгар турында Агасике хәзер күп белә. Су юлыннан башка Төн илләренә корыдан көтригурлар аша да килергә була икән. Әтил суы белән күтәрелү кыенрак булыр. Әтил елгасының түбән ягы хәзәрләр кулында. Хак анысы, базилевс хәзәрләрне дә, болгарларны да коралландыра. Базилевс моны бу ике туган халык үзара орышып бер-берен кырырлар да үзенә Төн илләренә юл ачылыр дип уйлый булса кирәк. Ачылырмы? Мажарлар янсә угор-фин кабиләләре каршы төшмәсләрме?.. Аннары көнчыгыштан һаман төркиләр агыла тора. Аварлар, алар артыннан төркиләр. Юк, бу илләрне үз кул астында тоту кыенга киләчәк базилевска. Кайткач, Агасике аңа барысын да аңлатып бирер. Булган күршеләр белән тыныч яшәргә кирәк, буласы күршең нинди була бит әле, бер хода үзе белә.

Болгар һәм туган як, туган ил Патшакала, Бөек Византия. Сагына иде Агасике туган илен, үзе киткәндә биш яшьтә калган улын да, инде кияүгә чыгарга вакыты җитеп киләдер — кызын да. Улын базилевс сарай мәктәбендә укытырга ышандырган иде, сүзендә тордымы икән?.. Укыйдыр, шөт, сүзендә торгандыр базилевс.

Грек Агасике кисәк кенә кояшка карап чукынып алды. Моның белән ул болгарларның тәңренә дә, үз алласына да иман итте. «Әйдә, нинди генә йолага табынмасын, ул барыбер адәм баласы, ди әнә философ. Ике алланың саклавы — бер алла саклавы булмас».— дип, янә чукынып алды.

Болгарга килгәч, олуг хан аны үз янына дәштерде. Агасике килгәч, ул аның каршына табак белән җиләк-җимеш, эчемлек китереп, үзе үк алтын чокырларга койды. Агасикенең коты алынды, Кубрат хан аның Болгарга нинди максат белән килүен белә икән бит! Хәзер хан аңардан сорау алыр, аннары җәлладыннан башын чаптырыр. Болгарлар шымчылар белән аз сөйләшәләр, шымчыларны гына түгел, хәтта ирләренә хыянәт иткән хатыннарына кадәр ике аягын агачка бәйләп ботын-ботка аералар. Шундый хәлне күрде дә Болгарга төшә-төшүгә Агасике ике-өч көн рәтләп йоклый алмады. Менә сиңа Болгар белән Рум арасындагы аерма: базилевс фахишә хатыннар өчен өйләр салдыра, Кубрат хан исә фәхишә хатыннарны я ике агачка бәйләтә, я ат койрыгына тактыра. Базилевска һаман аз. Патшакала түрәләренең, сарай тирәсендә чуалган куштаннарның күңелен ачу өчен Һиндстаннан, Сасанидлардан, Хорезмнан, тагын әллә кайлардан уенчылар китерттерә. Аларны бушлай киендерә, ашата-эчертә, ә тегеләре үз чиратларында сарай түрәләренең һәм кала куштаннарының күңелләрен күрәләр, кайчак олы ук урында утырган түрәләрне аздыралар, үзләре белән ятакларына алып китәләр, җайлап-көйләп бар булган акчаларын алалар, ә кайчак ул түрәләрнең затлы киемнәрен дә урлыйлар иде. Бай кеше өенә кайта да янчыгын янә акча белән тутыра, уенчы хатын алып калган киемнәрдән дә затлырак киемнәр ала. Төптимерче кебек ярлы-ябага, үз көнен үзе күргән кеше нишләргә тиеш? Ул, бахыр, чарасыздан базилевска баш иеп килә, ярдәм итүен сорый. Аларның күбесен базилевс сарацинар белән сугышка җибәрә, кайберләрен, әйтик, Агасике кебекләрне махсус бурычлар йөкләп варварлар арасына озата. Агасикене дә мохтаҗлык китерде базилевска. Һәм император аның хәленә керде — Фанәгүргә озатты. Соңгы вакытта уенчылар Патшакаланы

баса башладылар кебек тоелды Агасикегә. Ярый әле китеп котылды. Мескен уенчыларның да хәленә керергә була иде, теге я бу уенчы куштаннарга ошамый башладымы, аны шундук базилевстан кудыралар, шау-шу куптаралар. Хак, базилевсның куштаннарга каршы киләсе килми, уенчыны куа. Ә теге мескен кайчандыр үзе кебек үк куылган иптәшләрен эзләп каладан-калага йөри-йөри дә кеше күңелен ачарга дучар ителә. Эшләргә бөтенләй өйрәнмәгән уенчыга яшәү өчен башка чара калмый. Уенчы азгын хатыннар янына Агасике дә баргалады. Даны калага таралган тимерче булса да, җилгә ташлый торгач, акчасы җитми башлады. Шунда Агасике базилевска мөрәҗәгать итте. Имеш, ул менә дигән тимерче, әмма яшәүнең очын-очка ялгый алмый газап чигә. Император аңа ярдәм итәргә булды. Ләкин бер шарт белән: тимерче әүвәл өч-дүрт ел варварлар иленә чыгып керергә, алар турында мәгълүматлар җыеп алып кайтырга тиеш булачак. Ике арада җитди сөйләшү булды. Ахыр Агасике император тәкъдименә риза булды.

Анысы бер хәл, мондый хәл Агасике башыннан гына узмаган, меңләгән грек чит-ят җирләрдә базилевс шымчысы булып йөри. Болгарга килеп төшүгә, аны Кубрат хан чакырып алды һәм Агасикенең котын алып: «Грек утының серен беләсеңме, тимерче?— дип сорады, аннары бик озак көтеп тә җавап ала алмагач:— Ярый, яшә, алачык ач, төптимерче бул»,— диде. Кубрат ханның авызыннан, грек утының серен беләсеңме, белмисеңме, дип ишеткәч, Агасике тәмам телсез калган иде. Ул утның серен греклар җиде йөз елга якын үзләрендә саклыйлар. Моны эшләргә түгел, белергә маташкан бик күпләрнең башлары чабылып диңгезгә очты, хәтта еретиклыкта гаепләнеп утта яндырылганнары да булды. Агасике хан алдына тезләнде, баш орды, ул утның серен белмим, диде. Имеш, мин бары тик тимерче, грек утын тимерчеләр ясамый, диде. Кубрат хан әллә ышанды аңа, әллә юк, әмма яңадан Агасикедән грек уты турында сорамады.

Агасике күккә карады.

Бу кояш шул хәтле кыздыра ки, кая яшеренер хәл юк. Урманга керергә ярамый, угорларның ташланулары бар, болгарлар урманда бөтенләй орыша белмиләр. Аттан төштеме — орышчы түгел болгар алыбы. Болгарларның өстенә яшел сырмалар, эссе булмасын өчен аркаларына тишекләр ясаганнар. Болгар иләгән күп җиңел, йомшак, нәфис булыр. Тирене болгардан да оста иләүче юк. Агасике өстендә исә атлас күлмәк, күлмәк өстеннән грек күненнән тегелгән сырма — хәтта тикторганда тирләтә. Кая да булса күләгәгә күчәргә инде әллә?.. Агасике белән бер болгар да сөйләшми, ә янында яткан кол белән төптимерченең сөйләшәсе килми иде.

Багатыр да, алостаз Дәян да һаман юклар. Түзмәде Агасике, болгар алыплары кебек атының тезгененнән алды да, атын ашата-ашата йөренергә тотынды.

## 10

Алостаз Дәян багатырны тапмады. Урманны чыгуга, аның алыпларын йөзләп угор уратып алды. Һәм аңа алыплар башлыгы ыстанга таба юл күрсәтте. Аны да эләктерделәр, димәк. Ташбулат та, Илбарыс багатыр да күптән угорлар кулындадыр. Угор урманда мәче кебек үткер, җылан кебек шома, бүре кебек сизгер. Дала белән диңгездән гайрене күрмәгән багатыргамы угорлар белән ярышырга. Аһ, юкка җибәрде багатырны, юкка! Хәзер әнә үзе дә килеп капты.

Төрки мәргәне Ташбулатны гел исәпкә дә алмады алостаз Дәян, әллә бар иде ул аның өчен, әллә юк. Җилдән килгән — җилгә китте дә. Ә менә багатыр өчен борчылды. Дәянның түшендә Кубрат хан тарафыннан угор князе өчен бирелгән килешү тамгасы бар. Килешүне Куб-

рат хан белән князь теге вакытта бозау тиресенә яздылар. Шул тамгалы тирене Кубрат хан алостаз Дәянга биреп җибәрде. Олуг хан да угорлардан бераз шикләнгән, күрәсең, әйтергә генә кыймаган.

Ыстанның ачык капкаларына чаптырып барып керделәр. Алар артыннан өзәңгесез атка атланган угорлар иярде. Капкаларны шундук ябып та куйдылар. Дәян атын туктатты, түшен капшап карады. Бозау тиресе урынында иде.

— Мин олуг хан алыбы Дәян, мине князь янына илтегез!— диде алостаз, ат башына килеп тотынган угорга. Аңламады угор, тылмач чакырттылар. Тылмач шундук килеп тә җитте.

— Тылмач, мин угорча бераз сукалыйм, дөрес аудар. Мин Бөек Болгарның алыбы Дәян, мине князьгә илтегез...

Тылмач ат башыннан токтан йөзбашка алостаз Дәянның сүзләрен аударып бирде. Бу сүзләрне ишеткәч, йөзбаш колагына кадәр елмайды, аннары сикереп атына атланды. Йөзбашта болгар өзәңгеләре иде, кылыч та болгарныкы. Эске кирмәнгә килгән коралларны алып торалар, дип уйлады Дәян һәм атының кабыргасына тибеп алдан киткән угор йөзбашына иярде.

Ике катлы итеп салынган өй князьнеке иде, болгарлар килеп туктаганда князь болдырда басып тора иде инде.

Ул ат башы итеп ясалган таягын күтәрде, ярдәмчеләренә:

— Болгар илчесе алостаз Дәянны һәм аның алыпларын кунак итегез, каравыш кызлар бирегез!— дип боерды.— Алостаз Дәянны князь иртәгә кабул итә!

— Олуг князь, без, болгарлар сиңа зур йомыш белән килдек. Олуг князьгә җиткән булса кирәктер, Эске кирмән янә Болгарда. Чалбай хан үтерелде, башы Фанәгүргә озатылды. Бүген иртәгә Эске кирмәнгә Рум сәүдәгәрләре килеп җитәчәк, Рум сәүдәгәрләрендә һәрвакыт затлы товарлар була, угорларга кирәк әйберләр...

— Хәбәрең өчен рәхмәт, алостаз Дәян. Инде тагын нинди теләгең бар?

— Олуг князь, мин Кубрат ханның тәрбиягә алган Илбарыс атлы угланын югалттым...

— Багатырың миндә, алостаз Дәян. Ул ял итә. Багатырның уң кулы мәргән Ташбулат минем кызымны ай тырнагыннан коткарды, кызым бик үтенгәч, мин кызымны мәргәнгә кияүгә бирергә булдым. Багатырның уң кулы Ташбулат, алостаз Дәян, угорда калыр. Мин шулай кылдым. Багатыр ризалашты.

— Баш өсте, олуг князь. Инде алыпларыгызга боерсагыз иде, олуг князь, калган алайны ыстанга дәшсеннәр иде.

— Болгар алыплары тиздән ыстанда булыр, алостаз Дәян. Мин боердым инде. Ә син алыпларың белән ял ит.

Шулай диде дә князь, борылып, сырлап-бизәкләп ясалган ишеккә таба китте. Алостаз Дәян аны ишектән кереп киткәнче баш иеп озатып калды.

## 11

Алдагы дүрт угор алыплары арасында — Илбарыс багатыр, алостаз Дәянны да дүрт алып уратып алган. Багатырның уң кулы Ташбулат житен чәчле, ап-ак йөзле, маңгаена кызыл тасма бәйләгән князь кызы белән янәшә бара. Болгар алыпларын ыстанда ук калдырдылар, князь аланга алып барырга теләмәде. Кая алып бара князь багатыр белән алостазны? Төрки мәргән Ташбулат исәптә түгел, кыз чынлап та мәргән егетне сайлаган бугай, бер-берсеннән күзләрен дә алмыйлар. Ни белән күңелен яулады микән бу мәргән егет князь кызының?.. Бер тәңре үзе белә моны. Чынлап та кызны мәргән аю тырнагыннан кот-

кардымы, әллә булмаса егетнең һөнәрен күреп кияве итәргә булдымы бу князь?.. Сәеррәк хәл иде бу алостаз Дәян өчен. Алайны ыстанда калдырдылар, ә аларны елга буена алып баралар. Нигә? Әллә соң князьнең Кубрат ханнан үч алырга исәбеме?.. Кичә кич белән, ял итеп алгач, алостаз Дәян бозау тиресен князьгә җибәрде. Әмма кичке якта да, иртән дә князь тире турында ләм-мим бер сүз әйтмәде, ә алостаз үзе сорарга кыймады. Үч алырга иткән булса, князь башта, әлбәттә, багатыр белән аны суга батырып үтерер, аннары ыстанда калган болгарларны җыеп китерерләр.

Мәгәр соңгы мәлдә генә князь ыстанда калган болгар алыпларын да китерергә боерды. Күп тә үтмәде, Агасикегә ияреп, болгарлар да килеп җиттеләр.

Яр буена туктагач булды бу хәл. Елганың текә яр читендә берсеннән-берсе ике адым ара калдырып, өч әйбер куелган иде: ипи, кылыч, туфрак өеме. Күрде дә алостаз Дәян ни кыларга белми багатырга карады. Әмма багатыр язмышы белән килешкәндәй башын иеп бара бирә иде. Туктадылар. Дуга ясап, ике төмән алай болгарларны уратып алды. Бу хәтле тыгыз сафларны ертып кош булсаң да очып чыгып китеп булмас иде. Угор алыплары болгарларның һәр хәрәкәтен күзәтеп тордылар. Алостаз Дәян әле алдагы өч хикмәтле әйбергә карады, әле болгар алыпларына. Юк, болгарлар җәя тартып өлгерә алмаячаклар. Беренче сафта укчылар, икенче булып сөңгечеләр баскан, угорлар князьдән әмер генә көтәләр кебек иде. Әллә соң бу төрки мәргәне князьнең шымчысы булдымы, болгарларны тотып китерүеме? Алай дисәң, ни кыланып Чалбай ханга каршы орышты. Кирмән диварына кадәр барып житкән чаклары булды. Угор шымчысы булса, ул кадәр тәвәккәл кыланмас иде, ахыр чиктә шымчылар куркаграк булалар. Ташбулат шымчы булса, алостаз аңа хәнҗәр атарга өлгерер.

Алостаз Дәян янә князьнең кызына күз төшереп алды. Кызның аягында Болгардан алган сафьян читек, атланган атында да болгар йөгәне, йөгән Эске кирмәндә эшләнгән — көмеш таңкәләр белән бизәлгән. Кодрак илхан көмеш ярата, шуңа аңа «Көмеш илхан» дип кушамат тактылар. Төс-йөзгә ул хәтле чибәр булмаса да, кыз матур иде, гелән үзенә тартып тора.

Олуг князьнең күзләре багатырда, җансакчылары князьнең һәр ишарәсенә омтылырга гына торалар. Алостаз Дәян аңламады. Нигә бу тамаша князьгә? Болгарларны үч алу нияте белән елгага батырып үтерергә булган икән, сузмасын иде инде. Мәгәр бу фаҗигане Кубрат хан ишетер дә буйтурларының берсен угор князен акылга утыртырга җибәрер. Явызлык — явызлык тудыра.

— Бөек Болгарның багатыры Илбарыс, Кубрат ханның улганы Илбарыс,— диде, ниһаять, князь.— Шигем юк, син миңа изге ният белән килгәнсеңдер. Мин синең күңелеңдә изгелекме, яманлыкмы ята — белергә телим. Күрәсеңдер, багатыр, яр өстендә ашъяулыкта өч әйбер. Шуларның җаның теләгәнен ал да миңа китереп бир...

Багатыр ярдәм көткәндәй алостазга, аннары арырак басып торган төптимерче Агасикегә карады. Илләә алар да әйберләргә нинди мәгънә салынуын белмиләр иде — һичнн әйтә алмадылар, шул ук вакытта князь багатырны ашыктырды.

— Йә-йә, багатыр, атла!

Илбарыс багатыр күккә карады, баш очында гына тургай талпына иде. Менә тургай таш булып җиргә атылды, кинәт юкка чыкты. Шул мизгел эчендә аның язмышы хәл ителер, ул әйтер сүзен дә әйтеп өлгерә алмас...

Багатыр алга таба кузгалды, әйберләрне юри текә яр кырына ук куйганнар. Ялгышуы булыр, аның аркасына сөңге кадалыр, багатыр яр астына очар, аңа сөңгедән атарга уңлап угор алыбы хәзерләнеп тора.

Багатыр моны артына әйләнеп карамаса да күрде. Ун адым... Бары тик ун адым ясыйсы да... Кичә багатырны Ташбулат алдады. Ул аны ыстанга чакырды. Ыстанның капкалары.ябык иде. Шунда Ташбулат: «Багатыр, мин монда, кер, князь сине кабул итә!»— дип кычкырды. Шуннан аны кунак иттеләр, әче бал эчерделәр, князь уң кулы Ташбулатка кызын бирергә теләве турында әйтте. Багатыр балны күбрәк эчеп ташлады бугай... Ташбулат аңа әйтте, угорларда бер яман гадәт бар, килгән бер олы кунакны су буенда сыныйлар. Сынауны бирә алмыйча башсыз калган «кунак»лар да булгалый икән... Башта багатыр моңа бик үк игътибар итмәгән иде, иртән иртүк князь шул сынауны уздырырга җыена башлагач ышанды. Ун адым, бары тик ун адым ясыйсы да... Алда бер өем туфрак тора. Нинди мәгънә салына микән алар таптап йөргән туфракка?.. Уртада кылыч. Кылыч калкан өстендә, калкан кан кызылга буялган, димәк, Румнан килгән, Рум сәүдәгәрләре китергән. Әйбәт кылыч, Димәшкъ тимерчеләре суккандыр, корычы ялтырап, күзне камаштыра. Өченче әйбер — икмәк. Икмәк нигә?.. Их, багатыр янында төптәңре булса икән, я булмаса шаман. Шаманны юкка җибәрде, ул барысын да белә иде... Ун адым, бары тик ун адым ясыйсы да...

Багатыр әйберләргә килеп тә җитте. Нигәдер ул уртага килеп басты. Язмыштыр, тәңре шулай язгандыр! Аннары нинди генә мәгънә салынмасын, ул алып, ә алыпка беренче чиратта корал кирәк. Коралсыз алып — кынасыз калып. Багатыр кылыч-калканга үрелде, кулына калкан-кылычны алды. Әле тураеп җитмәс борын ук сизде ул аны: уратып алган халык аһ! итте. Шулай ук ялгышты микәнни? Тураеп басты һәм князьгә таба кузгалды. Шунда күрде ул, аңа уннарча сөңге, йөзләрчә җәя тартылган иде, барысы да аңа төзәлгән. Әйе, язмыштан узмыш юк. Багатыр князьгә таба китте. Шунда күрде ул: князь янына төшеп баскан уң кулы Ташбулатның йөзе ап-ак булды, ул кемнәндер мәрхәмәт сорарга дип авыз ачарга итә, әмма бер сүз дә әйтә алмый тора, аскы ирене калтырана иде. Сөйгәне-сайлаганы аның белəгенә ябышты, аның да күзләре акайды. Йолалары шулмы, гореф-гадәтләреме?.. Кыргый гадәт... Әйе, язмыштан узмыш юктыр. Багатыр күккә карады, баш очында гына карлыгачлар чиреләп очыналар, әллә тургай бөтенләй булмадымы, күзенә генә күрендеме? Козгыннар күренми. Үлем булмас... Әйе, үлем булмас, аларның барысын да суга батырып үтерерләр. Козгыннар суга батырылган мәетләргә җыелмыйлар...

Князьгә биш адым, өч адым калды, багатырның йөрәге кага башлады. Кан кызыл төскә буялган калкан һәм аның өстендә яткан кылыч тоташ бер төскә әверелде. «Бәхил бул, Чәчкәм, тәңре безнең язмышларны үзенчә хәл итте. Багатырың онытма, мин үлгәндә дә синең турыңда уйлап үләм. Безне аера алмаслар, без синең белән оҗмахта очрашырбыз. Без изге җаннар идек».

Соңгы мәлдә генә, князьгә ике-өч адым калгач, багатыр уң кулы Ташбулатка таба борылды, аңа таба китте. «Мин сиңа бирмим кылыч-калканны, князь. Үзем биргән кылыч белән үзең үк башым кисәр идең. Мин аны үземнең мәргәнемә бирәм. Синең шымчың булса, минем башым чабар, булмаса сиңа ташланыр»,— дип уйлады багатыр торгач саен йөрәге ярсына баруын тоеп.

— Уң кулым, Ташбулат,— диде багатыр, мәргәнгә җитүгә.— Бу кылычны, калканны мин, каенатаң илен сакларсың, дошман белән дусны аерып чабарсың дип сиңа бирәм. Рәхим итеп ал, мәргән!

Сынау үткән төбәкне чолгап алган алыплар эх! дип, җиңел сулап куйдылар. Уң кулы мәргән калкан белән кылычны багатыр кулыннан алды, артында басып торган җансакчысына бирде, үзе колачын киң җәеп, багатырны кочты.

Олуг князь кам таягын күтәрде, шаулаша башлаган алыплар шым булдылар.

— Багатыр, угорда гореф-гадәт болай ди: туфракны алсаң — син бу җиргә яшәргә килгәнсең, ипине алсаң — кунагым булырсың, кылычкалканны алсаң — кылычтан китәрсең. Кылыч күтәреп килгән — кылычтан китәр, ди, угор. Син кылычны алдың, багатыр!

Сынау төбәгеп бөжрага алган угор алыплары сөңгеләренә ябыштылар, янә җәя керешләре тартылды. Шундый ук җәя керешләре калган болгарларга да тартылган иде. «Менә үлем сәгате дә килде. Һавада козгыннар юк... Аксакаллар ялгыша, козгыннар сизми калган орышлар да була икән,— дип уйлады багатыр, Ташбулатның җансакчысы кулында яткан кылычка күз төшереп алды. Әйе, аны тиз генә ала алмаслар.

Шул вакыт олуг князь аксакаллар белән нидер киңәшеп алды. Аннары ул янә кам таягын күтәрде.

— Бөек Болгарның Кубрат хан багатыры Илбарыс! Ташбулат мәргән минем киявем булу сәбәпле, син сынауны дөрес уздың: кылычны минем җирләрем, урман-суларым сакларга дип аңа бирдең. Инде йола буенча, багатыр, яр башындагы тагын бер әйберне алып бир!

Багатыр җиңел итеп сулап куйды һәм зур-зур адымнар белән ярга таба китте. Алар угор җирендә калмыйлар, ул хәзер белә инде, туфракны алмас, ипине алыр. Багатыр ипине алды, әмма кире борылды, бер уч туфрак та эләктерде. Һәм князьгә китереп бирде.

— Син кунак, багатыр,—диде князь.— Иллә бер уч туфрак нигә?

— Бер уч туфрак уң кулым Ташбулатның угор җирендә калуын аңлатыр, олуг князь.

Князь бу җавапны, күрәсең, бөтенләй көтмәгән иде, кам таягын кисәк һавага чөйде.

— Аксакаллар, алыпларым, Бөек Болгар багатыры Илбарыс минем иң олы кунагым булыр!— дип кычкырды.

* * *

Калганы бик тиз эшләнде. Кич белән князь сараенда зур мәҗлес булды. Мәҗлестә багатыр олуг князьгә Кубрат хан бүләген — көмеш чүлмәкне бирде. Кулына көмеш чүлмәкне алгач, князь башта соклануын яшермичә бик озак әйләндерә-тулгандыра карады, аннары багатырга биленнән кылычын салып бирде. Мәҗлестә грек эчемлеге юк, эче бал гына иде. Шушы әче балга өйрәнеп киткән грек Агасике варварларының гореф-гадәтләреннән исән калу хөрмәтенә күбрәк эчеп ташлаган иде, ул, урыныннан торып, багатыр янына килде, сөенечен уртаклашты, аннары аш-су китерүче сары чәчле, зәңгәр күзле угор кызларын кочакларга үрелде. Әмма тегеләр, матур һәм буйсынучан елмайсалар да, җитез генә аның кочагыннан шуып чыктылар, серле елмаюлар ташлап, үз юлларына киттеләр. Агасике князь янына барырга кыяркыймас тора иде, эчеп алгач, аңа таба кузгалды, мәгәр князьнең җансакчылары аны иләп кенә янәдән үз урынына китереп утырттылар. Мондагы мәҗлес тә, князь үзе дә, аның серле сынаулары да, сары чәчле кызлары да ошады аңа. Хак анысы: су буенда котны алдылар, аның каравы ахыры әйбәт — кунак итәләр.

Олуг князь аягүрә басты, кулында агач җам, җам алтын тасмалар белән билләнгән. Агасике дә торып басты, мәҗлескә күз ташлады. Вәт хикмәт, әгәр дә мәгәр туган иле Румда хатыны, балалары булмаса, ике дә уйламый ул шушы варварлар илендә калыр иде. Агасикенең янәшәсендә алостаз Дәян утыра. Төптимерче бу кешене яратып бетерми. Артыгы белән күп белә, акыллы. Акыллы — акыллыны, җүләр җүләрне яратмас, ди. Хәзер дә ул аңа ләм-мим бер сүз әйтмәде. Ә бит сөйләшәсе килә.

— Кунаклар,— диде князь.— Ышбу җамнарны кунаклар хөрмәтенә эчеп куйыйк. Мин ышандырам Болгар багатырын: кичекмәстән угор сәүдәгәрләре Эске кирмәнгә юлга чыгарлар.

Барысы да аягүрә баскан килеш эчеп куйдылар. Ашчылар ризык-нигъмәт китерә башладылар. Иң түргә, князь белән багатыр каршына ат башы китерелде. Ат башы — йола билгесе. Әче балны артыграк эчеп алган Агасике:

— Бу дөньяда бердәнбер алла изге Гайсә,— дип атылып чыкты.

— Юк,— диде аңа каршы моңа кадәр дәшми-тынмый утырган алостаз Дәян.— Тәңре бердәнбер алла. Дөньядагы бөтен җан иясен тәңре яраткан.

— Юк!— дип кай тарафтандыр килеп чыкты угорлар шаманы. Моңа кадәр күренмәгәч, барысы да шаманга борылып карадылар.— Юк, Агасике, алла бер изге Гайсә генә түгел, бер тәңре генә дә түгел, дөньядагы һәммә җанны аю яраткан. Ул бар нәрсәгә дә ия, урманга да, елга-суларга да.

Олуг князь кулын күтәрде, тынычланырга кушты.

— Мин сезгә бер сорау бирәм, Агасике, алостаз Дәян, хөрмәтле шаманым. Ярый, дөньядагы барлык җан иясен изге Гайсә, тәңре, аю яратты, ди. Әмма Гайсәне, тәңрене, аюны кем яратты икән?

— Алла,— диде Агасике.

— Тәңре,— диде болгар Дәян.

— Аю,— диде угор шаманы.

Олуг князь кам таягын күтәрде.

— Агасике, моны ничек исбат итә аласың?

— Олуг князь, аллаһы-тәгалә барлык җан иясен булдыргач, адәм баласын ясый, дөньяда йолалар күбәеп киткәч, аллаһы-тәгалә изге Гайсәне халык арасына җибәрә. Изге Гайсә ялгышкан халыкларны изге юлга төшерргә өнди. Аны каферләр тоталар һәм агачтан тәре ясап, кул-аякларыннан кадаклыйлар. Гайсә җан бирә, әмма ул үлми, җаны күккә аша.

— Күрдеңме инде, грек Агасике, күк-кояш икән бит олуг тәңреләрнең олугы!— дип, сикереп торды алостаз Дәян.

— Кояшны да, айны да, дөньядагы бар нәрсәне дә аю ярата. Кояшны, айны ул күлдән алып күккә ата,— дип шаман һаман үзенекен тукыды.

Олуг князь уйга калды. Аюны, җир-күкне кем яраткан? Алла, ди Агасике, тәңре, ди болгар Дәян?.. Алланың үзен кем яраткан микән соң?.. Кеше үземе?.. Әйе, дөнья катмарлы, һәркем үз алласын мактый, һәркемгә үз алласы, үз йоласы кадерле. Кубрат хан угор җирләрен яулагач, олуг князь илендә тәңре йоласына димләүчене калдырды, халыкны көчләп үз йоласына батындыра башлагач, угорлар аны кул-аякларын бәйләп урманга илтеп ташладылар. Алар аңа болай диделәр: синең йолаң өстен икән, аю сиңа тимәс, инде йолаң ялган икән — аю сине ашар. Исән кайтсаң, йолаң кабул итәрбез, аю ашаса — бигайбә, тәңрең кичерер.

Тәңре динен угорлар арасында таратырга калдырылган болгарны урманда аю ашады. Шул хәлдән соң угорлар үз йолаларында калырга булдылар. Кубрат ханга бу хәбәр барып җитсә дә, угорларга алай җибәрмәде. Бер сүз белән: «Аюга табынган угорларга төптәңре җибәрмәгез, табынсыннар табынган йолаларына»,— диде. Кубрат ханның бу сүзләрен, әлбәттә, олуг князьгә җиткергәннәрдер, бәлкем, шуңа болгарларны якты йөз белән каршы алгандыр князь?..

Болгарларны олуг князь Сура елгасына кадәр озата килде. Елгага җиткәч, багатыр атыннан төште, князь янына килде, бил бөгеп, аңа тагын рәхмәт әйтте.

Олуг князьгә багатыр ошады, күрәсең, атыннан төште дә муенына таккан аю сурәте төшерелгән алтын җепләр белән чигелгән бөтнен кунак муенына такты.

— Ак юл сиңа, багатыр. Бөти сине төрле афәтләрдән саклар,— диде.



## 12

Соңгы ике елда греклар урам-урам булып Фанәгүргә күчеп утыра башладылар. Греклар — оста һөнәрчеләр, кулларыннан килмәгән нәрсә юк, җимеш үстерәләр, эчемлек ясыйлар, икмәк игәләр. Элек утрак болгарлар кырга арпа, тары гына чәчәләр иде, греклар арыш-бодай алып килделәр. Әйе, греклар бар яктан да оста халык. Әмма алар яу чапмадылар, җәйләүдән җәйләүгә күчеп йөрүне яратмадылар. Фанәгүргә килә башлагач та грекларның бу ягын күреп алган Кубрат хан кул селтәде. Әйдә, белгәннәрен эшләсеннәр, матур-матур әйберләр ясасыннар, таратсыннар Болгарның данын — сәүдә итсеннәр. Соңгы вакытта болгарлар да җәйләүләргә бик йөрми башладылар. Аларның кайберләре греклар кебек үк яши башладылар. Аерма шунда гына иде: грекларның яше-карты сурәткә табына, болгарлар — тәңрегә. Әйдә табына бирсеннәр.

Көннәрдән бер көнне Кубрат ханга патрикий Симеон килеп керде. Кич иде инде, кояш баеп килә, әмма сарайда якты иде әле. Дин әһеле килеп керде дә ханга баш орды, аннары нәреп килгән колына табгач ефәгенә төргән әйберне сүтәргә кушты, хан каршына куйдырды. Каршындагы кол тотып торган сурәтне күрде дә Кубрат хан әкрен генә тәхетеннән күтәрелә башлады. Ис китәрлек хәл иде! Ана ханша Аппак карап тора. Ул шул хәтле чын һәм ихлас итеп ясалган ки, гүя авызын ачып ханына дәшәр кебек иде.

— Кем кулы ясады бу сурәтне?

Патрикий Симеон кулларына карады. Хан барысын да аңлады, янә елмаеп куйды. Патрикий Симеон ханнан мондый ягымлылыкны көтмәгән иде, күрәсең, тәхеткә якынрак килде. Әмма бик үк якын килергә аңа Кубрат ханның кавханы бирмәде.

— Шуннан гына әйт сүзең,— диде кавхан ишетелер-ишетелмәс кенә.

— Сөйлә,— диде хан аның авыз ачып сүз әйтергә кыймый торуын күреп.

— Бу сурәтне чиркәүгә куярга булдык, олуг хан. Ханша Аппак бер дә Мәрьям анадан ким түгел икән...

Олуг ханның күңеле күтәренке иде, сынап, патрикий Симеонга карады, үз итеп авыз чите белән генә елмайды.

— Чиркәү ачасың да мени?

— Шушы атнада, олуг хан, синең изге теләгең искә алып, Фанәгүрдә яшәгән греклар (христианнар дияргә кыймады патрикий Симеон) чиркәү чаңын ишетәчәкләр. Бу икона Аппакка багышлап язылды, чиркәүгә куелыр, олуг хан. Аны карарга бөтен Фанәгүр...

— Рәсем мындә калыр, Симеон. Чиркәү өчен икенчене ясарсың.

— Син әйткән кылыныр, олуг хан. Өлгертә алсам.— Симеон ханга бил бөкте, чыгар ишеккә чигенә башлады.

— Истәлекче!— диде хан.— Утыр, яз. Һиҗри белән алты йөз дә кырыгынчы елда куян җаендә Фанәгүрдә чиркәү эшли башлады. Чиркәү башы Симеонга олуг хан Гайсә пәйгамбәр җиргә ирешкән көнне чаң кагырга рөхсәт бирде.

Хан янына кавханы килде, кыеп, сүз сорады. Кубрат хан аңа ияк кагып кына рөхсәт бирде.

— Олуг хан, бу хәбәрне ишеткәч, төптәнре үзе яклы кавханнар бе-

лән сарайга килерләр. Тәгәрәп киткән йомгакны җебеннән тартып кына җыеп булмый.

— Килсеннәр,— диде хан, кавханы ягына карамый гына.— Киләбирсеннәр. Ахыр чиктә греклар да болгарларны данлар, Кубрат ханны.

Бүген чынлап та Кубрат ханның кәефе әйбәт иде. Иртәнге якта гына аңа Илбарыстан хәбәр ирештерделәр: багатыр Эске кирмәнне алган, Чалбай ханның башын кисеп, Фанәгүргә җибәргән. Багатыр үзе мажарлар белән угорлар янына җыена икән.

Моннан өч-дүрт еллар элек грекларга чиркәү салырга рөхсәт биргәч, хан янына төптәңре Ирсан килеп кергән иде. Ул, күрәсең, Кубрат хан моңа барыр дип башына да китермәгән иде. Шуннан түгәрәк бер нәтиҗәгә килде бугай төптәңре: хан чынлап та картайган, зиһене-акылы таркаулана башлаган. Башта ул өлкән кавханнар белән сөйләшергә булды. Һәммәсенә кереп, Кубрат ханның картаюы, зиһене чуала башлавы, аның урынына илханнарның берсен утыртырга кирәклеге турында әйтте. Төптәңре Ирсанның алай ук тәфсилләп сөйләмәсә дә тел төбен аңлаган кавханнар теге якка да, бу якка да бер сүз әйтмәделәр. Өлкән кавхан Саксин гына төптәңре белән килешкәндәй ияк кагып утырды, мәгәр аның да кай якны яклавын аңлавы кыен иде.

Төптәңре Ирсан ни кылырга белми гаҗизләнде, гасабиланды. Шулай берничә көн үтте, ә ул арада кала уртасына диярлек чиркәү дивары өя башладылар. Греклар биналарны, аерата чиркәүләрне оста салалар, нык итеп җиренә җиткереп эшлиләр. Шуның өчен төптәңре тизрәк чарасын күрергә теләде. Ул көннәрдә төптәңре тәмам аштан калды, әмма һични кыла алмады. Күп уйлана торгач, сабыр итәргә булды. Әйдә, салсыннар чиркәүләрен. Салып бетерерләр, чаңнарын куярлар, иртәгә ачабыз дигәндә генә илханнардан ут салдырыр, бөтен Фанәгүр болгарын котыртып, нигезен җир белән тигезләтер. Әнә шулай ике ел узып та китте.

Кичә аңа таныш грек: иртәгә чиркәүне ачалар, Румнан килгән чаңнарны элделәр, диде. Бу төндә төптәңре бөтенләй йокламады. Әйе, бары бер көн калды. Кала уртасындагы чиркәү атна саен чаң кага башласа, болгарлар тәңредән ваз кичәр. Чиркәү йоласы да, синагог йоласы да, Фанәгүрдә күренгәли башлаган мөслим йоласы да болгарларга ят йола, барысы да кешене алла колы дип бара. Ә кол кем? Кол — кеше күләгәсе, ике аяклы хайван. Юк, болгар беркайчан да кол булмас, тәңре йоласы аны кол итмәс. Төптәңре болгарларны гадел юлга төшерергә тиеш. Кешене кеше итүче йола — тәңре.

Шулай уйланып утырганда төптәңре янына Илбарыс багатырдан кайткан атчабар килеп керде. Сөенче әйтте. Төптәңре атчабарның учына ике алтын салды.

Илханнар барысы да Фанәгүрдә. Хәзер үк барырга да аңлатырга, үгетләргә, сорарга, үтенергә. Җәйләүләрен, ыстан-калаларын саклап калырга телиләр икән, бүген төнлә үк чиркәүне җир белән тигезләсеннәр. Шунсыз аларга җир дә, ил дә, җәйләүләр дә юк, чиркәү белән бергә үзләре дә империя канаты астында калырлар. Фанәгүргә греклар килеп тулыр, Тимеркүкне басарлар һәм болгарга көчләп йолаларын тагарлар.

Йулыш каганга йөз тотса, аңа күчеп китсә?.. Әммә шундук төптәңренең күз алдына алостаз Дәян килә. Төптәңре Ирсан алостаз Дәян белән беркайчан да тату яши алмады. Шул ук мәлдә кеше күзенә бәрелерлек дошман да түгелләр иде, алай да бу ике кеше арасында ихлас татулык булмады. Алостаз Дәян карусыз тәңрегә инанды, әллә бар иде аңа төптәңре, әллә юк, күрмәде дә, белмәде дә. Ул һәрчак мәгълүматлар җыйды һәм аларны түкми-чәчми ханга җиткерде. Нәрсә эшләргә җыена иде Кубрат хан ул мәгълүматлар белән — бер тәңре үзе белә. Эске кирмәннән кайтып, атчабар, әлбәттә инде ханга алостаз Дәяннан

да хәбәр алып кайткандыр. Атчабарның аркасындагы дала тузаны әле булса күз алдында төптәңренең. Кирмәннән кайтып җиткәнче ничәмә ат алыштыргандыр. Хәер, ат ни аңа. Төпчәнре сөенчегә ике алтын биргән булса, олуг хан уч тутырып биргәндер. Тәңре генә хаерхак була күрсен, тәңрегә табынган, язмышын тәңре белән бәйләгән һәммә кеше боларның барысын да бушлай эшләргә тиеш иде дә бит, юк, ханнан башлап, сарай куштанына кадәр сөенче әйткән кешегә уч тутырып акча бирәләр. Әйтик, греклар әнә бер дә диннәренә инанган өчен кешедән акча сорамыйлар, яу чабалар икән — алла өчен, кеше үтерәләр икән — хода кичерер. Иоанн Фасиан тора да тәңрене яманлый, тора да яманлый, ә хан тыңлый, дәшми. Әйт шунда Иоанн Фасианга, синең динең мескеннәр дине дип, юк, дәшмәс була. Алла колы патриций Симеон турында әйтеп тә торасы юк. Әйе, чиркәү җимерелергә тиеш!

Төптәңре урамга чыкты. Аның йөрәге ашкына иде. Әйе, бүген ни дә булса кылыныр. Чиркәү җимерелер. Кайсы илханнан башларга?.. Кайсысын киездә күтәреп олуг хан итәргә?.. Өлкән илхан Батбай. Әйе, әйе Батбай. Аспарух илхан күңеле белән көнбатышка баккан, Кодрак илхан Төн илләре белән саташа, Балкырның җәйләүләреннән кайтып кергәне юк. Әйе, иң ышанычлы илхан — Батбай. Ни сәбәпледер ул башта ук Батбайга тартылган иде. Димәк, тәңре куша. Тапшырдык. Батбайның кул астында Кубрат буйсындырган хәзәр бәкләре дә бар. Аннары болай: төптәңре үзе дә Батбайны яклап чыкты. Булды андый хәл дә. Күптән түгел Йулыш каган бәкләренең берсе Батбай илханның ат көтүен куып алып киткән иде. Батбай илхан угрыларны куа бармаган, ике ат яндырып, Кубрат ханга кайткан. Үч алырга алай сорады. Ә үзендә ун мең алай бар. И орышты, и орышты илханны Кубрат хан, алдына гына тезләндермәде. Шунда аны төптәңре яклап чыкты, йола буенча илхан атланып кайткан атны чалып, корбан итсәң, нярен каплап ияр өстенә корбан канын койсаң — языгы юыла. Шулай итеп, өлкән илхан Батбай аксакаллар һәм сарай түрәләре алдында акланды. Батбайның рәхмәте зур иде төптәңрегә. Ни кушса, шуны кылыр ул хәзер аңа — чиркәүне яндырыр, манарасын җимереп, чаңнарын тимерчеләргә биреп, кораллар ясатыр.

Болгарда бердәмлек югалып бара, һәр илхан үз җәйләвен генә кайгырта. Ханда исә бары бер генә кайгы — ничек грек утының серен кулга төшерергә... Болгар хәзер ком ярына салынган өй хәлендә, дингездә давыл куптымы, суга убылачак. Кубрат ханга теше-тырнагы белән тәңрегә ябышырга иде дә бит, әллә ниткән диннәргә рөхсәт бирә. Чукынасылары килә икән, грекләр әнә үз илләренә кайтып чукынсыннар. Болгар тәңрегә табына, тәңре белән туды, тәңре белән үләр дә. Кем Бөек Болгар итте онагурларны[1]?.. Тәңре!

Җимерсеннәр чиркәүне илханнар, чапсыннар яу белән роська, империягә. Иң мөһиме — күрше-тирә илләргә тынгы бирмәү. Бүген Бөек Болгар аларга яу чапмаса, иртәгә алар Болгарга яу белән килер. Йулыш каган әнә җыена да инде. Дәүләтең яшәсен дисәң — яу чап, яңадан-яңа биләмәләр булдыр, җәйләү ызаннарына балбаллар утырт, үткән-сүткән сәүдәгәрләр күрсеннәр, кем иле аша үтүләрен белсеннәр, Болгар җире, Бөек Болгар җәйләүләре аша узалар икән...

Кубрат хан Бөек Болгарны төзеп йөргәндә Ирсанга яңа үҗәтлек яз тулып килә иде. Балачагы, яшьлеге аның далада, җәйләүләрдә узды. Болгарның олуг ханы Фанәгүргә утыргач та төптәңре тиз генә калага кайтмады. Кубрат хан белән яу чапкан чаклары да булды. Хак анысы, мәргән алыплар чиратында йөрмәде, әмма аның кебекләр булмаса, Кубрат ханга ялан-ялан җиңү килмәгән булыр иде. Ун-унбиш ел буена тоташтан яу чапкан Кубрат хан үз алыпларын сынап бетергән

---

[1] Онагур — борынгы болгар кабиләсенең атамасы.

иде инде, ул аларның һәрберсенә эш тапты: кайсын алгы сафка укчы итеп куйды, кайсыннан атларын каратты, кайсыларын олауга куйды, ук ясатты. Ирсан укчылар арасында йөрде, мәргән исемендә үк йөрмәсә дә, уктан ул оста атты. Шул елларда Кубрат хан аны төптәңре итеп куйды. Ирсан аның өчен үкенми, аның каравы ул бу һөнәргә Илбарыс багатырны өйрәтте. Шундый итеп өйрәтте Илбарыс углан җыен саен бүләкләр алды, Болгарны бөек Болгар итү өчен төптәңре кулыннан килгәннең барысын да эшләде. Төптәңре итеп билгеләгәч тә гел Болгар турында кайгыртты. Әле дә Бөек Болгар өчен, аның киләчәге өчен өзгәләнеп йөри.

Җитәрдер, төптәңре Ирсан унҗиде яз буена Кубрат ханга бил бөкте, ул ни кушты, шуны эшләде. Хәзер ул Бөек Болгар башына үзе теләгән илханны куяр. Куяр да... !

Аспарух илханны төптәңре Ирсан кояш баюга таба тәгәри башлагач эзләп тапты. Кылыч тотып, уңлы-суллы селтәнгән чагына туры килде ул илханның. Төптәңрене күргәч, икенче ишектән Саксин кавхан чыгып китте. Төптәңре аны күрсә дә, күрмәмешкә сабышты, илханга сәлам юллады, түргә узды.

Кара чәчле, күксел кара күзле, буйчан гәүдәле Аспарух илхан төптәңрегә түмәр куйды, үзе янәшәдәге түмәргә утырды. Чаршау артыннан караган каравыш кызга илхан:

— Кымыз китер,— диде.

— Рәхмәт, илхан. Син мине һәрчак ачык йөз белән кабул иттең. Хатының бала тапты, диделәр, малай икән, игелекле булсын — төптәңре күкрәгенә кулын куйды, торып, бил бөкте. — Минем сиңа йомышым бар, илхан. Хәтерем ялгышмаса, атаң Кубрат синең яшеңдә көн-төн яуда булды. Ә син, күрәм, кылычың бушка селтисең. Йулыш каган алай җыя, Түбән Этилгә кирмән сала икән.

— Без Эске кирмәнне салдык, төптәңре. Икенче калабыз Тимеркүк калкып чыкты.

— Түбән Этил каганда калсынмы! Күршең Рось көч җыеп ятсынмы?

— Рось белән Болгар килешүдә. Агабыз Ураган авар ханы Баянны тар-мар иткәндә каганның уң кулына рось князе баса.

— Баса, баса, баса! Ашин белән Дулу да кайчандыр бер ыру булып яшәгәннәр. Хәзер әнә кан дошманнар. Кем аларны кан дошман итте?.. Дошмисең?! Табгачлар императоры белән Рум императоры Төркине икегә аердылар, үзара сугыштыралар. Император Ираклий Кубрат ханга патрикий титулын бирде, Табгачлар императоры Йулыш каганны кул астына алыр. Тагын орышыр ике кардәш халык, тагын кан кояр, тагын императорлар ут уйнатырлар — отарлар.

— Ата — баш, без — каш, анам — муен, төптәңре. Синең кем булырга исәбең?.. Дәшмисең! Хәзәр кузгалса, абам Батбай хәбәр итәр, энем Балкыр да тик ятмас...

— Сиңа мәгълүм булсын, хәзәрлар белән болгарлар-төркиләр бер телдә сөйләшәләр, бер тәңрегә табыналар...

Аспарух бик озак уйланып утырды. Төптәңре сүзләрендә хаклык бар иде. Кайчандыр Дулу ыруы да, Ашин ыруы да бер каган кулы астында яшәгәннәр. Хәзер әнә ике туган халыкны икегә аердылар. Кем аерды?.. Табгач императорымы? Әллә булмаса, атасы йөз тоткан Рум императорымы?.. Юк, ыру башлары үзләре. Гасырлар буена бер-берсен үтерешеп-суешып яшәгәннәр. Соң инде аларны килештерергә, төптәңре, соң. Җәйләгәндә мин Истер[1] елгасына кадәр җиткәләдем, император тимәде. Хак, атам картайды, төптәңре, бер дә яу чабам дип тормый. Мәгәр кирәкме яу безгә? Кирәкми. Безгә булган җәйләүләребез бик җиткән.

[1] Истер — Дунай.

— Сакай,— дип артына каерылып җансакчысына дәште Аспарух.— Бар, абам Батбайны чакыр, илханның йомышы төште, тиз килсен дип әйтте диген.

«Сакай,— дип уйлады төптәңре, ишеккә таба китеп баручы алыпның аркасына карап.— Сакай. Көтригур алыбы, Көбер хан җибәргән алып. Яшь хан җизнәсенә ел саен алыплар җибәреп тора. Җизнәсенә ярарга тырыша. Кем белә, бәлкем бу Сакай Көбер хан тарафыннан Болгарга шымчы итеп җибәрелгәндер. Тугрыхан кызына Кубрат хан өйләнеп кардәшләшсәләр дә, элек көтригурлар белән онагурлар дошманнар иде. Дөрес, дошманлыкны авар каганы Баян булдырды. Баян хәзер юк, Баян каганның башына Ураган каган җитте... Әнә шулай, әнә шулай төрки бер-берсен кыра.

Күп тә үтми, Батбай илхан килеп керде. Өлкән углан һаман өйләнми йөри. Кубрат хан өйлән дип кыстамады, илхан үзе ашыкмады. Аспарух илхан, атасы кебек, кәләшне көтригурлардан китерде, шуның белән биләмәләрен бермә-бер арттырды. Өлкән углан Аспарух илханга караганда буйга карсаграк, әмма төптән-юан, җилкәле иде. Илханнар арасында көрәш булганда өлкән абалары өстен чыкты. Тиле көч бар иде кебек илханда. Өлкән углан үсмер чакта ук төптәңре тиле көч күргән иде илханда. Әнә хәзер шул көч, күзгә бәрелеп тора башлады. Кәрәкерүгә Батбай илхан түргә узды, икесе белән дә кул биреп күреште. Аннары каравыш кыз китереп куйган чүлмәктән кымыз коеп эчте. Көчленеке замана дипме, өлкән углан һәрчак югарырак утырырга тырыша иде. Хәер, бу табигый иде — ул өлкән углан, аңа кайчан да булса бер олуг хан буласы. Дөрес, өлкән углан олуг хан булсын өчен аксакалларның ризалыгы кирәк, әмма моны төптәңре үз өстенә алыр иде. Аспарух илхан кебек акыллырак булса, белеклерәк булса, өлкән углан, мөгаен, бүген үк тәхеттә утырыр иде инде. Мәгәр Батбайга тәңре көчне күбрәк биреп, акылны кимрәк иткән, кызганган. Хәер, олуг хан Кубрат кебек үк акыллы булырга тиеш түгел, иң әүвәл ул төптәңре кулында уенчык булсын. Шул ук вакытта Аспарух илханга да каршы түгел иде төптәңре. Бераз кырысрак, дөньяви хәлләр турында күп сөйләргә яратмаган Аспарух та аның сүзеннән чыкмас. Илханнарның төптәңрегә хөрмәтләре зур. Балкыр да үз урынында илхан, икенче углан Кодрак та. Кодрак илханны Кубрат хан чит илләрдән дә кайтармый, рәтләп күзгә дә күрсәткәне юк. Ни өчен булыр микән?.. Әллә соң нәкъ менә шул илханның тәхеткә утыруыннан куркамы олуг хан?.. Төпчек илхан Аслан турында уйлыйсы да килмәде төптәңренең. Ул күптән инде император колына әверелгәндер, төпчек илханның хәзер язмышын бары тик император хәл итәчәк. Болгарны тәмам кул астына җыйгач, император, бәлкем, илхан Асланны Болгар тәхетенә утыртыр. Анда инде Бөек Болгар булмас, Бөек Болгар империянең бер өлкәсенә әверелер. Менә шуны булдырмаска кирәк төптәңрегә. Ә моны булдырмау өчен беренче чиратта — чиркәүне җимерергә.

Бертуган илханнар янәшәдән утырдылар да орыш уеннары турында сөйләшә башладылар, гүя алар янында төптәңре дә юк иде.

— Угланнар, атагыз Кубрат картайды,— дип сузыбрак башлады төптәңре.— Әйе, олуг хан картайды. Бүген төнлә минем төшемә керде: тәңре төшкән икән, тәңре миңа олуг ханны үзем белән алам, Бөек Болгар тәхетенә олуг хан сайла, төптәңре Ирсан диде. Кайсысын?— дип сорадым... Аңлашмый калдым, кисәк юкка чыкты. Колагыма чалынганы шул булды: чиркәүне җимергәне диде. Иртәгә чиркәүнең ишекләре ачылачак, илханнар,— төптәңре илханнарга сиздерми генә күз төшереп алды, дикъкать белән тыңлыйлар иде.— Кайсыгыз кыла бу изге эшне, шул утырыр олуг хан тәхетенә.

Илханнар күзгә-күз карашып алдылар, икесе дә күзләрен идәнгә төшерделәр. Аталары Кубрат ханның ачуы яман, ни сөйли бу төптәң-

ре? Кеше ишетсә?.. Атасы янында шымчы өстенә шымчы... Әллә соң төптәңре дә... Бу хәлне ишетсә, аталары кичермәс, икесен ике ат коерыгына тагып, далага чыгарып җибәрер. Илханнарга уйланырлык иде, төптәңре аларны ашыктырмады. Ул белә иде, һәр ир-егетнең күңелендә йөгәнле ат булыр.

Бу мәлдә илханнарның миләрен көйдергән нәрсә: нигә аларны гына сыный? дигән сорау иде. Әйе, Кодрак илхан кая?.. Чит илдә. Булсын да, ди. Балкыр илхан Фанәгүрдә ич, нигә аны да чакырмаган төптәңре?..

Төптәңре көтте. Шул арада ул бер фикергә килде. Олуг хан урынына Батбайны сайларга. Күрде бит, сизде бит, Аспарух илхан бөтенләй югалып калды. «Батбай илхан!»— дип күңелен янә бер ныгытып куйды төптәңре.

Төптәңре Ирсан торды, кам таягын кулына алды. «Ишегалдына чыгыйк, илханнар»,— диде.

Ишегалдына чыктылар, йорт уртасындагы балбал янына туктадылар.

— Әүвәл син әйт сүзең, өлкән углан Батбай?

— Тәңре ни куша, шуны кылыр өлкән углан, төптәңре.

— Инде син, Аспарух илхан?

— Төптәңре,— дип кисәк кылычын селтәп алды Аспарух.— Төптәңре, олуг хан тәхете синең кулыңда түгелдер бит?! Түгелме! Шулай булгач, кеше күңеленә язык салып йөрмә, хан тәхетенә кем утырасын бер син генә хәл итмисең, аксакаллар, кавханнар хәл итә. Син бик кыю икәнсең, төптәңре, мәҗлес җый, мәҗлестә торып фикереңне әйт. Мин дә фикерем мәҗлестә әйтермен.

— Мин мәҗлес җыя алмыйм, илхан, мәҗлесне бер олуг хан гына җыярга хаклы.

— Шулай булгач, төптәңре, илханнар арасын болгатып йөрмә. Ил өстендә тынычлык булсын өчен мин әйтәм: без ишетмәдек, син әйтмәдең бу сүзләрне, төптәңре.

— Юк, туганкай,— диде Батбай.— Син хаклы түгел. Мин синең белән килешә алмыйм. Атамыз картайды. Безгә чынлап та яу чаба алырлык олуг хан кирәк.

Аспарух һаваны чаҗлатып, янә кылычын селтәп алды. Төптәңре Ирсан әкрен генә күтәрелде, йомры башлы кам таягын күккә күтәрде.

— Йа, тәңрем! Яздырма акылдан илханны, аны шайтан котырта, акылына зыян китермә! Йа, тәңрем!..

Төптәңренең кам таягы башында кояшсыман алтын чукмар, каракүксел болыт астыннан чыккан кояш нуры шул чукмарда чагылып, күзләрне камаштырды. Аспарух кам таягы башындагы шарсыман нәрсәдән күзен дә ала алмый торды. Менә төптәңре чукмарбашны Аспарухның күзенә үк китереп терәде.

«Ул мине сихерли»,— дип уйларга өлгерде Аспарух илхан һәм таякка ияреп кузгалуын сизми дә калды. Илхан туктарга тырыша, ә куллары-аяклары гүя аныкы да түгел, гүя башка бер кеше аның аякларын хәрәкәтләндерә иде.

— Күктә — тәңре, җирдә — мин. Чыкма минем сүземнән, илхан... Батбай илхан син дә...

Шул чак гөрелдәп каядыр еракта күк күкрәде.

— Угланнар,— диде төптәңре телен көчкә әйләндереп.— Угланнар, мин тәңре белән сөйләштем... Иртәгә көн туганчы чиркәүне җимермәсәгез, Фанәгүрне җир убар...

Ике туган илхан ни әйтергә белми телсез калдылар, әмма төптәңре кабат сүз катмады, борылды да китеп барды. Кисәк ул туктады, әйләнеп янә илханнарга карады, кам таягын күккә күтәрә башлады. Моны күреп, ике илхан тиң җиргә тезләнделәр.

— Яндыру өчен аланнардан килгән нефтә алыгыз.

Төптәңре китеп баргач та ике илхан тезләнгән килеш йорт уртасында тордылар. Ниһаять, Батбай илхан телгә килде.

— Чиркәүне кояш чыкканчы җимерәбез, Аспарух. Иртәгә кояш чыгар алдыннан алыпларым белән чиркәү янында булырмын,— диде Батбай.

— Моның өчен атам башыбызны кистерер,— диде, ниһаять, Аспарух.

— Барысы да тәңре кулында, Аспарух. Язмыштан узмыш юктыр.

Аспарух илхан бер сүз дә әйтмәде, китеп барган абасы Батбайның аркасына бик озак карап торды. Хәтта Батбай абасы капкадан чыгып киткәч тә ул бик озак уйланып бер урында таптанды.

Чиркәү җимерүгә күп өмет баглады төптәңре. Чиркәү җимерелгәч, базилевс Кубрат ханга үпкә белдерер, китәр ике арада бәхәс, өскә калкып чыгар элеккеге вак-төяк килешмәүчәнлекләр. Базилевс Фанәгүрдән грекларны чакыртып алыр, Йулыш каганга йөз тотар. Бу хәлләрне белеп алгач та Кубрат ханга буйсыныр-буйсынмас торган хәзәр бәкләре кузгалыр. Шунда төптәңре Ирсан тәхеткә өлкән илхан Батбайны тәкъдим итәр, Йулыш каганның уң кулы Җаек бәктән яшь ханга кыз соратыр. Җаек та, каган да каршы килмәсләр, гореф-гадәте, теле-дине бер булган халык янә берләшер, янә дөньяны дер селкетеп торыр. Төптәңре Ирсанга да Биләмҗиргә юл ачылыр. Каганның төптәңресе Урәгәй картайган икән, рәтләп сөйләшә дә белми икән. Бер-рәттән төптәңре Ирсан яраткан угланы Илбарысны да үзе белән Биләмҗир каласына алып китәр.

Әйе, бүген аңа багатыр Илбарыс кирәк иде. Илбарыс багатыр илдә булса, ул да чиркәүне җимерергә барыр иде. Бәлкем, ул кайтып та килә-дер инде, юлладыр.

Төптәңре Ирсан ни сәбәпледер багатыр Илбарысны түземсезлек белән көтте. Илбарыс багатырның угры Чалбай ханны җиңүе турындагы хәбәре килгәч, ни кылырга да белмәде. Илбарыс багатыр хан өчен барысын да эшләр: хан кызын аңа димләр. Тәхеттән төшерелгән Кубрат моңа риза булмас, дулар, мәгәр дулар-дулар да барыбер кызын багатырга бирергә мәҗбүр булыр. Әйе, Илбарыс багатыр Фанәгүргә тизрәк кайтсын иде. Чыны-ялганы белән шуны белә иде төптәңре: базилевсның угланы Юстиниан кәләшен алырга юлга җыена икән. Бу хәбәр чынлап та хак булып чыкса, Фанәгүргә кораб-кораб байлык җибәрер базилевс, сарай куштаннары моңа шатланыр. Күп тә үтмәс, хан кызы Чәчкә баласын күтәреп, кияве Юстиниан, ягъни ире белән Фанәгүргә әйләнеп кайтыр. Кубрат хан кияүне уң кулына утыртыр. Анда инде Бөек Болгарны яңадан үз мөстәкыйльлегенә кайтарам димә, Рум дәүләте әкренләп Болгарны канат астына җыяр. Әйе, ашыгырга, ашыгырга, иртәгә соң булуы бар.

Ишегалдына әнә шундый уйлар белән кайтып керде төптәңре, бик озак җимеш бакчасында уйланып утырды.

* * *

Төптәңре Ирсан йөрәге дөп-дөп тибүдән уянып китте. Коточкыч төш күрде: күктән төшкән аждаһа аны кай тарафкадыр күтәреп китеп бара... Куркудан шыбыр тиргә баткан иде ул. Бакчадагы түмәргә утырып, агачка башын терәгән килеш кенә йокыга киткән ләбаса. Аждаһа аны дөрләп янган чиркәү өстенә алып бара иде. «Бу ни булыр?»— дип гасабилана башлады төптәңре. Янә башын агачка терәде, янә йокыга китте. Төше дәвам итте. Юк, бу юлы аны аждаһа түгел, греклар янган

чиркәүгә таба күтәреп алып баралар, янгын эченә ташламакчылар. Арада патриций Симеон да бар икән, имеш.

Бу юлы уянуга, төптәңре дер-дер калтырана башлады. Хәтта төшемме, өнемме икән дип, үз-үзен капшап карады. Иа, тәңрем, бар икән соң әле, яман төш кергән янә.

Төптәңре торды да өйгә керде, юынды, гарәпне чакырды, аш әзерләргә кушты. Ашап-эчкәч, гарәбе аны ишегалдына кадәр озата чыкты. Кол ике гарәп сәүдәгәрен дәшмәкче, ашап-эчертеп җибәрмәкче икән. Дәшсен. Кунак итсен. Гарәпләр көчәеп бара, базилевсны нык кына борчый башладылар, шәһәр артыннан шәһәр югалта империя. Нинди-дер Мөхәммәт дине белән көчлеләр икән гарәпләр. Мөхәммәт кырык алланы бер иткән, 601 елда пәйгамбәр титулы алган икән. Кол барысын да белә. Сөйли, төптәңре дәшми. Аның үз кайгысы кайгы: чиркәүне яндыру. Төптәңре гарәп колына ияк кенә какты. Янәсе, кайда кунакларың.

Ирсан урамга атлады. Кояш чыгып килә иде. Туктап, көнне каршы алды, тәңредән игелекле көн теләде. Шунда аның колагына чаң-чоң иткән авазлар ишетелде. Төптәңре үз колакларына үзе ышанмады. Чиркәү яклап,көек исе килергә тиеш иде. Мәгәр шик юк, чаң кагалар, грек халкын чиркәүгә чакыралар иде. Төптәңренең аяк буыннары бушап китте, бер тынга ул аңына килә алмый торды. Әйе, китте Фанәгүр Болгар кулыннан, үзенә-үзе кабер казыды Кубрат хан.

Төптәңре чиркәү янына ашыкты. Аннан кисәк туктап калды. Кая илханнар, ни кылып яталар? Нигә ут салмаганнар, нигә чиркәүне җир белән тигезләмәгәннәр?! Янә күзгалды, чиркәү тирәсендәге хәлләрне үз күзе белән күрәсе килә иде. Карале, барысы да — болгары, грегы, яһүденә кадәр чиркәүгә ашыга, төптәңрегә күз ташлаучы да юк. Башка вакытта...

Башка вакытта ничек була торган иде соң әле? Әйе, грегы, яһүде,. Болгарлар турында әйтеп тә торасы юк, төптәңрене күрүгә, бил бөгәләр, хөрмәтләп сәлам бирерләр иде, бүген исә әллә халыкның күзе тонган инде... Тыярга, туктатырга, туктатырга!

Ничек кенә ашыкмасын, төптәңрене узып китүчеләр дә булды, берәү хәтта: «Юл, юл бирегез!» — дип кычкырды. Чиркәүгә ашыгучыларның күбесе грек иде, әлбәттә. Әмма болгарлар да күренә, алар кая ашыгалар? Фанәгүрдә грекларның шулай күп булуын төптәңре күз алдына да китермәгән иде. Диңгез бугазы аша Боспор дәүләтеннән күчеп килделәрме әллә?..

Менә чиркәү мәйданы. Үзенә күрә бер моң чыгарып, туктап-туктап чаң кактылар, греклар чукына-чукына чиркәүгә тулалар, ә чиркәүне җимерергә тиешле бер генә алып та күренми. Кая Батбай, кая Аспарух илханнар?! Җитмәсә, тамаша кылыргамы, чиркәү ишеге янына болгарлар җыелган, барысы да авызларын ачып, ишек төбендә вәгазь укучы патриций Симеонга карап торалар. Дин әһеленең тавышы төптәңрегә ишетелә иде:

— Халаек, Фанәгүргә чиркәү салынды, бүген якшәмбе көн, изге Гайсәгә иманлы кешеләргә чиркәү ишекләре ачык. Алла колы Симеоннан фатиха алырга теләгән һәр кеше, нинди генә телдә сөйләмәсен, чиркәүгә керә ала. Мәрьям ана алдына тезләнеп, менә болай чукынды исә, муенына менә бу тәрене такты исә, үз гомерендә Гайсә пәйгамбәр аның турында кайгыртачак, киңәшчесе, ярдәмчесе, афәтләрдән саклаучысы булачак. Изге Гайсәдән иман алган изге кешенең җаны үлгәч тә җәннәттә булыр...

Күр әле ничек халыкны котырта, кара чикмән кигән албасты. Тәңрем, кыл бер-бер нәрсә: җирдән уптыр, уттан ялмат үзен, диварларын җимерт, түшәмен иш, җил-җилә куптар. Тәңрем!..

Төптәңре чиркәүгә якын килергә кыймады, танулары бар иде. Әнә,

караштыргалап та куялар түгелме... Борылды да кире китте. Аны монда болгарлар күрсә, тәңредән ваз кичәрләр, һәрберсе патрикий Симеон кулыннан муенына тавык тәпие тагып чыгар.

Төптәңренең йөрәге кысылып-кысылып куйды, тамак төбендә әче төер бөерләнде. Нигә, нигә Батбай илхан белән Аспарух сүзләрендә тормадылар икән?! Ә бит ут салабыз, көфер оясын җир белән тигезлибез дип калганнар иде.

Төптәңре туп-туры сарайга юнәлде. Кабул итәрме хан? Итәр, итми хәле юк. Ул аңа барысын да сөйләп бирер, ханны үгетләр һәм шуның белән күкрәгендә көйрәгән утны басар. Юкса бүген төптәңре Ирсан яшен суккан корыган агачтай дөрләп янып бетәчәк.

Төптәңренең йөзендә борчу күреп, каравыл алыплар сөңгеләрен читкә алдылар. Төптәңредә ят бер хис уянды, ул гүя хан янына да керми, ә базилевсның үзенә кереп бара.

Кубрат хан тәхетендә утыра иде, төптәңре ишектә күренүгә, башын күтәрә төште, хан да төптәңренең борчулы кыяфәтенә игътибар итте.

— Әйдүк, түрдән уз, төптәңре, уң кулыма утыр,— диде гаҗәпкә каршы олуг хан.

Төптәңре Ирсан хан янәшәсенә утырды, тирән итеп көрсенеп куйды. Шунда аның күзләре Кубрат хан каршындагы рәсемгә төште. Таң калмалы иде. Юк, бу Аппак рәсеме түгелдер, тәңредән туган ай үзедер. Алты бала анасы дип кем әйтер. Йа, тәңрем, бирсәң бирерсең икән кешегә гүзәллекне! Сурәт-рәсем алтынга буялган ырмага куелган иде. Каерылып карап торудан төптәңренең хәтта муены авырта башлады. Ханша Аппак күксел-зәңгәр томан артыннан чыгып килә. Анда, томан артында, Кубрат ханның сурәт чалымы, әмма хан сурәте шул хәтле сыек төшерелгән иде ки, таныса да бик якыннары гына таныр иде олуг ханны.

— Аппакның сурәтен патрикий Симеон чиркәүгә куйган икән,— диде олуг хан.— Болгарларны котырта дип уйлама, тагын. Мин Болгарда йолаларга ирек бирергә булдым. Син ничек уйлыйсың, төптәңре?..

Төптәңре Ирсан бу сорауга бермәлгә югалып калды. Ни дип әйтергә?.. Кубрат хан кулында Шөгер бабадан калган җәйпәк чүлмәк такта. Хан бармаклары белән капшап, җәйпәктәге изге юлларны укый иде. Кубрат хан яшь чакта Патшакала сараенда тәрбиядә булгангамы, грек телен бераз сукалый, грекча килгән китапларны да укыштыргалый иде. Картая башлагач, Кубрат хан күбрәк уку белән гомерен уздырды. Әллә соң шуңамы дөньяви хәлләр белән кызыксынмый башлады хан? Әйе, базилевс җибәргән философ Иоанн Фасиан искиткеч хәйләкәр булып чыкты, нәрсәгә керешмәсен, хан иң әүвәл аның белән киңәшә. Кайчан китә микән бу философ Фанәгүрдән?.. Базилевс аны иленә чакырган икән дип тә сөйләделәр, ә үзе һаман Фанәгүрдә. Менә ничә ел инде олуг хан да җәйләү чыкмый, философтан белем ала.

— Болгар бер Фанәгүр генә түгел хәзер, олуг хан, күзгә күренеп Тимеркүк үсеп килә. Биләмәләрендә уннарча телдә сөйләшүче халык яши. Аларның барысы да диярлек тәңре йоласына табына. Тәңре йоласы угорлар табынган аю түгел, аның нисби гомере алты мең елдан арты,— дип сөйләп китте ярсына барган төптәңре.— Хәйлә белән алдырмакчы Симеон, Аппак рәсемен ясаган да, Болгарны христиан диненә аударыакчы. Бүген әнә чиркәү ишекләрен ачтылар, грегы — грек инде, болгары шул тарафка агыла, иртәгә яһүде килә, гарәбе. Болгар тәңре белән яу чапты, тәңре белән дан тапты. Яу чап, олуг хан, яңа күршеләр табарсың.

— Яңа күршеләр,— диде үртәлеп хан.— Яңа күрше искедән яманрак булса?.. Дәшмисең. Юк инде, төптәңре, Кубрат исән чакта яу чабу булмастыр.

Шулай диде дә Кубрат хан, янә алдындагы җәйпәкне укырга кереште. Ул аны авыз эченнән генә укыды, төптәңре Ирсан исә бабалардан калган җәйпәк белән бөтенләй кызыксынмады. Төптәңре рәсемгә якынрак килде. Никадәр хиссият, никадәр садәлек, никадәр чынлык иде рәсемдә. Ханша Аппакны чынлап та изге Мәрьям ана иткән бу патрикий Симеон.

— Йә-йә, төптәңре,— диде Кубрат хан.

— Базилевс йоласы Болгарга килсә, ата улны, ана кызны танымас, олуг хан. Болгар тәүге гайрәтен җуяр, ыру-кардәшләр арасында ызгыш китәр. Болгарның көч-гайрәте тәңредә, олуг хан.

— Ул килде инде, төптәңре, яңа йола. Килеп ята. Аппакка тимә. Табыналар икән Аппак рәсеменә греклар, табына бирсеннәр. Борчылма, төптәңре, Болгар үз динендә калыр. Мәгәр мин башка йолаларны да тыймаска булдым. Орышсыннар үзара йолалар. Кайсы өстен чыгар, шул йоланы алыр болгар. Без әнә иртән торабыз да тәңредән изге көн телибез, кеше үлсә ярты байлыгын җир астына күмәбез, ә философ әйтә, бу — кыргыйлык, ди. Байлыкны җир астына күммәскә, хан казнасына җыярга кирәк, ди. Аннары нинди генә йолага табынмасын кеше, күңеле пакь булса, ул һәрвакыт саф күңелле булып калыр, инде кешенең күңелендә әшәкелек өстенлек итә икән, нинди генә йолага табынса да, ул һәрчак явызлык кылыр. Ник дәшмәс булдың, төптәңре?.. Дошманнарым мин бик яхшы күрәм, менә йолама табынган кешеләрем арасындагы дошманнар белән ни кылырга? Киңәшең әйт. Көнбатышкөнчыгышта әнә сарациннар көчәеп килә, гарәпләр. Ни куәт бирә аларга?.. Мөслим дигән яңа дин, яңа йола, ди философ... Мин бер йолага да каршы түгел, төптәңре. Җиткерделәр миңа, Батбай илхан белән Аспарухны аталарына каршы котыртып йөрисең икән... Хакмы? Дәшмисең! Кисәтәм, төптәңре, илханнар син котырткан җәбергә керешсәләр, мин синең дә, аларның да башларын кистерәчәкмен.

— Олуг хан, танмыйм, мин аларны чиркәүне җимерергә котырттым, мәгәр илханнар куркак булып чыктылар, һични кылмадылар. Симеон миңа аңлаешлы, ә менә син якын иткән философ нинди динне яклый, олуг хан?

— Хакыйкатьне яклаган динне, төптәңре, хакыйкатьне! Без базилевска тире, бал, балавыз, балык җилеме сатабыз, ә ул безгә корал бирә, кием-салым китерә. Бөек Болгар күзгә күренеп баый, аның даны ерак Римгә, ерак Табгачларга җитте, Димәшкъ сәүдәгәрләренең киткәне юк, Кодрак илхан өченче тапкыр корал алып кайта инде. Кисәтәм, төптәңре, моннан ары илханнарны ханга каршы котыртма. Хан данын, ил данын күтәр. Бары тик шунда гына башың исән калыр, төптәңре.

Кубрат хан тәхетеннән төште, таягы белән идәнгә төртте, шундук жансакчылары килеп керделәр, Кубрат хан аларга чыгып китегез дип ишарә ясады, жансакчылары чыгып киттеләр, алай да төптәңре агарынып киткән иде, Кубрат хан моны күрми калмады, әлбәттә, ирен чите белән генә елмаеп куйды. Олуг хан төптәңре янына килде, иңбашына кулын салды, авыр иде ханның кулы, төптәңренең иңбашы иңеп куйды.

— Төрмә, төптәңре, бер коллар өчен генә салынмый, анда хан әмеренә, хан боерыгына буйсынмаган кайнар башлар да ябыла. Тарихта кабатлана торган хәлләр була, атаң язмышын кабатламасаң иде, Ирсан. Сиңа да әйтим, мин базилевс кулындагы грек утының серен кулыма төшермичә, илханнарга тәхет бирмәскә булдым. Тиздән Илбарыс углан кайтып төшәр, ә ул углан грек телен яхшы белә, мин аны Патшакалага илче итеп җибәрергә булдым. Базилевс Чәчкәне алып китәргә ашыга, җыена да икән инде. Мин аңа ашыкмасын, тагын бер яз килгәнне көтсен дип әйтеп җибәрдем. Максатым башка: грек утын ясаучыны Фанәгүргә алып кайту. Илбарыс углан моны эшләр, мин аңа ыша-

нам. Төптимерче Агасикедә шигем бар иде. Шуңа күрә мин базилевстан аның хатыны белән балаларын Болгарга җибәрүен сорадым. Базилевс риза булды, бүген-иртәгә Агасикенең гаиләсе биредә булыр. Грек уты ясауның серен төптимерче Агасике белә икән, гаиләсе килгәч, ул Фанәгүрдә калыр, грек утын ясый башлар. Грек уты ясауның серен кулына төшергәч кенә Болгар Болгар булып калыр, төптәңре. Кыңәшем шул: бу эшемдә ярдәмчем булсаң иде. Илбарыс углан кайтуга, мин аны буйтур итәчәкмен, аксакаллар каршы килмәс, багатырның кылган яулары мактаулы булды. Ә сине мин, төптәңре...

Төптәңре кисәк хан алдына тезләнде.

— Мин синең колың, олуг хан.

— Тор, төптәңре. Синдәй акыллы кешегә хан алдында тезләнеп торү килешмәстәй хәл дип уйлыйк. Атаң синең башта акыллы яшәгән. Кыңәшем шул булыр сиңа, атаң язмышын кабатламасаң иде. Инде хуш!

Төптәңре акрын гына чыгып китте, ишектәге сакчылар айбалталарын ике якка алып юл бирделәр. Төптәңре аларга хәтта күз сирпеп тә карамады, хан аның гүя җелеген суырып алган иде.

Каланы ничек чыкканын белмәде, бары тик диңгез ярына җиткәч кенә туктап калды. Хәер, бүген төптәңрегә кай тарафка таба барса да барыбер иде.

## 13

Илбарыс багатыр алае белән Фанәгүргә җитеп килә дигән сөенче килгәч, сарайда ыгы-зыгы купты. Аерата Чәчкә очынды. Итек башлары гына күренеп торган кызыл төстәге чапан кигән Кубрат хан капкадан сарай ишегенә келәм җәяргә кушты. Урамда алыплар күренүгә, хан болдырдан төште. Чак кына алгарак чыгып, куанычыннан ни кылырга белми Чәчкә басып тора. Кубрат хан кызына кырын күзе белән генә карап алды. Кайчандыр, бик ихтимал, Аппак та үзе сөйгән көтригур багатырын шулай шатланып каршы алгандыр, әмма Аппакны тәңре аңа язмады. Син, бала, багатырны сөясең булса кирәк, мәгәр син аңа булмассың, киләсе язга ярәшкән егетең килер һәм сине Патшакалага алып китәрләр. Син рәхәт тормышка бик тиз өйрәнерсең, яшьлектә булган мәхәббәтең исеңә төшереп карамассың. Кубрат хан кызына нидер әйтергә иткән иде, кызның кәефен бозарга теләмәдеме, дәшмәде. Әйдә, сөенеп калсын, яшьлек ике килми.

Сарай капкасыннан беренче алыплар килеп керделәр. Иң алдан Илбарыс багатыр килә, аннан бер адым гына кала төшеп алостаз Дәян, төптимерче грек Агасике. Янә шуңа игътибар итте хан: багатыр Чәчкәне күрүгә, адымын тизләткәндәй итте, әмма шундук тыелып калды. Килеп җиттеләр дә ханга өчесе берьюлы баш ордылар. Олуг хан аларны берәм-берәм кочаклап, үбеп чыкты, төптимерче грекка җиткәч, ул җансакчысына кул изәде. Ни күзе күрсен — Агасикегә таба хатыны, җитеп беткән кызы, улы киләләр иде. Агасикенең күзләрен яшь пәрдәсе томалады, аннары ул хатынына каршы китте. Аларның очрашу шатлыгыннан күзгә яшьләр килде. Агасикенең киң җилкәсе вак-вак калтырана иде. Кубрат хан аңа аерата дикъкать белән карады. Чынлап та үз хатыны, үз оланнарымы?.. Үзенекеләрдер, бу чиккә җитеп шатланышмаслар, җыелышмаслар иде.

Кубрат хан кочканнан соң, Чәчкә:

— Абам!— дип, Илбарысның күкрәгенә капланды. Һәм акрын гына:— Мин сине сагындым, сагындым, сагындым, багатырым,— диде.

Кубрат хан халыкны аш бүлмәсенә чакырды.

Төптәңрене багатыр аш бүлмәсендә күрде. Төптәңре багатырны күрде дә, күз яше белән җылап җибәрде. Багатыр аның башын күкрә-

генә кысты, үзенең дә күзләренә яшь элпәсе эленде. Кисәк кенә рәхәт булып китте төптәңрегә. Менә кем җитмәгән икән бит аңа. Менә кем аның өчен кадерлеләрнең кадерлесе!

— Багатырым, балам, оланым,— дип бертуктаусыз тәкърарлады төптәңре.— Өметем минем, бердәнберем. Исән-имин, сау-таза илдәсең...

— Табынга! Табынга дәшә олуг хан!— дип кычкырды табынбаш.

Бары тик бер җам эчемлек эчкәч кенә төптәңре табындагыларга күз йөртеп чыкты. Олуг ханның уң кулында философ утыра, философ янәшәсендә төптимерче Агасике, ханның сул кулында Илбарыс багатыр, багатыр янәшәсендә алостаз Дәян.

Җамнарга эчемлек коелгач, Кубрат хан сүз алды. Олуг хан башта табындагыларга күз йөртеп чыкты. Ул теләгән аксакаллар, кавханнар, илханнар монда иде.

— Аксакаллар, кавханнар, мин ышбу мәҗлестә угланым Илбарыс багатырга буйтур титулы бирәм!— Хан шау-шу тынганны көтеп торды.— Сөрәнче, иртәгә көн тугач, минем боерыгым халыкка җиткер. Мин әйттем.

Хан җамны күтәреп эчеп куйды, муенындагы зур алтын тәңкәне багатырга такты, аннары кочаклап үпте.

— Атам, олуг хан,— диде багатыр каушый төшеп.— Багучым, ризык бирүчем, йомышың үтәүдә һәрчак ышанычың булырмын!

Мәҗлестән соң буйтурны олуг хан шахмат бүлмәсенә алып керде. Өстәл янына утырыштылар. Хан шахмат шәкелләрен кулына алды. Шахмат шәкелләре сөяктән ясалган иде, аларның ялтыравында үзең үтә күренмәле.

— Акмы, карамы, буйтур?

— Ак, олуг хан.

Ханның уенда уен түгел иде, игътибары таркау, начар, ахыр отылды. Икенчегә шәкелләрне дә тезеп тормады.

— Углан, мин сиңа тагын зур эш йөкләргә булдым.

— Минем өчен синең йомышны үтәү дан, олуг хан.

— Данны сорап алмыйлар, буйтур, дан кешегә үзе килә. Ул сиңа килде инде, кадерен белеп саклый күр. Мин сине, буйтурым, Патшакалага җибәрергә булдым. Йомышым җитди, катлаулы. Мәгәр мин сиңа ышанам, буйтурым. Яшьлек ышаныч белән, картлык тәҗрибә белән алдырыр, дигәннәр аксакаллар. Без ике акылны бергә кушыйк та... Әнә, үзең дә чамалыйсың... Әйс, буйтур, Болгарга грек утының сере кирәк. Утның дәһшәтлесе — империядә. Грек уты кулыма төшү белән мин Йулыш каганны җир йөзеннән юк итәчәкмен. Патшакаладан исән-имин әйләнеп кайтсаң, сиңа кавхан титулы бирелер.

— Ышанычың акларга тырышырмын, олуг хан.

Ханнан чыккач, буйтур укытучы Константин янына китте. Укытучы ни әйтер? Аның иленә бара бит, бәлкем кемгә дә булса сүзе бардыр. Укытучы аны ачык йөз белән каршы алды, түргә әйдәде. Утырыштылар. Илбарыс аңа Патшакалага сәфәр чыгачагы турында әйтте.

Башта укытучы бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенми торды бугай, аннары аңлады һәм чак кына буйтур алдына тезләнмәде.

— Йомышым үтәрсеңме, Илбарыс?

Буйтур аның каршына тезләнде, алар шулай бер-берсенә карашып тордылар. Икесе дә тезләнгәч, икесе дә бер нәрсә турында уйлыйлар.

— Мин аны күрермен, укытучым. Син биргән хатны бирермен. Беркем дә белмәс. Ышан.

Укытучы буйтурның башыннан кочты, бер тын сүзсез торды.

— Мин аңа хат язам. Ул хатны аннан башка беркем дә укымас. Укымас бит, буйтур?

— Укытучым, мин сүземдә торырмын. Императрицага...

Буйтур ни әйтергә белми тотлыгып калды.

— Иртәгә. Иртәгә мин сиңа ул хатны бирермен, буйтур. Хәзер мин сиңа сарайдагы тәртипләрне, кагыйдәләрне өйрәтәм.

— Миңа боларны философ өйрәтергә булды.

— Зыян итмәс. Син укыган кеше син минем укучым. Тәкәббер император варвар белән очраштым дип, үзен синнән өстен сизмәсен. Син болгар халкының вәкиле, укымышлы, белекле вәкил.

Буйтурны укытучы бик озак өйрәтте. Аннары ул хат яза калды. Сөйгәненә, бердәнберенә. Буйтур чыгып китте. Ул аның хатын императрицага бирер, вәгъдәсендә торыр. Укытучы аның өчен бердәнбер изге кеше, аның кебек үк гашыйк кеше.



* * *

Илбарыс буйтурны Патшакалага озату ханга шактый мәшәкать тудырды. Бар нәрсә җыйналды, тәгәлләнде дигәч тә, әллә ниткән өстәмә эшләр туа торды. Үзара рәтләп сөйләшә белмәсәләр дә, шул ике-өч көн эчендә төптимерче Агасикенең кызы Эгина белән хан койрыкчысы Денис табышалар һәм чиркәүдә никахлашалар. Кызның теләге белән койрыкчы Денис чиркәүгә кереп христиан динен кабул итте, Денисның муенына патрикий Симеон тәре тагып чыгарды. Чиркәүдән соң койрыкчы Денис белән Эгинаны далага алып китте, Перун алласыннан ризалык алып кайтты. Патшакалага иң зур корабларның берсе әзерләнгән иде, олуг хан корабны озатырга Фанәгүрдә булган барлык илханнарны, кавханнарны, тарханнарны чакырды. Кичә кич белән, мин дә илемә кайтып китәм, дип ханга кергән Агасике соңгы мәлдә генә үкенү кебек бер нәрсә тойды. Ә бит ул Фанәгүрдә дә кала ала, җыйган мәгълүматларын улына бирер дә үзе Фанәгүрдә калыр. Әмма туган туфракның җегәре көчлерәк булып чыкты — Агасике корабта, хан бөтен куштаннары белән аларны озата килгән.

Хан боерыгы белән корабка бер мичкә эчемлек тәгәрәтеп керттеләр, сәфәр чыгучылар да, озатучылар да китүчеләргә ак юл теләп, бер чокыр эчемлек эчтеләр. Бу хәлгә грек Агасикенең күңеле тагы да нечкәреп китте. Олуг хан үзе аның белән чәкәшеп эчте. Базилевс моны эшләр идеме? Мәңге юк. Ул Агасике кебек кешеләрдән җирәнә, җирәнмәгән хәлдә дә бер мичкәдән эчемлек эчми. Үзе болай саран да түгел кебек император Ираклий, киң күңелле булып күренергә тырыша, мәгәр барыбер ярлы белән байлар арасындагы чик-чаманы белә — атлап чыкмый иде. Императорның үз даирәсе, үз мохиты, ул ярлыларның чын хәлен белми, Агасике уйлавынча, беләсе дә килми иде. Ә монда олуг хан аның белән кочаклашып саубуллаша. Кубрат хан ишкәкче колларга кадәр эчемлек бирергә кушты. Фанәгүрдәге коллар ниндидер күләмдә иректә яшиләр иде, өйләнергә хокуклары бар, мәгәр балалары хан кулында иде — кемгә тели, шуңа кияүгә бирә, кая тели шунда җибәрә. Коллыктан котылу өчен колны сатып алучы иясенә мең алтын түләргә тиеш. Китәр алдыннан Агасике ике колын сатып калдырды һәм кесәсенә шактый алтын тутырды. Кыскасы, баеп кайта иде тимерче Агасике Болгардан.

Озатучылар төштеләр, басма алынды, ягирләрне күтәрделәр. Кораб әкрен генә ачык диңгезгә кузгалды. Соңгы мәлдә генә килеп житкән төптәңре багатырга ак юл теләп кул изәде: «Яшьлек — иленә булган тугрылык белән, картлык — иман белән кадерле. Тәңрене онытма, буйтур, һәр көн дога кыл!»

Кораб кузгалып киткәч тә яр башындагы һәммә кеше күккә карап сәфәрчеләргә ак юл теләде. Озатучылар арасыннан барысы өчен дә иң

борчылганы, мөгаен, олуг хан үзе булгандыр. Әлегә кадәр ышаныч баглаган төптимерче Агасике китте, белгән булса үзе белән ут серен дә алып тайды. Сиздермәде, чишелмәде. Хәзер бөтен өмете багатырда иде Кубрат ханның. Хәерле юл аңа.

Башта һичкемгә күрсәтми, төнлә генә озатырга иткән иде корабны Кубрат хан, әмма соңгы чиктә бу уеннан кире кайтты. Әйе, базилевсның шымчыларын шиккә калдырмаска. Илчеләрне озатырга кызы Чәчкә дә килде. Кыз, томыраеп, буйтурга карап тора. Алар, Кубрат ханга калса, күзләре белән сөйләшәләр иде. «Балакай, ошамый миңа синең бу кыланышың. Синең ярәшкән кешең бар — Юстиниан. Тәңре насыйп иткән булса, киләсе яздан да калмыйча Патшакалада булырсың. Дөньяда бер император сараенда кадер-хөрмәттә генә яшәрсең».

Әйе, Румга капчык-капчык мал-мөлкәт җибәрде Кубрат хан, император ни җибәрер?..

— Император берни дә җибәрмәс, юкка өмет итмә!

«Кем бу, ни ди?» Хан тавыш килгән якка, артына әйләнеп карады, әмма бер генә дә шикле кешене күрмәде. Әллә соң колагына гына шулай ишетелдеме, таңредән илаһи тавыш килдеме?.. Хан кузгалды, шунда гына ул халык арасыннан чыгып килүче төптәңрене күрде. Менә кем әйткән икән, минем эчке уйларны укый, күр әле син аны! Халыкны котырта, илханнарны, җитмәсә монда килеп ни ди. Базилевс белән тату яшәүне ошатмый. Аның белән орышып яшәсәк, кан койсак?.. Ә бит син сукыр, сукыр, төптәңре. Мин синнән күп тапкыр ераграк күрәм. Мине Болгарның бүгенгесе түгел, киләчәге дә борчый. Ә синең күзеңне нәфрәт уты томалаган. Акыллы кешегә исә нәфрәт юлдаш була алмый. Болгарның тәңресе мин үзем — Кубрат хан. Кубрат хан беркайчан да тәңрегә хыянәт итмәс. Тәңре минем җәйләүләремне, биләмәләремне ишәйтте. Үлгәндә дә тәңре белән үләр Кубрат хан...

## 14

Киңәш мәҗлесенә барлык җәйләүләрдән дә илханнар, тарханнар чакырылган иде. Кубрат хан аларның һәрберсенә сораулар бирде. Тимер капка каласы тарханы әйтте: Йулыш каган Биләмҗир каласына утыз мең алай җыйган икән, уң кулы Җаек бәктә дә шул чама алай, ди. Әмма тарханга ышансаң, Йулыш каган бер дә Болгарга яу чабарга җыенмый икән, киресенчә, кардәшләшергә тели икән. Шымчылары дөрес җиткергән булса, каган тиздән Фанагүргә Кубрат хан кызына яучылар җибәрергә җыена, имеш. Кыскасы, Йулыш каган Кубрат хан кызы Чәчкәне сорамакчы. Тарханның бу сүзләренә ни әйтергә дә белмәде Кубрат хан. Яман хәбәр алып килгән өчен Тимер капка каласы тарханын тотып орышыр иде, аксакаллар килештермәс. Аннары ул гаепләме, тархан ишеткән-белгәнен сөйли. Аннары яучы җибәрү төрки дөньясында гаепкә саналмый, яучы димләргә килә. Ә инде риза булуы яисә булмавы кызның, ягъни аталарының үз иркендә. Әлбәттә, Кубрат хан риза булмас, Чәчкә ярәшкән. Ничек бозмак кирәк вәгъдәңне!

— Балкыр илхан, хәзәр-болгар чикләренә албагучылар җибәрдеңме?— диде Кубрат хан, Тимер капка каласы тарханын җавапсыз калдырып.— Миңа Җаек бәк шул тирәләрдә алае белән йөри дип ишеттерделәр.

— Бүгенге көндә хәзәр чигендә йырмак алай тотам, атам. Алар миңа атна саен хәбәр китереп торалар.

— Хуш, углан. Җәйләүдә күпме алаең бар, төп ыстанында?

— Ун төмәнгә якын, атам.

— Алыпларың канәгатьме, ашау-эчүдән зарланмыйлармы, илхан?

— Зарланмыйлар, атам. Үлән күп, мал-туар көр быел.



*Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

— Инде Батбай илхан, син әйт: аланнар иленә кайчан китәсең? Кайчан карама, син Фанәгүрдә. Моны ничек аңлатырга исәбең?

— Олуг хан, кул астымда сигез төмән алаем бар, калганнары алан башлыкларында. Хәбәр салу белән алар миңа ике төмән алай китерергә вәгъдә бирделәр.

— Эске кирмәнне нығытасы иде, олуг хан,— дип, Саксин кавхан сүзгә кысылды.— Җаек бәк шул төбәкләрдә хәрәкәт итә дип ишеттерделәр.

— Кемнәр?

— Хорезмнан сәүдәгәрләр килгән иде, олуг хан.

— Кодрак илханга минем алаемнан ике төмән укчы бир, Саксин кавхан. Бүген-иртәгә ул юлга чыгар. Илханның калган алае Фанәгүрдә кала.

— Баш өсте, олуг хан.

— Кодрак илхан, үзең белән сеңлең Чәчкәне дә алып китәрсең. Җәйләүне анда уздырыр. Кирмәндә Адай тарханда кимендә бер төмән алай бар. Эске кирмәнне сакларга өч төмән алай җитеп торыр. Алай-болай булса, хәбәрче чаптар җибәр. Ярдәм итәрбез. Алатыр буйтурның угланы Чаканда бер төмән алай бар. Үз алаеңа кушарсың. Чакан миндә булып китте, сәүдә бик әйбәт бара икән, куандырып китте. Мин әйттем, илханнар.

Өлкән кавхан Саксин олуг ханга баш иде, бу аның киңәшенә дә колак салган өчен Кубрат ханга рәхмәте иде. Олуг хан урыныннан кузгалды, аксакаллар ягына борыла төшеп утырды.

— Аксакаллар, ишеттегез, Йулыш каган кызыма яучылар җибәрергә җыена икән, нә кылыйм?

— Яучыларны кабул ит, кыз бирүне үзең кара,— диде берсе ап-ак сакалын сыпырып.

— Кызың яраткан, хан, килешерме соң?

— Килешер, аксакал. Яучыларны кабул итәрмен, аңлатырмын. Бер кызны ике тапкыр яраштмиләр,— диде олуг хан.

— Хак анысы, хан, ярәшмиләр. Иллә кемгә ярәшкән кызың? Тәңрегә табынучы каганга мы, муенына тавык тәпие тагып йөрүче христиангамы?

Хан торып ук басты, җыендагыларга күз йөртеп чыкты, аннары артында басып торган җансакчысына:

— Боерыкчыны дәш!— диде.— Илханнар, кавханнар, тарханнар, иртәгә үк җәйләүләрегезгә китәсез. Аспарух илхан, син дә. Кыз минеке, аксакаллар, нә кылырга үзем уйлармын, киңәшләрегез күңелемдә... Мәҗлес тәмам, аксакаллар. Мин әйттем. Илханнар кала.

Табында илханнар һәм хан үзе генә калгач, Кубрат хан бер тын уйланып утырды. Ниһаять, ул башын күтәрде, Батбай илханга текәлде.

— Батбай углан, каган беренче булып сиңа ташланыр. Бик ихтимал. Ышанычым югалтма. Мин әле каганның хәйләсен белеп бетермим, шулай да бераз чамалыйм. Аның исәбе — Чәчкәгә өйләнеп, Бөек Болгарны канат астына алмакчыдыр. Йулыш каган болгар-хәзәр тәхетенә килеп утырса, миңа гына түгел, сезгә дә көн калмас. Ашин ыруы гомер-гомергә Дулу ыруына үчле булды. Җаек бәк, каганның уң кулы, Этилнең урта җирендә җәйли икән. Йулыш каганның да шул тарафка юл алуы бар. Андый хәбәр килә икән, мин сиңа чабышчы җибәрермен, Батбай илхан. Тиз арада алаең алып, мин чакырган төбәккә килерсең. Аспарух илхан, син дә, Балкыр илхан, син дә. Кодрак илхан, сиңа аерым хәбәр булыр. Мин әйттем, илханнар.

Фанәгүр өстендә кара болытлар йөзә. Кубрат хан кояшта җылынырга дип, диңгез буендагы Кызсарайга китте. Биек дивар уратып алган сарай йөзе белән диңгез ягына баккан. Диңгез яклап та, кала як-

лап та капкалар. Капкаларда һәрчак сакчылар торыр. Диңгез ягындагы капкаларны ачсаң, җиңел галера баскычына чаклы килә ала. Болгарда хәзер йөздән артык шундый галера бар. Шушы галераларга грек утын куясы иде дә Әтил буйлап менеп китәсе иде: хәзәрен, саксинын, мажарын буйсындырып, угор аша узып фин затларына ук барып житәсе иде. Әмма бу бары хыял — татлы, тормышка ашмас хыял гына иде.

Кубрат хан чапанына төренгән килеш ачык тәрәзә каршында утыра, диңгез яклап тымызык кына дымсу һава агыла. Салкынча һава муенын кытыклый, чапан изүе аша култык асларына керә. Шуңа тән куырылып-куырылып китә, әмма Кубрат хан тәрәзәне япмый. Кызсарайга тәрәзәләрне грек осталары ясап куйдылар, пыяланы Кодрак илхан Димәшкъ каласыннан алып кайтты. Анда күптән пыяла коялар икән инде, ә Болгардагы күп өйләрдә карындык. Шул пыяла коючыларны да китерсәң... Әнә хорезмлылар табгачлардан кәгазь ясаучылар китергән, ди. Бозау тиресенә язмый хәзер хорезмлылар, ап-ак кәгазьгә яза.

Диңгез өстендә акчарлаклар кычкыра, вак-вак дулкыннар йөгерешә, ара-тирә балыкчы көймәләре күренә. Кызсарай каршында балык тоту тыела, шуның өчен балыкчылар бик еракта йөриләр. Шушы тәрәзә төбендә ханша диңгезгә карап утырырга ярата, ул бирәдә көннәр буе утыра ала. Кайчак, аеруча моңсу вакытларында ханша җырлап җибәрә. Аның җыры диңгез өстендә очкан акчарлакларны дәртләндереп җибәрә, кошлар тагын да тырышыбрак чәрелдәргә тотыналар, шул чакларда хәтта акчарлаклар тавышында да моңсулану ишетелә. Кайчак ханша бик эссе көннәрдә баскыч буйлап аска төшә, чишенә, өрсәң очып китәрдәй тукымадан тегелгән күлмәктән генә калып су коена. Ханшаның су коенганын Кубрат хан яшертен генә карап торганы бар. Аппакның тәне шундый пакь ки, күз чагылыр сыман. Су астында ул тән тагы да ак үренә, әйтерсең, су анасы үзе. Су анасын шулай ап-ак тәнле диләр. Ханша әле дә аның күз алдында. Аскы баскычта утыра кебек. Өстендә үтә күренмәле юка күлмәк, күлмәк аша аның тәне Патшакалада күргән хатын-кыз сыннарын хәтерләтә. Андый сыннарны греклар бик оста ясыйлар, күрсәң — таң калмалы. Патшакалада тәрбиядә чакта андый сыннарга Кубрат көннәр буена карап йөрер иде. Сыннар — Аппакка, Аппак сыннарга охшаган. Аның гәүдәсен ак мәрмәр сыннардан аеру кыен иде. Әйе, Аппакка сокланмаган кеше юктыр. Философ кадәр философ, Аппак килеп кердеме, бит очларына кадәр кызарына. Кубрат ханга Аппак һаман яшь, чибәр тоела иде. Ә бит аңа Аппагы биш ул, бер кыз табып бирде. Әле булса хәтерендә, беренче тапкыр Аппакны күргәч, Кубрат тәмам телдән калган иде. Күктән төшкән алиһә кебек күренде кыз аңа. Башта ул аны айга тиңләде, аннары кояшның үзенә.

Баштанаяк коралланган, яу чаба-чаба дала исе килеп торган ханны күргәч, Аппак үзе дә әллә нишләп киткән иде. Гәүдә-куәте, килешкилбәте, коралы-нигъмәте белән сихерләде бугай ул кызны. Һәм шул житте.

Тугрыхан кызы Аппакның язмышы әнә шулай хәл ителде. Ул бәхетле булды кебек, ә менә кызын нинди язмыш көтә икән? Юстинианны Чәчкәнең күргәне дә юк, бәлкем ул кеше карамастай ямьсездер. Хәер, матурлык — туйда, акыл тормышта кирәк, диләрме әле. Ирләрнең матурлыгы йөздә түгел, акылда, кылган эшләрендә. Язганмы таңре Чәчкәгә Юстиниан хатыны булырга, юкмы?.. Дөнья булгач төрле хәлләр була.

Моннан күп еллар элек, империягә бер яктан аварлар, икенче яктан фарсылар ташлана. Әнә шундый кыен чакта Ураган каган базилевска ярдәмгә килә. Угланы Бүрене Тимер капка каласы аша Иберияга җибәрә, үзе аварларның артларыннан төшә. Ярдәм килүне күреп, император Ираклий кирмәннән чыга һәм кыска гына вакыт эчендә уртада калган аварларны кырып бетерәләр. Шул орышта авар каганы

Баяр үтерелә. Аварлар язмышы хәл ителгәч, иленә юнәлә Ураган каган, чөнки анда Ашин ырулары баш күтәргән булалар. Император ираклий исә Бүре угланга ярдәмгә Иберияга китә. Шул елда император фарсылар яулап алган бик күп калаларын кире кайтарып ала, ахыр Бүре угланга ярдәмгә килеп, Тифлисне камыйлар. Айдан артык камауда тоталар кирмәнне. Әмма ала алмыйлар. Тифлистә Бүре илхан белән очрашкан император, илханның башына үзенең таҗын салып кигерә, яшь багатырны кочаклап өч тапкыр үбә. Бүре илхан императорга утыз төмән алай бирә. Шушы куанычтан ни кылырга, яшь илханга нинди изгелек эшләргә белмәгән император аңа кызын кияүгә бирергә вәгъдә итә, хәтта Бүре илханга кызы Евдокиянең рәсемен дә күрсәтә.

Икенче елны төркиләр Тифлис каласын алалар, ә император Ираклий Әрмәнстанны буйсындырырга керешә. Шул вакытта Иран шаһы Хөсрәү Фәрвазны үтерәләр, аның урынына шаһ угланы Кавад Шөрәй килә. Кавад Шөрәй император Ираклийдан солых сорый, ул яулап алган җирләрне императорга калдыра. Нәкъ шул елларда төрки каганатында чуалышлр башлана. Иленә кайткан Ураган каган чуалышларда Ашин ыруы Төркҗанны гаепли һәм аны үтерә, әмма чуалышлар вакытында Ураган каганны, Кубрат ханның агасын да үтерәләр. Ураган каганның уң кулында йөргән Кубрат хан көнбатыш төркиләргә баш булып кала, көнбатыш төркиләре аны ак киезгә салып, хан итеп күтәрәләр. Бүре илхан Тифлисне алганнан соң бик күп байлык төяп иленә кайта, әмма ике ыру арасындагы ызгышта аны да үтерәләр. Шунысы кызганыч: император Ираклий сүзендә торган була, кызы Евдокияне бер төмән алай һәм бик күп байлык белән Бүре илханга җибәрә. Бүре илханның кәләше Боспорга җитә һәм илханның үлеме турында ишетә. Кәләш бөтен байлыгы, бер төмән алае белән кире Патшакалага борыла. Язмаган була Бүре илханга Евдокияне. Шушы хәлләрне исенә төшергән саен Бүре илхан өчен уңайсызлана башлый Кубрат хан. Күптән булган хәл, әмма һич кенә дә күңел түреннән куып җибәрә алмый. Әйе, барысы да таңре кулында, кызы Чәчкәнең язмышы да.

Аны әнә таңре көтригур кызы Аппак белән чәчен-чәчкә бәйләде.

Кубрат үзе дә, каенатасы да бер-берсен бик тә яраттылар. Кызы Аппак бала тапкан саен Тугрыхан Фанәгүргә килде, килгән саен бер төмән алай алып килде һәм аны Кубрат ханга биреп калдырды. Алты балага алты төмән алай килде көтригурлардан. Хәзер болгар белән көтригурны аеруы да кыен.

Аппак аңа бик теләп килмәде. Башта кыз Кубрат ханга аяк терәп каршы булган икән. Әмма соңыннан килешкән. Моны аңа каенатасы сөйләде. Бу хәл өченче угланы Аспарух тугач булды.

Кубрат хан кызын сорагач, Тугрыхан Аппактан: «Сине Болгар ханы Кубрат сорый, өнисеңме ханны, юкмы?»— дип сораган.

Кыз атага: «Юк, атам, өнәмим Болгар ханын»,— дигән.

Шунда ата: «Өнәмәсәң өнәмәссең, син аңа барырсың, бармасаң, тышаулап озатырмын»,— дигән.

Кыз бер сүз дә дәшми, яшенә тыгылып, үз ягына чыгып китә. Бераздан кыз янына Тугрыхан керә һәм, кәнизәкләрнең котын алып, аяк тибә. Кәнизәкләрне шундук җил ала, атасы исә Аппак янына килә дә: «Җыен!» — ди. Бары шул бер сүзне әйтә. Атасының кырыс холкын белгән кыз килешеп ияк кагудан ары китә алмый. Тугрыхан кәнизәкләрне чакырып ала һәм кызны юлга җыярга куша.

Аппак Фанәгүргә килгәч, олуг ханның хатынын күрү өчен барлык җәйләүләрдән тарханнар агылды, йөк-йөк бүләкләр китерделәр... Яши башлагач, Аппак Кубрат ханга ияләште. Шул елларда Кубрат хан грек осталарыннан диңгез буена Кызсарай салдырды. Кызсарай салынып беткәч, алар Аппак белән икәү кулга-кул тотынышып, манарага менде-

лэр. Аппакның болай югарыдан диңгезне беркайчан да күргәне булмаган икән, башы әйләнеп китте, ирнең киң күкрәгенә капланды һәм елап та җибәрде. Соңыннан Кызсарай бүлмәсендә йокларга калгач, Кубрат ханның җылы куйнына сыена-сыена: «Кубрат, миннән дә бәхетле хатын юктыр бу дөньяда. Булса да мин беренчеседер»,— диде.

Иртәнге якта Аппакны сихерләгән нәрсә — чыгып килгән кояш булды. Көнне бергәләп каршы алдылар, тәңредән игелекле көн теләделәр. Кубрат хан урнысына барып ятты, үтәли күренмәле күлмәк кигән Аппак тәрәзәдән диңгезгә карап тора башлады. Аппакның мондый сихри манзараны беренче тапкыр күрүе иде, тәмам әсәрләнеп карады. Шунда Кубрат хан хатынны кулына күтәреп алды. Аппак аның муенына сарылды, сөеп чәчләреннән сыйпады, киң, куе кашларына кагылды. Хан тансык сөелүгә эреп китте, күзләрен йомды. Үлеп яраткан хатыннан беренче тапкыр сөелүе иде аның. Ир-хан яшь түгел иде инде, маңгае җыерчыклар белән ермачланган, тирән утырган күз төпләрендә карасу-шәмәхә төс, тутсылрак йөзендә кояш нурлары биешә, кысыла төшкән юка иреннәре тәүге сөю сүзләрен кабатлыйлар кебек. Кичә ул хатынын аккошка тиңләгән иде, бүген исә күктән төшкән алиһәгә ошатты.

Гомер диген син аны, кайчан гына җәйләүләрдә йөреп кайткан саен күңеле менә шул Кызсарайга ашкына торган иде. Ханша аны шунда көтеп алыр иде, капкадан килеп керүгә, Кубрат-ирнең кочагына иңәр иде. Кызыксынудан чарасыз калып торган каравыл алыпка хан күз кысып алыр иде. Әйе, Кубрат ханга да картлык килде, кул-беләкләрендә буын сыек, мәгәр йөрәктәге дәрт-дәрман җиде алыпка җитәр кебек иде әле.

Болын яклап ат караучылар чыгымчылаган атларны ияр-йөгәнгә өйрәтәләр. Кычкырышалар, шау-гөр киләләр. Бераздан алар да каядыр китеп югалдылар. Диңгез өстендә кычкырышкан акчарлаклар моңы гына йөрәккә өеп-өеп сагыш тутыра иде. Далага тартыла күңел. Атка атланып, яшь чактагы кебек далага чыгып китсәң иде. Очсыз-кырыйсыз дала. Тезгенне җибәрәсең дә, малкайга: «Һоп!» дип, үз итеп бер дәшеп аласың. Синең ни теләгәнеңне аңлап алган малкай сөлек кебек сузылып чаба башлый. Юк, ул мәлләрне онытып буламы!.. Хәзер әнә атка да кеше ярдәме белән генә атлана Кубрат. Ат көйсезрәк юырта башласа, эче төшә, имчәдән эчен сылатып интегә. Аппак та сукыр түгел, ханның картаюын күрә. Килеп утыра да хан янына, нидер әйткәнен көтә. Ни әйтсен аңа Кубрат. Әлегә берни дә әйтә алмый. Башта ул грек уты ясауның серенә төшенергә тиеш. Бары тик шуннан соң гына тәхетен илханнарның берсенә бирер.

Ана кеше, кодрәтеннән килсә, угланнарының дүртесен дә хан итәр иде. Төпчек углан санда түгел, төпчек углан тотык хәлендә. Аннары ул, күзгә бик чалынмагангамы, ятрак кебек ханга. Хәерле булсын. Бөек Болгар ханы корыч куллы булыр. Кубрат хан илханнарны сыный-сыный гына куяр хан итеп. Кайсы лаек? Вакыт күрсәтер. Юк, Кубратта көч бар әле, атка кеше ярдәме белән атланса да, кулында кылычын нык тота әле ул.

Күпме генә әтәчләнмәсен, Кубрат хан, соңгы вакытта еш кына үлем турында уйлана башлады. Төшенә еш кына тәңре керә, үз янына дәшә. Бер тапкыр хәтта Ураган агаен күрде. Ураган агасы җитәкләп алды да Кубратны ниндидер тауга алып менеп китте. Ярый әле каяндыр Аппак килеп чыкты һәм йолыккалап, тарткалап алып калды. «Юлдадыр ул үлем дигән нәрсә, килеп кенә җитә алмыйдыр»,— дип уйлады Кубрат төшенкелеккә бирелеп. Бу сүзләрне үлем урынында яткан кешеләргә төп тәңре әйтер иде. Үлемең юлга чыккан, әмма син ашыкма, аның килер юлы озын, бик озын әле, дияр иде. Элек хан төптәңренең һәр сүзенә ихластан ышана торган иде, хәзер юк, хәзер аның күзен философ ачты.

Йола ул кеше күңеленә төшкән иман гына икән, хикмәт кайсы диндә булуында түгел, хикмәт инануда. Соңгы вакытта Кубрат хан бу диннәр мәсьәләсендә тәмам буталды. Еш кына сәүдәгәрләр сараена барып утыргалады, төрле илләрдән җыелган дин әһелләренең бәхәсләренә колак салды. Әмма берсенең дә өстенлеген күрмәде. Төптәңре аңа һәр өйдә өй иясе бар, мәгәр ул беркемнең дә күзенә күренми дип сөйли торган иде. Гомере узып бара, Кубрат ханның төптәңре сөйләгән хикмәтләрнең берсенә дә тап булганы юк. Курыкканга куш күренә, диләр. Курыкканнарга бәлкем күренәдер дә улияләр, әмма Кубратның күргәне булмады.

Курыкканы Кубрат ханның өй-йорт ияләре түгел, көчәеп, ишәеп килгән Ашин ыруы иде. Йулыш каган ашыга-ашыга алай җыя. Нигә булыр? Билгеле инде, яу чабарга. Кай тарафка чабар Йулыш каган?.. Болгаргамы, угоргамы, мажаргамы, роськамы? Кай тарафка чапса да, әйләнер-тулганыр да Болгарга килер Йулыш каган. Шуңа күрә Кубрат ханга грек уты кирәк, бик күп кирәк. Йулыш каганга Хорезм шаһы ярдәм итә ди. Хорезмдагы алай санын берәүнең дә белгәне юк. Орына күрмәсен. Алостаз мәгълүматларына караганда, андагы халыкның игечиге юк.

Кояш кичке якка таба авыша барган саен диңгез яклап дымлы һава агылды. Кубрат хан чапанына төренә төште, әмма тәнгә җылы килмәде. Алтмыш беренче язы юл алганга да шактый булды инде. Халык та күрә башлады олуг ханның картаюын, күрә, әмма бер сүз дә әйтми. Моны Кубрат үзе дә сизә, кавханнарына кадәр шикләнебрәк карый башладылар. Сарай тирәсендә, тәхеткә яшь хан килә, дигән сүз йөри. Төптәңре Ирсан эше, итәк астыннан ут йөртә... Төптәңре Ирсанның да үпкәләрлеге бар иде Кубрат ханга. Ике тапкыр яраткан кешесеннән мәхрүм итте диярлек. Ачуны эченә җыя килгән икән, менә хәзер Кубрат хан картая башлагач, чыгарырга кереште. Башкаласы итеп Фанәгүрне сайлагач, Кубрат хан сарайга кешеләрне үзе сайлады. Юк, ул агасы Ураган кебек үз янына аксөякләрне генә җыймады, шул аксөякләр життеләр агасының башына. Кубрат хан үзе белән яуда йөргән, үзенә карусыз хезмәт иткән алыплар арасыннан сайлап алды сарай хезмәтенә кешеләрне. Һәм үкенми, уңды. Бары тик бер Ирсан гына Йулыш каган тегермәненә су коя.

Кояш баеды: уйлану, үткәннәрне искә төшереп утыру тәмам арытты Кубрат ханны, ул әкрен генә күтәрелде дә түр бүлмәгә менә башлады. Әмма анда гына тукталып калмады, манарага күтәрелде. Аннан, югарыдан бер тын тирә-якка тамаша кылып торды. Болындагы ат өйрәтүчеләр учак алганнар, казан асканнар, учак тирәли утырганнар да сөйләшеп утыралар. Аларның үз дөньясы дөнья, әмма аларга күп тапкыр җиңелдер. Кояш баюга, күрмәсләр дипме, балыкчылар Кызсарайга якынрак күчә башладылар. Шул вакыт берәүнең манарага менеп килүче аяк тавышларын ишетте хан. Аяк тавышлары Аппакныкы иде. Кубрат ханның күңеленә тынычлану килде. Хан тиз генә Аппакка каршы төшә башлады, әмма манарага менүче ханша түгел, кызы Чәчкә иде.

— Атам,— диде кыз ханны күргә.— Анам...

— Анаң кая, Чәчкә?

— Ул сине чакырды, атам. Мин кояш баеганны күрергә дип менәм. Иртәгә Кодрак абам белән Эске кирмәнгә кузгалабыз.

— Бик җиңел киенгәнсең, салкын тимәсме, өшемәссеңме?

— Мин өшемим, атам. Манарадан каравы шундый рәхәт. Атам, әйт әле, диңгезнең чиге бармы?

— Бар, балам.

— Патшакала биредән еракмы, атам?

— Ерак, кызым. Сине аннан кораб белән килеп алырлар. Зур кораб белән. Ишкәкчеләре генә йөз кеше булыр...

Чәчкә уфтанып куйды, күзләре дымланды. Кубрат хан кызының башына кулын куйды, чәченнән сыйпады.

— Юстиниан илхан начар кеше түгел, диләр, кызым. Син аның белән бәхетле булырсың. Ике-өч көннән Илбарыс абаң Патшакалада булыр, базилевска Болгарның бүләкләрен тапшырырлар. Мин каенатаң буласы император Ираклийга хат яздым. Синең арттан килүне бер язга кичектерсеннәр. Кодрак абаңда утырмада бул, аннан Аспарух абаңа барырсың, телисең икән Батбай абаңа Тимер капка каласына кит. Балкыр абаң да сине көтә...

Хан сүзсез калып кызына карап торды. Сылу иде Чәчкә. Кызның сылулыгын Рум сәүдәгәрләре император сараена җиткергәннәр, буласы кияве Юстиниан да ишеткәндер. Яратыр ул сине, бала, яратыр. Чәчкәнең күзләреннән агылган нурдан күңелләргә моң килә, дигән иде илче. Кубрат хан үз кызына соклануын яшермичә карады.

— Атам, патрикий Симеон минем сурәтемне ясый, һәр көн үз янына чакыра. Бетерә инде.

— Ясасын. Болгарда акыллы кешеләр арткан саен ил даны дөньяга тарала, балам. Симеон иконалар язучы, аның һөнәре шул. Минем илдә батырлар күп иде, хәзер акыл ияләре дә була башлады. Мин үзем, кызым, патрикий Симеонны өнәп бетермим. Миңа философ күп тапкыр якынрак. Акыллы ир, киңәше ипле.

— Атам,— диде Чәчкә очсыз-кырыйсыз диңгезгә карап.— Атам, Илбарыс буйтур әйләнеп кайтыр микән?

— Мин аңа иң ышанычлы кешеләрем биреп җибәрдем, бала. Илбарыс абаң кыю йөрәкле буйтур. Аның яшендә мин берәүгә дә буйтур аты биргәнем юк иде әле. Илбарыс ике-өч тел белә, мин аны илчем итәрмен. Җүләр илче — бер алып, акыллы илче мең алыпка торыр, дигәннәр бабаларыбыз. Озак торма, кайт...

Капкадан үткәндә каравыл алыплар айбалталарын читкә алдылар. Сарай урамының башында берәү әкрен генә кубызда уйнап утыра иде, ханны күргәч, аягүрә басты, бил бөкте.

— Уйна, уйна.

Җырлап утыручысы ханга хәтта күтәрелеп тә карамады. Ул, күзләрен йомган да, мәрткә киткәндәй җыр хиссиятенә кереп чумган иде.

Кубрат хан китеп барды. Җырны аңа Аслан илхан чыгарган диделәр. Җырны Аслан илхан Болгар сәүдәгәрләләренә җырлап күрсәткән икән, ә тегеләре отып алганнар. Менә хәзер бөтен Фанәгүр шул җырны җырлый. Җыр — туган ил, туган як турында.

Утырдым мин, әй, кәмәнең түренә,
Карадым мин суларның төбенә.
  Су төпләрендә, ай, кара юк,
  Хак язмышын күрми, әй, чара юк.
Су төпләрендә, ай, кара юк,
Язмышларны күрми чара юк...
  Карлыгач кара, ай, муйны кара ала,
  Ник моңая икән лә бу бала,
Моңаймас та, ла, иде бу бала,
Әчләрендә аның, ай ла, ут яна...

Кубрат хан туктап җырны ахырынача тыңлап торды. Пөрәге кысылып куйды, тамак төбенә төер килеп тыгылды. Кузгалып китте. Хан турында чәчәннәр нинди генә җырлар җырламыйлар, Кубрат аларның берсен дә болай хиссиятләнеп тыңлаганы юк иде әле. Ә монда Аслан оланы нинди сагышлы, бәгырьне теләрдәй җыр язган. Туган якларны, туган илне сагына, балакай.

Кубрат хан әрнешеп үкенү тойды. Ә бит ул Илбарыс буйтурдан Асланны алып кайтарта ала иде. Әйтмәде, андый бурыч йөкләмәде буйтурга, ул турыда исенә дә килмәде. Аслан җыры ханны тәмам сихерлә-

де. Ул хэтта үзе дә сизмәстән авыз эченнән генә көйли башлады. Җыр татлы итеп, аккош каурые белән кагылгандай күңелне моңландыра иде. Аны күп кенә чәчәннәр кояшка, киң далага тиңләделәр, хан боларны гаме килми генә тыңлады. Хак анысы, үзен мактаган сүзләрдән аның күңеленә тымызык кына рәхәт коела иде, әмма йөрәк кысылырдай сагыш күрмәде ул чәчәннәр җырында. Румнан китерелгән музыка коралларында кубыз моңын тапмады. Сарайда музыкантлар куштаннар рәтендә яшәделәр. Моңа кадәр күңел ачуларны Сабантуйларда, җыеннарда гына ишеткән Кубрат хан музыкантларны килештереп бетерми иде. Алай да философ һәм Болгарга килә-китә йөргән илчеләр хакына өч-дүрт музыкант тотты. Аларны күбрәк философ тыңлады. Кубрат хан грек көйләрендә эллә ни моң тапмады. Ә монда, сарай урамы чатында тыңлаган җыр, аның күңелен айкап ташлады. Кубызчыны, җырчыны сарайга китерергә дигән фикергә килде ул адымын тизләтә төшеп.

Сарай баскычыннан күтәрелгәндә ханның күңелен икенче бер уй биләп алды. Кичә аңа төптәңре килде. Чиркәүгә йөри башлаган болгарлар бар икән, муенына тәре тагып чыгучылар да күренгәли икән. Патрикий Симеон христиан йоласын иң изге йола дип бара. «Изгесен изге,— дип уйлады ишекләрне ачып торучы сакчылар яныннан үткәндә хан,— әмма кешене нәкъ менә греклар кол итеп сатып алалар».

Чиркәүгә йөргән халыкны тыймаска булды Кубрат хан. Нинди генә йолага табынмасыннар, ахыр чиктә Фанәгүргә яу килгәндә корал тотып, болгарлар белән бер сафка басарлар.

Әйе, моннан ун-унбиш язлар гына элек үзе яу чаба иде Кубрат хан, хәзер әнә «яу килсә» дип уйлана башлады.

Аш табынына утыргач, ханша Аппак ир-канатына карап-карап алды да:

— Хан, мин балаларны да дәшкән идем, иртәгә барысы да җәйләүләргә китәләр... сүзең бардыр,— диде.

Хан Аппакка өнәми генә карап алды.

— Ханша, минем иңемдә үз башым бар. Вакыты җиткәч, кемне кем итәргә үзем боерырмын,— диде.— Аннары,— хан кисәк хатынына игътибар итте.— Алтын — байлык билгесе, ханша. Ханнар өчен алтын беркайчан да бизәнү билгесе булмады. Гүзәллек билгесе кешенең үзендә, алтында түгел. Кисәтүем дип уйлама, ханша, килиннәреңә дә җиткер, моннан битәр сарайга минем каршыга алтын-көмешкә күмелеп килмәсеннәр. Кодрак илханның хатынында баштан алып, аякларына чаклы көмеш. Мин әйттем.

Ханшаның бит-йөзенә гүя ут капты, ояла белә иде әле ханша, хатын бер тын ни әйтергә белми аптырап калды. Мәгәр сүзсез калырга көтригур каны агамы аның тамырларында! Моңа кадәр ханшасы ни генә димәсен, ничек кенә йөрмәсен — күрми дә, белми дә иде хан. Хәзер күзе ачылдымы! Алтмыш язын узгач, хатынына күзе төштеме?!

— Син хаклы, ханым, акыллы кешене алтын түгел, акыл бизи. Мәгәр бу вәгазең синең ир-атка кагыла. Түшеңдә бала башы хәтле алтын тәңкә йөртүеңне ничек аңлатмакчы буласың? Мин хатын-кыз, болынны — чәчкә, хатын-кызны кием бизәр, дигәннәр. Ир-атны түшкә таккан бала башы хәтле алтын түгел, дәүләт данлар, хан.

— Ханшам, элек синең миңа иң әүвәл пакь йөзең күземә чалынып иде, хәзер алтын-көмеш тәңкәләреңнән күзем чагыла. Сиңа түгел, кызың Чәчкәгә килешә төшәдер бу бизәнү әйберләрең.

— Чәчкә яшьлеге белән сылу, мин байлыгым белән, хан. Мин сиңа ошарга тырышам. Салкынайдың. Уең-хисең башкадамы?.. Башыңны дәүләт кайгысы бастымы?..

Ханша кисәк торды да Кубрат ханның күкрәгенә капланды. Кубрат

ханшаның маңгаен уратып бәйләгән алтын тәңкәләр тезгән тасманы сыдырып алды, бер читкә куйды, хатынның башын күкрәгенә кысты.

— Ханша, шигем бар; кызыбыз Чәчкә сагышта, күзләрендә тәүге нур юк, гәүдәсендә җитезлек күрми башладым. Син, ана, ханша, ни булды кызымызга?

Аппак башын күтәрде, туры хан күзләренә карады.

— Ул бала Илбарыс угланны ярата, хан.

Олуг хан җиңел сулап, елмаеп куйды.

— Ярату гаепме, ханша. Патшакалага киткәч, барысы да онытылыр. Яшьлектә сөйгән — яшьлектә калыр...

## 15

Диңгез өсте тыныч, ишкәкче коллар ишкәкләрен бер җәмдә күтәрәләр, сөйләшеп куйгандай бер җәмдә төшерәләр. Җил юк, җил чыкса Денис җилкәннәрне күтәрер иде дә очар иде дулкыннар өстеннән; ишкәкчеләргә генә калгач, кораб бик әкрен бара. Хак анысы, ишкәкчеләрне ашыктырып, камчы белән дә суга алалар, әмма Денисның алай иттерәсе килми. Ишкәкче коллар арасында аның якташлары бар. Каравылбаш Камай исә ишкәкчеләрне ашыктыра, «ишегез-иш!» дип камчы белән дә селтәнгәли. Камайның бу кыланышы койрыкчы Дениска ошамый, ул, Камай оста җикергән саен тешен кыса, яңак итен чәйни. Камайның өстендә күн сырма, күн чалбар, кулында чәч толымыдай үреп ишкән камчы. Ишкәкчеләрнең күзләре каравылбаш Камай кулындагы кызыл саплы каеш камчыда. Кем иптәшләренә салыша, кайсы ишкәкче эленке-салынкы ишә, камчы шуның сыртына төшә. Камчы белән ишкәкче колларны куалаучы Камайны койрыкчы Денис беренче көнне үк ошатмады. Ахыр түзмәде, Фанәгүрдән чыгып өченче көн дигәндә, Камай камчы белән бик селтәнә башлагач, аска төште, каравылбашның кулыннан камчыны тартып алды һәм болгап диңгезгә ташлады. Каравылбаш Камай койрыкчының изүенә ябышты, бөтереп, кораб читенә китереп терәде. Ишкәкчеләр ишүдән туктадылар, түбән катта шау-шу ишетеп, өске катта йөргән буйтур йөгереп аска төште. Аскы катта каравылбаш белән койрыкчы идәндә тәгәри-тәгәри якалашып яталар иде, икесен ике аерып җибәрде һәм кылычын чыгарып:

— Койрыкчы Денис, бар урыныңа! Камай, каравылбаш Камай, моннан ары ишкәкчеләргә кул тидерәсе булма! Китегез күз алдымнан!

— Баш өсте, буйтур,— диде Камай, әмма шундук башын чөя төшеп:— Ул килмешәк минем камчымны суга атты!— дип зәһәрләнде.

— Күп телеңә салынма, каравылбаш. Урыннарыгызга китмәсәгез, икегезне дә диңгезгә ташлатамын!

Каравылбаш Камай да, койрыкчы Денис та үз урыннарына киттеләр. Ишкәкче колларның болгар булмаганнары да төрки телне аңлыйлар иде, буйтурны әллә яклап, әллә куәтләп шаулаша башладылар.

— Ишкәкчеләр, безгә тизрәк Патшакалага барып җитәргә кирәк. Карусыз ишсәгез, анда барып җитүгә, мин сезгә ирек бирәм. Тизрәк барабыз икән, тизрәк ирек алырсыз...

Шул көннән кораб тизлеген бермә-бер арттырды. Алай да ишкәкчеләр арасында буйтур сүзләренә ышанмаучылар табылды.

— Буйтур сүзендә торырмы, Камай ата?— дип сорадылар ишкәкчеләр сабырланып калган Камайдан.

— Мин багучы түгел, сарай мәктәбен дә бетермәдем, мин бары тик каравылбаш. Хан безнең язмышны буйтурга тапшырды, ни тели — шуны кыла. Сез минем кол, мин аның колы, ә ул хан колы. Без барыбыз да коллар, безнең язмышлар бер.

— Язмышлар берен-бер,— диештеләр ишкәкчеләр.— Тик синең кулыңда камчы, безнең кулда ишкәк, бер дә әнә камчыңны ишкәккә алышырга теләмисең.

Ишкәкчеләр каравылбаш белән койрыкчы арасында ызгыш булып алганнан соң кыюлана төштеләр. Койрыкчы Дениска, гомумән, күктән төшкән тәңре үзе дип карадылар. Койрыкчы алар янына төштеме, ишкәкчеләр аңа олылап сәлам бирделәр, ә инде койрыкчының хатыны грек Агасикенең кызы икәнен белгәч, тәмам әсәрләнделәр, тегеләр икәүләп аскы катка төштеләрме, икесенә дә мактау сүзләре яудырдылар, гүзәл Эгинаны айга тиңләделәр.

Кичкә таба, барысы да тынычлана төшкәч, Илбарыс буйтур койрыкчы Денис янына килде.

— Койрыкчы, нигә алай кыланасыз?

— Буйтур, ишкәкчеләр арасында минем якташым бар...

— Мин аларга Патшакалага җиткән очракта ирек вәгъдә иттем.

— Кайтканда ишкәккә үзебез утырабызмы, буйтур?

— Минем белән егерме алып бара, койрыкчы.

— Тылмач та алмадың, буйтур.

— Миңа тылмач кирәкми, койрыкчы. Күз буяу өчен тылмачка сине алырмын.

— Ә-ә,— диде Денис һәм күн сырма чабуы белән авызын сөртеп алды.— Авызны җимерде, оста орыша каһәр төшкән Камай. Ипи шүрлегенә менеп төшкәнен сизми дә калдым.

— Хан каравылчыларын грек укытучылары укыта. Сугышырга да, орышырга да.

— Без аның белән килештек инде. Ә греклар турында дөрес әйтәсең, буйтур. Хан сараен греклар басты. Кызы Чәчкәне дә император углына биреп куйса... Хәер, үзем дә әнә грек кызына өйләндем.

— Үкенәсеңме әллә, койрыкчы?

— Юк, буйтур, үкенмим. Яратып өйләндем. Каенатам да яхшы кеше күренә.

Илбарыс буйтур койрыкчының кулын кысты.

— Әйт әле, Денис, мәхәббәт бармы, сөю-сөелү?

— Бар, буйтур. Сагынасың?.. Күрдем бит мин, буйтур, хан кызын яратасың, ул...

— Әйтмә алай, Денис...

— Буйтур, буйтур. Хан кызы төркиләрдә илханнарга гына...

Буйтур түзмәде, торып китте. Койрыкчы Денис аның артыннан карап калды. Шунда буйтур кырт борылды да койрыкчы янына килде.

— Җил юк,— диде койрыкчы сүзне икенчегә борырга теләп.—Җил булса, ишкәкчеләр дә бераз ял итәрләр иде. Патшакалага җиткәч, ирек бирәбез дигәч, җан көчләрен салып ишә башладылар.

— Әйе, җил юк. Тып-тын.

— Буйтур, бер сорау бирергә ярыймы?

— Әйт, койрыкчы.

— Олуг хан сиңа бик күп алтын бирде. Ни кылмакчысың?

— Бүләк ул, император Ираклийга бүләк.

— Чәчкәне бер язга кичектерергә исәбе икән Кубрат ханның. Ханнарга ышансаң... Ханнан өмет иткән — җәһәннәмгә киткән. Ул синнән котылырга тели кебек, буйтур.

— Койрыкчы, телең тыймасаң, ишкәкчеләр янында сиңа да урын табылыр.

— Патшакалада барыбер ирек бирерсең, буйтур.

— Ирекне алмасаң?

— Каенатам сатып алыр, буйтур. Болгардан сандык тутырып алтын алып кайта. Мәгәр мин Патшакалада калмаска иттем, буйтур.

Ханнарга ышанмыйм дисәм дә, Кубрат ханга ышанам. Ул миңа Эске кирмәндә җәйләү бирәм, диде. Болыны булса, малы булыр.

— Мин дә өметем өзмим, Денис,— тынычлана төште буйтур.— Тәңре язганы булыр. Исән-имин кайтсам, бәлкем хан...

Денис куеныннан перун алласын чыгарды, нидер укып, кире куенына тыкты.

— Перун аллам сине яклар, буйтур. Без исән-сау Фанәгүргә әйләнеп кайтырбыз, олуг хан сиңа кызы Чәчкәне бирер...

«Тәңрем, кабул ит рось Денис әйткән теләкләрне. Кабул ит, кабул ит, кабул ит...»

Сиздерми генә кич җитте, ишкәкчеләр ашадылар да йокларга аудылар. Илбарыс буйтур бүлмәсенә керде, ут алды, табгачлардан килгән кәгазьгә күргән-белгәннәрен язып куйды. Аннары шәмнең берсен генә калдырды да сузылып сәкегә ятты. Кораб читенә сүнеп-сүрелеп килгән дулкыннар бәрелә, әйтерсең лә берәү кыяр-кыймас кына керергә сорый иде. Күрше бүлмәдәге сакчылар ярымтавышка гына нидер сөйләшәләр. Өске каттагы сакчы әле койрык якка үтә, әле түр якка юнәлә. Ике сакчы бер-берсе белән очрашкан саен айбалталарын чыңлатып алалар.

Илбарыс буйтур кулларын баш астына куйды, уйга чумды.

Иртәгә сәяхәт чыгабыз дигәндә Илбарыс янына көтмәгәндә анасы килеп керде. Аның артында сандык күтәргән колы басып тора иде.

«Бәбкәчем, угланым!»— диде ана һәм улының күкрәгенә килеп капланды.

«Анам, ни булды?»

«Берни дә булмады, оланым-канатым, берни дә булмады. Ерак җирләргә сәяхәткә җибәрә икән бит олуг хан. Тәңре генә саклый күрсен инде, оланым-канатым. Үги атаң әйтте, олуг хан оланың ерак сәяхәткә җибәрә, диде. Оланым-канатым, мин синең каршыңа мәрхүм атаңның васыятен үтәргә дип килдем. Аварларга яу чабар алдыннан мине янына чакырды да: «Илбарыс углан бәлигъ булып буйтур дәрәҗәсен алгач, мәнә шул сандыкны аңа бирерсең»,— диде. Атаң васыяте. Нәзерем тотар дип гел куркып йөрдем. Менә мин сиңа сандыкны тапшырам, олан, тәңре шаһит...»

Кол сандыкны буйтур каршына китереп куйды.

«Рәхмәт, анакай».

«Исән-имин әйләнеп кайт, олан. Саклан. Тәңре саклаганны саклармын дигән...»

Анасы киткәч, Илбарыс бик озак сандыкка карап торды. Тимер кыршау, тимер кадаклар белән эшләнгән юл сандыгы иде бу. Сандыкның почмаклары бакыр калайлар белән ныгытылган, урта бер төшеннән тасма итеп көмеш калай кадакланган. Сандык кайчандыр ук савыты булган булса кирәк. Соңгы елларда Кубрат хан ук йөртүчеләргә зур сандыклар ясатты. Хәзер укларны ике тәгәрмәчле арбада йөртәләр иде болгарлар. Элек яу чапканда атасы йөрткәндер сандыкны, хәзер әнә угланына калды.

Анасы уч төбенә салып киткән ачкыч белән Илбарыс сандыкны ачты. Гаҗәпләнгәне шул булды: капкачны ачканда эчтәге ышерен кубыз чыңлап, көйләп куйды. Хикмәтле сандык калдырган атасы буйтурга.

Иң өстә сандал агачыннан кырып ясалган, кан кызыл күн белән тартылган калкан ята иде. Буйтур җете кызыл төскә буялган калканны кулына алды. Җиңел һәм уңай итеп эшләнгән иде калкан. Аннары сандыктан кылыч чыкты, бер учма ук, грек ятаганы. Буйтур ятаганны кулына алды, икенче кулына калканны элде. Шунда гына ул калканны тишеп чыккан сөнге эзен күрде. Калкан матур, җиңел һәм уңайлы итеп эшләнгән, әмма аны кемнеңдер сөнгесе тишеп чыккан... Сөнге тишеген

күрүгә, буйтурның аркасы чымырдап куйды. Калканны тишеп, атасын үтергән сөңге эзе... Болгарлар мондый калканнарны инде күптән ясатмыйлар, калканны күн белән түгел, тимер белән тышлыйлар. Грек ятаганы белән дә орышка баручы сирәк хәзер, болгар алыпларының күбесендә Димәшкъ кылычы, табгачның кәкре очлы кылычлары. Соңгы вакытта болгар тимерчеләре дә кәкре кылычлар ясый башлады. Ятаган сабына кушаяклап чабып баручы ат төшерелгән. Ат шул хәтле өлгерелдам чаба иде ки, күз төшүгә, сикереп атланасы килеп китә. Сандык төбеннән кызыл табгач ефәгенә төрелгән тагын бер нәрсә чыкты. Сүтте дә ефәкне буйтур, күзе камашудан күзләрен йома төште. Аның кулында скиф бабалардан калган алтын саплы хәнҗәр иде. Алтын сапка батырылып затлы ташлар тезелгән. Буйтур хәнҗәрнең сабыннан алды, кулына кысты. «Менә бу бүләк. Их!»— диде буйтур дошманга селтәнгәндәй.

Сандыкта тагын нидер бар иде, әмма буйтурның һәр нәрсәнең ләззәтен озаграк тоясы килә иде, һәр әйберне кулына алган саен бик озак карады, тәэсирләнеп тикшерде. Сандыкның иң төбендә тагын нәрсәдер бар иде әле, киемгә охшаган. Илбарыс буйтур сандык төбендәге киемнәрне тартып чыгарды. Күр әле син моны! Буйтур киемнәре! Буйтур шаккатты. Атасы шул киемнән йөрде микән?..

Буйтур тиз-тиз чишенде, киемнәрне киде. Киенде дә йөгереп ишегалдына чыкты, баздагы суга бакты. Күрде дә үзен буйтур киеменнән, таң калды. Аңа су төбеннән мәһабәт, күркәм гәүдәле алып карап тора иде. Ул да түгел, буйтур йөгереп аты янына килде, сикереп атланды да, кала урар капкасын узып, далага чапты. Хан болынында ат көтүләре утлый. Илбарыс алар яныннан чаптырып узып китте. Көтүчеләр, ханның яшь атларын ияргә өйрәтүчеләр буйтурны танымадылар, шуңамы, кем икән бу, кай илдән килгән атчабар дип, кызыксынып, бик озак карап калдылар. Әлбәттә, көтүчеләр аны кавханга охшатканнардыр, кием кавханнарныкы иде. Менә ул дала! Ат кош кебек оча. Илбарыс тезгенен җибәрде, кулларын җәйде. Каршы җил битне иркәли, куеннарга тула, даладан хуш ис килә, күңел каядыр ашкына, каядыр омтыла, кемдер дәшә, чакыра сыман!

Юк, колакка гына ишетелгәндер. Әнә һавада кошлар патшасы бөркет талпына, бөркет Каф тауларына таба оча. Кош булсаң икән! Мәгәр кеше кош түгел. Кешенең күңеле генә канатлы, диләр. Аның менә бүген күңеле канатланды, күңеле белән әллә кайчан хан кызы Чәчкә янында ул. Ай-һай-һай-һай!.. Чү-ү, тагын аңа кычкыралар түгелме?.. Буйтур әрәмәләр яклап күз ташлады. Әрәмә яклап, аңа таба... Йа, тәңрем, чынлап та син! Чәчкә! Чәчкә!

Илбарыс буйтур атын борды, томырылып Чәчкәгә таба чапты. Чәчкәгә килеп җитәрәк, ул кала яклап килүче ханшаны һәм ике-өч сакчы күрде.

Чәчкә яныннан буйтур җан фәрманга чаптырып узып китте.

«Чәчкә, ияр, калышма!»

Әрәмәлекне узуга, тарлавыкка килеп чыгасың, тарлавык белән бераз гына барсаң, урман башлана. Буйтур Чәчкәне шунда әйдәде. Хан кызы ат өстендә шундый оста тота иде үзен, сокланмау мөмкин түгел. Чәчкәгә буйтурның шул хәтле күп сүз әйтәсе бар; аңласа икән, аңласа икән шуны Чәчкә! Аңлыйдыр, аңламаса, бер тотам калмыйча аның артыннан чапмас иде. Алар ханша һәм сакчылардан качарга тиешләр, бер мәлгә генә, бер мизгелгә генә булса да качарга тиешләр.

Атлар өздереп чабалар, сакчы алыплар күптән инде күздән яздылар. Менә ул урман, менә юл, менә алар көткән алан.

Илбарыс атыннан сикереп төште, Чәчкә атының йөгәненнән тотты, кызга аттан төшәргә ярдәм итте. Чәчкә аның кочагына инде.

«Буйтурым-арысланым. Мин сине шундый-шундый сагындым...»

Нәрсә булды аларга? Кичәле-бүгенле барысы да үз урынында кебек иде ласа. Ә менә бер-берсенең кочагына килеп кергәч, аларга кисәк кенә төшенеп бетмәгән оялу килде. Әйе, хакыйкать хыялдан башкарак икән шул. Хыял күп тапкыр татлырак булса, хакыйкать мең тапкыр сизгеррәк эш итә. Нәкъ менә хакыйкать килде аларга бүген ярдәмгә. Әгәр дә мәгәр хакыйкать килмәгән булса, алар бәлкем бу мизгелне хыялый рәвештә генә татыган булырлар иде. Менә шунда, аланлыкта сизде085ләр алар бер-берсе өчен яратылуларын. Хәзер аларны беркем дә аера алмас! Алар тормышта булган барлык сынауларны җиңеп чыгарлар. Кайда гына булмасыннар, кай тарафларда гына йөрмәсеннәр, Чәчкә күңелендә буйтур булыр, буйтур күңелендә — Чәчкә... Әйе, хәзер буйтуры китсә дә ярый, хәзер хан кызы Чәчкә үз көченә ышана — көтәр. Бәлкем, буйтуры аның Патшакаладан бөтенләй әйләнеп кайтмас?.. Юк, кайтыр, ул теләгәнгә кайтыр. Инде язмыш аларны аера икән, хан кызы Чәчкә күңеле белән барыбер аның янында булыр, мәңгегә, үлгәнче, җаны җәннәткә киткәнче.

Шул мәлдәге тетрәнүе, шигәюе, куркуы, киләчәк өчен борчылуы тикмәгә генә түгел иде Чәчкәнең. Хан кызы сизенә, тоемлый; атасы вәгъдәсендә торачак, аның Юстинианга ярәшүе политикага бәйле нәрсә, ике илнең килешеп яшәвенә. Мәгәр Чәчкә үкенмәс, үртәлмәс, ул менә сөйгәненнән бүген сөелә, бүген бөтен гомеренә җитәрлек назны алып кала, менә шушы аланлыкта, аулакта!

«Чәчкә, Чәчкә»,— ди Илбарыс һәм кызның татлы алсу битләренә, сусыл иреннәренә тартыла. Әнә ат тояклары тавышлары да ишетелә башлады. Сакчылар килеп чыксалар — харап. Олуг хан буйтурны беркайчан да кичермәс, ул иртәгә үк аның башын кистерер. Әмма йөрәк дигәнең моны кабул итми, ат тупырдаулары да үтеп китәр сыман, атасы да буйтурны кичерер шикелле.

Шул ук мәлдә сакчылар якынайган саен Чәчкәне курку били. Кем өчен?.. Үзе өченме?.. Юк, тагын бер тапкыр юк! Буйтуры өчен! Чәчкә сөйгәне буйтур кочагында үләргә дә риза. Тик аңа гына тимәсеннәр, аны гына рәнҗетмәсеннәр.

«Алар безне эзлиләр, буйтурым. Сакчылар явызлар, тапсалар шундук укка алырлар»,— шулай диде Чәчкә, әмма буйтур кочагыннан чыгуы булды, яңадан кереп эреде.

«Чәчкә, Чәчкә, мин сине...»

«Буйтурым. Атландыр мине атыма. Атландыр, соң булуы бар. Алар якыннар, бик якыннар. Атландыр!»

«Буйтурым,— диде атына менгәч Чәчкә.— Буйтурым, мин Кодрак абам белән Эске кирмәнгә утырмага китәм. Кайту белән син анда кил. Мин сине көтәрмен, буйтурым, көтәрмен, кө-тәр-мен...»

Чәчкә атын чаптырап, аланлыктан чыгып китте. Ул сакчыларга каршы китте.

«Хан кызы Чәчкә бирелә, ханша!»— дип кычкырды сакчыларның берсе. Буйтур атына атланды, атын атлатып кына бөтенләй башка якка юнәлде.

Өенә кайткач, сандык төбеннән атасы анасына бүләк иткән зәбәрҗәт кашлы балдак тапты. Балдакны ул сөйгәне Чәчкәгә бирер. Әмма кич якта да, иртән киткәндә дә Чәчкәгә балдакны бирә алмады. Кубрат хан кызыннан күзен дә алмый күзәтте.

Кораб кузгалганда күзләре белән яр башындагы Чәчкәне эзләде буйтур. Тапты. «Сау бул, Чәчкәм!»

Чәчкә корабтагыларга маңгаена бәйләгән зәңгәр тасмасын салып болгады. «Сау бул, буйтурым!»— дия кебек иде кыз.

Буйтур кулъяулыкка төреп, түш кесәсенә куйган балдакны капшап карады. Балдак урынында иде. Килер бер көн, шушы алтын балдакны Чәчкәнең бармагына кидерер буйтур. Кидерер дә берәм-берәм бармак

битләрен үбеп чыгар. Аннары алар Кызкуыш туенда катнашырлар. Чәчкә рәтләп йөгереп тә тормас, буйтурдан шундук тоттырыр.

Буйтур хиссияткә бирелеп, авыз эченнән генә җырлап җибәрде. Шул чак бүлмәгә төптимерче Агасике килеп керде.

— Буйтур моңлана,— диде ул һәм түргә узып, сәке читенә утырды.— Моңлана буйтур. Илдән аерылу кемгә дә җиңел түгел шул.

Төптимерче буйтурның хәленә керергә тели кебек иде. Кайчандыр Болгарга китеп барганда Агасике үзе дә шулай моңланган иде. Илдә ике бала белән хатыны кала, ә үзе базилевс йомышы белән хәтәр эшкә китеп бара. Башкайлары исән-имин иленә әйләнеп кайтырмы, юкмы — белми иде. Шактый гомерен Болгарда уздырды Агасике, ничәмә ел Кубрат ханга бил бөкте. Хәер, Кубрат хангамы, әллә базилевскамы? Әйе, базилевска, Византиянең императоры Ираклийга бил бөкте ул. Ни бирер император Агасикегә — бер хода үзе белә. Шул еллар эчендә әнә кызы җиткән, аллага шөкер, алтын куллы кешегә кияүгә чыкты, улы сарай мәктәбен тәмамлагач, император алачыгында эшли башлаган. Бер шик бар-барын. Агасикедә. Кызы Эгина үзгәргән. Нык үзгәргән. Анысына бик исе китмәде. Бишектәге бишкә төрләнер, диләр. Йа хода, инде барысы да артта калды. Тиздән изге Константинопольга җитәрләр... Юк, ходайдан каргалган кеше түгел икән әле, рәхимле мизгелләрдә туган адәм икән. Сәяхәте уңды, куенында Төн илләренең картасы, анда яшәгән халыклар турында мәгълүматлар. Кайту белән император аны янына чакыртыр, сорашыр, төпченер. Буйтур турында да сорашыр. Ни әйтер Агасике?.. Ни өчен бара Патшакалага Кубрат ханның тәрбиягә алган угланы?.. Ни генә булмасын, Агасике Кубрат ханга хыянәт итәргә кыймас. Хан аны якын итте, үз итте. Буйтур тагын... Император бик төпчена башласа белгәнен әйтер: буйтур ханнан бүләкләр китерде, кораллар алып китәргә исәбе, шул исәптән үтенече бар — Чәчкәне алырга император угланы Юстиниан бер язга кичегеп килергә тиеш, хан үтенече.

Агасике һәрчак базилевстан курку тойды. Яшерен илчесе Агасикенең Кубрат хан белән татулашып китүен сизсә, базилевс аны кичермәс. Әйе, базилевс аны кеше итте, эш бирде, акча бирде, ирек бирде, яшерен илчесе итте, шул ук вакытта базилевс аны юк та итә ала иде.

Тимерчелекнең нечкәлекләренә Агасике Фанагүрдә төшенде. Болгарларның угы авыррак, озынрак, сызгыра торган. Андый ук очканда зәһәр тавышлар чыгара, ерак оча. Болгарга килгәч, шуңа шаккатты Агасике: биредә коралларны көйлерәк, җайлырак ясыйлар иде. Киемсалымнары да җиңел, җайлы. Тире иләүгә килгәндә — иң йомшак тиреләрне болгарлар или. Болгар сурәттә дә каядыр ашкына — хәрәкәтнең иң бөек ноктасына омтыла кебек иде. Болгар ясаган әйберләр нәфис булыр, күзгә ятыш, сокландыргыч булыр. Болгарның һөнәрчеләре генә түгел, гореф-гадәтләре дә ошады Агасикегә. Әгәр дә мәгәр артыннан бертуктаусыз патриций Симеон күзәтмәсә, Агасике, бәлкем, гаиләсе белән Болгарда да калган булыр иде. Мәгәр башкалар артыннан бер-берсен күзәткән кебек, аның артыннан да күзәтүчеләр куйган иде базилевс. Болгарда калса, аны шундук үтерәчәкләр иде, греклар үтерәчәк иде. Болгарда базилевсның йөзләрчә шымчысы бар. Алар бар өлкәдә дә эшлиләр, хезмәт итәләр. Ни генә булмасын, Агасике базилевс йөкләгән бурычны үтәде. Иртәгә кораб Херсонеска җитәр, Херсонес — империя биләмәсе. Ә менә дәүләт булып оешып киткән Болгарны тиз генә биләмәсе итә алмас базилевс. Каты чикләвек империя өчен Болгар, Әмма эш шуңа таба бара. Болгар христиан динен кабул итү белән империя канат астына керер.

Алай да Агасикенең беләсе килә иде: нинди йомыш белән бара икән Кубрат хан илчесе Патшакалага? Әллә соң буйтурны грек уты сере борчыймы?.. Бик ихтимал ич. Ул сорауны Агасикегә Кубрат хан Болгарга килгәч тә биргән иде...

— Сагышланасың, буйтур?

— Сагышланам, төптимерче.

— Белсәң кирәк, буйтур, император белекле алыпларны ярата, ул сине дә Патшакалада калырга өндәр. Серең әйтерсең, кичерер.

— Минем базилевстан серем юк, төптимерче.

— Базилевстан юктыр, ә менә миннән бар.

— Синнән дә, Агасике. Мин Патшакалага корал алырга барам. Бер рәттән хан кызы Чәчкәне бер язга кичектерүләре турында сорармын. Хан үтенече. Кубрат хан борчуда, көнчыгышта хәзәрлар көчәеп бара,— буйтур торып утырды Агасикенең күзләренә карады.— Агасике, Денисны Патшакалада калдырырга исәбең юктыр бит?

— Буйтур, койрыкчы Денис минем киявем.

— Ә ул Патшакалада калырга теләмәсә, Агасике?

— Калыр, буйтур, калыр. Мин киявемә ышанам.

— Әнә ничек икән.

— Мин синең дә калуың теләр идем, буйтур. Базилевс каһарман сугышчыларның кадерен белә торган кеше.

— Беләдер, ышанам. Әйт әле Агасике. Син үзең кире Фанагүргә кайтырга теләмисеңме?.. Базилевсның йомышын үтәдең, нигә дип гаиләң белән кире Фанагүргә китмәскә ди?

— Мин туган илемдә, буйтур. Туган ил дигәнең туган илдән китеп торганда гына кадерләнә икән ул. Җитәрдер, күп йөрдем, күп гиздем.— Агасике буйтурның иңбашына кулын куйды.— Утың алыштыр, буйтур. Утыңны дим алыштыр. Сүзем бар.

Буйтур яңа шәм кабызды, урынына килеп утырды. Әмма нидер исенә төшеп, сәке астыннан бер чүлмәк эчемлек чыгарды, ике җам куйды.

— Синең туган илеңә исән-имин әйләнеп кайту өчен, Агасике!

Агасике кыстатмады, бер җамны эчеп тә куйды, буйтур аңа тагын койды.

— Син миңа баштан ук ошадың, буйтур. Оста сугыша алуың өчен генә түгел, акыл белән сугыша алуың өчен ошадың. Ул сәләт бар кешегә дә бирелми. Ничек алдырдың ике мең алае булган Чалбай ханны. Грекның бөек полководецлары да мондый җиңүләргә сирәк ирешә алганнар. Хан сине күтәрде, буйтуры итте. Кул астында ун мең алай булыр. Хәзер әнә Патшакалага хан илчесе булып киләсең. Хан булсам, мин синдәй кешегә кызым бирер идем.

— Ханга тимә, Агасике.

— Кызын оныта алмыйсыңмы?..

Буйтур дәшмәде, аның Чәчкә турында сөйләшәсе килми иде.

Агасике торды, чүлмәктән бер җам эчемлек салды, күтәреп эчеп куйды һәм буйтурга тыныч йокы теләп, чыгып китте.

Икенче көнне Херсонеска җиттеләр. Су алдылар. Су китерүчеләрне Денис ашыктырды.

— Тизрәк, тизрәк, сучылар, бер мичкәгә бер алтын, ашыктырсаң ике алтын, соңга калсаң ярты алтын, сабыр калган ни алган,— дип авызына нинди сүз килде, шуны такмаклап торды.

Иртә таң белән кузгалдылар. Херсонес артта калды. Денис Херсонестан кипкән балык, ит, сыр, тоз, кәрзин-кәрзин алма-җимеш алган иде, барысына да өләшеп йөрде. Херсонестагы греклар белән Агасике бик озак сөйләшеп торды. Агасикене өске каттан буйтур күзәтеп торса да, әллә нигә бу греклан ул шикләнмәде. Херсонестан соң Патшакалага ике-өч көнлек су юлы кала. Димәк, берсекөнгә булмаса да аннан алдагы көнгә алар Патшакалада булачаклар. Әлеге диңгездә давыл-фәлән юк, тәңре саклый.

Кораб кирәк тарафка яткач, Денис буйтурга диңгездә йөзгән зур кораблар турында сөйләде. Иң яхшы койрыкчылар греклар түгел, финн-

кияләләр икән. Әмма аларны табуы кыен икән хәзер. Кайсы-кая таралып беткәннәр. Кайчандыр, моннан күп еллар элек, финикияләләр дөнья читенә кадәр бара алганнар, әмма кире әйләнеп кайтмаганнар, әллә яңа җир тапканнар, әллә үзләрен диңгез алласы алган. Диңгез алласының бик күп кызлары бар икән. Аларны су анасы диләр. Су анасы кораблардан күбрәк ирләрне ала икән. Бу турыда Дениска философ сөйләгән. Денис грек философны ярата, ул аңа бик күп хикәятләр сөйли икән. Философның буйтурга да диңгез турында хикәятләр сөйләгәне бар. Ул әкәмәтләрне тыңлый-тыңлый төннәре йокысыз үтәр иде. Греклар болай итә икән: диңгездә давыл купса, диңгез алласы ачулана, корбан сорый дип, башта ишкәкче колны ташлыйлар. Анда да давыл туктамаса, икенче ишкәкчене дулкын эченә ыргытканнар, анда да туктамаса, диңгез алласы сине сорый дип, кораб башлыгын ташлыйлар. Хәзер андый хикмәтләр бик сирәк сирәген, әмма булгалый, юк-юк та кешеләрне су анасы алгалый икән.

Диңгез кояшында Денис чүлмәктәй каралды, болай да җирән сакалы тагы да җирәнләнә төште. Зәңгәр күзләре генә офык читеннән кодрәт көткәндәй алга карыйлар. Җил шактый ипле исә, болай барсалар тиздән изге София чиркәү манарасы да күренер. Яшь хатыны аңа изге София чиркәве турында төннәр буе сөйләгәне бар, хәзер койрыкчы шул әкәмәт чиркәүне менә-менә офыкта күренер дип көтеп бара иде. Буйтур Денисны сирәк борчыды, хәтта ни белергә теләсә дә: «Денис, Патшакалада каласыңмы, кире Фанәгүргә кайтасыңмы?»— дип сорамады. Ул ышана иде, койрыкчы Кубрат ханга хыянәт итмәс. Шулай да вакыт-вакыт күңелгә шик төшә, андый чакларда ишкәкчеләр янына үтә буйтур, каравылбаш Камай белән сөйләшеп утыра иде.

Грек Агасике, Патшакалага якыная башлауга, бүлмәсеннән бөтенләй чыкмас булды. Ул озын көн буена хатыны, улы, кызы янында утыра, нидер сөйләшәләр, киңәшләшәләр. Киңәшерлеге бар: төптимерче баеп кайта.

Патшакалага якыная башлагач, койрыкчы Денис үз-үзенә урын таба алмый интекте. Ул әле буйтур янына килеп утырды, әле ишкәкчеләр янына төште.

Кояш баер алдыннан Денис өске катка менде һәм кызарып барган офыкка карап җырлап җибәрде. Җыр үтә дә таныш иде буйтурга. Илбарыс койрыкчы янына барып утырды, җырга кушылды. Денис башта аптырап калды. Каян белә буйтур рось җырын? Дөньяда нинди хозурлык! Шәфакъ нуры сүрелеп бара, күңел әллә кайларда, туган якларда. Җитмәсә буйтур аның туган телендә җырлый.

— Туганкаем, кем син? Каян беләсең бу җырны?

— Анам җырлый иде,— диде Илбарыс.

Денис аягүрә басты, буйтурның күзләренә карады.

— Минем дә туган илем бар, буйтур. Ул еракта, бик еракта. Елгалар, урманнар артында. Синең бу җыруың миңа, минем кардәшләрем яшәгән ыстаным хәтерләтте. Мине явыз кнэзь бик яшьли Кубрат ханга биреп җибәрде. Минем анда бабам-анам, туганнарым калды. Бабам да, атам да көймә ясаучылар иде. Атамны кнэзь бервакыт яуга алып китте, шуннан ул әйләнеп кайтмады. Кнэзь мине үзенә алды, шуннан Кубрат ханга биреп җибәрде. Ышанма, буйтур, хан белән кнэзьләр вәгъдәсенә. Йомышын йомышлый алмасаң, хан синең башың кисәр. Ханнар белән кнэзьләргә кеше башы бер тиен дә тормый.

— Денис, мине өнәсәң, әйтмә Кубрат хан турында яман сүз, ул миңа ата булган кеше, ул мине бакты, сараенда белем бирде. Яман сүз кеше үтерер, ди.

— Беләм, буйтур. Алай да күңелемдәген әйтми булдыра алмыйм. Хан сине барыбер Фанәгүрдә калдырмас, кызын сиңа бирмәс. Син грек утының серен белергә барасың, буйтур.

— Син каян белдең, Денис?

— Агасике белән кызы сөйләшкәнне тыңлап тордым. Греклар ул утның серен гасырлар буена саклыйлар. Алар Кубрат хан сине юри җибәргәндер, диләр.

— Денис, мин үзем дә ул утның серен белүчене табуыма шикләнәм. Миңа чынлап та Кубрат хан шундый бурыч йөкләде. Мәгәр алып кайта алмасам да Кубрат хан минем белән берни дә кылмас.

— Мин сиңа кулымнан килгән кадәр ярдәм итәрмен, буйтур. Ант эчик.— Денис хәнҗәрен чыгарды, бармак очын кадап канатты канны пычак йөзенә буяды, аннары буйтурга бирде, буйтур да шулай ук итте.— Инде ант эч, буйтур.

Денис хәнҗәр йөзен иреннәренә тигезде, буйтурга бирде, буйтур да канлы хәнҗәр йөзен иреннәренә тигезеп алды.

Кемдер тамак кырды, аларга таба Агасике килә иде, Денис тиз генә хәнҗәрен кынысына тыкты.

— Буйтур,— диде Агасике аларга килеп җитәр-җитмәс.— Сине минем улым дәшә. Аның сиңа әйтер сүзе бар.

Буйтур бар көченә Денисның кулын кысты. Бу — мин синең белән ант эчтем, дию иде.

— Әйдә,— диде буйтур һәм Агасикегә иярде.

— Буйтур, сине императорның алачыгы кызыксындыра дип ишеттем, хакмы шул?

— Мине бернинди алачык та кызыксындырмый, Агасике.

— Ярый, буйтур, син дигәнчә булсын. Ачуланма, синең нә йомыш белән Патшакалага килүең билгеле.

— Төптимерче Агасике,— диде тавышын күтәрә төшеп буйтур.— Төптимерче Агасике, исеңә төшеримме әллә, мин Патшакалага кораллар алырга барам.

— Алай да син тыңла әле мине, буйтур. Сөйләш улым белән. Ул сиңа ярдәм итәргә тырышыр. Болгарлар — император өчен варварлар, минем өчен хәзер кардәшләр. Патрикий Симеон да, философ Иоанн Фасиан да Болгарга сөрелгән кешеләр. Алар Болгарны изге дингә димләргә тиешләр. Болгар җитди сынау алдында тора. Сарациннар көчәеп килә. Болгарда иң ышанычлы акча — дирһәм. Сарациннар акчасы дирһәмгә ияреп яһүд-сарациннар килә башладылар. Кая китте Болгардагы грекның көмеш милирәсе, кая китте императорның алтын солиде!... Юк алар. Сарациннар, яһуд сәүдәгәрләре йотып кала Болгарны, император да кала арты кала югалта. Императорны әнә шул борчый бүген, буйтур, улым сөйләде. Бүген аңа Кубрат хандай дуслар кирәк. Рум-Болгар татулыгы бозылмас, бозыла күрмәсен иде.

Агасике гаиләсенә иң зур бүлмә бирелгән иде. Буйтур бүлмәгә килеп керүгә, төптимерче гаиләсенә түбәнчелек белән баш иде. Аңа түрдән урын бирделәр.

— Исеңдә тотсаң иде, буйтур, мин Кубрат ханга яманлык теләмим,— диде Агасике һәм хатыны белән кызын бүлмәдән алып чыгып китте.

— Мин дикъкать белән тыңлыйм сине, буйтур.

— Рәхмәт, оста. Мин сиңа оста димен, ялгышмыймдыр?

— Юк, буйтур, ялгышмыйсың. Мин чынлап та император алачыгында эшлим.— Егет савытларга чүлмәктән эчемлек койды.— Болгарларга минем хөрмәтем зурдыр. Болгар ханы атамны бай итте. Атам миңа әйтте, сине, буйтур, грек утының сере кызыксындыра диде.

— Оста, мине бернинди дә грек уты кызыксындырмый, бары шуннан: мин — буйтур, оста алып. Орышка йөргән һәр алып яңа корал белән кызыксына. Шул гына.

— Болгарлар — варвар. Никадәр генә империягә дус булмасыннар, базилевс аларга грек утының серен бирмәс. Кызганыч, буйтур, бик кыз-

ганыч, грек уты мин эшләгән алачыкта ясалмый. Император анда варварларны түгел, грекларны да энә күзеннән үткәреп кертә. Грек утын ясаучыларны халык арасына чыгармый. Ул алачыкта эшләгән кеше йә шунда үлә, йә сугышка китеп котыла. Алачыкта эшләгән осталарның берәүсе дә сугыштан әйләнеп кайтмады. Сугышта үлмәгән хәлдә аны...

— Үтерәләр...

— Мин алай дип әйтмәдем, буйтур. Аннан бары тик бер оста чыкты, буйтур. Симокатта карт. Аның онығы моннан бик күп еллар элек Болгарда тотык итеп калдырылган икән. Ә ул шагыйрь булган, императрица Мартинаны яраткан, аңа багышлап шигырьләр язган. Онығын сагына карт. Болгардан сәүдәгәрләр килгән саен портка килә, көннәр буена шулар янында урала. Ут серен сатмасын дип, император шымчылары аңардан күзләрен дә алмыйлар... Ни өчен үтерми соң ул картны дисеңме?.. Хикмәте бар, кайчандыр император Ираклий аның белән бер күршедә үскән, ярдәме тигәндер картның, диләр.

— Аның онығы Константин мине дә укытты. Ул чынлап та шагыйрь.

— Карт әнә шул онығын сагына. Грек утының серен белсә, шул карт белер, буйтур.

— Кабат әйтәм, оста. Мине ул ут бөтенләй кызыксындырмый.

— Мин сиңа белгәнем әйттем, буйтур. Аңлашмадык булып чыга. Без икебез ике ярда басып торабыздыр, күрәсең.

— Анысы хак, оста. Без чынлап та икебез ике ярда басып сөйләшәбез.

— Алай да киңәшем тотсагыз иде, буйтур. Картны мин сиңа үзем күрсәтермен. Калганы аның эше.

Буйтур үз бүлмәсенә кергәндә тышта караңгы төн иде инде. Кораб дулкыннарда чайкала, өске катта каравыл алыплар йөренә, койрык ягында пыскып кына ут яна. Буйтур шәм кабызды, сәкегә ятты, утын да сүндерергә онытып, шундук йокыга китте.

Әмма күп тә үтми уянды да. Кемдер бүлмә ишеген капшый кебек иде. Чынлап та, шудыргычны ачарга тырыша сыман берәү. Буйтур сак кына урыныннан торды, кулына хәнҗәрен алды. «Кем булыр, ни калган?— дип уйлады буйтур, шыпырт кына ишеккә атлады.— Кем аның янына керергә тели? Камай? Юк, Камай аңа дәшәр иде. Кем? Агасике?! Түгелдер. Төнлә. Агасике аласын алды инде болгарлардан. Кем?...»

Илбарыс буйтур аяк очларына гына басып, ишеккә якын ук килде. Кем капшана? Шудыргычны ачу мөмкин түгел. Ничек керергә исәбе бүлмәгә бу кешенең? Каракмы? Кубрат ханның алтынын алмакчымы?.. Алтынны алган хәлдә кая кача ала ул. Тентерләр, табарлар, каракны шундук диңгезгә ташларлар. Каравыл сакчылар кая? Нигә йөрмиләр?!

Буйтур кисәк шудыргычны тартты һәм тышка чыкты. Ишеккә терәлеп диярлек каравыл торучы алып йоклый иде. Буйтур аның якасыннан эләктереп алды да селкә башлады.

— Уян, уян диләр сиңа, Камай!!— дип тамагы ертылырдай зәһәр тавыш белән кычкырды буйтур.— Каравыл, Камай!

Буйтур янына каравыл алыплар йөгерешеп килделәр, сулышына кабып, каравылбаш Камай килеп җитте. Килеп җитте дә каравыл алыпның яңагына чабып җибәрде. Алып күзләрен ачты, керфекләрен каккалап торды. Ниһаять, ул тәмам айныды, шаккатып, үзен урап алган халыкка карады.

— Йә, йә, айныдыңмы, ни булды?— диде Камай.

— Су анасы,— диде алып.— Су анасы...

— Су анасы?!— дип кайтарып сорады Камай.— Нинди су анасы, иләсләндеңме әллә?

— Әйе, булмаганны, тузга язмаганны,— диештеләр.

Айлы якты төн иде. Шул мәлдә диңгез өстендә бер алиһә пәйда булды. Кайсыдыр күреп:

— Әнә ул!— дип кычкырды.— Әнә, әнә!

Чынлап та, ярты гәүдәсен чыгарган килеш су анасы корабка таба йөзеп килә иде. Кайсы җәясен тартты, кайсы сөңгесенә ябышты. Ай яктысы ни якты булса да, су өстендәге хикмәтне аермачык күрү мөмкин түгел иде, шулай да корабтагылар моның чынлап та су анасы икәненә ышанып, беравыздан диярлек кычкырып җибәрделәр. Су анасына тияргә ярамый, моның өчен диңгез алласы давыл чыгарыр, корабны кыяга орыр.

— Укка алмаска, сөңге ыргытмаска! Тәңрегә дога кылыгыз!— дип боерды буйтур.

Корабтагы һәммә кеше идәнгә тезләнде, кулларын күккә күтәреп тәңредән ярдәм сорады. Дога укылды, тәңре аларның теләкләрен кабул итте, күтәрелеп караганда диңгез өстендә су анасы юк иде инде.

Беренче булып каравылбаш Камай исенә килде.

— Икенче каравыл алып кая?

— Аны, каравылбаш, су анасы алды,— дип тәүге сүзен кабатлады тәмам исенә килгән алып.

Барысы да моңа ышандылар һәм янә тәңрегә дога кылдылар.

Шулай итеп, бу төндә корабтан бер каравыл алыпны су анасы алды. Иртән кояш чыгып, якты көнне каршы алгач, грек Агасике буйтур янына килде.

— Каравыл алыпны су анасы түгел, диңгез алласы алгандыр,— диде.— Гадәттә су анасы адәмнәрне сирәк ала, алыпның гаебе, язгы булгандыр. Икенче каравыл алыпны да диңгезгә ташламасагыз, су анасы иртәгә дә, берсекөнгә дә килер.

— Денис!— дип кычкырды буйтур.— Койрыкчы Денис, кил әле бире!

Койрыкчы кыюсыз гына алар янына килде.

— Тыңлыйм, буйтур.

— Койрыкчы Денис, бүген каравылда синең белән икәү торырбыз...

Күрде буйтур, шул сүзләрне әйтүгә, грек Агасикенең күзләре дүрт булды. Төптимерче кинәт буйтурның алдына тезләнде.

— Буйтур, кылма андый боерыгың, диңгез алласының сине дә алуы бар.

— Денис,— дип кабатлады буйтур.— Бүген төнлә өске катта без икәү каравыл торабыз.

— Баш өсте, буйтур.

— Койрыкчы Денис, боерыгымны кабатла!

— Бөек Болгарның олуг хан буйтуры Илбарыс, бүген төнлә койрыкчы Денис каравылда булыр!..

Кич кояш баегач, Буйтур белән койрыкчы өске катка каравыл чыктылар. Корабта барчасы да йоклый шикелле, шул ук вакытта буйтур белә: беркем дә рәтләп йокламый. Үткән төндә булган хәл барысын да йокыдан калдырган иде. Кичәге төндә булган хәл ишкәкчеләргә кадәр ирешкән, аларны да куркуга салган иде.

Денис корабның койрыгына килгәндә, Илбарыс буйтур түргә — борынга таба узды. Диңгез өстендә дулкыннар йөгерешә. Патшакала ягында кичке шәфакъ янә, икенче яктан әкрен генә, иренеп кенә ай калкып килә. Диңгез алласымы, су анасымы кичә дә нәкъ менә ай калкып бераз күтәрелгәч өскатка менә һәм бер алыпны кочаклап ала да, матур-матур сүзләр әйтә-әйтә, битләреннән сөя-сөя диңгезгә алып төшеп китә. Аннары янә күтәрелә, икенче каравылны сихерли башлый, шулай ук кочаклый, иркәли, назлый, әмма каравыл алып коты очып куркуданмы, андый хикмәтләрне аңламый, чытырдап буйтурның ишек

бавына ябыша. Шуның белән исән кала. Философ белән укытучы Константинның сөйләвенә ышансаң, диңгез алласының су астында патшалыгы бар икән, патшалыкта кызлар гына яши икән, теләгән адәмне юхалап диңгез төбенә алып төшмичә, кызларның кияүгә чыгарга хаклары юк икән.

Буйтур боларның берсенә дә ышанып җитмәде. Бит аңа соңыннан философ әйтте, болар барысы да матур әкият диде. Ничек инде матур әкият булсын ди?.. Әнә, кичә төнлә белән бер каравыл алыпны алды, бүген икенчесен алып китсә...

Денис белән очрашкан саен буйтур, сер бирмәскә тырышып:

— Су анасын тотсам, мин аңа өйләнәм, Денис,— диде.

Денис ашык-пошык кына куеныннан перун алласын чыгарды, нидер пышылдап кире куенына тыкты. Шуннан соң гына:

— Тәңреңә иман кыл, буйтур, шулай әйтергә ярыймы?

Денис су анасының өске катка менүенә ихластан ышана, жанькоты үкчәсенә җитеп көтә иде. Диңгез өстен көмеш төсенә кертеп, тирәюньне тоныкк кына ай яктырта башлагач, Денисның ышануы тәмам чигенә җитте. Ул шылт иткән тавышка да ялт итеп әйләнеп карады, кулындагы сөңгесен ныграк кысты. Аның бер дә үләсе, дөресрәге, су анасына китәсе килми иде. Су анасыннан да матур, сылу хатыны Эгина бар, ул аны ярата, ул аны сөя, ул ансыз яши алмый. Буйтур үзе дә ни батыр кыланса да курку тоя, туктап һәр тавышка колак сала, шулай дикъкать белән тыңлаудан аның колаклары чыңлый, ахыр ул гасабилануын яшерергә теләп, авыз эченнән генә җырлый башлый. Кораб борынына таба үткәндә дә, койрыкка әйләнеп килгәндә дә буйтур бер генә мәлгә дә бүлмәсе ишеген күзеннән яздырмаска тырышты. Бар хикмәтләргә күңеле ышанган хәлдә дә аның бүлмәсендә Кубрат хан биреп җибәргән ике мең алтын бар. Ул алтын императорга диган бүләк түгел... ул алтын грек утының серен кулга төшерү өчен бирелгән. Алтын буйтур бүлмәсендәге кечкенә сандыкта ята. Сандыкны бүлмәдән алып чыгып китүе җиңел түгел, сандык күрше бүлмәдәге каравылбаш Камай ягына нечкә кыл белән бәйләнгән, кыл башында көмеш кыңгырау. Сандыкны күтәреп алуга, кыл өзелер һәм каравылбаш бүлмәсендә көмеш кыңгырау чыңлар. Әмма оста һәм тәҗрибәле каракның кылны өзеп, сәке аягына бәйләп куюы да бар иде.

Ары үткәндә дә, бире килгәндә дә буйтур бүлмәне күздән яздырмады, ахыр бүлмә ишегенә килеп сөялде. Ай күк гөмбәзенең уртасына җитеп килә, диңгез өсте тыныч, ник бер җан иясе күренсен, курка-шикләнә ятсалар да арулары җиткән булса кирәк — корабта сөйләшүләр бетте, йоклады халык. Тып-тын.

Мәгәр нәкъ менә шул үтә тынлык күңелгә торган саен ниндидер курку, шом өсти бара. Иртәгә иртән алар, койрыкчы ялгышмаса, Патшакалада булырга тиешләр. Инде максатларына ирештеләр дигәндә су анасы килеп чыксын әле. Бүген дә су анасы күренсә, кемне булса да диңгез алласына алып китәргә итсә, иртәгә бер колны суга ташламый булмастыр. Су анасы шунсыз тынычланмас. Шунсыз кораб Фанагүргә әйләнеп кайтмас, давыл чыгып, кыяга бәрелер, берәүсе дә исән калмас, буйтур үзе дә.

Буйтур су анасына ышанып та җитми иде, шулай да күңел шомлана, тыныч түгел.

Чынлап та, су анасы аның каршында пәйда булса, ул нишләргә тиеш?.. Су анасын үтерергә ярамый, аннары диңгез алласы аларны көне белән юк итәр. Юк, күргән хәлдә дә үтермәскә, куркытырга, хәнҗәр белән янарга. Ә ул болгар телен аңламаса?.. Аңламаса, күтәрергә дә суга атып бәрергә. Су анасы суда батмый.

Буйтур ни кылырга белми әйләнә-тирәне күзәтте. Атнага якын юлда булдылар, диңгез түзәрлек тыныч булды. Соңгы көндә генә әллә нишлә-

де, жил купты, дулкыннар йөгерешә башлады. Менә төн килүгә янә тынычланды диңгез, алай да дулкыннар тынып ук бетмәделәр, койрыкчы ярдәмчесе дулкыннарга каршы тотса да чайкала иде кораб.

Дулкыннар йөгерешә... Корабтагы тынлык белән диңгездәге тынлык бер түгел шул...

Кинәт буйтурның зиһене ачылып киткәндәй булды. Бернинди су анасы да юк, корабта карак бар һәм аның бүлмәдәге алтынга күзе кызган...

Буйтур яныннан Денис үтеп китте һәм күп тә үтми янә әйләнеп килде.

— Мин бу Камайның алыпларына шаккатам, ни кылып яталар икән көннәр, төннәр буена?

— Шахмат уйныйлар, койрыкчы. Син беләсең булса кирәк, Кубрат хан сарай сакчыларына кадәр шахмат уйнатып ала.

— Анысы хак, мине дә өйрәтте. Ышансаң ышан, ышанмасаң юк, буйтур, көннәрдән бер көнне бу миңа үзенең җансакчысын җибәргән... Мине шахмат уенына өйрәтергә килгән. Ни ул миңа сөяк шәкелләр. Менә кораб ясарга дисәң, кулларым кычыта башлый... Их, давыл купмаса гына ярар иде, буйтур,— дип уфтанып куйды Денис.— Иртәдән дә соңга калмыйча Патшакала күренер... Мине Эгина һаман Патшакалада калырга кыстый, буйтур.

— Кубрат хан ошатырмы соң, койрыкчы? Әйтәсе юк, император синдәй останы колач җәеп каршы алыр, биш куллап.— Миңа калса, буйтур, бу грек Агасике кызы Эгинаны тикмәгә генә сиңа бирмәгәндер, тикмәгә генә берни дә эшләми грек.

— Туган ягым Рось, торган җирем Болгар булды, буйтур. Болгарда игелекле яшәдем. Олуг хан төпоста итте...

— Болгар-Рось элек-электән бертугандай тату яшәгәннәр. Әле борын заманда ук Этиолан белән рось дружинасы франкларга яу чабалар. Яуда росьлар арысландай орышалар. Этиоланга яшь воевода ошый, ул аңа кызын бирә, кайтыр юлда алар иленә туктый. Туктаган төшкә зур кала салдыра — Кияүкала. Этиолан киявенә бер төмән алай да биреп калдыра... Кубрат хан да росьлар белән тату яши, күрше-тирә илләрне буйсындыргач, Роська юнәлә, князьгә бик күп бүләкләр алып бара. Князь аңа минем анам Анияне һәм бер оста биреп җибәрә.

— Мин ул, мин, буйтур!

— Син!

— Әйе, мин. Князь мине Кубрат ханга биреп җибәрде. Ананны беләм, мин нибарысы ундүрт яшьлек малай идем, анаң житкән кыз иде инде. Менә каян рось җырларын беләсең икән син, буйтур...

Шул чакта диңгез өстендәге йөгерешкән дулкыннар арасында нәрсәдер күренеп китте. Каравыл торучылар ачкан авызларын яба алмый шым булдылар. Дулкыннар эчендәге кара нәрсә бер күренде, бер күздән язды.

— Буйтур, буйтур,— диде Денис өненә килеп.— Буйтур, су анасы... Әнә, әнә...

— Денис, йөгер, Камайны чакыр. Шауламa. Тиз бул! Тотабыз аны.

Денис китеп тә өлгермәде, хатын-кыз сурәтендәге су анасы өске катка менде. Су анасы шул хәтле зифа сылу иде ки, буйтур бермәлгә өнсез калды. Юк, су анасы түгел икән бит, Чәчкә, аның сөйгәне Чәчкә килә аңа таба. Әнә күр: йөреше дә, буй-сыны да гел Чәчкәнеке...

Су анасы әкрен генә килде дә буйтурның кулыннан алды, колагына нидер пышылдады, ниндидер серле сүзләр әйтте. Буйтур карусыз аңа иярде. Мәгәр зиһене томаланмый калган бер өлештә: «Ул мине сихерләде, ул мине үзе белән диңгезгә алып төшеп китмәкче, мин һични кыла алмыйм. Тәңрем, син кая? Коткар, коткар буйтурыңны! Тәңрем!..»— дип уйларга өлгерде.

— Буйтур, буйтур!— Кораб койрыгы яклап каравылбаш Камай, аңа ияреп бернич алып йөгерәләр. Алар буйтурга дәшәләр, әмма буйтур бармагын да селкетә алмый, һаман кораб читенә таба атлый. Менә кораб чите. «Су анасы мине диңгез патшасына алып бармакчы. Тәңрем!..»

— Буйтур, буйтур Илбарыс!

Буйтурның йөзенә дулкыннардан очкан тозлы су чәчри, шул чак аны Камай тотып ала, селкеп, үз ягына таба әйләндерә.

— Буйтур, нишләвең бу? Диңгезгә чумасың киләме?

Буйтур, башына суккандай бер мәлгә миңгерәүләнеп, һични аңламый каравылбаш Камайга карап тора.

— Чәчкә... Су анасы...

— Нинди Чәчкә, нинди су анасы, буйтур?

Буйтур башына тотынып, як-якка чайкалды. Чынлап та, нинди су анасы? Күктә ай йөзә, диңгез өстендә һични юк, дулкыннар йөгерешә, кораб салмак кына чайкалып тора.

— Денис кая? Койрыкчы кая, каравылбаш?!

— Денис!— дип кычкырды Камай.— Денис, койрыкчы! Ни карап торасыз, алып килегез койрыкчыны!

Ике алыпны гүя җил алды, алар Денисның бүлмәсенә таба йөгерделәр.

— Мин монда, буйтур. Монда,— дип бөтенләй башка яктан килеп чыкты Денис.— Монда мин, буйтур. Синең бүлмә ишегең ачык, буйтур.

— Ничек, ачык?! Кем ачты!?

Буйтур йөгереп барып бүлмәсенә керде, сәке астыннан сандыгын тартып чыгарды, ачкычы белән ашыга-кабалана ачты. Алтын урынында иде. Шуннан соң гына бүлмәсенә күз йөртеп чыкты. Бүлмәдә ике шәм яна, кем кабызган? Ни эзләгәннәр бүлмәдә?.. Әйберләрнең астыөскә килгән. Кием сандыгын тартып чыгарды. Сандыкта әйберләр калмаган, кайсы-кая сибелеп аунап ята.

Илбарыс буйтур аларны тиз-тиз генә җыйды, сандыкка салды. Ишек яры каравылбаш Камай, койрыкчы Денис карап торалар. Агасике килеп житте, ул да кызыксынып карап тора башлады. «Агасикегә ни калды микән?»— дип уйлады Илбарыс буйтур.— Денис, ишекне яп та бире кер әле. Камай, син урыныңда бул!

Денис эчкә керде, бүлмә ишеген япты. Буйтур күрше бүлмәгә сузылган кылны тикшереп карады. Кыл өзелмәгән иде. «Димәк, карак ялгыш икенче сандыкны ачкан. Ачкан, бөтен әйбернең астын-өскә китергән, әмма алтынны тапмаган. Кем булыр? Су анасы, имеш. Яшь, чибәр, хан кызы Чәчкәгә охшаган. Мин аны хәтта Чәчкә дип белдем... Денис хатыны?»— дип уйлады буйтур һәм кинәт зиһене ачылып киткәндәй койрыкчының якасыннан эләктереп алды.

— Денис, хатының кая синең?

— Йоклый, буйтур.

— Йоклый?!

— Әйе, буйтур, миннән йоклап калды.

— Әйдә сиңа!

Денисның күзләре зурайды, янып торган шәмнәргә карап алды.

— Син, буйтур, минем хатыннан шикләнәсең?

— Шәмнәр яндырып, иркенләп эзләгән...

— Кем, буйтур?

— Киттек!

Денис бүлмәсенә килеп керделәр. Бүлмә иясе кабалана-кабалана шәм алды. Буйтур шәм белән идәнне яктыртты, идәндә су тамчылары ялтырый иде.

— Менә ул су анасы!— Илбарыс буйтур Денис хатынының чәченә

кагылды. Хатынның чәче юеш иде. Хатын уянмады, ыңгырашып икенче якка әйләнеп ятты.

— Аңлашыла. Әйдә, Денис, Камай бүлмәсенә.

Буйтур белән койрыкчы каравылчы алыплар бүлмәсенә килеп керделәр. Сәке астыннан тартылган кылны буйтур бик тиз тапты.

— Кемнәр йокламаган иде?

Өч алып буйтур каршына бастылар.

— Күрше бүлмәдә берәр төрле тавыш ишетмәдегезме?

— Юк, буйтур, без бернинди тавыш та ишетмәдек, синең тавышны гына ишеттек.

— Денис,— диде буйтур койрыкчыга таба борылды.— Денис, алтынга синең хатының кергән. Кичә ул бер каравыл алыпны суга аткан. Бүген мине олактырмакчы иде...

— Буйтур, буйтур!— Денис Илбарыс буйтур алдына тезләнде.— Буйтурым, ни дигән сүз бу?

— Бумы, койрыкчы?! Синең хатының йә шымчы, йә карак. Ул безнең алтынны урламакчы булган!

— Юк-юк! Ул андый түгел, буйтур! Андый түгел! Булмастайны сөйләмә, буйтур...

— Греклар диңгездә балык кебек йөзәләр, Денис.

— Хатыным түгел, буйтур. Ышанмыйм. Кайната Агасике эше. Эгина аңа бармас. Синең хакка, минем хакка...

— Денис, тор, тынычлан. Тынычлан һәм минем белән килеш. Без кергәндә хатының йоклаганга сабышып ята иде, чәчләре юеш, иләндә су тамчылары... Юк, Денис, хаталанма...

— Юк-к, буйтурым, ул андый түгел, түгел!.. Ул албасты түгел!

— Иә-йә, ярсынма. Ышанмасаң, бар, үзең тикшер, юеш түгелме чәче, юкмы? Бар-бар, аннары миңа килеп әйт...

Денис йөгерә-атлый бүлмәдән чыгып китте.

— Син, син,— диде буйтур ике алыпка.— Койрыкчы Денистан күз дә алмагыз, ул кая бара, сез шунда. Ишеттегезме! Йокламаска!..

Каравылбаш Камай кайтып керде.

— Буйтур, Агасикедә шигем бар.

— Агасике түгел, Денисның хатыны кергән бүлмәгә.

— Әйтәм күзләре бик елтырый иде. Сихерчедер бу дип уйлаган идем, хак икән. Әфсен дә укый белә инде болай булгач. Әфсен укый да су анасы рәвешенә керә, әфсен укый да янә Денисның хатыны була, бер сүз белән әйткәндә, албасты.

Илбарыс буйтур сәкегә утырды. Төрле хайваннар рәвешенә әверелә алган сихерчеләр, албастылар, күз буяучылар турында сөйли торган иде укытучы Константин. Ул кеше башта синең күзеңә карый һәм сине сихерли. Ул синең алдыңда әле бала була, әле карчык, әле җиткән кыз... Эгина һәм Чәчкә?.. Ул минем күземә Чәчкә сурәтенә кереп күренде. Буйтурның шиге-шөбһәсе калмады, алтынга Эгина кергән. Ә менә үзе генәме эш итә, атасы Агасике беләнме — монысын буйтурга ачыклыйсы бар иде. Ә Денис, Денис белгәнме? Әллә булмаса Денистан башка гына эш итәләрме?.. Алтынны алган хәлдә кая китәргә уйлады икән? Буйтур башын күтәрде, әмер көтеп торган каравылбаш Камайга:

— Каравылга ике алып куй, минем белән Денис урынына. Сак булсыннар. Мин ял итәргә ятам.

Буйтур үз ягына чыкты, шәм кабызды, сәкегә сузылып ятты. Кисәк бүлмәгә җил кергәндәй булды, почмактагы уентыга утыртылган шәм калтыранып, куркынып, дерелдәп куйды, аннары тагын тураеп басты. Янә җил керде, янә шәм калтырана башлады, шәм уты күләгәсеннән диварда шомлы күләгәләр йөгерде. Буйтур урыныннан сикереп торды, Денис бүлмәсенә юнәлде. Ишекне шакыды, җавап бирмәделәр.

Киереп ишекне ачты, түргә узды. Сәке буш иде. Мендәр юеш иде. «Юк, ул ялгышмаган: Эгина йә карак, йә сихерче».

Бүлмәгә Денис килеп керде, шәм алды.

— Буйтур, Эгина гаепле түгел.

— Мендәр әле дә юеш.

Денис мендәрне кулына алды, битенә тигезеп карады. Мендәр чынлап та дымлы иде.

— Юк минем Эгинам. Ул беркая да юк, атасы янында да!

— Сихерче синең Эгинаң, Денис. Бүген су анасы, иртәгә карчык, тели икән...

— Эгина су анасы, буйтур. Минем Эгинам!— Денисның күзләре шарланды.— Су анасы... Аның тәне һәрчак салкын булыр иде... Шулай ук...

— Әйдә, Денис, Агасикегә.

Мәгәр Денисның хатыны Эгина атасы белән анасы бүлмәсендә дә юк иде. Кызының юкка чыгуын ишетүгә, Агасике яткан җиреннән сикереп торды, хатыны чукынырга кереште. Агасике чишенми яткан иде, бу хәл буйтурны янә шиккә калдырды, әмма ул төптимерчегә бер сүз дә әйтмәде. Әгәр дә мәгәр Эгина чынлап та сихерче икән, ул турыда Агасике дә белмидер, инде Эгина карак кына икән ул корабтан беркая да китә алмас. Нәкъ менә шунда буйтурның күзе Агасикенең улы ятагына төште. Ятак буш иде. Улы кая төптимерченең?

— Агасике, мин бүлмәдә синең улыңны күрмим,— диде буйтур һәм Денискә күз сирпеп алды.

— Ул өстә йөри, буйтур. Нигәдер ул йоклый алмый интегә.

«Йоклый алмый интегә,— дип эченнән кабатлады буйтур.— Кулына төшмәгән алтын йокысын качырдымы?..»

Атасының сүзен раслап, бүлмәгә төптимерченең улы кайтып керде. Таң нуры белән килеп кергән кунакларны күрде дә, гаҗәпләнә калып, чакырылмаган кунаклар белән баш кагып кына исәнләште, үз ятагына таба үтте.

Таң атты, тышта яктырып килә, эче пошудан йоклый алмаган кешенең өске катка чыгып йөрүе табигый иде. Әмма Денисның хатыны кая? Денис үзе дә борчулы күренә. «Бу бичара йә хатынының сихерче икәнен белми, йә белеп миннән яшерергә тырыша. Алай дигәндә алар мине бу бүлмәдә бөтереп тә алган булырлар иде»,— дип уйлады буйтур, кулын хәнҗәре тирәсендәрәк тотып.

— Эгина үзендә, бүлмәсендә йоклап ята,— диде егет ятагына сузылып яткач.— Эгина үзендә йоклый, җизни.

Денис белән Илбарыс күзгә-күз карашып алдылар.

— Бүлмәдә, йоклап ята?!— дип кайтарып сорады Денис.

— Бүлмәдә, бүлмәдә,— дип кабатлады терсәгенә таянып егет.— Бүлмәдә!

Денис кабаланып чыгып китте һәм күп тә үтми әйләнеп тә килде. Койрыкчының куанычы йөзенә үк бәреп чыккан иде.

— Буйтур, Эгина чынлап та йоклап ята. Мин аны уяттым, ул беркая да чыкмаган... Чәчләре дә коры...

Бу юлы Агасике белән улы күзгә-күз карашып алдылар.

Өске катта ыгы-зыгы, шау-шу купты, Денис белән Илбарыс тышка чыктылар. Койрык ягыннан ике алып йөгереп килде.

— Буйтур, буйтур, койрыкчыны су анасы алды. Ярдәмчесе авыз ачып сүз әйтә алмый, әллә әчкән, әллә иләсләнгән.

Буйтур белән Денис койрыкка йөгерделәр. Койрыкчының ярдәмчесе кораб читенә тотынган да бертуктаусыз каравыл кычкыра, килә-килүгә, буйтур алыпны үзенә таба йолкып алды, күзләренә карады.

— Акырма! Туктал. Бу — мин, буйтур! Ишетәсеңме,— диде буйтур аның колагына иелеп.— Ишетәсеңме, кычкырма!

Бу — койрыкчы Денисның икенче ярдәмчесе иде, беренче ярдәмчесен су анасы алган булып чыга.

— Буйтур, Илбарыс буйтур,— диде ярдәмче тирә-ягына карап алды.— Хәзер генә корабта су анасы булды.

— Су анасы безгә ачу тота, корабта языклы кеше бар, аны суга ташламыйча су анасы безне ташламаячак, башкача безгә котылу юк, туганнар,— диде Денис.

— Тиктор, Денис! Ишетәсеңме, тиктор! Бернинди дә су анасы юк,— диде буйтур, күзе белән каравылбаш Камайны эзләп тапты.— Камай, әйдә минем белән. Алыпны имче карасын.

Буйтур йөгерә-атлый бүлмәсенә кайтты, каерып ишекне ачты. Бусаганы атлап керде дә туктап калды. Бар нәрсә дә үз урынында кебек иде. Буйтур тиз генә сәке астыннан сандыкны тартып чыгарды, ачкыч белән йозакны борды, ачты. Алтын урынында, исән иде. Буйтур шапылдатып капкачны япты, сандык өстенә утырды, җиңе белән маңгаена тибеп чыккан тир бөртекләрен сөртеп алды.

— Буйтур,— диде каравылбаш Камай.— Икенче алыпны су анасы алды. Денис языклы кеше булгандыр, ди. Языксыз кеше буламы. Син дә әнә хан кызы...

— Каравылбаш Камай, менә бу сандыктан бер тәңкә алтын югала икән, шул булыр синең языгың, беренче итеп сине суга ташларбыз! Денис белән мин үзем сөйләшермен. Коткы таратып йөрмәсен...

— Буйтур,— диде Камай кыюлана төшеп.— Буйтур, мин алардан шикләнәм, греклардан. Денисның хатыны суда балык кебек йөзә. Кызсарай алдында коендылар, үзем күрдем...

Буйтур бер тын каравылбашка карап торды, аннары терсәге белән тезенә таянды да, башын кулына куйды.

— Ишкәкчеләр нигә шаулыйлар?

— Су анасы икенче алыпны алганнан соң ишкәкчеләрнең котлары алынган, алыпны кочаклап суга сикергәнен күргәннәр.

— Тынычландыр үзләрен, су анасы колларга тими диген. Кылган языклары булса, таңредән кичерү сорасыннар. Хәер, дөрес әйтәсең, кем языксыз бу дөньяда. Бүген бер алыпны, иртәгә бәлкем мине алыр...

Каравылбаш Камай җилкә аша як-ягына төкеренеп алды.

— Син әйтмәдең, мин ишетмәдем, буйтур, бу сүзләрең, авызыңнан җил алсын. Әйттем-кайттым, дигез.

— Әйттем-кайттым.— Буйтур йөрәгенә чыдый алмый ачуланып торып басты, сандыкны сәке астына этеп куйды.— Алтын өчен башың белән җавап бирәсең, Камай!

— Баш өсте, буйтур.

— Мә сандык ачкычын. Бер мизгелгә дә бүлмәне ташлатма, каравылга иң ышанычлы алыпларың куй!

— Кояш чыга, кояш чыга!— дип кычкырдылар өстә. Буйтур бүлмәдән чыгып китте, Камай башын кашып, ишек бавына тотынып калды. Алтынны саклый алмаса, Кубрат хан аның башын кистерәчәк.

Буйтур кояшны каршы алды, таңредән игелекле көн бирүен теләде. Шунда берсе:

— Патшакала!— дип кычкырды.

Чынлап та, алда иртәнге зәңгәрсу төскә кертеп өртелгән һава аша әкияттәге ташкаладай Патшакала җәйрәп ята иде. Әнә, Денис күрергә теләгән София чиркәве, аның алтын түбәсендә кояш нурлары биешә, тонык кына чаң суккан тавыш ишетелә. Греклар дүртесе дә өске катка чыкканнар иде, Патшакалага карап тиз-тиз чукынып алдылар.

Гүзәл Патшакалага кораб якыная башлауга, койрыкчы кияве янына грек Агасике килде.

— Бир әле, кияү, койрыкны. Читкә китеп тор. Шулай. Кубрат хан корабын император бухтасына кертәм. Болгар илчеләренең корабын үз портына кертергә боерган император...

«Кайчан, кем?— дип сорыйсы килде Денисның, ләкин бер сүз дә әйтмәде, читкә тайпылды.— Керт әйдә боергач».

Агасике шул хәтле оста туктатты корабны, Денис кайнатасына сокланып карап торды.

— Ташла ягирләрне!— дип кычкырды Агасике, аннары борылды да:— Шул булыр император порты, кияү,— диде.

Яр яклап сумала, дегет, балык исе килә. Ягирләрне төшереп, яр буендагы баганаларга аркан ыргытып та өлгермәделәр, сарай ягыннан корабка таба өч кеше килүе күренде. Алар ашыкмадылар, һәрхәлдә буйтурга шулай тоелды. Басма салынды, басмага беренче булып буйтур аяк басты. Өч кеше килеп җиткән, корабтан төшеп килгән буйтурны көтәләр иде инде. Буйтурга грек Агасике, аның гаиләсе, кияүләре Денис иярде. Алар артыннан императорга дигән бүләкләрне күтәргән хезмәтчеләр кузгалдылар.

Болгар илчеләрен каршы алырга килүчеләрнең өстендә кызыл бәрхеттән теккән чапан, башларында кибән хәтле башлык, аякларында болгарның сафьян итекләре. Илчеләрне каршы алырга килүчеләрнең берсе алгарак чыгып баскан, икесе исә бераз арттарак торалар. Киемнәрендә аерма юк кебек. Әһә, бар икән, алдарак басып торганының билендә кан кызыл төсенә буялган киң пута, путага алтын тәңкәләр тезгән, тегеләренең путаларында көмеш тәңкәләр. Илбарыс якынаюга, кунакларны каршы алучылар, сөйләшкәндәй, берсүздән бил бөктеләр.

— Галиҗанәпләре Болгар илчесе Илбарыс! Килер юлыгыз ерак. Сау-имин килеп җиттегезме?

Буйтур күкрәгенә кулын куеп бил бөкте, аннары:

— Юлыбыз уң булды, рәхмәт сезгә, ил күркәмнәре!

Буйтур артына әйләнде, Дениска:— Аударып бир, ни карап каттың!—— диде.

Денис буйтур янәшәсенә килеп басты, буйтурның сүзләрен аударып бирде. Мәгәр буталды, телен көчкә әйләндерде.

Ул арада Агасике алга чыкты, каршы алучыларның берсенә:

— Дариан! Син исән?!

— Агасике, туганкай! Син дә...

— Исән, Дариан, исән! Аллаһы-тәгала саклады.

— Син Болгарданмы?... Ә-э, беләм... Әйт әле бу варварга, сарайга кузгалсыннар, император көтә диген.

— Чү-ү, Дариан, Болгар илчесе грекчаны синең белән миннән остарак белә.

— Белсә... Кузгалдык!— дип кул изәде илчеләрне каршы алучы. Барысы да аларга иярделәр, Агасике Дариан белән янәшәдән атлады.

— Бер кулың йөрмиме әллә, Дариан?

— Сарацинннар яралады. Император ташламады, сарайга хезмәткә алды. Зарланмыйм. Яхшы түлиләр.— Дариан буйтурга әйләнеп карады, көтеп алгандай итте.— Агасике, Болгар илчесен император көтә... Күр әле син бу скиф токымын, матур адәми, һич тә варвар димәссең үзенә.

— Дариан, Болгар илчесе грекча белә дидем түгелме мин сиңа!

— Ә-э, кичер, Агасике, гел онытып җибәргәнмен. Кичә хәзәрләр килгәннәр иде, бер авыз сүз белмиләр, бөтенесен тылмач аударды.

— Болгар илчесен грек Константин укытты. Шагыйрь.

— Императрица Мартинаны яраткан шагыйрьме?

— Үзе, Дариан.

— Андыйларны император тотамы. Һай, карале, кайтасы да килмиме?..

— Аның анда гаиләсе бар, балалары.

— Ә императрица?.. Ул аны әле булса онытa алмый, диләр, хат язышалар икән.— Дариан як-ягына каранып алды.— Әллә син дә шагыйрьдән императрицага хат алып кайттыңмы, Агасике?.. Үләм шундый хикмәтле хәлләрне яратам... Юкмы... Ә өйләнүе хак булса, кызганыч. Сорама, императрица аның өйләнгәнен белми, димәк.

— Агасике,— диде Илбарыс.— Агасике, укытучы Константин беркемгә дә өйләнмәде, берүзе тора.

— Һо-һо-һо, мөнә синә варвар, мөнә сиңа скиф оныгы, бик һәйбәт сөйләшә бит бу изге телдә...

— Мин шулай дип ишеткән генә идем, буйтур, кичер,— диде Агасике.

Алар янәшә атлыйлар иде инде. Ике якка ачылмалы тимер капкаларны уздылар, айбалталы сөңгеләр тоткан каравыл алыплар Болгар илчеләрен сәерсенеп озата калдылар. Алыпларның берсе ак аю тиресен күтәргән иде, мондый затлы тиреләрне күрүгә, грекларның күзләре янды.

Ике канаты челтәрләнеп коелган капкаларны узуга, күп санлы болгарлар гөлбакчадан бара башладылар. Ике якта да хатын-кыз, ир-ат сыннары. Бер кулына гөлҗимеш чәчкәсе, икенче кулына кабырчык тоткан хатын-кыз сынын күрүгә Денис:

— Күр әле, буйтур, тач су анасы,— дип пышылдады.

— Су анасы диңгездә калды, бу су анасының сыны, Денис.

— Философ шулай дидеме?

Буйтур дәшмәде, су анасының сыны гаҗәеп-гүзәл иде. Сын яшькелт мәрмәрдән уелган, гөлҗимеш чәчкәсеннән күз яшедәй тамчы тама, ә кабырчыктан су бөркелеп үк тора иде.

Дариан белән Агасике дөньяларын онытып сөйләшеп баралар, бу могҗизалы сарайда йөрү алар өчен гадәти хәл иде, күрәсең. «Димәк, Агасике биредә бер тапкыр гына булмаган,— дип уйлады буйтур.— Кем син?.. Кемгә яллandың, кемгә хезмәт итәсең? Кемне сатасың, кемне яклыйсың?.. Дусмы син Болгарга — Кубрат ханга, дошманмы?.. Әллә булмаса Болгарда да император теләкләрен үтәп йөрдеңме?.. Юк, Агасике Кубрат хан яклы түгел, хан яклы булса императрицага дигән хатны укытучы аңа биреп җибәргән булыр иде. Хатны укытучы миңа бирде, димәк, грек Агасикегә караганда ул миңа ышанарак төшә...»

Баскычлардан югары мендeләр, төп сарай ишекләренә юнәлделәр. Илчеләр килеп җитәр-җитмәс ишекләр ачылды. Ниһаять, Болгар илчеләре тәхет бүлмәсенә керделәр. Диварларда — канатлы фәрештәләр, ят җирләрен һәм гәүдәсен тукыма белән каплаган ир-атлар, сурәткә төшерелгән аксакаллар, идәннәре мәрмәрдән, ялтырап тора, бүлмәнең нәкъ уртасына куелган балык авызыннан һәм аның янәшәсендәге гөлҗимеш гөленнән су бөркелә. Бүлмәдә дымсурак саф һава. Җәннәт дигәннәре шулмы әллә, дип сөйләнде болгарлар. Ике якка баскан сакчылар янын нан уздылар. Сакчыларның кулларында капкада торган сакчыларныкы кебек айбалталы сөңге түгел, ятаган, киемнәре дә кыска, үзгә иде.

— Болары императорның җансакчылары,— диде буйтур, Денис бик каерылып карый башлагач.

Императорның тәхете янына якынлаштылар. Дариан алгарак чыкты, төзрәк атлап китте. Бүлмә түрендә биек тәхеттә башына алтын таҗ кигән император Ираклий утыра, аның уң кулында... «Йа, тәңрем,— дип сихерләнгәндәй императрицага карады буйтур.— Йа, тәңрем, бу кадәр Аппак ханшага охшар икән». Бер күрүгә үк императрицага үзе дә аңламаган якынлык тойды Илбарыс. Ирексездән укытучы биреп җибәргән хатны капшап карады. Түшендәге хат исән иде.

— Галиҗанәпләре бөек императорыбыз, күп яулар каһарманы, бөтен дөньяга ия хода илчесе Ираклий, кыеп әйтергә мәҗбүрмен, Болгар илчеләре исән-имин килеп җиттеләр. Илчеләр башлыгы Кубрат ханның буйтуры Саклаб улы Илбарыс сезнең алда!

Тантаналы рәвештә илче турында әйтеп биргәч, Дариан бер читкә китте, артында янәшә басып торган Илбарыс белән Дениска юл бирде.

Императорның уң кулында чукмар башлы таяк: өстендә кызылга алтын җепләр тукылган чапан, аякларында болгарның сафьян итекләре «Кубрат хан бүләге»,— дип уйларга өлгерде буйтур. Императрицага карап алды. Бая ул, күргәч тә императрицаны ханша Аппакка охшаткан иде. Хәзер исә алар арасында андый охшашлык күрмәде. Императрица Мартина тутсыл йөзле, кара чәчле, төз, озынчарак борынлы иде. Күзләре коңгырт. Императрицаның күзләрендә әйтеп бетермәслек мөлаемлек, бөркелеп торган наз күрде буйтур. Императрицаның аяк астында аю тиресе, иңендә кеш тиресеннән тегелгән шәл, шәле иңнәреннән төшебрәк тора, ялангач иңбашларын үтә күренмәле челтәр белән каплаган.

— Бөек Византия империясенең галиҗанәпләре, Бөек Болгар дәүләте илчесе Илбарыс сезгә исәнлек, саулык, тазалык һәм мәхәббәт тели.

Император ярдәмчесенә күз сирпеп алды, елмайды, императрица исә кызыксынып илчегә карап куйды.

Илбарыс буйтур белән Денис императорга, аннары императрица Мартинага бил бөктеләр.

— Хәерле килүең белән, илче!

— Галиҗанәпләре бөек император Константин углы Ираклий, Бөек Болгар ханы Кубрат гүзәлләрнең гүзәле императрица Мартинага, дөнья халыклары белән идарә итүче Ираклийга күптин-күп сәламнәр юллады. Хәбәр итәргә кушты: болгарларның башкаласы Фанагүрдә чиркәү салынды, барлык христиан халкы якшәмбе көн саен гыйбадәт кылырга җыелалар, аллаһы-тәгалә ирке белән киләчәктә дә йөрерләр.

Император бу юлы башын түбәнрәк иде, императрица ягына карап, бөтен битен тутырып елмаеп алды.

— Янә шуны әйтергә кушты Бөек Болгар ханы Кубрат, галиҗанәпләре, кызы Чәчкәне улыгыз Юстинианга бирү вәгъдәсен бозмады хан, әмма кайбер сәбәпләр белән киләсе язга кадәр кичектерүегезне сорады.

Император белән императрица күзгә-күз карашып алдылар, императрица сизелер-сизелмәс кенә ияк какты.

— Теләген кабул итәм, илче. Кубрат ханга җиткер, император риза диген.— Император Дениска ияк кагып күрсәтте:— Кем дип белик ярдәмчең, илче?

— Тылмач,— диде буйтур.— Тылмач итеп алган идем.

— Илчене кем укытты? Грекча бик әйбәт белә?..

— Шагыйрь грек илче Феофан улы Константин, галиҗанәпләре.

Константин исемен ишетүгә, императорның кашлары җыерылды, императрица исә чарасыз кузгалгандай итте.

Денис буйтурга:

— Корал, корал турында әйт!— дип терсәге белән җай гына төртеп алды.

Император ярдәмчесе белән ярымтавышка гына сөйләшә башлады. Илбарыс күзләре белән императорның улы Юстинианны эзләде. Кайсы икән?.. Монда юктыр. Булса читтә тормас иде. Күр әле, илхан Аслан... Буйтур Асланны күрде дә елмайды. Аслан һични аңламый аңа карап тора иде. Аслан илханны тану мөмкин түгел, ул нәкъ дин әһелләреча карадан киенгән, кулында күн тышлы китап.

— Корал турында әйтәсеңме, юкмы буйтур?— Денис тәмам гасабилана башлаган иде.— Буйтур дим!

— Шапырынма, бүләкләрне китерә башлат,— диде аңа буйтур. Аннары императорга сүз әйтергә теләп, бил бөкте:— Галиҗанәпләре бөек император изге Константин углы Ираклий, Бөек Болгар ханы Кубрат сездән бик күп корал сорады. Көнчыгышта, Этил елгасы тамагында

хәзәрләр күтәрелеп килә... Әмма әүвәл, галиҗанәпләре, сезгә Кубрат ханның бүләкләрен тапшырырга рөхсәт итегез,— буйтур, әйберләрне император алдына куярга дип ишарә ясады, җофар тиресеннән тегелгән тунны императрица каршына куярга боерды. Алдына өелгән бүләкләрдән канәгать калуын яшермичә, император аягүрә басты, кузгалды, килеп буйтурны уңлы-суллы кочаклады. Бүләкләр арасында ниләр генә юк иде. Сафьян итекләр дисеңме, көмеш өзәңгеләр, тәпән-тәпән бал, сандал агачыннан ясалган иярләр, хатын-кыз калфаклары, затлы тиреләрдән теккән бүрекләр, иләгән күннән эшләнгән күлмәкләр, өс киемнәре дисеңме — һәммәсе бар иде. Җофар тиресеннән тегелгән тун исә күз явын алып императрица иңенә салынды. Хатын-кыз бирелә дә хатын-кыз булып калды, бүләкне алгач, императрица күрше бүлмәгә чыгып китте. Бераздан ул әйләнеп тә керде, күз-йөзе елмая, бүләктән канәгать иде. Хатынының елмаюын күреп, император тәхетенә утырды, кулына таягын алды.

— Илче, патрикий Кубрат хан империягә гаять матур бүләкләр җибәргән. Болгар илчеләре минем иң кадерле кунакларым булыр. Бүген үк Кубрат ханга өч кораб корал озатыгыз!— дип боерды янәшәсендә баскан ярдәмчесенә император.— Иң әйбәт коралларны илченең корабына төягез. Үтәгез!

Император сөйләүдән туктап, бер тын уйланып утырды, аннары тәхет тирәсендәгеләргә күз йөртеп чыкты. Шиге калмады, кирәкмәгән кешеләр юк иде. Чөнки кичә генә ул Йулыш каган сәүдәгәреннән коллар сатып алган иде һәм бер кораб корал биреп җибәргән иде. Коллар бик кирәк иде императорга, якшәмбе көннәрдә ипподромга чыгып орышырдай көчле алыплар калмады. Ә халык тамаша көтә, ипподромда бер-берсен үтергәнче алышкан кол алыплар орышын күрергә гадәтләнеп киткән куштаннар гауга куптаралар, бу хәлдә күбрәк императорны гаеплиләр иде, аннары императорның үзенә дә үлемсез алышларны карарга күңелсез була башлады. Ә хәзәр сәүдәгәрләре Төн илләреннән әллә ниткән батырлар китерәләр. Аларның бер-берсе белән канга батып орышулары, үлем белән яшәү арасында тартышуларын каравы үзе бер гомер. Ул колларны сарациннарга каршы сугышка җибәрәсе иде дә бит, халык шаулый, азынды, бабалардан калган гадәтләрне таләп итәләр. Шуның өчен коллар алырга алтын да, корал да кызганмады император. Ахыр чиктә, кол тамаша кылу өчен генә кирәкми иде империягә, кол сугышта беренче булып кирмән диварына меңүче дә иде. Кол артка чигә алмый, император укчылары аны шундук үтерәчәкләр, колга дошман дивары өстенә менү күп тапкыр артыграк. Чөнки дошманны җиңгән хәлдә генә орышта катнашкан кол ирек алачак иде.

Ниһаять, илче Илбарыс императорга соңгы амәнәтне тапшырды — Кубрат ханның пергаментка язган хатын бирде. Шунда ул укытучысының императрицага булган хатын янә капшап карады һәм императрицага текәлеп карап алды. Күңеле сизде бугай императрицаның, шул хәрәкәтләрдән соң ул буйтурдан күзен дә алмады. Буйтур да моны сизде һәм күзе белән генә аңа да хат булуы турында сиздерде.

Император пергамент төргәген кулына алгач, әйләндереп-тулгандырып карады. Шиге калмады: тамга Кубрат ханныкы иде. Император хатны вәзиренә бирде. Тегесе төргәкне сүтте һәм кычкырып укый башлады. Кубрат хаты грек телендә иде. «Философ язган»,— дип уйлады Илбарыс.

Хат укылгач, император Кубрат хан үтенечен хәзер үк үтәргә дип янә бер тапкыр боерык бирде. Шуннан соң гына базилевс императрицага күз төшереп алды. Үзенә генә билгеле булган бер эчке сиземләү белән тойды императрица: ирe тарафыннан варварлар арасына куылган сөйгәне, шагыйрь Константин Болгар илчесе аша аңа хат җибәргән. Константинның хатларын әлегә кадәр император төрле юллар белән

кулына төшерә килде, укыды, әмма бу турыда беркайчан да императрицага сиздермәде, һәрхәлдә, сиздермәскә тырышты. Әмма императрица белә иде иренең бу эшен.

Кабул итү мәшәкате бетте, император илчеләрне урнаштырырга кушты. Аларны Дариан килгән ишекләр аша алып чыгып китте, Агасике император янында калды.

Болгарларны корабка кадәр Дарианның ярдәмчесе озата китте. Илче Илбарысны һәм аның тылмачын кунак сараена урнаштырдылар.

Кунак сарае түшәмнәренең биеклегенә ис китмәле иде. Түшәмнәрдә янә төрле сурәтләр — аллалар ясалган. Сарайның мәрмәр баганалары күзге кебек ялтыратылган. Бизәкле идәннәр, мәрмәр баганалар, түшәмдәге рәсемнәр — барысы да сине шаккатыра, күренеше белән әсир итә. Мондый мәһабәт биналарны Болгарларның күргәне юк. Таң калырлык иде гүзәллек, мәһабәтлек иде сарайда.

Кисәк кенә Илбарыс үзен шушы бинада бик кечкенә тузан бөртеге кебек итеп сизә башлады. Бина түшәмнәре аны басар, сытар, изеп ташлар, мәһабәт мәрмәр баганалар җимерелер, диварлары өстенә ишелер сыман иде.

Илчеләрне каршы алган Дариан ян ишеккә алып кереп китте. Менә алар төрле сыннар куелган бүлмәгә килеп керделәр. Сыннар менә-менә кузгалып китәрләр, кузгалып китәрләр дә кемнәр болар, нигә монда йөриләр, дип сорарлар кебек иде.

Ишекне ачып аларны сарай хезмәтчеләре каршы алды. Дариан аларга хәтта күтәрелеп тә карамады, ә тегеләре исә Дарианга барчасы бил бөгеп калдылар. «Монда халык та мәрмәр сыннар кебек,— диде пышан гына Денис.— Күр әле әнә тегесен, башына ни кигән, кош оясы диярсең».

Буйтур аңа җавап кайтармады. Ул һаман укытучы хаты турында уйлады. «Аңладымы икән императрица сөйгәне Константиннан хат алып килүем турында?.. Аңлагандыр, түшемдә аңа хат булуы турында ишарә ясагач, ничек кинәт йөзе яктырып китте. Мәгәр ничек бирергә аңа бу хатны?.. Дарианга бирсәң?.. Юк, Дарианның сатуы бар... Асланга бирергә. Аслан императрицага тапшырыр. Аслан, Аслан, ничек син яшисең бире дә?.. Кыендыр сиңа. Син бит далада, киң болыннарда үскән кеше. Ә монда бар нәрсә дә сине изәдер, сытадыр».

Бары тик шуны аңламады Илбарыс: ни өчен император сарайларын мәһабәт сыннар белән тутыра да, Кубрат ханны бөтенләй башка нәрсә — грек уты кызыксындыра икән? Әллә соң моның төп сәбәбе әнә шул мәһабәт сыннардамы, зур-зур биналардамы?.. Кубрат ханга бүген яшь дәүләтне ныгыту кирәк, шуның өчен тырыша, ә император боларга бик күптән ирешкән. Кем белә, дәүләт нигезен һәм чикләрен ныгыткач, бәлкем Кубрат хан да сарайларына әнә шундый сыннар ясата башлар, менә шундый мәһабәт биналар салдырыр.

Греклар барысы да христиан диненә табына. Христиан дине кеше сурәтен ясауны тыймый, әнә яһүд-мөселманнар сурәт ясауны тыялар, ди философ. Кемдә хаклык? Кемгә зыян килә бу сыннарны ясаудан! Бит соклангыч итеп ясалганнар, карап туярлык түгел.

Сул як ишеккә борылдылар, тарлавыктай озын арадан уздылар. Дариан янә бер ишекне ачты.

— Рәхим итегез,— дип ул алдан Илбарыс белән Денисны кертеп җибәрде.— Яшәвегез шунда булыр.

Дариан аларны эчкә алып керде, йөрәк турына кулын куеп саубуллашты да чыгып китте.

— Йа хода, бу кешедән дә котылыр көнебез булыр икән! Ошамады бу кеше миңа, буйтур.

— Без аңа ошадыкмы?

— Анысы аның эше, әмма бу тәкъва кеше белән мин яуга чыкмас идем.
— Синең белән яуга барырга җыенмый да ул, Денис. Аның үз дөньясы дөнья. Бу кеше, беләсең килсә, сарациннар белән сугышта яраланып кайткан һәм аны, батырлыгы өчен, император сарайга эшкә алган.
— Таяк йоткан кебек йөри.
— Туктале, Денис, синең хатының кая?
— Ул анасы белән китте, буйтур. Кайтыр ул, кайтам диде. Ә нигә, буйтур?
Илбарыс дәшмәде, императорның тәхете кебек итеп ясалган, әмма бермә-бер ким итеп ясалган урындыкка утырды. Бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Түр якта каракош утыра, ишек яклап балык койрыклы итеп ясалган хатын-кыз сыны кулындагы чүлмәктән су агып тора, шул тирәдә үрмә гөлләр. Түр тәрәзә каршында нефрит таштан ясалган өстәл, сул якта чыбылдык, чыбылдык эчендә ятак булырга тиеш.
— Хатыныңың бире алып килсәң, Денис, мин корабка китәр идем. Мондый ятакны ханнарның да күргәне юктыр.
— Исең китмәсен, буйтур. Безнең Кубрат хан аю-бүре, кеш-җофар тиреләрендә генә йоклый, ә монда мамык тутырылган чүпрәк. Димәшкъ сәүдәгәрләре бөтен болгар базарын тутырдылар мамык-чүпрәк белән.
— Хатыныңны алып килмисеңме, Денис?.. Алып кил, күрсәт үзенә җәннәтне.
— Юк, буйтур, алып килмим. Илендә кунак булып калсын. Бер киткәч, әллә күрә, әллә юк туган якларын...
— Кызык та соң бу хатын-кыз язмышы, Денис. Синең хатын әнә Болгарга китәр, хан кызы Чәчкәне тиздән бирегә китерерләр...
Ишек шакыдылар.
Буйтур сикереп урыныннан купты, грекча «керегез» дип әйтте.
Чүлмәкләргә салып, сарай эчемлеге, җимешләр керттеләр. Икенче ашчы җиз табак белән өстәлгә ризык-нигъмәт китереп куйды. Ашчылар ничек керделәр, шулай тавыш-тынсыз гына чыгып та киттеләр, әмма берсе ялт кына янадан әйләнеп керде һәм буйтурга императрицаның тәңкәсен сузды.
Илбарыс императрицаның тәңкәсенә күз төшереп алды.
— Императрицаның иң ышанычлы кешесе Харон,— диде ашчы, буйтурга бил бөкте.— Императрица Константинга дип хат бирде.— Харон ишек яры карап алды һәм буйтурга түшеннән пергаментка язылган хат чыгарып бирде.
Тамга императрицаныкы, укытучы бу тамганы аңа күрсәткән иде инде. Буйтур укытучы хатын түшеннән чыгарды Харонга бирде, императрицаныкын түшенә яшерде.
Харон шунда гына елмайды, буйтурга кул бирде.
— Ак юл сиңа, Илбарыс буйтур. Мин сезне шундый кеше дип күз алдыма китергән дә идем. Укытучыга миннән дә сәлам юллагыз — Хароннан.
— Ашарга бушка китермәгәннәр, акча алды,— диде буйтур Денискa таба борылып.— Утыр, капкалап алыйк. Нишләптер авыз корып китте.
Денис аңа шикләнеберәк карады, әмма бер сүз дә әйтмәде, куллары юды, өстәл янына килеп утырды, чокырларга эчемлек койды. Күзгә-күз карашып кына чәкәшеп алдылар, эчеп куйдылар. Табында кыздырылган каз, ниндидер үләннәр, тоз, борыч, тагын әллә ниткән хикмәтле ризыклар бар иде. Денис аларның һәрберсен кабып-тәмләп карады. Кайсын капкач йөзен җыерды, кайсын кабуга, авызын чәпелдәтеп елмайды.
— Менә бу ризык ичмасам, буйтур. Менә бусы, бусы,— дия-дия

ул үзе кабып караган тәмле дип тапкан ризыкларны буйтурга да тәкъдим итте.

— Сиңа ошаган, миңа ошамавы да бар бит...

— Шулай ашап-эчеп кенә ятасы иде, буйтур. Һични кылмый, ә?..

— Без монда тиккә генә килмәдек, Денис. Миңа Асланны күрергә кирәк. Теге Симокатта дигән картка юл тапмас микән. Минем башта Аслан белән сөйләшәсем килә. Әйт әле, Денис, нигә килмәде икән ул безнең янга?

— Кушмаганнардыр. Ул бит хәзер кеше кешесе. Безнең кебек. Борчылма, буйтур, килер ул, җаен табалмый торадыр. Карале буйтур, ана телен онытмады микән бу Патшакалада?

— Ана теле онтыла буламы, Денис. Әнә син онытмыйсың бит үз телеңне... Укытучы Константин да...

— Фанәгүрдә һәр унынчы кеше — грек, ә монда күзгә сөртергә бер болгар табып булмый.

— Ана теле. Ана теле кешегә ана сөте белән керә, ди укытучы. Җырла әле, Денис. Кычкырып җырла.

— Җырларга була ул, буйтур. Килешерме соң... Тел турында дөрес әйтәсең, буйтур. Ана теле ана сөте белән керә. Әнә мин төркине барыбер бик үк оста сукалый алмыйм.

Денис балык авызыннан аккан суга карап, бер тын дәшми утырды, аннары карашын каракошка күчерде, урындык терәкләренә күз төшерде. Терәкләрне алтынга манганнар, терсәк куя торган төше парча белән тышланган, кул астында арыслан башлары, арка терәкләрендә алан гәүдәләре. Пөхтә, чиста иде бүлмә, затлы җиһаз. Базилевс бу бүлмәне илчеләр өчен генә тота, күрәсең.

Буйтур торды, тәрәзә каршына килеп басты. Тәрәзәдә пыяла, Болгарда исә бу пыяла хан сарайларында гына, күп кешедә — карындык, тире.

Тәрәзәдән кораб күренә. Корабка керүче дә, чыгучы да юк. Билгеле инде, Илбарыс буйтурны көтәләр. Корабка кайтуга, ишкәкче коллар ирекка җибәрүләрен сорарлар. Җибәрмичә дә булмас, ышандырды. Буйтур кайтмыйча, каравылбаш Камай аларны беркая да җибәрмәс.

— Син Аслан да, Аслан дисең, буйтур. Асланнан битәр безгә Агасике кирәк, минем кайнатай. Ни кырып йөри микән? Ул мине эзләп табармын дигән иде.

— Агасике император янындадыр. Агасике Болгар турында артыгы белән күп белә, Денис. Император аңардан сорау аладыр. Империягә сарацинннар тынгы бирми, көнчыгышта хәзәрләр кузгалырга тора. Императорның барысыннан да хәбәрдар буласы киләдер.

— Минем кайнатай Болгарга яманлык кылмас, буйтур. Беләсеңме, китәр алдыннан Эгина мине чиркәүгә алып барды, шунда Симеон мине чукындырды, муеныма тавык тәпие такты. Мин анда кидем, дәшмәдем. Ә менә кайткач...

— Кайнатаң сине Патшакалада калдырмакчы, Денис!

— Мине?! Кайнатам?! Буйтур, менә ул тавык тәпие. Гади җиздән ясалган. Мин бу тәрене беркайчан да перуныма алыштырмаячакмын, буйтур. Мин аны янчыгымда йөртәм, ташлар идем, Эгина үпкәләр дип куркам...

— Эгина, Эгина. Алай да, Денис, теге вакытта нигә аның чәчләре юеш булды икән? Кем алды ике алыпны? Чынлап та су анасымы, әллә булмаса синең...

— Юк-к, буйтур, зинһар алай әйтә күрмә, Эгина андый түгел. Бар ул су анасы, бар!

— Беләсеңме төптәңре ни ди, Денис. Дөньяда тәңредән башка бернинди алла да юк, ди.

— Тәңре. Ә минем перуным, христианнарның Гайсәләре? Чалбай

ханның эт башы, угорларның ат башы, аюлары?.. Юк-к, дөньяда аллалар бик күп, буйтур. Тәңре. Тәңре үзенә, перун үзенә алла. Алыплар язык-лы булганнар, менә су анасы алган аларны.

— Алай дисәң, мин дә языклы, Денис.

— Нинди языгың бар, буйтур.

— Хан кызын яратам, ә ул император улы Юстинианга ярәшкән.

— Ярат, буйтур, ярат.— Денис торып йөренә үк башлады.— Укытучың әнә ячатуны изге нәрсә, ди. Әнә Эгина әйтә, борынгы грекларның мәхәббәт аллалары булган, ди. Ул дингез күбегеннән яратылган, ди. Шуңа гүзәл икән. Борынгы греклар шул мәхәббәт алласына багышлап салынган сарайга барып, ирләрне үзләренә гашыйк иткәннәр, ди. Эгина беләсеңме нәрсә диде ханша Аппакны күргәч, мәхәббәт алласына охшаган, диде.

Денис тынычлана төште, каракош янындагы урындыкка күчеп утырды. Аның күз алдына Кияүкала ыстаны, су коеныл, көймә белән балык тотып йөргән Варух елгасы килә, шул елга буена кер чайкарга төшкән күрше кызы Радянька. Ул кыз үзенә күптән иш тапкандыр инде, я булмаса явыз воевода аны үз ыстанына алгандыр. Радяньканы яраткан иде Денис, уникe яшьлек сабыйлар яратуы белән яраткан иде. Шуннан күп тә үтми алар утрагына воевода килде һәм көймә ясаучы Денисны слободага алып китте. Аннан Денисны явыз князь Кубрат ханга бирeп җибәрде. Варух елгасы буенда бабасы белән көймә ясап яткан Денисны язмыш әнә кайларга китереп ташлады. Кайда утыра көймә ясаучы Денис? Бөек императорның кунак бүлмәсендә. Затлы итеп эшләнгән савытлардан затлы эчемлекләр эчә.

— Буйтур, буйтур дим, моннан исән-имин әйләнеп кайтсак, әйттем бит инде, Кубрат хан миңа җәйләү, мал бирәм дип ышандырды.

— Кубрат хан сүзендә торыр, Денис.

— Алай да мин, буйтур, князьләр белән ханнарга ышанып җитмим. Слободада мин бер кызга гашыйк булган идем. Князь шуны сизде дә, тегене бер куштанына бирeп җибәрде.

Шул вакыт ишек ачылды, бусагада Агасике пәйда булды. Төптимерче елмая, шат иде. «Базилевс эшен мактаган, күп итеп акча биргән, шуңа авызы колагына җиткән»,— дип уйлады төптимерчене бусагада күргә буйтур.

— Илчеләр,— диде авызын җыя алмыйча Агасике.— Сезне император кичке ашка чакырды. Кичерә күрегез, буйтур, тылмач сорамадым. Берсе киявем, икенчесе якын дустым дидем.

Илбарыс буйтур Агасике килеп керүгә шат иде, ул шатлыгын сиздермәскә тырышып, беравык дәшми утырды. Ике алыпны су анасы алуы, Эгинаның юеш чәчләре, Агасикенең киенгән килеш ятагында ятуы — барысы да ниндидер җеп белән Агасикегә килеп тоташа кебек иде. Шик юк, Агасике императорга җаны-тәне белән хезмәт итә.

— Мин сезне бераздан ала керермен. Җыена торыгыз, дуслар.

Шулай диде дә Агасике чыгып китте.

Илчеләр өс-башларын караштырдылар, җыендылар. Ул арада Агасике килеп керде.

— Әйдәгез, дуслар, императорны көттермик, иртәрәк барыйк.

Алдан Агасике, аңа буйтур белән койрыкчы иярделәр.

Килгән юлдан сарайга юнәлделәр. Аш бүлмәсенә килеп керүгә — бүлмә генә түгел бу, зур бер сарай иде — сәрәнче:

— Бөек Болгардан килгән Кубрат хан илчеләре Илбарыс белән Денис!— дип кычкырды.

Түргә уздылар. Озын өстәл янында императрица, аның каршына Илбарысны утырттылар. Илбарыс баш иеп кенә император һәм императрица, булган кунаклар белән исәнләшеп алды. Моны аңа укытучы

өйрәткән иде. Чынлап торган чүлмәк җамнарга эчемлекләр койдылар, кем күпме тели эчеп куйдылар.

Патшакалага китәр алдыннан Кубрат хан философны чакыртты һәм буйтур Илбарысны сарайда буласы очрашуларга өйрәтергә кушты. Илчене император сараенда үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтә-өйрәтә ике көн буена җәфаланды философ Иоанн Фасиан. Күпме түләгәндер хезмәте өчен философка Кубрат хан, әмма буйтур аңардан канәгатьләнерлек билгесе алган иде. Шуның өчен булса кирәк, буйтур табынчы күрсәткән урынга бик кыю килеп утырды. Моны, әлбәттә, император да күрми калмады, буйтурга карап елмаеп куйды. Буйтур җамны эчемлек белән тутыра барган саен аз-аз гына эчеп утырды, ә менә Денис белән бераз чатаклык килеп чыкты. Койрыкчы салган бер эчемлекне күтәреп эчеп куйды, шуңа күрәдерме, исерә төште, кыюланды, кычкырыбрак сөйләшә башлады.

Императрица Мартина Илбарыска еш кына күз сирпеп алгалады, ул кайчак аңа шундый иттереп үз итеп карады ки, буйтур ни кылырга белми күзләрен түбән төшерде. Мәҗлескә императрица тагы да матуррак киенеп килгән иде. Аны беренче тапкыр күргәч тә буйтур бу хатындагы чибәрлеккә таң калган иде, кич белән исә императрица тагы да чибәрләнә төшкән кебек күренде. «Менә кемнән карап язган икән иконаларын патрикий Симеон»,— дип уйланып утырды буйтур. Чиркәүгә кергән бер болгарга нәкъ менә патрикий Симеон бушлай тәре бирде, Мәрьям ана сурәте дип иконалар өләште. Имештер, әнә шул иконаны почмакка шәм яндырып куйсаң, аңардан һәрдаим игелек сорасаң, бар кайгы-хәсрәтләрең җиргә сибелгән бөртекләр кебек коела да бетә икән. «Әллә соң императрица белән ханша әнә шул Мәрьям анадан туганнармы? Нигә алар бер-берсенә охшаганнар...»

Император тамак кырды, барысы да шым булдылар. Императорның кулында алтын җам. Аңа карап барысы да җамнарын күтәрделәр.

— Мәҗлес күркәмнәре, дусларым, бирелә безнең мәҗлестә патрикий Кубрат хан илчесе Илбарыс буйтур һәм аның тылмачы утыралар. Илчедән мин канәгать.— Император хатыны Мартинага карап алды, тегесе аны куәтләп ияк какты.— Якын дустым патрикий Кубрат хан һәм аның илчесе Илбарыс буйтур исәнлегенә күтәрик шушы җамнарны!

«Кубрат хан исәнлегенә!— дип эчеп куйды буйтур Дениска гына ишетелерлек итеп.— Ишетәсеңме, Денис. Кубрат хан исәнлегенә дим, әчәбез».

— Әйе, әйе, буйтур.

Румда ясалган эчемлекне яратып бетерми иде буйтур, күп эчмәде. Сабый чактан ук җәйләү ыстаннарында кымыз, үлән төнәтмәләре, яу чаба башлагач кына әче бал эчкәләгән Илбарыска грек эчемлеге ошамый, ул аның сарусын кайната, башын авырттыра иде. Аның каравы «тылмач» Денисның күзләре тона башлаган иде инде. Аш караучылар беркемне дә кыстамыйлар, алга китергән бер нәрсәне — ашаганмы ул аны, ашамаганмы — бераз тоталар да алып китәләр, аның урынына икенче ризык китерә торалар. Нигъмәтләр китерү император алдында торган ризыкларга карап эшләнә иде. Император бик аз ашады, китергән бер ризыктан бер-ике генә капты да сөйләвен дәвам итте.

Император янә җамын күтәрде.

— Бу җамны, кунаклар хөрмәтенә күтәрик, кадерлеләрем! Хөрмәтле илче Илбарыс буйтур, скифның Болгары борын-борын заманнан ук империянең зур терәге булып торды. Моннан соң да шулай булыр. Кубрат ханның империягә бал, тире, балавыз, балык җиме җибәреп торуын хуплыйм. Боерыгым куәтләп әйтәсем килә, илче Илбарыс, Болгарга дигән кораллар корабыгызга төяделәр дә инде. Калган икесе бүген кич белән Фанәгүргә кузгалдылар. Империя үзенең дусларына

хыянәт итмәс. Кубрат ханга хыянәт иткән грек ил дошманы итеп хөкемгә тартылачак...

Император сөйләде, Илбарыс аңа карап торды һәм уйланды. Күп калганмы императорга яшәргә? Юктыр. Маңгаен җыерчыклар баскан, күз төпләрендә капчыклар, йөзендә сары күләгәләр биешә.

Мәҗлес барган арада Агасике каядыр юкка чыкты. Ләкин Илбарыс буйтур моңа игътибар итмәскә тырышты. Үз йомышы белән йөридер. Теләсә-теләмәсә дә буйтурның күзләре императрицага тартылды. Буйтур шат иде. Укытучысына ул барысын да түкми-чәчми сөйләр. Сөйләми мөмкинме! Әле булса чибәр икән бит кайчандыр ул гашыйк булган Мартина, әле булса ул Константинны онытмаган — хат язды. Хат аның түшендә, буйтур аны иң кадерле бүләге итеп саклар һәм укытучысына тапшырыр. «Укытучым, мин аңа синең күзләрең белән карыйм, син караган күзләр белән. Кайчандыр син аңа, бәлкем, менә шул аш бүлмәсендә шигырьләреңне укыгансыңдыр, ул сине әсәрләнеп тыңлагандыр...»

Мәҗлестән соң шул ук Дариан аларны бүлмәләренә кадәр озата килде, шулай ук күкрәгенә кулын куеп, саубуллашып, тыныч йокы теләп чыгып китте.

• • •

Иртән ашарга китерделәр. Ашап-эчкәч алар янына Агасике килеп керде. Денисны буйтур корабка җибәрде, үзе Агасике белән китте. Император аңа илчене китапханәләрдә йөртергә кушкан икән. Агасике бик аз сөйләде, каядыр ашыкты, кабаланды, әйтерсең аны кемдер ашыктыра иде. Менә алар белем сараена килеп керделәр. Биредә китаплар шул хәтле күп иде ки, буйтур һәрбер киштә янында тукталып-тукталып торгалады. Кубрат хан да үзенә күрә белем сарае салдырды, әмма моның янында ул бик кечкенә булыр иде. Кичә беренче тапкыр сарайга килеп кергәч тә аны сәер бер хис биләп алган иде, бу хис белем сараена керүгә янә кабатланды, янә ул үзен тузан бөртеге кебек кенә сизә башлады. Киштәләр түшәмгә хәтле куелган. Һәр киштәдә йөзләрчә китап. Тоташ карадан киенгән ак сакаллы белемче, буйтур янына килеп, бил бөгеп исәнләште.

Кәҗә сакаллы белемче, чандыр гәүдәсен салмак кына йөртеп, буйтурның һәр теләген үтәргә әзер булуын сиздереп тора иде.

Буйтур белемчедән Кубрат ханның улы турында сорады.

— Кубрат хан улы Александр биредә,— диде белемче.— Ул китаплар күчереп яза.

Каршы алу тантанасыннан соң Аслан юкка чыкты. Нигә килмәде ул алар янына? Бит туган илдән кардәшләре килгән. Асланның кисәк юкка чыгуы, бүген дә күренмәве сәер иде, әмма Александр монда дигәч, буйтур аны чакырырга кушты. «Бик яшьли алып киттеләр илханны Патшакалага, бизүе шулмы»,— дип уйлады буйтур кичәге хәлне исенә төшереп.

Шул чак белемче карт тузан сөртеп йөрүче бераүгә Асланны чакырырга кушты. Аслан көтмәгәндә түр ишектән килеп керде. Керде дә оялa-тартына гына буйтурга таба килә башлады. Килеп җитте, кулын сузды. Асланның кулы каз мамыгыдай йомшак иде. Укытучының: «Кылыч тотар кулларда — язар каурыйлар»,— дигән шигырь юллары исенә төште буйтурның.

— Кардәшем-туганым, саумы?!

— Барысы да тәңре кодрәтендә, Аслан ихлан. Барыбыз да тәңре кулында.— Аслан тиз-тиз чукынып алды.— Син нәрсә, туганый, әллә христиан динен кабул иттеңме?

— Әйтмә алай, Илбарыс туган, әйтмә. Минем өчен тәңре юк, ул минем өчен үлде. Мин христиан алласын кабул иттем.

— Ихтыярың, илхан. Алай да әйт әле, Аслан, атаң-анаң, апаң Чәчкәне, өлкән абаларыңны сагынасыңмы?

— Тиздән Чәчкә бирегә килер. Юстиниан император углы сарациннар белән орышта. Ул тиздән кайтыр, Болгарга барып Чәчкәне алыр. Миңа аның белән күңелсез булмас, туганым Илбарыс.— Аслан сагыш тулы күзләрен буйтурдан яшерергә теләп, читкә карады.— Константин укытучы исәнме, миннән күп сәлам җиткер аңа.

— Исән-сау, ул һаман сарай мәктәбендә укыта.

Яшенә күрә түгел иде Аслан, артык аек фикер сөрә иде. Илханны кызганудан Илбарыс ни кылырга белмәде, беләгеннән кысып тотты.

— Телисеңме, Аслан, мин сине илгә алып китәм. Ә?! Телисеңме?! Император сине җибәрер, ул мине аңлар. Болгар балаларын укытырсың?

— Алладан курык, Илбарыс туган. Ни сөйлисең син!— Аслан күзләрен түшәмдәге сурәтләргә текәп, чукынып алды.— Хода бу сүзләрең өчен сине мәңге гафу итмәс.

Алар янына белемче карт килде.

— Александр,— диде ул грекчалап.— Александр, менә бу китапны бишенче киштәгә илтеп куй әле.

Аслан карусыз гына китапны киштәгә илтеп куйды.

— Аслан туган, ничек ул сиңа боера? Илханмы син?!

— Христиан динен кабул иткән һәммә зат изге китапны кулына алуга горурланырга тиеш, Илбарыс туган. Мин...

Буйтур түзмәде, Асланны кочагына алды, күзенә яшь йөгерүен яшермичә:

— Аслан, Аслан, нишләттеләр сине, нишләттеләр?..

— Җитте,— диде моңа кадәр дәшми торган карт белемче.— Җитте, Александр. Варварга китәргә вакыт.

Буйтур акырын гына аңа таба борылды һәм шундый иттереп карады, карт корт чаккандай читкә тайпылып куйды, әмма урынында калды.

— Әй син, сарай корты, варвар түгел мин, Бөек Болгарның Кубрат хан илчесе. Ә бу углан Болгар халкының илханы. Ишетәсеңме, соры корт, илханы!

Илбарыс кызарынып, теш арасыннан ыслап әйтүгә, кара киемле белемче башына чикмән башлыгын ташлады һәм күзләрен түшәмгә төбәп чукынып алды. Аннары:

— Еретик,— диде.— Мондыйларны Византиядә утта яндыралар.

— Утта яндыралар. Мин монда олуг вазифа белән килдем. Илче булып килдем. Ишетәсеңме, Бөек Болгар иленнән илче булып. Их, очратасы иде сине киң далада, күрсәтер идем мин сиңа варварны.

— Кызма, тыел, буйтур.— Аслан аны тынычландырырга теләде.— Ул әйбәт кеше, орышма аны, ходай каргар үзеңне. Кызган аны, аның дине-өне башка.

— Орып атам мин аның динен. Күктә — тәңре, ә аның дине миңа...

Аслан кисәк Илбарыс алдына тезләнде.

— Әйтмә алай, Илбарыс туганым!

Илбарыс аны күтәреп аягына бастырды. Юашланып калган Асланның күзләрендә яшь елтырый иде.

— Аслан илхан, синең монда китүеңә атаң гаепләме?

— Әйтмә атама сүз, буйтур... Анамны сагынам, апам Чәчкәне, даламны...

— Мин сине императордан сорап алып китәм, Аслан. Ул сине җибәрер. Бүген үк, хәзер үк...

Аслан куркынып артка чикте, калтыранган кулы белән чукынып алды.

— Аллаһы-тәгаләдән өстен булып булмый, буйтур, сорама, мин үзем теләмим...

— Үзең теләмисең?!. Теләрсең... Мин болай итәм: башта мин синең муенына таккан тавык тәпиеңне өзеп ташлыйм.

Бу юлы Аслан тәпен-тәпен артка чикте, шуны гына көткән кебек, кара чикмән алар арасына килеп керде.

Кай тарафтандыр Агасике килеп чыкты, кара чикмәнгә баш иде, картның учына бер алтын салды.

— Кичер аны, Август, зинһар кичер. Хода хакы өчен кичер. Аның дине-өне башка...

Кара чикмән учына салган алтынны кысты, борылып китеп барды, ул үзе белән юл өстендә аптырап басып торган Асланны да җиңеннән эләктереп алды.

— Нигә аңа тикторганда алтын бирдең, Агасике?

— Христиан булган һәр кеше чиркәүгә сәдака бирә, буйтур.

— Мин чиркәүдәмени?

— Син изге София чиркәвенең китапханәсендә, буйтур.

— Синдә алтын шулай күпмени, Агасике?

— Юк-к, буйтур, бик аз. Алтыным күп булса икән минем!

— Алтының аз булгач, нигә,— буйтур Аслан белән белемче киткән якка ияк какты,— алтын бирдең?

Агасике дәшмәде, иңбашын гына сикертеп куйды, аннары буйтурны култыклап, изге йорттан алып чыгып китте. Бары тик корабка җитәрәк кенә ул:

— Сәдака бирү гадәткә кергән бездә, алла кабул итсен,— диде. Буйтур дәшмәгәч, өстәде:— Сездә болгарлар әнә кешеләрне бөтен корал-җиһазлары белән күмәләр. Ул байлык җир астында чери. Мин биргән алтын кешегә исән чакта ук игелек китерә. Без икебез ике аллага хезмәт итәбез, буйтур. Алтын ул — исән кешегә байлык, мул тормыш, иминлек. Базилевс тынычлыкны күп вакытта алтынга сатып ала.

— Минем йомышым башкарсаң, Агасике мин сиңа күп итеп алтын бирер идем.

Кораб туктаган порт капкасына җиттеләр, ике якта да сәдакага, хәергә сузылган куллар.

— Ни сорыйлар алар, Агасике?

— Хәер сорыйлар, буйтур.

— Ни ул хәер сорашу?

— Хәер сорашу ачлык галәмәте, буйтур.

— Моңа кем гаепле соң? Изге Гайсәме?.. Тәңрегә табынган кеше хәер сорашуның ни икәнен белми, Агасике.

Агасике як-ягына каранып алды.

— Әйтмә алай, буйтур. Патшакаладагы хәерченең дә император шымчысы булуы бар.

Буйтурның: «Кубрат хан да кимен куймый»,— дип әйтәсе килгән иде, әмма дәшмәде, чит илдә үз ханын, җитмәсә, атасы кебек күргән ханны хурлыйсы килмәде.

— Агасике, син минем йомышымны үтәсәң, мин сиңа үз гомереңә җитәрлек алтын бирер идем,— дип кабатлады баягы сүзен буйтур.

Агасике янә як-ягына каранып алды.

Алар корабка таба баралар, бертуктаусыз очрап торган сарай алыплары Агасике белән баш кагып исәнләшеп калалар иде. Диңгез буендагы балыкчылар казан асканнар, аш пешерәләр, шул якта җырлаган авазлар ишетелә.

— Мин синең, буйтур, Фанагүрдә үк нә йомыш белән Патшакалага килүең чамалаган идем.

— Мең алтын азмы, Агасике.

— Йомышына күрә аз да, күп тә, буйтур.

— Ике мең.

— Кубрат ханга грек утының сере кирәк. Шулаймы, буйтур?

— Кемгә ул утның сере кирәкми, Агасике, кайсы илгә?..

— Анысы хак, һәр ил ут серен кулына төшерергә тырыша. Мәгәр әлеге утны ясау серен шул хәтле нык саклыйлар греклар, буйтур... Ялгышмадым, сөрәеп карамагыз, мыскал да ялгышмадым... Кызганычка каршы, кем ул утның сере белән кызыксына, икенче көнне үк башы диңгезгә оча. Грек утының серен бер император гына сакламый, буйтур.

— Ничек эшлисең бит, Агасике. Сарык та исән калып, бүре дә тук булса ничек?..

— Бер башка ике мең алтын!— диде Агасике гаҗәпләнүен яшермичә.

— Әйе, төптимерче, ике мең алтын.

— Буйтур,— диде Агасике тавышын баса төшеп.— Буйтур, минем Кубрат ханга да, сиңа да хөрмәтем зур. Әмма миндә ике баш түгел, бер генә баш.

— Шуның өчен мин синең бер башыңа ике мең алтын бирәм дә бит, Агасике.

— Ут сере, ут сере. Башта бер уй туып килә-килүен.— Шунда грек Агасике бер картны күреп алды:— Симокатта!

Чал чәчле, көрәк сакаллы, кирәкмәгән зур башлы, уртача буйлы, бөкересен турайтырга теләп, таякка таянган карт борылып Агасикегә карады.

— Агасике бит, үзе,— диде карт.— Шул үзе. Исән! Саумы, император көчеге!

— Симокатта, хәерең шулмы?

— А-а,— дип кул селтәде карт.— Кем бу? Синең яныңдагы кеше кем дим?

— Болгар илчесе, скифиядән, Саклаб угланы Илбарыс.

— Болгар илчесе?! Скифиядән?!— дип кызыксынып кайтарып сорады Симокатта карт.— Әй, илче, минем онытым беләсеңме?

— Беләм, аксакал,— диде Буйтур саф грек телендә.

Картның гаҗәпләнүе чиктән ашты.

— Варвар грекча белә, Агасике!

— Сарай мәктәбендә укыган болгарлар барысы да белә, Симокатта. Бу илче Кубрат ханның асрауга алган оланы.

— Оһо,— диде карт тагы да гаҗәпләнә калып, кулындагы таягын дык-дык таш юлга дөңки-дөңки Илбарыс тирәли әйләнеп чыкты.— Бу адәм бөтенләй варварга охшамаган. Әйтәм аны Болгар скифләрен мактыйлар. Ханнары гадел икән, коллар сатмый, килгән кешегә җир бирә. Феофан миңа онытым Константин турында бернәрсә сөйләми. Алып калдымы хан, үзе калдырдымы... император сөрдеме?.. Сөрүе дә бик мөмкин. Мартинасын ярата иде. Һәй, заманасын әйтсәм әйтим... Сарациннар әнә дәүләт арты дәүләт яулыйлар, Феофанның гарәплардән кайтканы да юк, ике алланы бер итәргә йөри... Константин Мартинага хат артыннан хат яза диләр. Хакмы икән шул, сәүдәгәрләр гайбәте генәмедер... Византия сәүдәгәрләренә ышансаң, башыңда чәчең калмас.— Карт болгарларның корабына карап ым какты.— Аларныкымы, Агасике?..

— Ут серен шушы карт белә, гомере буена император алачыгында эшләде,— диде Агасике буйтурның колагына.

Илбарыс буйтур картка түбәнчелек белән баш иде.

— Әдәпле илче,— дип сөйләнде карт, гүя ул коллар базарында иде.

— Аксакал,— диде Илбарыс,— онытың Константинга ни әйтим?

— Ни әйтәсең? Иленә кайтсын! Бабаң көтә диген. Якты дөньядан китәргә күп калмаган инде үзенә диген. Кайтсын, фатихам алып калсын, булган байлыгым. Атасы Феофанга калдырасым килми, череп баеды.

— Мин синең сүзләреңне җиткерермен, аксакал.

— Кем? Нинди сүз ул тагын?

— Болгарлар олы кешегә акыл иясе — аксакал, диләр,— дип аңлатты картка Агасике.

— Аксакал,— дип сакалын сыпырып куйды карт.— Аксакал. Матур сүз, хөрмәткә лаек сүз.

Алар тирәсендә ике кеше йөренә, Агасике аларны күрде дә карттан:

— Сине сагалыйлармы?— дип сорады.

— Мине. Мине булмый кемне булсын,— диде карт.— Скиф онygы әйтмешли, бу аксакал император алачыгында бөкересен аз чыгармады шул. Мин иблисне ут серен сатып җибәрмәгәе дип куркалар. Күзәтәләр.

— Симокатта, син бик картайгансың.

— Ярты гомерең император алачыгында эшләп кара әле син. Аннан соң миннән килеп сорарсың. Йөриләр бит ачуым китереп сатлык җаннар. Ничә ел инде шул ике көчек мине күзәтә. Ут серен сатмасын, имеш. Башым икеме әллә минем. Әйттем исә иртәгә үк башым диңгезгә очачак. Әллә соң бу скиф онygына да ут сере кирәкме?

— Аңа да кирәк ут сере, Симокатта.

Карт уч төбенә йөткереп, елмайды.

— Ут сере хәзер бөтен дөньяга кирәк. Илләмәгәр аның серен саткан өчен император мине генә түгел, бөтен ыру-туганымны юк итәчәк. Императорның кулы озын, Болгарга да җитә аның кулы. Фанәгүргә барып Константинның башын кистерер, һич булмас димә. Юк, Агасике, грек утының сере Византиядә туган, Византиядә калыр да,— дип Симокатта карт таягы белән дөк-дөк таш юлны төйде.

— Аксакал, мин синең белән саубуллашмыйм,— диде Илбарыс, кузгала башлап.— Язмыш безне тагын очраштырыр әле.

— Акыллы сөйләшә бу скиф онygы. Рәхмәт сиңа, илче. Мең рәхмәт. Кешегә хода бары тик бер муен биргән шул. Константин онygыма бабаңны күрдем диген.

— Онygың мине мәктәптә укытты, аксакал.

— Сине? Минем онygым Константин?!— дип гаҗәпләнде янә бер тапкыр карт.— Болгарда мәктәпләр бар?!

— Бар, Симокатта, бар. Язулары да бар, язар әйберләре дә бар,— диде Агасике.— Үз күзләрем белән күрдем.

— Скиф болгары беркайчан да империягә каршы булмады, баш та бирмәде. Тарих атасы Геродот ни дигән, бер скиф алыбы орышта өч персиянга, ике грекка тора дигән... Ә син миңа нә бирәсең, скиф онygы?.. Бир Симокатта картка ике алтын! Нигә дип сорама. Әнә күрәсеңме император көчекләрен, күрәсеңме дим?.. Күрсәң шул, бир миңа ике алтын, әнә шул көчекләргә ташлыйм. Кулларына алтын керү белән, әйтте диярсең, табаннарын ялтыратачаклар.

Илбарыс янчыгыннан чыгарып, Симокатта карт учына ике алтын салды.

— Аллага синең өчен гыйбадәт кылырмын, скиф онygы. Ошадың син миңа.— Карт Агасикегә карамый гына аның ягына таягы белән төртә-төртә:— Ә бу сарай көчегенә ышанма син, скиф онygы. Әйе, әйе, бу да император көчеге, олырагы, зуррагы, тәҗрибәлерәге. Болгарда нишләп ятты дип беләсең син аны! Һә, тимерче, имеш. Византиядә һәр уныгчы кеше тимерче, тукучы яки игенче. Алар янына бер кәтү уенчы. Соңгылары ипподромда Агасике кебек куштаннарның күңелләрен күрәләр.

— Симокатта, әллә син исерекме?

— Исерек, Агасике, эчтем. Онygым укыткан скифны күрүгә исерекмен. Их, яшьлектәге гайрәтем булса икән ул, утырып идем дә китәр идем онygым янына. Син миңа ачуланма тагын, Агасике. Онygым Константинны сагындым, бик сагындым. Ышан, мин аны атасыннан да ныграк яратам. Билләһи, китәр идем. Кая, җибәрәме соң император. Сизә-

нитә калса, Болгарга кадәр кудыртыр.. Ни өченме?.. Сорап тора бит әле... Симокатта карт егерме елдан артык гомерен император алачыгында грек утын ясап уздырды. Җелегем суырды ут ул минем, җелегем...

— Китик,— диде Агасике буйтурга.— Бу картның эше беткән. Чит илләрдән килгән кораблар янында тик уралып гомерен уздыра. Ник дип сорама, әнә бирдең бит әле, акмаса да тама.

— Нигә курка ул императордан, Агасике?

— Ишетмәдеңмени. Карт император алачыгында эшләгән, грек утының серен белә. Гадәттә аннан кеше исән чыкмый. Бу әнә чыккан, исән-сау, чөнки улы Феофан императорның иң якын илчесе.

Алар кораб янына җиттеләр, баскычтан менә башладылар.

— Агасике,— диде буйтур басмада туктап.— Агасике, ярдәм ит миңа, җибәр картны миңа биреп, ә?.. Алтын кызганмам, син мине беләсең...

— Беләм-белүен... Алай да күпме бирер идең?..

— Әйткәнемчә, ике мең алтын, Агасике.

— Ике мең. Ярый килештек. Эше авыр, буйтур. Үзең беләсең, мин бу карт урынына берәүне үтерергә, аның киемнәренә киендерергә һәм билгелерәк җиргә ташларга тиешмен. Симокатта карт икәненә кешеләр ышанырга тиеш. Исемен карт җуяр, исемен-атын җуймаса, император аны кая китсә дә эзләп табар.

— Аты Симай булыр. Болгарда Симай исеме белән йөрер.

— Тукта, ашыкма. Үзе риза булырмы соң?.. Бармыйм дисә?! Килешмәсә?.. Оныгы өчен риза булса гына инде. Константин аның чынлап та бердәнбер оныгы.

— Агасике, инде килештекме, ике мең алтын?

— Килештек, буйтур. Миңа бу эш җиңел булмас-булуын.

— Симокатта картны мин кич белән көтәм, кояш баегач.

— Юк, иртәнгә, буйтур. Таң атар-атмас Симокатта карт корабта булыр. Бурычың әзерләп куй.

— Агасике, син әйбәт кеше.

— Юк, буйтур, мин начар кеше. Әйбәт кеше ил серен сатмый.

— Картның ул ут серен белмәве дә бар,— диде буйтур, Агасикенең сүзләренә игътибар итмәскә тырышып.

— Грек утын ул карт сукыр көйгә дә ясаячак. Ышан Агасикегә.

Агасике басмадан чыкты да китеп барды. Кияве белән кызының хәлен белмәве буйтурны бераз сәерсендерде сәерсендерүен, илла киләчәк бит әле, ул картны китерәчәк. Эгинаны атасы да, анасы да җибәрмәскә иткәннәр икән, әмма хатын, имеш, качып киткән. Шулай дигән булды Агасике.

Корабка менеп басуга, Илбарыс буйтурны ишкәкче коллар уратып алдылар. Шаулашалар, нидер таләп итәләр. Буйтур кулын күтәрде.

— Кешеләр, сез ирекле. Каравылбаш Камай, һәр кешегә ике алтын акча бир. Ирек аларга! Хәзер үк корабтан чыгып китсеннәр! Моны сезгә Кубрат хан буйтуры Илбарыс әйтте.

Буйтурдан шул сүзне ишетүгә, коллар аның алдына тезләнделәр. Бу тәүлек арасында алар бик күп гыйбрәтле нәрсәләр күргәннәр икән. Империядә аларны янәдән кол итәчәкләр, шуның өчен кире Болгарга, шунда ирек алырга исәплиләр икән.

Илбарыс буйтур һични аңламады. Коллар юл буена аңардан ирек дауладылар, ә монда янәдән ишкәккә утырырга ризалар.

— Ярый,— диде буйтур, колларның үтенечләрен тыңлап бетергәч.— Мин риза, калыгыз.

Коллар яңадан шаулаша башладылар.

— Тагын ни?— дип сорады китә башлаган буйтур.

— Буйтур, алар синнән вәгъдә иткән алтынны сорыйлар,— диде Камай.

— Бирегез!— дип боерды буйтур.

Денис килеп чыкты, буйтурның иңенә кулын салды.
— Иртәгә таң белән кузгалабыз, буйтур. Кайната кызы Эгина белән дә саубуллашмады. Эгинаны җибәрмәскә иткәннәр...
— Әйтте ул миңа Эгина турында,— диде буйтур.— Гафу ит мине, Денис. Мин синең хатыныңның Эгинага ышанып җитмим. Аның исемен ишеттемме, күз алдыма теге төн килә.
— Буйтур, Эгина андый түгел. Эгина ул төнлә чәчен юып яткан булган.
Буйтур җилкәсен сикертеп алды, шунда ул корабка таба килүче кызыл чапан кигән Дарианны күрде. Күрде дә басмага таба китте. Дарианны шунда каршы алды.
— Болгар илчесе, Илбарыс. Сине император дәшә. Миңа сине сарайга китереп җиткерергә боерылды.
Буйтурның ике ягына ике алып килеп басты.
— Хәзер үкме, Дариан?
— Хәзер үк, Илбарыс буйтур. Һәм үзегез генә.
— Мин тылмач, мин барам буйтур белән,— диде Денис.
— Юк, Денис, каласың. Император минем үземне генә дәшкән.
Буйтур юл буена уйланып барды. Нигә чакырыр икән император?.. Әллә соң ул-бу сизенүеме?.. Агасике — шымчы. Бернинди Симокатта карт та юк, уенчы, шымчы уенчы, мине тотар өчен эшләгәннәр...
Император аны беренче көнне каршылаган кебек үк ачык йөз белән кабул итте. Янәшәсендә элеккечә императрица Мартина утыра. Бүген императрица башында таҗ түгел, бизәкләп бәйләнгән матур калфак иде, утыртма якасына энҗеләр тезелгән, билләп тегелгән алсу күлмәге күзне камаштырыр сыман. Илче килеп басуга, императрицаның куе күксел-кара күзләре буйтурга төбәлде.
Тәхеткә җитәр-җитмәс буйтур баш орды, киредән басты да императрица Мартинага бил бөкте.
— Якынрак кил, Илбарыс буйтур, якынрак,— диде император.
Император янындагы кеше алтын чылбырдан ясалган китап тотып тора иде.
— Илче буйтур, минем Кубрат ханга хөрмәтем гаять зурдыр, мин аңа Рум тарихын бүләк итәргә булдым.
— Галиҗанәпләре император Ираклийга, гүзәлләрнең гүзәле императрица Мартинага рәхмәтем чиксездер.
Императрица сабыр-тыйнак кына елмайды, император ягына сирпелеп алды һәм буйтурга үбәргә кулын сузды.
— Без сине яратып та өлгергән идек инде.
Буйтур укытучы өйрәткәнчә Мартинаның кул аркасыннан үпте. Императрицаның кулларыннан хуш исләр килә, бармакларындагы йөзек-мәрҗәннәрдән күз чагыла иде.
— Илче,— диде император.— Патрикий Кубрат ханга әйтәсе сүзем шул булыр: олуг хан философ Иоанн Фасианны Патшакалага кайтарып җибәрсен, Феофан улы Константин калып торыр.— Император кырын күзе белән генә хатыны Мартина ягына карап алды.— Константин болгар балаларын укыта икән, укыта бирсен. Патрикий Симеонны да логофет кайтармаска кушты. Алла ярлыкасын...
Буйтур баш иде, аннары алга бер адым ясады:
— Галиҗанәпләре Бөек Румның бөек императоры изге Константин улы Ираклий, инде минем үтенечем тыңлагыз: хан улы Аслан илгә кайту теләген белдерде...
Император белән императрица бер-берсенә карашып алдылар.
— Александрга Фанагүргә кайтырга иртәрәк әле, илче. Хуш!
Менә шул, бары тик шул. Император янадан аның белән сөйләшмәячәк. Император илче белән эше һәм сүзе бетүен аңлатып, китап

тоткан адәмгә карады, императрица исә урыныннан кузгалды, буйтур янына килде.

— Мин сиңа, илче, тагын бер тапкыр рәхмәт әйтәм.— Бу юлы императрица үбәргә дип кулын сузмады, аналарга хас итагатьлелек белән буйтурның маңгаеннан үпте һәм пышылдарга өлгерде. «Мин аны онытмадым, илче»,— диде. Аннары императрица кулына китапны алды, буйтурга бирде.

— Күз караң кебек сакла. Бөтен Рум тарихы. Олуг хан Кубратка бүләге... Хуш, ак юл сиңа, хөрмәтле илче.

Буйтур, китапны ике кулына тоткан килеш борылып, ишекләргә таба китте. Аны берәү дә туктатмады, аңа берәү дә дәшмәде. Буйтур йөгерә-атлый баскычлардан төште, әмма артына әйләнеп карарга кыймады. Порт капкаларын керүгә, ул үзенә таба килүче каравылбаш Камайны күрде.

— Буйтур, без борчыла башладык...

— Азык-төлек, су ал, каравылбаш Камай. Иртәгә таң белән кузгалабыз.

Төн бик акрын узды, күзгә йокы кермәде. Агасике сүзендә торырмы? Император аны Симокатта карт өчен чакырмаган. Димәк, Агасикенең чынлап та картны алып килүе бар. Буйтур торды, сәке астыннан сандыкны тартып чыгарды. Ачты һәм ике мең алтынны санап, күн капчыкка койды, әйбәтләп бавын бәйләп куйды. Грек уты серен алып кайта алса, Кубрат хан ни кылыр? Ни сорасаң, буйтур, шуны бирәм дисә?.. Ул Чәчкәне сорар... Хан биргән вәгъдәсеннән ваз кичәрме?.. Чәчкә дә әйтер, мин атам, буйтурны яратам, дияр. Әйтер, йөрәккә йозак салып булмый.

Азык-төлек алынды, мичкәләр белән су кертелде. Камай һәр мичкәгә көмеш акча ташлап чыкты. Көмеш булганда су тиз генә сөрсеми, моны сәфәр чыккан һәркем белә, болгарлар су мичкәләренә һәрчак көмеш ташлыйлар иде.

Буйтур бүлмәсеннән чыкты, өске катта йөренә башлады. Каравыл алыплар арлы-бирле йөреп торалар, ә яр буенда беркем дә күренми. Кисәк җил чыкты, дулкыннар йөгерешә башлады, буйтур яр буеннан күзен дә алмады. Нигә озак бу Агасике?.. Бик вакыт инде. Тиздән таң атыр. Әнә ата да инде.

Чынлап та, җил белән бергә көнчыгыш тарафта күк гөмбәзенә кояш нурлары үрләде.

Агасикегә дә җиңел түгелдер. Симокатта картны канауга төшеп үлде дип ышандырыр өчен аңа чынлап та картка охшаган берәүне үтерергә туры киләчәк. Портка төнлә керү өчен һәрбер сакчыга уч тутырып димәсәң дә алтын бирергә тиеш булачак. Барысы уңай чыккан хәлдә дә Симокатта карт исемен алыштырырга риза булырмы?.. Агасике риза булыр, диде. Риза булгач, нигә һаман юклар...

Таң да атты. Күк гөмбәзенә таба көлтә-көлтә кояш нурлары сузылды. Яр буена берәү дә килмәде.

Буйтур янына Денис килеп басты.

— Буйтур нигәдер йоклый алмый?..

— Йокы алмый шул, Денис. Ә син нигә йокламыйсың?..

— Эч поша, буйтур. Карале, буйтур, минем кайнатам теге картны биреп җибәрү өчен чынлап та берәрсен үтерергә тиешме?

— Денис, нигә аңа кеше үтереп торырга. Патшакалада көненә меңләгән кеше үләдер... Аннары нинди үтерү ди ул, кем әйтте сиңа?

— Эгина әйтте, буйтур, мин барысын да беләм.

Эгина бүлмәдән бер тапкыр да чыкмады, каян белә ул атасының кемне булса да үтерергә тиешлеге турында?.. Юк, монда нәрсәдер бар... Иә Эгина чынлап та сихерче, йә кияве Денис Агасике белән бәйле...

— Әнә алар, киләләр!

Денис изүен ачып перун алласын чыгарды, нидер пышылдады да яңадан яшерде.

— Тәңрем,— диде буйтур таң атып килгән якка карап.— Тәңрем, ярдәмеңнән ташлама, игелекле ит туасы көнең...

Агасике белән карт бер дә ашыкмыйлар кебек, әмма бу көтеп торучыларга гына шулай тоела иде, чынында исә Агасике белән карт йөгерә-атлый корабка таба киләләр. Буйтур корабны кузгалырга хәзерләргә боерды, корабта ыгы-зыгы, шау-шу купты.

Буйтур янына каравылбаш Камай йөгереп килде.

— Ягирләрне дә күтәрикме, буйтур.

— Күтәрегез!

Агасике басмадан йөгереп үк менде, картны алдан уздырды һәм буйтур кулыннан кун капчыкны алды.

— Сау бул, картлач,— диде ул Симокатта картка.— Бәхетле бул. Онытың күрергә язсын. Аллаһы-тәгалә ярлыка күрсен...

— Сау бул, Агасике. Патшакалада калма, кая да булса күчеп кит. Алла сакласын...

Симокатта карт Агасикегә кул болгады һәм корабка керде, чукынып алды. Шуннан соң гына:

— Буйтур, шушы мизгелдән мин Симокатта түгел, мин Симай карт,— диде.— Күрсәт миңа бүлмәмне.

— Төкле аягың белән, хөрмәтле Симай ата!

— Ә-ә, игелекле бул. Күрәм, оныгым тәрбиясе. Варвар кем ул? Варвар шул ук кеше, башка телдә сөйләшә торган кеше. Греклар үзләре аңламаган телдә сөйләшкән кешеләрнең барысын да варварлар дип атыйлар. Бер дә акыллы сүз түгел. Симай ата. Матур исемдер бит. Миңа ошый, кыска, әйтергә җиңел.

Буйтур Симай атаны бүлмәсенә кертеп җибәрде, үзе өске катка күтәрелде, яр башында кул болгап калган Агасикегә кул изәде. Кораб ашыга-ашыга диңгезгә чыкты һәм Фанәгүр ягына юнәлеш алды.

«Тәңрем бар соң икән әле»,— дип эченнән сөйләнде буйтур Агасикенең кичерәйгәннән-кичерәя барган гәүдәсенә карап. Төптимерче муенындагы кызыл тукыманы ул бик озак күрде. Ниһаять, барысы да күздән язды, иртәннән бирле ныклап исә башлаган җил, ачык диңгезгә чыгуга, очыртып алып китәргә теләгәндәй корабны алга әйдәде. Корабның йөреше, җилкәннәрнең киерелеше буйтурның күңел киеренкелегенә тәңгәл килә иде.

Яр буйлары күздән язгач кына, буйтур Симай ата бүлмәсенә керде. Бүлмәгә кергәч тә чукына башлаган карт, кораб җилле генә йөзеп киткәч, тынычланган, сәкегә менеп яткан, күзләрен йомган килеш нидер үзалдына сөйләнеп ята иде.

Илбарыс буйтур сак кына ишекне япты, әйдә йокласын, ял итсен, төн буена чаба-чаба арыгандыр.

Офык читенә таба дулкыннар йөгерешә, кып-кызыл калканны хәтерләтеп зәңгәр диңгез читеннән кояш чыгып килә иде.

* * *

Херсонеска җитәрәк Илбарыс буйтурны өскә дәшеп алдылар. Кара аләм кадаган корабны беренче булып күргән койрыкчы Денис:

— Хәзәрләр!— дип кычкыра иде.

Илбарыс буйтурның каган әләмен күргәне юк иде әле, кызыксынып карап торды. Әлек хәзәрләр Понте[1] диңгезендә болай иркенләп йөрмә-

[1] Понте — Кара диңгез.

гәннәр, греклар җай бирмәгән. Хәзер әнә әләмнәр тагып йөриләр. Көчәя хәзәр. Мәгәр бу бер дә сәүдә корабына охшамаган. Димәк, хәрби кораб. Нишләп йөри монда. Византиядән кайтып киләме, ни төягән?..

Дулкыннар тагын да ярсына төштеләр, кораб ныгытмалары ыңгырашып-ыңгырашып алды.

— Хәзәрләр бик акрын баралар, буйтур. Корал төягәннәрме әллә?..

— Бик ихтимал, Денис. Симай ата әйткән иде аны...

— Бер дә исең китмәсен, буйтур, императорга кемгә корал сатса да барыбер. Коллар китергән булганнардыр, император колларга, уенчыларга туймый. Хорезмлылар хәзәрләргә, хәзәрләр румнарга, румнар дөнья каласы Римгә илтеп сата колларны. Императорның кылган эшләрен санасаң... Фанагүрдә генә йөзләгән шымчысы бардыр. Минем кайната да әнә аның шымчысы булган икән.

— Агасикегә тимә, Денис. Ул безнең өчен бик зур эш эшләде. Минемчә, император ул кылган эшне абайламыйрак калды.

— Абайлагандыр. Бер сүздәләрдер әле. Карга карганың күзен чукымый.

— Минемчә, Денис, безгә тиярга аңа императрица Мартина кушмаган. Императрица Мартина, койрыкчы Денис, минем укытучымның сөйгәне, аны яраткан өчен император укытучыны Болгарга сөргән...

— Әнә ничек икән ул... Күр әле, буйтур, хәзәрләр безгә тагылдылар.

— Тагылсыннар. Син аларны күрмә, Денис. Тиздән Херсонес.

Кич кояш баегач кына буйтур, хәлен белергә дип, Симай атаның бүлмәсенә керде. Көнозын йоклап кайткан грек карты, буйтур кергәч, сәкегә торып утырды, Илбарыска түмәрдән урын күрсәтте.

Буйтур ут алды, бүлмә эче яктырып китте.

— Хәзер безгә ашарга китерерләр, Симай ата.

— Ашау ярый. Утыр, нигә тагын бастың. Сораш, белгәнем сөйләрмен. Утыр, утырып сораш. Аяк өсте ялган, утырышкан чынын көйләр, дигәннәр. Утыр, утыр. Мин битне генә сыпырып керәм. Ул арада ашы да килер.

Карт чыгып китте, ашчылар аш китерделәр, өстәлгә кипкән ит, сыр, балык куйдылар. Симай карт та әйләнеп керде.

— Җилле барабыз, җил уңай. Тиздән Херсонеста булырбыз. Ә-ә, аш та килгән икән.— Карт кулын-кулга ышкып алды.— Әллә, мәйтәм, буйтур, аш алдыннан... кичәдән бирле тамак төбе кычытып тора.— Карт үрелеп кенә сәке астыннан чүлмәк алды, ике чокыр куйды.

— Эчемлек хәл кертер, ашау чыгарыр, ди. Христос кичерер, иншалла.— Симай карт чокырны күтәреп эчеп куйды, иткә үрелде.— Эч, буйтур. Эчемлек эчкән кеше я исәр булыр, я кусәк булыр, диләр бездә. Мәгәр мин аның хикмәтен беләм: аз эчсәң зиһен дигәнең ачыла, күп эчкәндә томалана. Сине онытым Константин укыткан икән... Килмәде аңа. Анасы бик яшьли үлде. Атасы Феофан улын гел үзе белән йөртте. Атасы бер дигән илче, мохтаҗлыкта үсмәде малай, сарай мәктәбендә белем алды, атасы илче итеп хәзерләргә иткән иде, ә ул юк, әнә шагыйрь булды. Мартинаны кем яратмас, кем гашыйк булмас ул гүзәл затка. Тартылгандыр үзенә бичара, кояшка тартылган чәчкә кебек тартылгандыр... Онытым, сине дә күрер көнем булыр микәнни!— дип, карт почмактагы Мәрьям анасына карап чукынып алды.

Ашагач-эчкәч карт янә сәкегә менеп сузылып ятты.

— Иртә таң тирәсендә Херсонеста булырбыз. Җил уңай. Аннан ике көнлек юл кала, җил уңай булганда бер көндә дә үтеп була. Белә, белә, Симай карт бу юлларны. Килгән-киткән сәүдәгәрләрдән сорашып, җаннарын ала торган идем. Фанагүргә кораблар киткәндә күземнән яшь кипмәде. Юк, ташламый аллаһы тәгалә бер дөньяга китергән баласын, ташламый, иманы саф булса ташламый. Нигә дәшмисең, буйтур?.. Со-

раш. Грек уты турында сораш. Симай атаң аны күп ясады, бик күп. Аны ясый башласам мин сезгә мәшәкать тудырырмын. Олуг ханыгызны әйбәт бәндә, диләр. Сорашмыйсыңмыни?.. Иә, бар, ял ит. Иртәгә.

Симай картның берүзен калдырып Илбарыс буйтур һавага чыкты. Җилкәннәр киерелгән, ишкәкчеләр ял итә. Уңай җил алар өчен күктән төшкән алла.

Иртәнге якта җил басыла төште. Херсонес күренде. Ишкәкчеләргә ишәргә боерылды. Фанәгүргә кайткач, ирек ышандыргангамы, алар аерата тырышып ишәләр иде.

— Денис!— дип боерды буйтур.— Койрыкка үзең бас!

Менә яр аерма-ачык күренде, яр башында чаң суга башладылар. Чит кораб килә, яр буе каравылларына хәбәр салалар. Илбарыс буйтур корабның әләмен күтәрергә кушты. Әләм күтәрелгәч, яр башындагылар чаң кагудан туктадылар. Таныш әләм, Болгар кардәшләре.

Үзенә бер дәүләткала булып яшәгән, әмма дине-рухы белән империягә буйсынган херсонеслылар яр буена мәһабәт храм салып яталар, храм тирәсендә кешеләр мәж килә. Күптән түгел херсонеслылар Византиядән аерылырга теләп карадылар, әмма император шундук бирегә үзенең иң ышанычлы төмәнен җибәрә һәм херсонеслыларны янә империягә буйсынырга мәҗбүр итә. Херсонеслылар дала яклап биек-биек дивар өеп, манаралар утыртып, кирмән салганнар, Кирмән бик нык саклана. Әмма ул диңгез яклап ачык, император Ираклийның төмәне кораблар белән нәкъ шул диңгез яклап калага килеп керәләр. Шул хәлдән соң император Ираклий бер генә мәлгә дә Херсонесны күздән яздырмый. Шул ук вакытта херсонеслылар Кубрат хан дәүләтен дә танырга мәҗбүрләр. Чөнки Фанәгүрдән аларга тире, бал, ашлык килә. Херсонеслылар үз чиратларында болгарларга чүлмәк, пыяла, корал, кораблар ясап саталар.

Херсонесны коллар каласы дияргә була. Биредәге колның исәбе-хисабы юк. Мәгәр болгарлар килеп, калага үзләренең тарханнарын куйгач, соңгы вакытта херсонес патшасы императорга бик үк буйсынмый башлады. Болгарлар херсонеслылар белән бары тик сәүдә генә итәләр, болгарларның һун бабалары куеп киткән тарханнар әллә кайчан греклар булып беткәннәр.

Кораб күперге җитүгә, ягирләр ташланды, басма салынды. Басмадан корабка Херсонес тамгачылары керделәр, товарларны өстән-өстән генә карап, чыгып киттеләр. Херсонеслылар чыккач, ике җансакчысын ияртеп корабка Болгар тамгачысы килеп керде, кирәк-ярак әйберләрне керттерде.

— Һәй, кардәшләр, коллар кирәкмиме?.. Кораб башы кем була?

— Мин,— диде буйтур аның каршына басып.— Мин булам, кардәш, кораб башы.

— Ишкәкче коллар кирәкмиме?

— Алсаң — сатам,— диде Илбарыс буйтур көлемсерәп.— Син, кордаш, Херсонес каласындагы Кубрат ханның илчесе бит?

— Үзе, буйтур. Кая колларың багыйм әүвәл. Кыз-кыркынмы?

— Кыз-кыркын юк, кичер, кардәш.

— Мин кыз-кыркыннар гына алам. Әй,— дип кычкырды ул яр башында әвәрә килгән колларга.— Мичкәләрне тизрәк тәгәрәтегез.— Аннары ул буйтур янына килде, бер кисәк бозау тиресен җәйде.— Тамгаң сал, буйтур. Өч мичкә эчемлек. Ике читән кипкән балык, дүрт мичкә су. Ит күпме кирәк?... Дүрт читән икән дүрт читән. Тамгаң сал. Хуш, буйтур, юлың уң булсын...

— Рәхмәт сиңа, тамгачы.

Басмадан төшә башлаган тамгачы туктады, буйтурга карады.

— Бер киңәш сиңа, буйтур. Бирелә кунмагыз, диңгезгә чыгып ягир ташлагыз... Сәбәбен син сорама, мин әйтмим. Һәй, бер атна элек коллар баш күтәрделәр, беришe котылды, далага качтылар. Урманда яшеренеп йөриләр, диләр. Төнлә килеп корабыгызга керүләре бар...

— Тагын бер рәхмәт сиңа, кордаш. Сау бул!— Буйтур койрыкчы янына узды.— Кузгал, Денис. Ачык диңгездә кунабыз.

— Баш өсте, буйтур.

Иртән бик иртә кузгалдылар. Диңгездә һаман дулкыннар йөгерешә, ә жил юк хәлендә, ишкәкчеләр эшкә кереште. Кораб кузгалуга, буйтур Симай карт бүлмәсенә юнәлде. Картны ул баштан ук үз бүлмәсенә алырга теләгән иде, әллә нигә соңгы мәлдә генә кире уйлаган булды, күңелдә ниндидер шом. Күңелдән һич кенә дә су анасы китми. Бит аның үзен дә су анасы диңгезгә алып төшеп китә язды, буйтур тәмам ихтыяр көчен җуйган иде. Илбарыс күк йөзенә карады, күк гөмбәзен тоташ болытлар томалаган. Бөркү, шыксыз көн туып килә иде. Бу хәл буйтурның күңелендәге шикне тагы да тирәнәйтә төште.

Бүлмә ишеген шакыды. Юк, карт дәшми. Эчтә «аһ»! дигән тавыш ишетелде. Буйтур үз-үзен белештермичә, ишеккә орылды. Ишек келәсеннән ычкынды, ачылып китте. Бүлмәдә ике кеше көрмәкләшә иде, тоташ кара кием кигәне картны тышка сөйрәмәкче була. Мәгәр буйтурны күрүгә, тоташ карадан киенгән кеше күз ачып йомганчы картны калдырып, ишеккә ташланды. Буйтур аңа үзе дә сизмәстән юл бирде, бары тик озын чәчле, сылу гәүдәле кешенең хатын-кыз икәнен абайлап алгач кына исенә килде. Гәүдә артыннан ташланды, әмма ике атлап, авыз ачарга өлгермәде, карадан киенгән кеше диңгезгә сикерде. Буйтур бар тын тораташтай басып торды, ахыр бүлмәгә борылып керде. Симай ата кул-аягы бәйләнгән килеш идәндә ята, авызына чүпрәк тутырылган, ыңгыраша, тәгәрәп йөри иде. Буйтур аның авызыннан чүпрәген алды, тиз генә кул-аякларын чишеп ташлады.

— Ни булды, Симай ата? Кем иде ул?..

Симай карт башын чайкады, ишеккә таба ымлады. Буйтур аны күтәреп алып сәкегә салды, ишекне ачып каравыл кычкырды.

Аның янына шундук ике алып килеп бастылар.

— Берең Қамайны дәш, икенчең картка эчемлек салып бир. Әнә шул чүлмәктән. Тиз!

Симай карт сәкегә торып утырды, эх тә итми бер зур чокыр эчемлекне эчеп куйды. Аннары сәкегә сузылып ятты да күзләрен йомды. Буйтур каравыл алыпка картны бер минутка да ташламаска кушып, бүлмәдән чыкты, диңгезгә карады. Диңгез өстендә һични күренми, һични юк кебек. Тагын су анасымы? Ни кылмакчы иде су анасы Симай карт белән?.. Яшьләр булса бер хәл. Буйтур әйләнеп бүлмәгә керде.

Симай ата эчемлек чүлмәгенә таба ым какты, буйтур каравыл алыпка салып бирергә кушты. Симай карт утырды, чираттагы чокырны күтәреп эчеп куйды. Һәм янә сузылып сәкегә ятты.

— Мине су анасы урламакчы булды, буйтур,— диде ул бер тын яткач.

— Су анасы?!— дип кайтарып сорады буйтур.

Су анасы сүзен ишетүгә, каравыл алып ык! итеп кузгалып куйды. Буйтур аның иңеннән умырып тотты, үзенә тартып китерде.

— Тавышың чыгарсаң, шундук диңгезгә ташлыйм. Ишек келәсен рәтлә, карттан күзеңне дә алма. Ишеттең!

— Баш өсте, буйтур.

Шулай дип әмер бирде дә Илбарыс чыгып китте. Ул туры Денис бүлмәсенә юнәлде, койрыкчы бүлмәсенә килеп җитәр-җитмәс үк ачык

ишек күреп, шиге тагы да арта төште. Ишек каерылып ачылган, эчтә һичкем юк — Эгина да, Денис та.

«Эгина — су анасы, пәри»,— дигән уй буйтурның зиһенен өтеп алды. Буйтур туры койрыкка йөгерде, койрыкта аның ярдәмчесе генә иде. Йөгереп килгән буйтурны күреп, койрыкчы курка калды.

— Денис кая?

— Аны Эгина чакырып алды, хатыны, буйтур.

— Эгина?!

— Әйе, буйтур, хатыны Эгина. Килде дә йомышым бар, койрыкны ярдәмченә бир диде дә култыклап алып китте.

— Камай!— дип тамагы ярылырдай дәрәҗәгә җитеп кычкырды буйтур.— Камай!

Каравылбаш кабалана-каплана койрыкка килеп җитте.

— Ни булды, буйтур?

— Бөтен корабны астын-өскә әйләндерегез, койрыкчы Денисны табып китерегез!

— Баш өсте, буйтур.— Камай алыпларына:— Ишеттегезме буйтур боерыгын, корабны астын-өскә китереп булса да койрыкчыны табарга.

— Җилкәнчеләр, җилкәннәрне төшерегез. Камай ишкәкчеләргә әйт, бар көчләренә ишсеннәр. Тыңламаганнарын соңыннан миңа күрсәтерсең. Койрыкчы, корабны ярга таба бор! Камай, ишкәкчеләрнең җанын ал, ишсеннәр.— Буйтур барысына да эш тапты.— Бернәрсә дә күрүче юкмы?!

— Буйтур, мин ярга таба китеп баручы көймә күрәм.

— Куып җитәргә! Ишетәсеңме, Камай, ишкәкчеләргә әйт, көймәне куып җитә алмасалар, барысын да диңгезгә ташлатачакмын!

Көймә белән кораб арасы күзгә күренеп якыная башлады. Ишүче берәү генә иде, икенчесе көймә төбендә ята. Ярга да ерак калмаган иде, корабның төпкә утыруы бар. Шул чак кораб тизлеген югалта төште.

— Камай, әй, астагылар, ни булды?

— Буйтур, ишкәкчеләр хәлдән тайды, ишүдән баш тарталар.

— Каравылбаш Камай, баш күтәргән ишкәкчене диңгезгә ташла! Мин әйтәм моны сиңа, Кубрат хан буйтуры!

Алай да буйтурның янавы файдага китте, кораб көймәне куып җитте.

— Оста йөзүче алыплар, суга сикерергә!

Берсе артыннан берсе өч-дүрт алып суга сикерделәр һәм көймәгә таба йөзә башладылар. Алар көймәгә җиткәндә генә ишкәкче дулкын эченә кереп югалды.

— Су анасы!— дип кычкырып җибәрде бер алып.

Аны кемдер куәтләп:

— Су анасы, су анасы!— дип чәрелдәргә тотынды.

Ярга таба йөгерешкән дулкыннар арасында су анасы күренеп-күренеп киткәли иде. Кояш чыкмаган әле, әмма диңгез өстендәге нәрсә ап-ачык күренә.

Су анасы калдырып киткән көймәне корабка күтәреп алдылар, көймә төбендә кул-аяклары бәйләнгән килеш яткан койрыкчы Денисны күреп бер мәлгә өнсез калдылар. Койрыкчыны өч-дүрт алып күтәреп алдылар, буйтур боерыгы буенча бүлмәгә кертеп, сәкегә сузып салдылар.

— Имчене дәшегез!

Буйтур боерыкларын кыска-кыска бирә торды:

— Койрыкчы, корабны Фанагургә бор, җилкәннәрне күтәрегез! Ишкәкчеләргә берәр чокыр эчемлек бирегез!

Буйтур янына каравылбаш Камай килде.

— Илбарыс буйтур,— диде ул тавышын тыя төшеп.— Синең әмер белән ике ишкәкчене диңгезгә ташладык.

— Калганнарын әйбәтләп сыйлагыз. Диңгезгә ташлаганнарын су анасы сорады диң, юкса барыбыз да диңгез төбендә булыр идек диң. Безгә уңай җил чыгып тора. Су анасы сораган корбаннарны бирдек! Диңгез алласы уңай җил бирде!

## 16

Фанәгүргә бер көнлек су юлы калгач, күтмәгәндә офыкта ят кораб күренде. Хәле арулана башлаган Денис буйтур янында басып тора иде, ят корабны күрүгә, кычкырып ук җибәрде:

— Хәзәрләр корабы!

— Шаулама, Денис. Ишетәсеңме, шаулама. Исән калганыңа дога кыл.

— Буйтур, Эгинам кая минем, кая китте ул?

— Эгина түгел ул, су анасы, кеше сурәтенә кергән су анасы.

Денис куеныннан перун алласын чыгарды, үбеп алды, авыз эченнән нидер пышылдады.

— Ул мине ырымлаган, сихерләгән булган, буйтур.

— Шаулама, Эгина су анасы булса, ерак китмәгәндер, корабны озата киләдер.

— Эгина су анасы?.. Буйтур, ул минем хатыным иде.

— Ул Эгина сурәтенә кергән булган, синең хатының сурәтенә. Кая хатының, Эгинаң кая?..

— Бүлмәдә ул, йоклый.

Буйтур койрыкчының изүеннән умырып тотты.

— Синең бүлмәңдә беркем дә юк. Мин анда каравыл куйдым.

— Хак, буйтур, Эгина анда юк. Эгина минем йөрәгемдә калды. Ярата идем мин аны, буйтур...

— Су анасынмы? Албастынымы?

— Эгина су анасы булса, су анасын, буйтур.

Алар янына каравылбаш Камай килде.

— Камай, Симай ата нишли?

— Нишләсен, җырлый-җырлый да җылап җибәрә. Эчемлекне авызыннан өзми. Мине базилевс шымчылары урламакчылар иде дип сөйләнә. Буйтур коткарып калды, ди. Саташамы шунда. Койрыкчының хатыны Эгина турында ул гректа бер оста йөзүче ди. Ул бер дә Агасике кызы түгел, император шымчы итеп җибәргән кәнтәй, ди.

— Агасике кызы түгел?!

— Тәңрең ишетер, буйтур, кычкырма шул тиклем. Су анасы шымчы буламы?

— Белмим, койрыкчы, Симай ата шулай ди.

— Димәк, койрыкчы Денис, синең Эгинаң Агасике кызы булмаган, алдан ук сөйләшеп җибәрелгән шымчы кыз булган? Никадәр мәкер бу императорда, Денис, никадәр мәкер! Ә бит ни тамаша төчеләнде. Димәк, ул Симай атаның китәсен алдан ук белгән. Әйе, алтынны да алалар, картны да алып калалар. Соңыннан кем урлады дисәк, су анасы алды. Шулаймы, Камай, шулаймы Денис?!

— Буйтур,— дип алар янына каравыл алып килде.— Буйтур, хәзәрләр безгә каршы төшмәкчеләр.

— Узып китәргә!

Буйтур, койрыкчы белән каравылбашны калдырып, Симай ата бүлмәсенә керде.

— Уз, утыр, буйтур. Таралып ятам. Сәкене болгар киң ясый икән. Әйт әле, буйтур, кем сине кызыксындыра? Су анасымы, император шымчысы Агасикеме?.. Әһә, икесе дә, димәк...

Симай ата сәрхүш иде, каравылда калучы алып буйтур боерыгын арттырып үтәгән, түмәр өсте тулы ризык, чүлмәк белән эчемлек.
Симай ата торды, көн яктырып килсә дә, почмактагы икона янындагы шәмнәргә ут алды, Мәрьям ана сурәтенә карап чукынып куйды. Шуннан соң гына ике чокырга эчемлек койды.
— Минем исән калуга, буйтур. Эч, эч, әйбәт эчемлек зиһенне ача, канны куа, ир-атка гайрәт өсти. Эчмәгән булсам, императорның иң оста йөзүче шымчысы Симай картны әллә кайчан херсонесларга илтеп тапшырган булыр иде инде. Эчеп алуым ярдәм итте, җан гайрәте белән чәбәләндем. Ни чәбәләнсәм дә бәйләде бит, убырлы нәмәстә, кычкыра башлаган идем, авызыма чүпрәк тутырды. Җен көчләре бардыр ул хатында. Бернинди су анасы да түгел ул, буйтур. Гап-гади йөзүче. Әмма балык та балык, бу да балык... Элек булса олимп каһарманы булыр иде, хәзер әнә император нинди эшкә җигә башлаган кешеләрне. Җитмәсә хатын-кыз бит...
— Сине алып китәргә тырышуы миңа билгеле, нигә аңа Денис кирәкте икән? Менә шуны әйт син миңа.
— Денисныммы, койрыкчынымы?.. Яратты ул аны. Бик яратты. Үзе белән алып китмәкче булгандыр.
— Алып китмәкче?!
— Ә нигә, император Ираклий остага туямы? Бөтен дөньядан осталар, уенчылар җыя. Тиздән кәгазь ясый башлар. Табгачлардан кәгазь ясаучы сатып алган. Тегеләр ак кәгазь ясыйлар икән. Базилевсның тамагы тыгылганны күрә алмадым инде, киттем, аллам ярлыкасын. Улы Юстинианны мактыйлар, әйбәт диләр... Син борчылма, буйтур, мин Кубрат ханга грек утын ясап бирермен. Иллә белеп торсын иде, император ул утны хәзәрләргә күптән сатып ята инде. Бер колга бер чүлмәк диме шунда...
— Симай ата, ни сөйлисең син?!.
— Мин ни сөйләгәнемне бик яхшы беләм, буйтур. Император әллә кайчаннан бирле инде Болгарны да, Хәзәрне дә коралландыра. Мине каравыллап утыручы тоз күз хәзәрләр корабы күренә диде миңа. Ни төягән дип беләсең син аны.!. Һе, товар булмый ни! Товар ди сиңа. Грек уты тутырган чүлмәкләр дә корал, сугыш коралы, буйтур. Мин ул утның серен Болгарга ачармын, буйтур, онығым хакына эшләрмен мин аны. Хикмәт чүлмәккә тутырылган грек утында түгел, хикмәт аны үзеңдә ясый башлауда. Ә хәзәрләр аның серен белмиләр, ялындылар, ялвардылар алар миңа, тылмачлары табанымны гына яламады... Юк, мин сатлык җан түгел, буйтур! Түгел! Мин онығым хакына эшлим моны Кубрат ханга...
— Димәк, хәзәрләрнең корабында грек уты тутырылган чүлмәкләр, Симай ата?
— Константин, бәгырем, сине күрер көнем дә булырмы, гомерем өзелеп калмасын... Шагыйрь ул, буйтур, ә шагыйрьләр үлмиләр, үзләре үлсәләр дә сүзләре кала.
Буйтур әкрен генә күтәрелде һәм Симай атага сиздерми генә булмадан чыгып китте.
Сарай мәктәбендә укыткан шагыйрь Константин аларга еш кына шигырьләр укый иде. Күп кенә шигырьләрен ул ханша Аппакка багышлый торган иде. Шигырьләргә ак болыт, ак бәхет, ак ат, ак күлмәк, аппак чәчле хатынның хиссият дөньясына чумып, ак чәчкәләр җыеп йөрүе турында иде. Кемгә җыя? Сөйгәненә икән ласа. Укытучы аларга иле турында сөйләр иде. Византия нигездән чери, император янында йомакайланып йөргән сарай көчекләре ил турында кайгыртмыйлар, базилевска ихлас күңелдән хезмәт итмиләр, кулларына алтын-зиннәт кергәндә императорның үзен сатып җибәрергә дә күп сорамыйлар икән. Кыскасы, империя таудан тәгәрәгән кар түмгәген хәтерләтә, дигән

иде. Ул вакытта буйтур укытучысын аңлап җиткерми торган иде, хәзер, империянең үзендә булгач, моңа ышана башлады. Әйе, укытучы хаклы, империя нигездән чери. Кая карама ришвәт алу. Күр инде син бу Агасикене! Эгина бөтенләй үз кызы булмаган бит. Бәлкем аның кызы да, улы да, хатыны да үзенеке булмагандыр, император җибәргән шымчылар булгандыр? Шымчылар. Кем өчен тырышалар алар? Империя өчен. Димәк, империя укытучы әйткәнчә үк тиз генә таркалмас. Тиздән император Ираклий дөнья куяр, аның урынына тәхеткә улы Юстиниан утырыр, ул исә яңа реформалар алып килер, империя яңарыш чорын кичерер. Яңарыш чорын империягә китерүченең хатыны аның сөйгәне Кубрат хан кызы Чәчкә булыр... Иә, тәңрем, мөмкин хәлме бу?!

Буйтур янына, урыныннан кубып, Симай ата чыкты, каравыл алып аны озата килде.

— Буйтур, буйтур, хәзәрләргә ышанмагыз. Базилевс мәкерле җан, аларга да корал сатты.

— Чынлапмы бу шулай, Симай ата?

— Ант итәм, буйтур.— Карт уңлы-суллы чукынып алды.— Тәрем тотып ант итәм, буйтур.

— Хәзәрләр шул ук төркиләр, болгарларга кардәш халыклар.

— Иа-йа, шулайдыр, шулайдыр. Император аларны үзара сугыштырырга телидер. Ярый, шулай да булсын... Мине бүлмәмә илт, алып. Алып дим, нигә синең чәчләрең бакыр төсендә? Ә? Менә минем чәчләрем күмер кук кара, ә менә синең чәчең нәкъ бакыр. Нигә бакыр, нигә кара түгел, ә?.. Белмисең, варвар...

— Грекча аңламый ул, Симай ата.

— Аңламый? Ярый. Аңламаса да мин аңа әйтәм. Чөнки ул дала кешесе, дала баласы, шуңа бакыр аның чәчләре, буйтур. Нинди кояш астында яши кеше, хода аңа шундый төс бирә.

— Алып кит син аны, урынына яткыр,— диде буйтур алыпка. Каравыл алып Симай картны култык астына кыстырды да бүлмәсенә алып кереп китте.

Буйтур койрыкчы янына килде.

— Хәзәрләр калышмый баралар, нишли алабыз?

— Җилкәннәрнең барысы да күтәрелгән, буйтур.

— Көн бик тиз үтте. Иртәгә Фанагүрдә булырбыз. Уза алсаң, уз хәзәрләрне.

— Алар безгә тимәсләр, буйтур. Бергә-бергә кайту җиңелрәк.

— Шулай дисеңме?.. Алайса тот шулай, бик якын да барма, бик ук ерагайма да...

Сакчылар арлы-бирле йөренәләр, кораб әкрен генә йөгерешкәндәй дулкыннар кочагында чайкала. Иртәгә алар Фанагүрдә булырлар. Анда туган ил, анда Чәчкә... Чәчкә Кодрак илхан белән Эске кирмәнгә киткәндер. Кубрат хан Румга илче итеп җибәрмәгән булса, ул да анда булыр иде, бәйләме белән буйтур Кодрак илханда.

Кубрат хан ат үрчетә, алай җыя. Көбән елгасы тугайларына хан көтүләреннән башка маллар кертелми. Атларны яу чабуга ашаталар, ияргә, йөгәнгә өйрәтәләр. Атна-ун көн саен орыш уеннары уздыра. Болгарлар да көтригурлар кебек үк уйлый, көтригурлар көенә җырлый сыман. Аппак йогынтысы.

Бүлмәгә күзгә күренмәс ярыклардан тымызык кына диңгез һавасы тула башлады. Каравыл алыплар арлы-бирле йөренделәр...

Иртән аны Денис уятты.

— Буйтур, хәзәрләр корабы безгә таба килә.

Буйтур әштер-өштер киенде, кылычын да алмый бүлмәдән чыкты. Кара әләм таккан кораб аларга таба килә иде.

— Уят, быргы белән уят, Денис!

Күчен угалый-угалый каравылбаш Камай килеп җитте.

— Камай, алыпларыңа боер, хәзәрләр якын килсәләр, орышабыз. Өстә Денис, мин, койрыкчы... Барыгыз да аста, күренмисез. Үтә, каравылбаш! Һәй, тукта, ишкәкчеләргә әйт, яхшы ишсәләр, Фанәгүргә кайткач, буйтур, тагын ике алтын ышандыра диген. Бар!

Симай ата бүлмәсеннән чыкты, буйтур янына килде. Картның күзләре кысылган, күз төпләренә капчыклар салынган иде. Килә-килүгә ул хәзәрләрнең корабына күз төшереп алды.

— Орышырга кирәкмәс, буйтур. Хәзәрләрнең кораб борыннары тимер белән тышланган, сезнеке бакыр белән.

— Денис, койрыкка үзең бас. Корабны һәрдаим яны белән куй.

— Баш өсте, буйтур.

— Ярдәмчең янында булсын.

— Буйтур, аларның йөкләре дә авыр, кораб-корабка орынса, безне сытып китәрләр.

— Китмәсләр, Симай ата. Денис аларга корабны аркылы куймас.

Ул арада хәзәрләр өске катка күтәрелделәр, кызыксынып болгарларны күзәтә, киңәшә башладылар.

— Киңәшәләр,— диде Симай ата.

— Киңәшсеннәр. Симай ата, барыгыз бүлмәгезгә бикләнегез. Тәңре сакланганны саклармын дигән.

— Тәңре,— дип карт авыз эченнән мыгырдый-мыгырдый китеп барды.

— Камай, корабта без икәү дә койрыкчы Денис. Ишкәкчеләр дә без. Ишетәсеңме, Камай. Алыпларың аста, әзер булсыннар. Шым бул! Ә хәзер, сиздерми генә түбән төш, барлык ишкәкче колларга корал өләш.

— Мөмкин хәлме бу, буйтур. Ишкәкчеләргә корал өләшсәк, үзебезне турап ташламасlarмы соң?..

— Бар, ишкәкчеләргә корал өләш, каравылбаш Камай!

— Баш өсте, буйтур.

Буйтур янына тагын Симай ата килде.

— Буйтур, миңа да корал бир. Грек үлгәндә дә корал тотып үләргә тиеш. Алла хакы өчен!.. Ямат бәк бу. Патшакалага коллар китереп сатучы сәүдәгәр. Ул мине бик кодалады. Бир миңа корал. Һич югы акинак бир.

— Камай, мен әле монда.— Каравылбаш менеп басты.— Симай атага ятаган бир.

— Буйтур, колларга корал өләшенде, куанычтан ни кылырга белмиләр.

— Камай, хәзер аска төш, ярдәмчең үз урыныңа калдыр. Миннән боерык булу белән өскә күтәрелсеннәр.

Хәзәрләрнең сөрәнчеләре оран сала башлады.

— Һәй, болгарлар, кай тарафка юл тотасыз?

— Дәшмәгез, куркалар дип белсеннәр.

— Болгарлар, нигә дәшмисез?!— дип кычкыра торды сөрәнче.

Диңгез өсте тыныч, вак-вак дулкыннар йөгерешә, Денис хәзәр корабының һәр хәрәкәтен күреп, һәрчак аларга борыны белән борыла.

— Өстә сигез алыбы күренә Ямат бәкнең, Камай. Аста ничә алыбы бар микән? Ул да ишкәкчеләргә корал өләшкән булса?.. Ә, Камай дим?.. Сөрәнче алыбыңны дәш.

Сөрәнче менеп тә җитте.

— Алып, сөрән сал. Ямат бәк, диген, нигә корабыгызны безгә таба бордыгыз, ни йомыш төште, диген.

Болгар сөрәнчесе кычкырганнан соң хәзәрләр бер мәлгә тынычландылар.

— Тагын киңәшәләр,— диде Камай.

— Денис, якын кил, качма, курыкма.

— Бер дә бүтән түгел, безне кол итмәкче бу, Ямат бәк,— дип сөйләнде Симай карт.— Грекны кол итмәкче. Итми тор!

— Без күбрәк, буйтур. Ишкәкчеләр коралланды.

— Аларда ишкәкчеләр юктыр дип беләсеңме, Камай?

— Безнең коллар ирекле, буйтур.

— Ирек яулаганда якташ якташны гына түгел, туган туганны юк итә, Камай.

Кораблар нык кына якынайдылар, хәзер сөрәнчеләрнең кирәге калмады, буйтур корабның өске катында кукыраеп басып торган Ямат бәккә:

— Ямат бәк,— дип кычкырды.— Кунакка керсәгез, коралларыгызны калдырып керегез.

— Һәй, сез, Кубрат этләре, корабыгызны алыгыз, сытып китәбез!

— Ямат бәк түгел, ярдәмчесе. Күрәм-карыйм да, буйтур, монда кан коелуы бар. Хәзәрләр белән бәйләнүне Кубрат хан котлармы?— диде Камай.

— Кире уйларга соң инде, каравылбаш Камай. Орышка әзерлән.

— Җәячеләр яшеренгән, уклар җитәрлек, коллар коралландырылды, буйтур.

Шул чак ян-яклары белән кораб корабка орынды, җилкәннәр эленгән баганалар шыгырдап, ыңгырашып куйдылар. Шунда ук өч-дүрт хәзәр алыбы болгарлар корабына сикерделәр. Денисның ярдәмчесе кылычын кулга алып дошманга ташланды, әмма аны шундук хәзәрләр укка алдылар. Ул ярдәмченең күкрәген тишеп чыкты. Моны барысы да күрделәр. Алып яман итеп кычкырып, идәнгә капланды. Яшеренгән болгар укчысы җәя тартучы хәзәрне укка тотты. Кораб читендә басып торган хәзәр алыбы диңгезгә очты.

Хәзәрләр сак кына буйтур белән каравылбашка таба килә башладылар.

— Буйтур, коралларыгызны ташлагыз!

— Ташламый тор әле,— диде Камай һәм әче итеп сызгырып җибәрде.

Астан дүрт-биш болгар алыбы күтәрелде һәм алар буйтур белән каравылбашка таба килүче хәзәрләрнең юлларына аркылы төштеләр. Җиңел төрки кылычы белән коралланган хәзәр алыбы ике болгарны суеп та ташлады. Буйтур хәзәрләрнең берсенә хәнҗәрен атты. Күкрәгенә хәнҗәр кадалган хәзәр кораб читенә чалкан төште.

— Камай, алга, ур-ра!

Аскы каттан үч канына сусаган, кулларына корал эләгүгә йөрәкләре ярсып киткән ишкәкче коллар күтәрелде, алар бердәм ташкын булып хәзәрләр өстенә ябырылдылар. Корабта бу хәтле болгар булыр дип күз алдына китермәгән Ямат бәк тә барлык көчен өске катка күтәрде. Ишкәкче колларга Камайның алыплары иярде. Башта хәзәрләр кысрыклаган кебек иде, әмма Камай алыплары күтәрелгәч, хәзәрләр Болгар корабына сикерми башладылар. Корабка сикереп төшкән һәр хәзәр күкрәгенә йә ук, йә сөңге кадалып ятып калды. Хәзәр корабына үрләүче колларның кайсысы диңгезгә очты, кайсысы хәзәрләр корабына менеп, шунда орыша башлады. Аларга янә болгар алыплары иярделәр. Бу хәлне һич тә көтмәгән Ямат бәк ике кулына ике корал тотып, җидесигез алыбына ешына-ешына борынга таба чигенде, Бер төркем хәзәрне койрыкка, икенче төркемне борынга таба кысрыклый башлаган коллар сафы сирәгәя барды, аларны болгар алыплары алыштырды. Гомерен орыш кырында, орыш уеннарында уздырган тәҗрибәле болгар алыпларын тиз генә ала алмады хәзәрләр, күзгә күренеп чигенә башладылар. Ике арада каты орыш китте. Нинди дер бер мизгелдә Ямат бәк орышны оттыруы турында аңлады, соңгы чөен салып, өч

болгар алыбын кадады. Моны күреп алган болгарлар Ямат бәк төркеменә ташландылар.

— Ямат бәкне үтермәскә, әсир итәргә!— дип кычкырды буйтур.

Хәзәрләр аз булмаганнар икән, һаман астан күтәрелә торалар. Шуңа карамастан, болгарлар аларның корабына күчеп килләләр иде инде.

Денис койрыкны өченче ярдәмчесенә бирде дә хәзәрләр корабына сикерде. Ул атылып койрыкчы янына килде. Башына тутый кош каурыйлы очлым кигән хәзәр койрыкчысы Денисны күргәч, койрыкны ярдәмчесенә бирде һәм кылычын чыгарды. Хәзәр койрыкчысының кылычы кәкре иде. Бу кылыч болгарларда да бар, Денисның беренче күрүгенә түгел, әмма мондый кылыч тоткан алыпка каршы беренче тапкыр орышуы иде. Кылыч төркиләрдән килгәндер, ялтырап тора. Әнә шул ялтырап китү Денисның сулышын кысып алгандай булды.

Денис димәшкъулеләрдә ясалган кылычын күтәреп сугарга җыенган арада хәзәрнең кылычы койрыкчының очлым читен уеп алды. Денис читкә тайпылды, моны күреп, хәзәр алыбы тагы да кыюлана төште. Шунда Денисның кылычы һава ярып, хәзәрнең уң ягын уйды. Бу юлы хәзәр алыбы читкә тайпылды. Денисның кылычы койрыкчының бозау тиресеннән теккән сырмасын ярып җибәргән иде. Денис хәзәрне алдар өчен багана артына чигенде, хәзәрнең кылычы баганага чабылды, зур гына йомычка уелып диңгезгә очты.

Шунда Денис болгарларның «ур-ра!» тавышын ишетте. Хәзәр койрыкчысы артында кулына грек ятаганы тоткан ишкәкче кол пәйда булды. Койрыкчы мизгел эчендә аңа селтәнде һәм шул мәлдә Денис аның башына кылыч белән чапты. Тутый кош каурые бер читкә очты, хәзәр койрыкчысы миңгерәүләнеп калды, икенче селтәнүдә Денис аның янбашына чапты һәм кылычның дошман тәненә батып керүен тоюдан сискәнеп китте. Әмма хәзәр койрыкчысының аркасына ишкәкче кол да ятаганын кадаган булып чыкты. Ишкәкче ятаганын сурып алды да аска төшеп китте.

«Ишкәкче хәзәр колларын чылбырлардан коткарырга тели»,— дип уйларга өлгерде Денис. Ләкин бу турыда шундук онытты да, борынга таба сугыша-сугыша чигенүче Ямат бәк төркеменә ташланды. Алдан баручы ишкәкче колларның күбесе хәзәрләр кулыннан һәлак булганнар, кайсылары суелган, чабылган килеш идәндә ауныйлар, кайсылары яраларын тотып аккан каннарын туктатмакчы була, кайберләре имчәдән ярдәм сорап үкеләләр.

Хәзәрләр корабына меңүгә Илбарыс буйтур ике алыпны ияртеп аскы катка төште. Шунда ук алар өстенә ике сакчы ябырылды.

— Уң кулдагысын мин алам,— диде алыпларга буйтур.

Хәзәр алыбы аңа пычак ыргытты, буйтур чак кына тайпылып өлгерде.

— Ташла коралыңны!

Җавап урынына алып алга сикерде һәм шуның белән зур ялгышлык кылды: кулыннан кылычы төште. Буйтур аның кылычына басты, алыпның бугазына кылычын терәде.

— Кулларыңны күтәр! Тиз!

Хәзәр алыбы кулларын күтәрде, өскә менә башлады. Болгар алыплары икенче хәзәрне кадаганнар иде инде. Икесе дә әсир хәзәр артыннан менеп киттеләр. Буйтур бүлмәләрне каерып-каерып ачты. Бер бүлмәдә кылыч-калкан, ятаган-хәнҗәр булса, икенчесендә кием-салым, кәбә күлмәкләр, өчлымнар иде. Өченчесендә... буйтур ачкан авызын ябалмый торды: анда грек уты тутырылган чүлмәкләр иде.

Шунда ук артында аяк тавышы ишетте. Ялт итеп әйләнеп карады, аңа таба кулына ятаган тоткан болгар ишкәкчесе, аңа ияреп ишек чылбырларыннан арындырылган хәзәр коллары килә иде.

— Буйтур, юл бир безгә!— диде ятаган тоткан ишкәкче кол.

Хәзәр ишкәкчеләренең күзләрендә чаткылар чәчә-чәчә нәфрәт уты яна, буйтур күз ташлау белән аңлап алды моны. Ни кылырга? Орышыргамы, ярдәмгә чакырыргамы?.. Өстә болгарларның «ур-ра!» тавышлары көчәйгәннән-көчәя бара иде.

— Корал кирәкме, ишкәкче?

— Корал кирәк, буйтур. Без сине изеп ташларбыз, кит юлыбыздан!— Ишкәкче кол әкрен генә буйтурга таба килә башлады.— Буйтур, без сиңа тимибез. Кораб безнеке, корабыгызны алыгыз да китегез.

— Мин сиңа ирек вәгъдә иттем, ишкәкче.

— Син бирсәң, башкасы алыр. Ирекне без үзебез яуладык, буйтур.

«Камай хаклы булган, колларга корал өләшмәскә иде»,— дип уйларга өлгерде буйтур. Һәм ишкәкче кол аңа ташланганчы ук чигә башлады.

— Алыгыз кораллар, кораллангыз. Канга — кан!

Ишкәкче коллар ишеге ачык бүлмәгә ябырылдылар, мәгәр анда чүлмәкләр генә күреп, буйтур артыннан ташландылар. Әмма буйтур баскычтан өскә менә иде инде.

Өске катта хәзәрләрне әсир иткәннәр, кулларын бәйләп, бер төбәккә җыйганнар иде инде. Буйтур артыннан ук хәзәр ишкәкчеләре күтәрелделәр, алар башка бүлмәләрдәге коралларын тапканнар, кайсылары хәтта көбә күлмәкләр дә кияргә өлгергәннәр.

Ыгы-зыгы, шау-шу белән болгарлар ишкәкче колларны абайламый калдылар, күрәсең. Алар тиз арада оешып, койрык янына җыелганнар иде инде. Астан чыккан коллар да аларга кушылды.

— Денис, Камай!— дип кычкырды буйтур.— Алыпларны бер төбәккә җыярга боерыгыз. Сөрәнче!

Сөрәнче калын тавыш белән болгарларны кораб очына җыелырга чакырды.

Коллар һичнинди чакырусыз койрык якка, исән калган болгарлар борын башына җыелдылар.

— Буйтур,— диде Денис.— Койрык алар кулында, корабны аерып алып китүләре бар.

— Борын яклап корабларны бер-берсенә ныгытырга!

Өч-дүрт алып боерган эшне башкарырга ташландылар, коллар әкрен генә борын якка таба кузгалдылар. Күзләрендә ачу кайный, кулларына менә дигән корал кергәч, аларның каны тагы да кыза төште, күрәсең.

— Буйтур, безгә син Ямат бәкне бир. Үзең алыпларың белән корабыңа күч,— диде алгарак чыгып җирән сакаллы кол.

— Денис, кем бу, якташың түгелме?

— Юк, буйтур, якташым башын салды.

— Атың, җирән сакал, атың әйт, атың кем?

— Атым Киши, телем угордыр, илем ерактыр, буйтур.

— Белекле угор,— диде буйтур.— Мин сезнең барыгызга да ирек бирәм.

— Ямат бәкне бирсен!— дип кычкырдылар арттагылары.

Җирән сакал кулын күтәрде.

— Буйтур, без ирекне яулап алдык. Ишкәкчеләрегезнең яртысыннан күбесе һәлак булды. Безне синең ишкәкче колың коткарды, без аны кораб башы итәбез.

— Ямат бәкне, Ямат бәкне бирсен!

Җирән сакал кычкыручының якасыннан эләктереп, аны алга йолкып чыгарды:

— Тыел, эттән туган!

— Ә ник тыелырга тиеш ул?!— дип кычкырыша башлады арттагы коллар. Җирән сакал ятаганын күтәрде, мәгәр шунда ук аның аркасы-

на берәүсе пычак салды. Җирән сакал артына әйләнеп карарга итте, әмма өлгерә алмады, буш капчыктай ишелеп төште.

Болгар алыплары кузгалышып куйдылар. Коллар алардан шактый күбрәк иде. Буйтур кулын күтәрде.

— Кузгалмаска. Җәячеләр, алга чыгыгыз, сөңгечеләр икенче рәткә басыгыз!

Колларны кемдер бик тиз җыйды. Җирән сакалны диңгезгә ташладылар. Алга баягы болгар ишкәкчесе чыкты.

— Буйтур, иманым тәңредер, телем көтригурдыр. Җибәр безне, койма кан. Без күп, сезне сытып ташларбыз. Ямат бәкне биргез, корабны калдырыгыз. Калдырмыйсыз икән корабны, без сезнең корабка күчәбез.

— Ишкәкчеләр, тагын бер тапкыр үтенәм, коралларыгыз ташлагыз. Ирек сезгә, ирек. Моны сезгә Кубрат хан буйтуры Илбарыс әйтә. Кан коймагыз. Тәңре шаһит, мин сезгә кылыч күтәрергә теләмим. Минем янда Кубрат ханның иң мәргән алыплары. Үзебезнең корабта да алыплар бар. Бер-беребезне кырышмыйк. Канны кан белән юмыйлар, акылны акыл белән юалар.

Коллар бик озак киңәштеләр.

Болгарлар корабыннан кулына ятаган тоткан Симай ата күчте, койрык тарафта оешып торган коралланган колларны күреп, акинагын идәнгә ташлады һәм колларга таба китте. Ис киткәне шул булды: идәнгә ташланган ятаган да аңа иярде, ул ничектер җылан кебек шуышып бара иде.

— Сез язык кылырга телисез, коллар. Язык кылсагыз, сезне берәмберәм су анасы алыр, диңгез алласы давыл җибәрер, корабыгызны кыяга орыр. Ташлагыз коралларыгызны минем ятаган янына...

Идәндә яткан ятаган селкенеп куйды, аннары икенче ягына әйләнде.

Иң алда торучы болгар ишкәкчесенең моны күреп, күзләре акайды, кулындагы ятаганы Симай картның коралы янына барып төште.

— Буйтур сезгә ирек ышандыра. Ул аны эшләр. Су анасы аңа тимәде. Су анасының каһәре яман, коллар, үзегез күрдегез...

Симай картның кулында чүлмәк пәйда булды: ул чакма таш алды да ут салды һәм чүлмәкне идән уртасына ташлады. Чүлмәк авызыннан бөркелеп ут чыга, чаткылары колларга кадәр барып сибелә иде.

Коллар берсе артыннан берсе Симай картның янына коралларын ташлый бардылар. Чүлмәктән һаман ут көлтәсе бөркелде. Бу хәлгә коралланып алган коллар гына түгел, кораллы болгарлар да өнсез калдылар.

Симай карт бер урында ут бөрки-бөрки бөтерелә башлаган чүлмәкне кулына алды: диңгезгә барып төшкән чүлмәк яман итеп шартлады һәм су өстенә ялкын капты. Корабтагыларның барчасы идәнгә тезләнде, тәңредән мәрхәмәт сорады.

Симай карт буйтур янына килде, коралларын тиз генә җыеп алырга кушты. Болгар алыплары коралларын җыеп алгач, буйтур алгарак чыкты, коралларга якын ук килде.

— Мин сезгә бүгеннән кол димим, ишкәкчеләр. Сез ирекле! Хәзер боерам, һәркем үз урынына ишкәккә утыра. Ямат бәк корабын тагабыз да кузгалабыз. Фанагүрдә сезнең һәрберегезгә дүрт алтын һәм ирек бирерләр!

Коллар аска төшә башлагач, буйтур Симай ата янына килде.

— Симай ата, ни иде ул?

— Грек уты, буйтур. Грек уты шулай яна, шартлый.

— Мин сезгә гомерем буе бурычлы, Симай ата.

— Бурычларыбызны теге дөньяда түләшербез, буйтур. Син мине тизрәк оныгым янына алып кайт. Шул булыр синең миңа булган игелегең.

Кораблар кузгалып киткәч, буйтур Ямат бәкне бүлмәсенә китерергә боерды.

Ямат бәкнең өстендә кеш тиресеннән тегелгән камзул. Озынча йөзле, зур борынлы, үзен гаять эре тота, билендәге кылычсыз кынысына тотынып-кагылып ала иде.

— Ямат бәк?.. Йулыш каганның сәүдәгәре Ямат бәк!

— Кубрат хан буйтуры Илбарыс, сине моның өчен Йулыш каган башыңнан сыйпамас, Кубрат хан да. Йулыш каган Кубрат хан белән карендәшләшергә торалар.

— Ямат бәк, Йулыш каган атын телгә алганда, Кубрат хан исемен телгә алма. Алар икесе ике кеше. Дулу ыруы, Ашиннар белән беркайчан да килешмәсләр. Син миңа шуны әйт, Ямат бәк, коралларны колларга алмаштыгызмы? Әллә булмаса, колларны алтынга сатып, коралларны һәм грек утын император бүләк иттеме?

— Мин синең бу соравыңа җавап бирмәмдер, буйтур. Урным-дәрәҗәм Кубрат хан белән сөйләшердә минем...

— Ярый, Ямат бәк, шулай итәрсең.— Илбарыс буйтур болгар алдына Ямат бәкне алып китәргә, аскы бүлмәләрнең берсенә бикләргә кушты.— Кара аны, күз карасыдай сакла!— диде ул аңа бәкне алып чыгып киткәндә.

Буйтур бүлмәсенә Симай ата килеп керде. Симай ата кергәч, буйтур аягүрә басты, ике чокырга эчемлек койды.

— Борчылмагыз, ата, тиздән Фанәгүрдә булырбыз. Әнә таныш ярлар, Аютауны узып барабыз, тиздән Алтын капкага җитәрбез.

— Батыр халык сез, болгарлар,— диде чокырны читкә этәрә төшеп Симай ата.— Мин эчмим, буйтур. Оныгыма кеше сурәтендә күренәсем килә. Рәхмәт. Инде инандыңмы, буйтур, императорның икейөзләнүенә. Әйттем бит, ул болгарларга өч кораб корал сатса, хәзәрләргә бишне сата. Базилевс кебек хәйләкәр, мәкерле кешене грек белмәде.

— Симай ата, сиңа ихтирамым зур булса да әйтергә кыям: император Ираклийга сүз әйтмә. Әйе, ул синең оныгын кугандыр, әмма ул Кубрат ханга патрикий дәрәҗәсе бирде, Болгар белән теләп сәүдә итә, иң әйбәт һөнәрчеләрен җибәреп тора.

— Җибәрмәгәннәрен урлап китәсез. Шулаймы?.. Ярый, буйтур, мин сиңа әйттем, калганын үзең кара.

— Әйдә әле, Симай ата Ямат бәк янына. Аста утыра ул, төрмә бүлмәдә. Ул миңа яный, каган моның өчен синең башыңнан сыйпамас, ди.

— Юлсыз төрки булмас, башсыз бүрки булмас, ди торган иде алачыкта эшләүче бер төрки кол. Төрки барда — йөрү бар дип йөри-йөри качып та китте бичара...

Буйтур белән Симай ата аскы катка төштеләр. Ямат бәк утырган бүлмәне сакчы алып ачты. Симай ата бүлмә бусагасын беренче булып атлады.

— А-а,— диде ул кергеннән артык сузып.— Таныш зат, Ямат бәк. Исәнме-саумы, коллар сәүдәгәре. Менә бит аны язмышны, тагын очраштык, Ямат бәк.— Симай карт буйтурга таба борылды.— Әйбәт тутый кошны эләктергәнсең, буйтур. Шул кеше булыр мине Биләмҗиргә димләүче, буйтур. Саклый күр үзен. Ычкынуы бар, җылан да җылан, Ямат бәк тә җылан.

Симай картның бу сүзләреннән соң Ямат бәк түшен киеребрәк утырды. Коллар сәүдәгәре бер дә Симай атадан курыккан кешегә охшамаган иде.

— Рәхмәт, буйтур,— диде ул.— Изгелегең онытмам. Бу кеше түгел, тәңредән дә, үз алласыннан да көлә. Илен саткан — динен дә сатар, диләр. Илемә тәңрем исән-сау алып кайтса, һәр христианның муенына табык тәпие тактырырмын. Кылган языгың тәңре хәл итәр, бәне илемә

жибәр, ишкәкче колларым, корабым бир. Корабсыз кайтсам каган минем башымны кисәр, ат коерыгына тагар.

— Олуг бәк Ямат, орышны син башлаучы, күрәсең, тәңре безнең якта булды. Кем беренче булып янады?!

Ямат бәк җавап бирмәде, йөзен читкә каерды.

— Калдыр, буйтур син аны,— диде Симай ата.— Хан үзе хәл итәр...

Камайның алыбы ишекне япты, богау элде. Өскә күтәрелгәч, буйтур Камайны дәшергә кушты.

— Камай, ишкәкчеләргә берәр чокыр эчемлек бир, әйбәтләп ашат, игелекле бул.

Симай ата үз бүлмәсенә китте. Буйтур койрыкчы янына юнәлде.

— Денис, кич җитеп килә, Судаг кирмәненә тукталабызмы әллә?.. Ишкәкчеләр арыдылар...

— Судаг әнә, туктасак туктыйк, буйтур. Фанагүргә төнлә кайту килешмәс.

— Син хаклы, Денис. Бор корабны.

Судаг кирмәнендә аларны Боспор дәүләтенең тарханы каршылады. Боспор дәүләте дә, болгарлар да бер-берләреннән товар өлеше алмыйлар, шуңа күрә тархан корабка да кереп тормады. Боспорда греклар, көтригурлар, болгарлар, греклашкан һуннар яшиләр. Корабтан ярга басма ташлауга, коллар янә шаулаша башладылар.

— Ни булды тагын?

Өскә Камай йөгереп менде.

— Буйтур, колларның кайберләре Боспорда калырга телиләр.

— Калсыннар.

Өскә күтәрелгән колларга буйтур дүртәр алтын бирде, хәерле юл теләде, үзе уйлады: «Боспор греклар кулында, греклашкан һуннар кулында. Боларның күбесен янә кол итәрләр. Ни ул дүрт алтын. Иреккә чыгу белән кайберләре эчемлеккә ябышыр, шуннан күп тә үтмәс тагын кол хәленә калырлар»,— дип, буйтур халык арасына кереп югалган ишкәкче колларның аркаларына карап калды.

Буйтур хаклы иде. Боспорда колның исемен көне белән алыштыралар, аларга иң ямьсез исемнәрне кушалар. Төсе-йөзе белән дә, килешкилбәте белән дә колларны боспорлылардан аерып булмаганда да кол булган кеше һәрчак исеме белән аерылып торыр. Авыр хәлләрдә яшәп коллар бик тиз картаялар, хәтта аналары биргән исемнәрен онытканнары да булгалый. Ахыр чиктә, картаюы җиткәч, колны иляре ишәк урынына өйдән куып чыгаралар. Кол шакшы сулар эчеп, чүплекләргә ташланган ризык-нигъмәт ашап, тиз арада агулана янсә авырып үлә, янсә ачтан үлә. Үлгән колларны императорның кала караучылары һәр көн иртән арбаларга төяп диңгезгә илтеп ташлыйлар. Патшакала, Херсонес, Боспор калалары тирәсендәге яр буйларында көтү-көтү кеше ашаучы акулалар йөри.

Император, кала башлыклары, патшалар, ханнар боларны күрмиләр, алар һәркөн күңел ачалар, җарияләр биетәләр, ипподромда тамаша кылалар. Җырлый янсә бии алмый башлаган уенчыларны император куып җибәрә һәм алар император билгән илләр буенча җырлап-биеп тамаклык акча җыеп, үз көннәрен үзләре көтә башлыйлар. Греклар ипподромнан куылган уенчыларны чегәннәр дип атыйлар. Аларның күбесе табор-табор булып оешалар, үзләреннән юлбашчылар сайлыйлар һәм каладан калага күчеп йөри-йөри көн күрәләр. Чегәннәрнең илдә күбәеп китүләренә базилевс бер дә борчылмый, ул һаман яңаданяңа мәзәкчеләр китертә.

Төн кунып, Судагтан чыгып киткәндә кояш чыккан иде инде. Судагтан чыккач та Симай ата буйтур бүлмәсенә килеп керде һәм юл буена Патшакаладагы яңалыкларны сөйләп барды.

Ахыр карт сөйләп туйды, күрәсең, янә онытын искә төшерде.

— Онытым күрер көн булыр микән, буйтур. Ул һаман шулай яшь кебек миңа. Чын шагыйрьләр картаймый, диләр бит.

— Күрерсең, күрерсең, Симай ата. Укытучы һаман да яшь әле. Ул миңа: җирдәге тереклек белән — вакыт, вакыт белән үлем идарә итә, дип әйтә торган иде. Барысына да төшенсәм дә мин аның шул сүзләрен аңламый идем. Кичә булган орыштан соң мин әнә шуны аңладым, Симай ата.

— Онытым хаклы, вакыт үтүчән, үлем котылгысыз, буйтур. Менә сиңа җавап. Аллалар гына үлмиҗ. Христос әйткән: бәндәм башта син миңа ышан, шуннан соң гына мин сиңа яшәү һәм вакыт серләрен ачармын дигән. Кеше кайчан үләсен белми, белсә яман булыр иде, кеше һәрчак өмет белән яши. Каравылбашың Камай миңа сине Кубрат хан кызы ярата дип әйтте. Шуннан миңа синең өчен курку килде/ буйтур. Әйе, кеше коткыдан азат түгел шул, кешенең беренче аты-исеме булса, икенче аты коткы булыр. Кеше үтерү язык, дибез. Чиркәү дә, яһүдләр дә, сарациннар да шулай дип баралар, болгарлар да, хәзәрләр дә, дөнья читендәге табгачлар да, буйтур. Бер куллары белән орышны котлыйлар аллалар, икенче куллары белән аны җуялар. Синең тәңрең исә кеше үлми, теге дөньяга гына китә, ахырзаман җиткәч, кире әйләнеп кайта, дип бара. Юк, буйтур, кеше дөньяда бары тик бер тапкыр гына яши, бары тик бер тапкыр. Ул беркайчан да якты дөньяга әйләнеп кайта алмаячак. Моны борынгы грек галимнәре әйткән, буйтур...

Симай карт терсәгенә таянды да уйга калды.

Буйтур да уйланды. Чынлап та, греклар кылган языкларын җую өчен чиркәүгә киләләр һәм поп аларны языкларыннан арындыра. Болгарлар исә тәңре алдында үзләрен аклау өчен иярләрен каплыйлар, яшь тай, сарык яисә балык корбан итәләр, корбан канын үз каннарына кушып иреннәренә тигезәләр дә кылган языкларыннан арыналар. Симай атаны аңлавы кыен иде. Менә икенче көн инде буйтур үзен начар хис итә. Хәзәрләр белән булган орыш, Ямат бәкнең янавы, хан кызы Чәчкәне Йулыш каганга димләүгә маташуы — барысы да аның кәефен кыруга көйләнгән иде.

— Варварларга ярдәмем тисә, чиркәү дине мине кичерсә дә Зевс кичермәс, буйтур. Зевсның талканы коры. Христос ярлылар алласы, йомшак күңелле. Христос белән эш итү җиңелрәк. Бөек Зевс ут рухы алласы Прометейны кешеләргә ут биргән өчен бик тә яман үлемгә дучар итә: ул аны һөнәрчеләр алласы Герместан таш кыяга чылбырлар белән богаулата һәм шул кыяларда яшәүче бөркеткә һәр көнне Прометейның бавырын чукырга боера. Мондый яман җәзаны моңа кадәр бер генә алланың да уйлап тапканы булмаган. Ә Прометей, ут рухы алласы, үзенә калса, кешеләргә игелек эшли бит. Илгә кайтсам, мине дә император шулай итәр, илгә хыянәт иткән өчен миңа иң яман үлем җәзасы уйлап табар. Син борчылма, буйтур. Мин үземнән курыкмыйм. Менә монда ул грек утының сере.— Симай ата күкрәгенә төйде.— Менә монда. Мин бирермен ул серне болгарларга, бирермен, күпләп ясармын. Хәзәрләр әнә каганнары бик ялгыша башласа, аны ефәк бау белән буып кайыйлар. Ничә ел каганлык итәсең тагын, дип сорыйлар икән. Әйтә икән, тагын бер ел дип, бер елдан үтерәләр, әйтә икән ике ел дип, ике елдан үтерәләр. Моны кем уйлап тапкан, буйтур? Дәшмисең? Тәңре. Тәңре уйлап тапкан, тәңрегә табынган төптәңреләр... Кубрат хан йолаларга ирек биргән икән, Фанагүргә чиркәү салдырган. Йола белән йола сугышкан вакытта чиркәү салдыра. Сарациннар ни өчен империянең кала арты каласын алалар. Яңа йола уйлап тапканнар, яңа йола. Феофан шул алладан курка. Сарациннарның аллалары яманрак, христиан дөньясын йотмагае, ди. Ил белән ил сугышмый хәзер, йола белән йола сугыша, буйтур. Сарацин белән христиан тыныша алмый. Әйдә, сугышсын-

нар — чөнки икесе ике йола, ә менә нигә бер телдә, бер аллага — тәңрегә табынучы кардәш халыклар сугыша? Менә шуны аңламый йөдим мин, буйтур. Бертуган төрки халыклар ни бүләләр?

— Төрки булсалар да, болгар белән хәзәр икесе ике халык, Симай ата. Без — Дулу, алар — Ашин ыруыннан.

— Әнә шулай диде бугай шул Феофан. Ике ыру тыныша алмый диде. Хәер, барысы да алла кулында, буйтур. Ул ни кыла, шул булыр, без адәм балалары, бары тик алла коллары гына.

## 17

Византия императоры Ираклий җибәргән көзгедә чын йөзен күреп, Кубрат хан куркып китте. Улмы, Кубрат ханмы бу?! Чәчләре чаларган, сакалы тимер төсенә кереп бара. Юк, бу көзгедән башка берәү күренәдер, Кубрат хан түгелдер. Кая китте кодрәте ташудан әйләнә-тирәдәге илләрне дер селкетеп торган Кубрат хан!.. Әллә соң тәңре дәрманы белән бөтен булган көче-куәте балаларына күчә барамы?..

Кичә кич белән Кубрат хан өлкән угланы Батбайны сарайга чакыртты. Корал-хикмәтләрен тагып, төз басып тәхеткә таба килүче угланны күрде дә, йөрәге кысылып куйды ханның. Үзе түгелме, яшь Кубрат. Бue бераз базинкырак та, йөзе җәйпәгрәк, юкса гел үзе. Тәңре илаһы белән Батбай угланы да, Кодрак та, Аспарух та, Балкыр да янындалар. Ә менә Аслан угланының йөзе күз алдыннан җуелып бара инде. Кайтарасы иде үзен, туйганчы сорашасы иде үзеннән. Үскәндер, күп нәрсәләр беләдер. Әйдә, кайтыр әле, өйрәнсен белемгә. Кайткач болгар балаларын укытыр, белекле сәүдәгәрләр артыр. Сәүдәсе барның белеге дә булырга тиеш.

Кичәгенәк Кубрат ханга җансакчылары бер сарацинны тотып китерделәр, болгарларга акча өләшә-өләшә үз динен таратып йөри икән. Кубрат хан аңа янамады, иртәгә сәүдәгәрләр сараена килер дип җибәрде. Сарацин килер, килми хәле юк, ул болгар алыпларыннан качып китә алмас, аның каладагы һәр адымын Кубрат ханның кешеләре күзәтеп тора.

Кубрат хан уйланды. Сәүдәгәрләр сараенда янә бәхәс кубар: иң көчле, иң куәтле дин кайсы? Тәңреме, Христосмы, Буддамы, Мөхәммәтме? Мөхәммәтне үлгәндә, мин алла илчесе дип әйтеп киткән, диләр. Сәере шул иде, кем ил юлбашчысы була, шул алла илчесенә әверелә. Каган кул астыннан чыккач, Кубрат хан да үзен тәңре илчесе итә ала иде. Юк, алай итмәде, үзенә төптәңре сайлады — Ирсанны. Төптәңре Ирсан бу исемне алуга, чит илләрдән килгән сәүдәгәрләр аны ил алласы дип йөри башладылар. Кубрат хан моңа чик куйдырды. Төптәңре олуг хан кешесе. Тәңре — күктә баш, без — җирдә.

Кубрат хан сарай бүлмәсенә күз йөртеп чыкты. Һичкем юк. Әмма аның һәр боерыгын үтәргә уннарча, йөзләрчә, меңнәрчә кешеләр әзер торалар. Әллә соң алла дигәнең әнә шул кешеләрне боерыгыңа буйсындыра алудамы?..

Юк, алай диясе килмәде Кубрат ханның. Аның боерыгын үтәмәгән кешеләрне дә күп күрде ул. Андыйларның беришен ат коерыгына тактырды, беришен җәллад балтасына бирде. Кубрат ханга ышану, аңа нәрү аның илдә кол сатуны тыюыннан башланды. Хәзер әнә коллар белән Йулыш каган сату итә.

Коллар сатудан баш тартып Кубрат хан дөрес эшләдеме?

Дөрес эшләде.

Батбайга аланнар илен биреп дөрес эшләдеме?

Дөрес эшләде.

Кодрак угланына Эске кирмән җәйләүләрен биреп дөрес эшләдеме?

Дөрес эшләде.

Аспарухка Әтил елгасының урта буйларын, көнбатыштагы җәйләүләрен биреп дөрес эшләдеме?

Дөрес эшләде.

Балкыр угланга Әтилнең түбән ягындагы җәйләүләрен бирен дөрес эшләдеме?

Дөрес эшләде.

Аслан оланын базилевска тәрбиягә биреп дөрес эшләдеме?

Дөрес эшләде. Болгарларга да белекле кешеләр кирәк.

Чәчкә кызын император Ираклий угланы Юстинианга ярәшеп дөрес эшләдеме?

Дөрес эшләде.

Әйе, барысын да дөрес эшләде кебек, әмма күңелдә әллә ниткән борчу бар. Ул борчу Патшакалага киткән Илбарыс буйтурның кайтып җитмәвеннән иде.

Кубрат хан зиһенен җыя алмый интекте.

Ни өчен Йулыш каган аңа яу чабарга тиеш соң әле?.. Бу хәбәрне китергән сәүдәгәрләрне кат-кат чакыртып сорашты Кубрат хан. Әмма рәтле җавап ала алмады. Тегеләр һаман бер сүзне тукыдылар — каган алай җыя. Кем аны җыймый, Кубрат ханмы, император Ираклиймы?..

Ашин ыруы гаять усал булды, Дулу ыруын һәрчак буйсындырып яшәргә омтылды. Төрки дөньясы — бер халык, аны икегә аерып, икегә бүлеп, һәрчак ике ыру башлары ызгышты. Дулуларны кара халык дип йөртәләр иде, әмма төс-йөзләренә карап түгел. Төс-йөзгә дулулар ак чырайлылар, ә хәзәрләләр киресенчә, кара чырайлы. Табгачлардан бу тамганы алган дулулылар һәрчак кара болгарлар дип йөртелделәр, кара, ягъни буйсынган, табгач императорына йөз тоткан, ашиннарга буйсынган, буйсынырга тиеш булган төркиләр. Ханнар исемлегенә карага́нда, төрки башында һәрчак дулулар торган. Шөгер баба да, аннан килеп Әти баба да, Әтиолан да дулулардан була. Ниһаять, төрки дөньясына, аның бөтен халкына исем биргән Иафәт бабадан Төрки углан туа. Төрки атаның ун угланы була: Агаер, Тирас, Авар, Угыз, Бәҗән, Торун, Хәзәр, Янур, Болгар, Савир. Гомеренең соңгы көннәрендә Төрки баба угланнарын җыя да һәрберсенә җәйләүләрен бүлеп бирә. Күпмедер вакыт төрки угланнар үз җәйләүләрендә дөнья көтәләр. Иллә көнчыгыштан табгачлар кысрыклый башлагач, көнбатыштагы туганнарының җәйләүләренә керә башлыйлар. Китә туганнар арасында килешмәүчәнлек. Үзара ызгышлар. Беришесен көнбатыштагы Табгач императоры котырта, беришесен көнчыгыштагы Рум императоры канат астына ала. Әнә шулай төрки халкына тамга сугыла, көнчыгышларга — ашин, көнбатышларга — дулу. Ашин тарафдашлар үзләрен дулулардан өстен саныйлар. Мәгәр төрки ыруы башында гел дулулар була. Ашиннарның төрки дөньясына баш булмауларын Болгар баба оныгы Кубрат хан исбат итте. Ашин ыруына йөз тоткан төркиләрнең күбесен буйсындырды, күбесен Хорезм шаһы биләмәләренә күчеп китәргә мәҗбүр итте. Әнә шуннан, Хорезм дәүләтеннән көч алып, Йулыш илхан төрки дөньясының өстенә менеп утырмакчы. Шактый алай белән Биләмҗир каласына килгән, каган дәрәҗәсенә ирешеп, Биләмҗирне башкаласы иткән.

Базилевска рәхмәт, Кубрат ханга тугры кала, кораб-кораб кораллар җибәреп тора. Хан сарай алаен тагын өч тапкыр арттырды.

Кубрат хан тәхет терәгенә кулларын куйды, эчке бер талгынлык тоеп оеп утыра бирде. Тәхет урындыгы биек терәкле, алтынга өретелгән затлы ташлар белән бизәлгән иде. Баштагы елларда, җәйләү ыстанназрында йөргәндә Кубрат хан иң биек, иң югары урынга нярен куеп утыра торган иде. Хәзер әнә императорга охшарга тырыша, тәхет урындыгы ясатты.

Кубрат хан кузгалырга итте, әмма оеп киткән сөякләрен кузгатасы килмәде. Кайчандыр аттан төшмичә атналар, айлар буе яу чапкан Кубрат түгел иде инде ул. Әллә соң аны да Болгар бабасы чакырамы?.. Дулу ыруы ханнарын диңгез буендагы калкулыкка күмгәннәр. Әллә бабалары чакырамы Кубратны? Картаюы життеме?

Картаюы житкәндер. Кайсы улын, кайсы илханны ак киезгә салып, олуг хан итеп кавханнардан күтәртергә?.. Тәңре дәшми иде. Димәк, үзе утыра әле. Килер ул үлем Кубратка да. Кубрат үлгәч, грек остасы ташка уеп: «Болгар углы Кубрат хан йир-суы» дип язып куяр. Төрки бабаның гадәтен боза буламы Кубрат. Тагын күңел түренә кызы Чәчкә килде. Олуг хан тураебрак утырды. Күңеленә Чәчкә кызы килүгә, күз алдына Илбарыс буйтур килеп басты.

Менә кем кирәк аңа бүген, менә нигә аның эче поша. Кубрат хан исәбе буенча Илбарыс буйтур Фанагүрдә булырга тиеш иде инде, ә ул юк та юк. Кубрат хан буйтурга зур өметләр баглый иде. Буйтур грек утының серен алып кайтса, хан ул коралны шундук ясата башлаячак. Диңгез буена зур-зур алачыклар салдырды, әле булса эш кайный. Бу төзелешне күргән философ башта аптырабрак калган иде, нигә, имеш, мондый зур алачыклар. Ахыр эшнең асылына төшенде бугай, дәшмәс булды.

Сарай янындагы диңгез буенда салынып бетеп килгән алачыкка киткән акчаны Кубрат хан үзе генә белә. Грек осталары бер дә бушка эшләргә теләмиләр. Башта аларга уч тутырып алтын бир, шуннан соң гына эшкә керешәләр. Хәер, Кубрат хан беркайчан да хажәт төзелешкә алтын кызганмады. Төн илләреннән килгән тиреләр бик тиз алтынга әверелә баралар иде. Йорт байлыгы — акчада, ил байлыгы — бакчада, диләр греклар. Әмма Кубрат хан аларга ышанып житми. Дәүләткә акча да, бакча да кирәк. Эске кирмәнне тагы да ныгытырга иде, кул житми. Сарациннар әнә дивар астыннан казып керергә хәвәсләр, ди. Шул хикмәтле сүзләрне ишеткәч, Кубрат хан кала диварларын дүрт терсәк озынлыгында казытып, өстәмә нигез салдырды. Сарациннар казып керсәләр, греклар дивар шартлатырга осталар. Хәзәрләр дә алардан ким куймаслар.

Шулай дип уйланды Кубрат хан, мәгәр шундук үз-үзенә шаккатты: ул һаман хәзәрләрдән яу көтә икән бит. Элек үзе яу чаба иде, хәзер әнә яу көтә. Теге вакыта каган кул астыннан бик күп жирләрне яулап алды Кубрат хан. Көнчыгышта яшәүче ашиннар аңа ачулы, жай гына көтәләр иде. Күп кенә ашиннар, хак анысы, Фанагүргә күчеп килделәр, илханнар жәйләүләренә таралдылар. Кызкуыш туйларында катнашып өйләнештеләр, утрак тормыш итә башладылар. Йулыш каган бу турыда да хәбәрдар, ул ырудашларын кичермәс, килә икән үч алыр.

Түр тәрәзәдән диңгез яклап кояш нурлары төшә, сарай эче мөлдерәп кояш белән тулган. Яктырып китте сарай эче, шушы яктылык Кубрат ханның да күңелен күтәрә төште. Кичә аңа аланнардагы тархан килеп китте. Хәзәрләрнең яуга әзерләнүләре турында борчылып сөйләде. Кубрат хан аңа бер төмән алай биреп жибәрде. Хәзәрләр әүвәл Балкыр илханга ташланырлар, шулайрак ишетелә дигән булды тархан.

Сарайга философ килеп керде. Иоанн Фасиан хәзер олуг хан янына кайчан тели, шунда килеп керә иде. Якын итә шул кешене Кубрат хан, аз гына уңай сөйләшә башласаң да, патрикий Симеон кебек муенныңа тавык тәпие тагарга тотынмый, философ күбрәк дөнья хәлләре турында аңгәмә тотарга ярата иде. Беркөнне патрикий Симеон Кубрат ханга сарай мәктәбендә укытучы Константин өстеннән дәгъва белән килгән. Хан аны хәтта тыңларга да теләмәде, жансакчыларыннан куып чыгарып жибәрергә кушты. Әйе, башта ул куып чыгарырга кушты дин әһе-

лен, аннары күңелендә ниндидер үкенү кебек бер хис уянуын тойды. Империя ни белән куәтле — дин белән, әнә шул христиан дине белән. Кубрат хан тәңре белән, Мөхәммәт пәйгамбәр алла белән, диләр...

Философ сүз катмады, ул ханның холкын белә иде, тәсбихен чыгарды, акрын гына тәсбих тарта башлады. Кубрат хан кырын күзе белән генә философ кулындагы тәсбихкә карап алды. Нинди тынычлану китерә микән бу тәсбих тарту, ә менә Кубрат хан ничә тартып карады, тынычлану тапмады. Әйдә, тарта бирсен, миңа синең тәсбихең кирәкми, миңа синең акыллы киңәшең кирәк. Төптәңре Ирсан аңа бер тапкыр бик ачуы чыккач, йөрәк белән әйтеп ташлаган иде: «Тәңрегә хилафлык кылсаң, сине аяз көнне яшен сугар». Ни өчен сугарга тиеш аны яшен, җитмәсә аяз көнне?.. Кубрат хан шул сүзе өчен төптәңрене сарайдан куып чыгарттырган иде. Соңнан кичерде тагын үзен. Төптәңрәк күз алдына китереп уйлаганда Ирсан сүзләрендә азмы-күпме хаклык булуын күргән иде ул.

Көн яп-якты иде, кисәктән диңгез ягыннан болытлар купты, зәңгәр күк йөзен кара болытлар томалады. Кубрат ханның күңелен дә көннән-көн болытлар томалый бара сыман.

Бүген кич якта Кубрат ханга христиан, яһүд, мөслимнәрдән сәүдәгәрләр килергә тиеш. Кубрат хан аларны түземсезлек белән көтте. Хикмәт шунда иде ки, хыянәт кылган төрле йолага табынучыларны бары тик үзләренең дин кануннары белән генә җәзага тартырга ярый иде. Фанәгүрдәге дин ирке әнә шундый мәсьәләләр китереп куйды Кубрат хан алдына. Һәм ул моны менә бүген хәл итәргә тиеш иде. Философның килүе бик әйбәт булды. Ул аңардан кайбер нәрсәләрне сорар. Ә аның белмәгән нәрсәсе юк.

Кубрат хан урындык терәгенә куелган кулын күтәрде, әмма сүз катырга да өлгермәде, ишекләр киң ачылды һәм сөрәнче:

— Христиан дине әһеле патрикий Симеон, яһүд дине әһеле Хасдай, мөслим дине әһеле Габдулла, төптәңре Ирсан,— дип, ишектән кергән һәр кешенең исемен кычкырып торды.

Кергән берсе Кубрат ханга баш иделәр, як-яктагы түмәрләргә утыра бардылар.

— Бүгенге көннән башлап,— дип сүзен башлады олуг хан, барысы да утырышып беткәч,— һәр җинаять кылган кешене, нинди йолага гына инанмасын, шул дин хакимнәре хөкем итәр. Хөкемдарларга айга ике тапкыр хан казнасыннан акча түләнәчәк.

Олуг хан дин әһелләренең һәрберсенә тукталып, карап чыкты. Патрикий Симеон өстендә кара чикмән иде, яһүд Хасдай яшел чапан кигән, төптәңре Ирсан кан кызыл атлас чапан өстеннән киң каеш буган, каеш аелына[1] кояш сурәте чүкеп ясалган иде. Ael саф алтыннан, шуңамы ялтырап тора.

— Олуг хан,— диде кисәк Кубрат хан алдына килеп тезләнде яһүд Хасдай.— Олуг хан, кыеп әйтергә телим: яһүдләрдә ике канун, Моисей һәм Яңа васыять кануннары. Кайсысы белән хөкем итик?

Хан торып басты, һәммәсен сөзеп карап чыкты. Моңа кадәр яһүдләрне Фанәгүрдән куганга үкенгән иде, үкенү тойса да кичерергә әзер иде, мәгәр Хасдайның беренче булып атылып чыгуын хан ошатмады.

— Утыр, Хасдай, урыныңа!

Хан алдына төптәңре Ирсан килеп баш орды.

— Олуг хан, болгарларны тәңре кануннары белән хөкем итүне мин якламыйм. Тәңре кануны языгы аз гына булган кешенең дә башын кисәргә хөкем итә, ә христианнар языклы кешене чиркәүгә кертеп үкендертәләр дә, аклап чыгарып җибәрәләр, яһүдләр белән мөслимнәр яуда

[1] Ael — пута тимере.

чакта үлгән кешенең җаны җәннәттә була дип баралар. Кая монда гаделлек?.. Тәңре йоласының мәрхәмәтсезлеген күреп, болгарлар башка йолаларга табына башларлар.

— Төптәңре Ирсан, тәңре сиңа баш биргән, уйла, уйла-уйла да миңа кил. Аксакалларны җыярбыз, киңәшербез, хәл итәрбез.

Кубрат хан сүзе бетүен аңлатып кул селтәде, бу аның чыгып китә аласың дигән шартлы хәрәкәте иде.

Барысы да чыгып киттеләр, хан янында философ кына калды. Кубрат хан дин әһелләренә сүз әйткәндә берьякка да кысылмады, бер йола кануннарын да якламады. Философ Иоанн Фасиан дин әһелләре белән булган очрашудан шуны аңлады: олуг хан әлегә бер йолада да өстенлек күрми.

— Олуг хан, синең кулыңда зур дәүләт, дистәләрчә җәйләүләр, калалар. Болгарны чын мәгънәсендә бөек итәсең килә икән, яңа дин кабул ит. Яшәү ул — көрәш, олуг хан, кеше күңелен биләүгә киткән көч, сәләт, акыл. Күк-кояш һәммә йолага табынучы кеше өчен дә бердер. Миңа шунысы билгеле: гарәпләрнең һәр кабиләсе үзенә бер аллага табынган. Шуннан Мөхәммәт килгән. Килгән дә башка барлык аллаларны юкка чыгарып, кешеләрне кәгъбәдәге күктән төшкән бердәнбер кара ташка табынырга өнди башлаган. Ул шагыйрь дә, оста оратор да, үз йоласына кайнар өндәүче дә булган, олуг хан. Мөхәммәт 571 нче елда туадыр, 601 нче елда пәйгамбәр дәрәҗәсенә ирешәдер, 632 нче елда вафаттыр. Үзе вафаттыр, йоласы калды әнә...

Кубрат хан философны сабыр гына тыңлады, әмма теге якка да, бу якка да сүз әйтмәде. Ул йолалар турында бөтенләй уйламады. Аның көткәне Патшакалага киткән Илбарыс буйтур иде.

Иртән бик иртә уянды Кубрат хан, ул хәзер күп вакытта диңгез буендагы Кызсарайда йоклый. Биредә җанга тынычрак. Иртән торып, иге-чиге булмаган зәңгәрсу кара диңгезгә карап утырырга була, аннары шул тарафтан илчеләре кайтырга тиешләр. Кубрат хан тарафыннан куелган вакыт күптән үтеп китте, борчылмаслык та түгел иде шул.

Кубрат хан әкрен генә урыныннан кузгалды, шулай ук салмак кына адымнар белән баскычтан түбәнгә төште. Соңгы баскычка җиткәч, тукталды, янә көнбатыш тарафка күз ташлады. Анда дулкыннар йөгерешә, бер генә көймә дә, кораб та күренми иде. Таң күптән атты, инде кояш чыгып килә. Кубрат хан соңгы баскычка утырды, чапанына төренә төште. Баскыч кырына дулкыннар йөгерешеп килә, берсе артыннан берсе куышып киләләр дә кире тәгәриләр. Дулкын. Кем аны кузгатып җибәргән? Тәңре. «Тәңре!»— диде Кубрат хан һәм ирексездән таң ягына — кояшка карады, кулларын күккә күтәреп көнне каршы алды.

Шул вакыт капка ачылганы ишетелде, берәү ашыгып йортка керде, каравыл алыптан ханның кайдалыгын сорады.

Кубрат хан аягүрә басты, чапанына төренә-төренә йортка юнәлде.

— Сөенче, сөенче, олуг хан!

Кавхан аңа тамгалы төргәк бирде. Кубрат хан тиз генә төргәкне сүтте, кыенлык белән булса да язуны укыды. Аннары:

— Йа, таңрем!— диде.

— Кавхан, император Ираклий Болгарга кораблар белән кораллар җибәргән. Каршы ал, сәяхәтчеләрне сыйла.

— Баш өстә, олуг хан.

— Тагын ни?

— Олуг хан, әйтергә кыям, Йулыш каган кызыгыз Чәчкәгә яучылар җибәргән. Дала як капкага килеп туктадылар. Бүләккә бик күп мал, җилем-җиһаз алып килгәннәр.

— Кавхан, боерам, яучыларны калага керткән хәлдә дә аларны кабул итүдән баш тартам.

— Ул кадәр мал-товарны кире алып китсеннәрме, хан?
— Базарга чыгарсыннар.
— Олуг хан, кыеп әйтергә кыенсынсам да әйтми булдыра алмыйм: каганның уе изге, яучы җибәрү төрки дөньясында бабалардан калган гадәт.
— Олуг кавхан,— дип тавышын күтәрә төште хан.— Олуг кавхан, беләсеңдер кебек: Кубрат хан кызы Чәчкә император Ираклий угланы Юстинианга ярәшкән. Бер кызны ике тапкыр кияүгә бирмиләр кебек иде төрки дөньясында.
— Беләм, аңлыйм, олуг хан, хәзәрләр каганы Йулыш төрки тәңрегә табына, базилевс угланы Юстиниан...
— Син картайдың, ахрысы, олуг кавхан. Иртәгәдән Балкыр илхан җәйләвенә китәрсең, үз урыныңа яшь кавханың калдыр. Мин әйттем.
— Халык синнән канәгать булмас, олуг хан. Туган өйгә ут салмыйлар. Мин башка бер сүз дә әйтмим, олуг хан...
Олуг кавхан борылды да капкага таба китте. Кубрат ханның йөрәге кысылып куйды. Олуг кавхан Савир белән Кубрат хан бик күп илләргә яу чапты. Савир кавхан һәрвакыт сул кулында булды, якын кинәшчесе иде.
«Юкка рәнҗеттем кавханны,— дип үкенү тойды Кубрат хан кавханы капкадан чыгып барганда.— Бир, тәңрем, сабырлык кешеңә...»
Кубрат хан үкенү тойды, әмма капка ябылганчы кавханның аркасына карап калды, дәшмәде, туктатмады. Әйтеләсе әйтелгән иде инде, иртәгә үк кавхан Балкыр илханга китәр, Балкыр илхан аны уң кулы итәр.
Кубрат хан үзе дә аңламаган бер теләк белән сарайга ашыкты, тәхетенә утырды, әйтерсең аның тәхетенә кем дә булса утырыр кебек иде. Тәхеткә утыруга, хан кычкырып ук җибәрде.
— Ханшаны дәшегез!
Олуг ханның бу тавышына гадәтләнмәгән җансакчылары ни кылырга белми каушап калдылар. Моны күреп, Кубрат хан тынычлана төште. Әмма үз-үзен тынычландырырга теләве аның тышкы күренеше генә иде, күңелен һаман исә Савир кавханга әйткән сүзләрдән үкенү тойгысы көйдерә.
— Ханша кая?— дип кабатлады ул, тавышын тыя төшеп.
Ул арада ханшаны китереп тә җиткерделәр. Ханның кыланышын ханшага җиткергәннәр, күрәсең, ул да бераз аптырый калган иде.
— Ни булды, ханым?
— Берни дә булмады. Әйдә, утыр, хәбәрем бар. Менә шул,— диде Кубрат хан фикерен тупларга тырышып.— Чәчкәне Йулыш каган сорый, яучылар җибәргән.
— Каган?!— диде ханша гаҗәпләнүен яшермичә.— Йулыш каган яучылар җибәргән?!
— Әйе, ханша. Безнең кызыбыз сорап, Йулыш каган Фанагүргә яучылар җибәргән, тегеләр тау-тау бүләкләр китергәннәр, дала капкасы ягыннан кереп яталар.
— Керсеннәр, кабул ит, яучы ил алырга килми, кыз сорарга килә, хан.
— Ашин ыруына кызым биреп, каган белән кардәшләшергә теләмим, ханша.— Кубрат хан тәхет терәгенә ябышты, кул бармаклары агарынып китте.— Ишетәсеңме, ханша, теләмим!
— Ачуыңны эчеңә җый, хан. Олуг кавхан хаклы, каган белән без кардәшләрбез.
— Кыз — ярәшкән!
— Ярәшкән, ярәшми ни!— диде кинаялап ханша.
Хан урыныннан купты, җилләнеп йөренеп килде.
— Кыз күптән ярәшкән, ханша!
— Хан, яучыларны кабул ит!

Кубрат хан тәхетенә барып утырды.

— Киңәшең шулмы, ханша?

— Киңәшем шул, хан. Кавханнарың ни уйлар, аксакалларың? Ялгыш яткан, ялгыш торыр да, яучыларга әйтер сүзең әйт.

— Кече кавханны дәшегез!— дип боерды Кубрат хан жансакчыларына.

Кече кавхан килеп житте, баш иде.

— Кече кавхан Актай, киңәшең әйт. Йулыш каган кызым Чәчкәне сорап яучылар жибәргән, кабул итимме, юкмы?

— Олуг хан, каган төрки нәселеннән, аның белән кушылу Болгарны тагын да көчәйтә төшәр иде. Мәгәр бала минеке түгел, бала синеке, олуг хан, ничек кылсаң, шулай булыр.

Кубрат хан урыныннан купты, кече кавхан янына килде, текәлеп күзләренә карады. Кече кавхан күзләрен читкә алмады, киресенчә, үзе сорау бирде:

— Олуг хан, әдәп йөзеннән булса да каган яучыларын кабул итәрсең. Бабаларыбыз әйткән: «Әгәр дә хан үзе кылса яманлык, кайчан булмак халаекта аманлык».

— Кыюсың, Актай кавхан, ай-һай кыюсың. Дәш илханнарны, дәш кавханнарны, дәш тарханнарны. Яучыларга әйт: мәжлес жыелган көнне сезне Кубрат хан кабул итәр диген. Мин әйттем.

## 19

Олы мәжлескә барлык илханнар, тарханнар, кавханнар жыелды. Жәйләүләрен ташлап килгән илханнар йөзендә канәгатьсезлек билгесе күреп, Кубрат хан янәшәсендә утыручы төптәңре Ирсанга карап алды. Төптәңре бик тырышып, укытучы Константинның императрица Мартинага язган хатын укый иде. Кубрат хан моңа кадәр укытучының хатларын үзе генә укый торган иде, бу хатны төптәңрегә укытырга булды. Чөнки сарай балаларын укытучы грек Константин императрица Мартинага язган хатларында тәңре йоласы турында кызык кына фикерләр әйткән иде. Әйдә, тәңре йоласындагы кимчелекләрне төптәңре Ирсан да белсен, дип уйлавы иде Кубрат ханның. Укытучы Константин, тәңре йоласының кулай якларын күрсәтү белән бергә, андагы күп кенә кыргыйлыкларны да ачкан иде. Төрки баба заманнарыннан килгән йоланың камилләшкән яклары бар — Кубрат хан аны яхшы белә, әмма йолада чынлап та кыргыйлыклар кылырга юллар калган гадәтләр дә бар икән әле. Әйтик, борын-борын заманда төркиләр, андый-мондый афәт тоташтан килә башласа, хан гаиләсендәге бер ир баланы тәңрегә корбан итә торган булганнар. Күп еллар буена килгән бу кыргыйлыкны Әтиолан баба туктата. Ул аны бик гади хәл итә: атка күчерә, кайбер ырулар эт корбан итәләр, болгарлар әнә малга, балыкка күчтеләр. Моның өчен алар ап-ак җәйпәк балыкны алалар, канын чыгарып үз каннары белән кушалар...

Соңгысы Кубрат ханга ошый. Әмма тугрылыкны бер балык белән тәңрегә корбан биреп кенә яулап буламы? Укытучы Константин сөйгәне Мартинага бу турыда гаҗәпләнеп яза. Укытучы хатларындагы йола мәсьәләләренә игътибар итте дә, итмәде дә Кубрат хан, аның белән әнә төптәңре шөгыльләнсен, ул өлкәне Кубрат хан аңа тапшырды. Кубрат ханны укытучы Константин хатларындагы дәүләткә караган хәлләр, әйтелгән фикерләр кызыксындыра иде.

Элек әнә ул хатларны укуы турында олуг Савир кавхан гына белә иде, бүген әнә төптәңре Ирсан да белде. «Белсен, халыкны белеп яшәсен»,— дип уйлады Кубрат хан, тәфсилләп хат укыган төптәңре Ирсан ягына күз төшереп.

Соңгы вакытта төптәңре ни сәбәпледер Батбай илхан янында урала

башлады. Нигә булыр? Әллә соң өлкән угланны олуг хан урынына хәзерлиме бу төптәңре? Бик мөмкин ич. Хан картайды, яу чабудан туктады, угланнарын җәйләүләргә җибәрде, ә үзе Фанәгүрне башкаласы итте дә утрак тормыш итә. Төрки халкы өчен гадәти хәлме бу... Төптәңре Ирсан исәбенчә, гадәти булмаган хәл. Шуңа күрә тәхеткә тизрәк илханнарның берсе утырырга кирәк.

Илханнар тирәсендә һәрчак кемнәрдер урала.

Батбай илхан тирәсендә төптәңре.

Кодрак илхан тирәсендә Димәшкътән килгән сәүдәгәрләр.

Аспарух илхан тирәсендә греклар бутала.

Балкар илхан тирәсендә Кубрат хан ягына күчкән хәзәрләр.

Кубрат хан янында кемнәр?

Кемнәр булсын, философ, хәзер әнә Йулыш каган яучылары.

Кодрак илхан Димәшкъ сәүдәгәрләре белән шул хәтле тыгыз элемтәдә иде ки, тегеләр моңа затлы тиреләр урынына капчык-капчык көмеш әйберләр ташыйлар. Шуңа күрә булса кирәк, Кодрак илханны «Көмеш илхан» дип йөртә башладылар. Җир-җәйләүләренең кадерен белеп торса, Кодрак илхан чынлап та Көмеш илханга әверелер. Димәшкъ сәүдәгәрләре тире-бал яраталар, ә ул товар Кодрак илхан кулында. Ярый, игелеге белән мал-көмеш җыйсын. Тимер тапкан — тилермәс, көмеш тапкан — баш бирмәс. Субаш кабиләсе Төн илләре белән бик әйбәт арадашлык итә, кыскасы, олуг хан икенче угланы илхан Кодрактан канәгать иде. Ә менә Батбай?.. Батбай илханның төптәңре белән бер суңмактан йөрүенә бигүк канәгать түгел иде Кубрат хан.

Кавханнар, илханнар, тарханнар — барысы да җыелдылар.

Кубрат хан аларга күз йөртеп чыкты. Илханнарның кәефләре юграк кебек иде. Хәер, аларның хәлләренә керергә була: атнадан артык аттан төшмичә башкалага килделәр, атларын куярга өлгермәделәр, олуг хан җыеп алды. Ике көн элек кенә Тимер капка кирмәненнән тархан килеп китте. Ул түкми-чәчми зур яуга җыенган каган турында сөйләп китте. Каганның йырмак түмәне Тимер капка кирмәне янына килеп, әйләнеп киткән икән. Каганның уң кулы Җаек бәк Этил буйлап күтәрелгән, шул тирәләрдә җәйләп йөри икән. Кәефсезләнеп утырмагыз, илханнар, тиздән каган белән чәкешергә туры килмәгәе. Ике арадагы мөнәсәбәтләр кискенләшә бара. Кайбер кавханнар каган ягына йөз тота башлаганнар дигән хәбәрләр дә килгәләде Кубрат ханга. Ул аларга бүген үк, шушы мәҗлестә үк хөкем чыгарыр: андый кавханнарны ат коерыгына тагарга!

Кубрат хан куе кашларын җыерып, илханнарга, кавханнарга, тарханнарга янә бер карап чыкты. Кичә кереп әйттеләр аңа: Йулыш каган Кубрат ханга бүләк итеп егерме дөя, йөз баш ат, ханның аяк астына юлбарыс тиресе, унлап төргәк табгач ефәге, капчык-капчык кипкән йөзем, хөрмә җибәргән. Шулар янына Йулыш каган Димәшкъ осталары ясаган күз явын алырлык көмеш табак, алтын кувшин һәм җиде алтын чокыр кушкан иде. Болар өстенә каган Кубрат ханга озын итеп битек язган. Битекне төркичә таныш руни белән язган иде. Кубрат хан ата-баба тамгалары белән язылган битекне рәхәтләнеп укыды. Янә бер яңалык бар битектә: ул табгачлар кәгазенә язылган иде. Битектә каган Йулышның Кубрат хан белән кардәшләшергә теләве турында көйләп-такмаклап әйтелгән. Йулыш каган хан кызы Чәчкәне төшләрендә күрә икән. Кыскасы, Йулыш каган кардәшләшеп алуның киләчәген җәннәт итеп сурәтләгән иде. Берләшкән төркиләрнең дәүләт чикләре Румда гына туктап калмас, франкларга җитәр дип ышандырган.

Илханнар үзләре ярымтавышка сөйләшеп утырган арада Кубрат хан Йулыш каган язган бу битекнең эчтәлеген янә бер хәтеренә төшереп алды. Табгач императорына йөз токтан көнчыгыш Ашин ыруы төркиләре аларны, кара халык, кара сарык дип кимсеттеләр дә, кол итеп

тә сатып җибәрделәр. Инде менә Дулу ыруы янә үзенә мөстәкыйльлек яулап, үзе ничек тели шулай яши башлагач янә муенга каган йөгәнен кияргәме?! Юк, тагын бер тапкыр юк! Кубрат яңадан каган кул астына керергә теләми. Яу белән килә икән Йулыш каган аның җәйләү-биләмәләренә, бөтен Болгарын күтәрер, әмма яңадан каган канаты астына кермәс.

Мәҗлестә философ, гомумән, чит ил кешеләре юк иде, чакыртмады аларны Кубрат хан. Болгарның эчке эшләрен болгарлар гына хәл итәргә тиеш.

— Илханнар, кавханнар, тарханнарым, мин әйтәм, тыңлагыз.— Мәҗлес шым булды, барысы да ханның авызына карадылар.— Явызлык Болгарга һәрчак явызлык китерде. Изгелек изгелек китерерме? Яңа хәбәр сезгә: кызым Чәчкәне каган сорый, яучылар җибәргән, тау-тау бүләкләр, киңәш бирегез!

— Атам, без табында каган яучыларын күрмибез,— диде Батбай илхан.

— Кече кавхан, чакыр яучыларны.

Күп тә үтми Йулыш каган яучылары табынга утырыштылар. Төрки гореф-гадәте буенча, аларның һәрберсе олуг хан каршына килеп баш орды.

— Яучылар биредә,— диде хан өлкән илханга карап.— Әйт киңәшең?

— Мин каган ягында, атам. Чәчкәне каганга бирү ягында.

— Кодрак илхан син?

Кодрак илхан торып басты, бил каешын рәтләде, ахыр ычкындырды, алдына сузып салды.

— Атам, Чәчкә миндә утырмада. Мин ашыкмаска кушам, атам.

— Аспарух илхан, син нә киңәш бирерсең?

— Атам,— диде илхан һәм хан янәшәсендә утыручы анасына сирпелеп алды.— Атам, мин дә каган ниятендә бернинди мәкер күрмим, уенияте изге каганның.— Аспарух илхан шулай диюгә, яучыларның йөзләре яктырып китте.— Мәгәр, атам, хәтереңдә булса кирәк, Чәчкә Рум императоры угланы Юстинианга ярәшкән иде. Вәгъдәсез ир, йөгәнсез ат, диләр. Килешерме икән бу Кубрат хан кадәр Кубрат ханга.

— Утыр, Аспарух илхан. Инде, Балкар илхан, син?

— Минем өчен, атам, анам әйтер.

— Ху-уш, анаң әйтсен.

— Балаларым, кавханнар, тарханнар, ханым. Бүген кызыбыз Чәчкә бер ханныкы гына түгел, бөтен бөек Болгар дәүләтенеке дә — илнеке. Йа, тәңрем, ни кылыйм бу ирләр белән? Ханым, юлдашым,— ханша Кубрат хан каршына килеп тезләнде.— Килеш минем киңәш белән. Киңәш әүвәл кызың белән, бала башына йөгән салма!

— Тор, ханша! Әйтмә алай бүтән! Ишетәсеңме, әйтмә бүтән алай! Үзеңә булган хөрмәтемне җуйма!..

Аппак ханша бер тын башын игән килеш тезләнеп торды, аннары торды да беркемгә дә күтәрелеп карамыйча урынына барып утырды.

— Кече кавхан Актай, ни әйтерсең?

— Ханша дөрес әйтә, олуг хан. Илхания бер хан кызы гына түгел хәзер, илнеке.

— Төптәңре Ирсан, син?

— Күктә — тәңре, җирдә — мин, олуг хан. Мин Батбай илханга кушылам. Хәзәрләр белән без канкәрдәшләр, телебез, йолабыз бер.

— Утыр, төптәңре. Хушыгыз кавханнар, тарханнар. Сарайда илханнар, кече кавхан гына кала,— дип боерды Кубрат хан.

Кавханнар, тарханнар, яучылар кузгалдылар.

— Кубрат хан,— диде тәхеткә таба атлап яучыларның берсе.— Хөрмәткә ия Кубрат хан. Яучылар итеп Йулыш каган иң кадерле, һәм

иң якын кешеләрен җибәрде. Сүзебез аяк астына салмасагыз иде, олуг хан.

Яучы баш иде һәм, борылып, китеп баручыларга иярде.

Сарайда илханнар гына калгач, Кубрат хан:

— Илханнарым, җәйләүләрегезгә китегез. Коралларыгызны барлагыз. Кодрак илхан, тарханың Адай, Румнардан килгән уклар җиңел һәм кыска, дип әйтә. Укларны озайтырга, сызгыра торган итеп ясарга, грек ятаганнарыннан кылычлар ясарга. Илханнар, Болгар баба да, Әтиолан да, агабыз Ураган каган да беркайчан Ашин ыруы белән тату яши алмаганнар. Йулыш каганга Чәчкә — орыш башлау өчен сылтау гына. Мин Чәчкәне Йулыш каганга бирмәскә, яучыларын кайтарып җибәрергә, император Ираклийга .биргән вәгъдәмдә калырга булдым. Моны ишетсә дә, ишетмәсә дә Йулыш каган яу чабарга җыена башлар. Уяу булыгыз. Миннән хәбәр килү белән мин чакырган төбәккә килеп житегез. Йулыш каганга каршы бердәм чыксак, Болгарны алдыра алмас. Балкыр углан, корбан балыгын китер.

Балкыр илхан көмеш табакка салып корбан балыгы китерде. Кубрат хан корбан балыгын алды да саңак астына хәнҗәр очы белән төртте. Аннары корбан канын алтын чокырларга тамызып чыкты, үз бармагына хәнҗәр белән кадап, кан чыгарды янә чокырларга тамызып чыкты. Хан артыннан илханнар, бармакларын канатып, чокырларга каннарын тамыздылар. Кече кавхан эчемлек китерде, кан,кебек эчемлекне чокырларга койды. Беренче булып чокырга хан үрелде, аннары Батбай илхан, аннары калганнары. Бер-берсенә ым кагып кына корбан каны катыш эчемлек салынган 'ант итү шәрабын эчтеләр.

Хан янә боерды.

— Батбай илхан, синнән — җиде көнгә бер, Кодрак илхан синнән — биш көнгә бер, Аспарухтан өч көнгә бер, Балкырдан ике көнгә бер хәбәрче көтәм. Җәегез матур үтсен, мал-туарларыгыз аман булсын, сәүдә эшләрегез уң булсын. Мин әйттем.

Илханнар бер-бер артлы олуг хан каршына килеп баш ордылар да сарайдан чыгып киттеләр.

Кичтән хәле китеп торса да, иртәнге якта Кубрат хан хатлар укып утыра иде инде. Менә тагын кече кавхан аңа укытучы Константинның императрица Мартинага язган хатын китерде. Хан грек телен бик үк яхшы белми иде, шулай да сукалады. Константин хатларны шул хәтле жанга җиңел һәм көйле итеп язган ки, укыган саен укыйсы килеп тора. Укытучы һаман императорны яманлый. Әйе, Ираклий укытучыны тикмәгә генә Фанәгүргә кумаган икән. Аппак янында укытучы кебек кеше уралса, Кубрат хан нишләр иде микән?.. Нишләсен, икенче көнне үк ат коерыгына тактырыр, я ике аягын ике агачка бәйләтеп ботын-ботка аертыр иде. Император хатыны Мартинага гашыйк булган кешене алай итми, бары тик Фанәгүргә куа. Башта ул бу турыда Кубрат ханга хат язды, атасы илче Феофан белән Фанәгүргә килгәч, мең сәбәп табып булса да Константинны алып кал дип язды. Сәбәп эзлисе түгел иде Кубрат ханга. Мәгәр ни өчен 'сер итеп язды микән аңа бу хәл турында император? Соңыннан беленде: атына тап төшүдән курыккан. «Тап төшүдән»,— дип кабатлады Кубрат хан. Нинди тап ди ул. Фахишәлеккә юл куймауның бары тик бер чарасы... Болгарда андый эшләр өчен... Йа, тәңрем, никадәр каты җәза ала кеше гашыйк булган өчен Болгарда! Күз алдына китерүе куркыныч. Менә шуның өчен, бәлкем, Кубрат ханның Болгарга яңа йола китерәсе килмидер дә.

Кояш нуры Кубрат хан ашап утырган табынга төште. Өстәл дә Румнан килә иде болгарларга. Тәрәзәләрдәге пыялалар да Румнан килә. Күптән түгел китерелгән пыялаларны Кубрат хан Эске кирмәнгә озат-

тырды. Бүген аңа алай җыярга кирәк. Күп, бик күп. Алай җыелыр, ничек аны коралландырырга. Әнә шул пыяланы да ясый белми бит болгарлар. Пыяла да алтынга сатып алына. Хак анысы, Төн илләреннән китерелгән затлы тиреләрне Болгар үзе алтынга сата, әмма Рум ул теләгән коралны бирми. Грек уты кирәк Кубрат ханга бүген. Бик кирәк!

Бары тик өч көннән генә Илбарыс буйтурның кайтып җитүе турында ханга сөенче китерделәр. Сөенче әйтүчегә Кубрат хан бил путасын салып бирде. Сөенче китерүче әйтте, Илбарыс буйтур каган корабын да тагып кайткан, ул гынамы, грек утын ясауның серен белгән Симай атлы останы алып кайткан. Бу хәбәрне ишеткәч, Кубрат хан куанычыннан ни кылырга белмәде.

Кече кавхан керде, грек картының аңа керергә теләве турында әйтте. Кубрат хан тынычланырга теләп:

— Дәш!— диде.

Мәгәр бу теләге аның ихтыяр көченә буйсынмый, шатлыгы йөзенә бәреп чыккан иде.

Кубрат хан Румнан китерелгән көзге каршына килеп басты, өс-башына күз ташлады. Грек утының серен белүче остага гайрәтле булып күренәсе килә иде аның. Кыяфәте ару икән болай. Ханның өстендә базилевсныкы кебек үк кан кызыл чапан, читләре кеш тиресе белән каелган, күкрәгендә уч төбе хәтле алтын тәңкә, аякларында сафьян читекләр. Башындагы очлымның нәкъ маңгай турысына кояш сурәте ясалган алтын, билендә кайнатасы бүләк итеп калдырган пута. Кубрат хан килеш-килбәтеннән канәгать калып, тәхетенә менеп утырды. Останы буйтур үзе алып керәчәк, ишек янындагы сөрәнче тәхет бүлмәсенә юнәлгән һәр кешенең атын, дәрәҗәсен кычкырып тора.

Бераздан грек карты керде, аннан бераз кала төшеп буйтур атлый. Грек карты күрер-күзгә мөлаем генә күренә: чал чәч, кара сакал, киң маңгай. Өстендә яшелгә кызыл буй төшкән юка чапан.

— Олуг хан,— диде алгарак чыгып Илбарыс буйтур.

— Тор, буйтур. Синең алдыңда мин баш иярга тиеш бүген. Тор, уң кулыма килеп утыр.

— Олуг хан,— диде грек карты тыйнак-тыенкы гына баш иде.— Мин онычым Константинны эзләп килдем.

Карт оста сүзен әйтеп бетерә алмады, Кубрат хан аның янына килде, тез чүгәргә әзерләнгән картны култык астыннан эләктереп алды.

— Кирәкмәс, оста.

Ханның бу кыланышын ни дип юрарга да белмәгән грек карты бер мәлгә аптырап китте.

— Хөрмәтлем, Симай ата!..

— Самокатта мин, олуг хан. Хәзер Симай аксакал буламдыр. Буйтурың кушкан атым.

— Колагыңа ят булмаса, оста, мин дә сиңа Симай ата диярмен.

Карт елмайды, тагын нидер әйтергә теләде, әмма грек телен бик үк шәп белмәгән хан аны култыклап алды һәм юлбарыс тиресе җәйгән урындыкка утыртты.

— Мин, Кубрат хан, бик шат синең Болгарга килүеңә, оста. Килүең сәбәбе онычың укытучы Константин...

Симай ата янә аптырап калды. Әллә соң аны грек утының сере кирәк диган булып, бөтенләй башка максат белән китерделәрме Фанагурга? Кайчандыр базилевс та онычы Константинны атасына гына яртеп җибәрә. Соңыннан... Самокатта картның ишеткәне бар иде, базилевс үзе яратмаган кешеләрне варварларга җибәрә һәм алардан үтерттерә. Илла онычыннан килгән хатларда бер дә андый мәкерле явызлыклар күрмәде. Ул гынамы, Константин Болгар халкын мактап яза торган иде. Аннары Кубрат хан барлык йолаларга да ирек биргән икән...

— Мин бик күп нәрсәләр беләм, хан. Болай каршылавың белән син мине тәмам аптыраттың. Тукта, буйтурыңнан сорыйм әле. Әйт, әйт әле кадерлем, бу кеше чынлап та Кубрат хан үземе.

— Үзе, үзе, оста,— диде буйтур көлемсерәп.

— Иа, хода, мин тагын бөтен нәрсә дә алла кулында дип йөри идем, алла сурәтендә йөргән ханнар да бар икән бит бу дөньяда!

— Куй, оста. Барысын да вакыт хәл итә, бар кылган эшләребез дә тәңре тарафыннан күзәтелә. Мин бары тик тәңрем кодрәте белән генә шушы тәхеттә утырам.

Симай ата түшәмгә карап, чукынып алды.

— Олуг хан, Фанәгүргә чиркәү салдыргансың икән, хакмы шул?

— Хак, оста. Базилевс кызымны улы Юстинианга ярәште. Буласы киявемнең теләге: чиркәүдә никахлашу диделәр.

— Алла куәт бирсен, чын ир-затлар нәселеннән икәнсең, олуг хан. Иллә, олуг хан, базилевска ул хәтле ышанып ятмавың теләр идем. Базилевс бер кулы белән Болгарны, икенче кулы белән Хәзәрне коралландыра. Буйтурың шаһит. Хәзәр корабында грек уты төялгән иде. Ул утны хәзәрләргә беренче генә җибәрүе түгелдер базилевсның.

— Базилевс турында яман сөйләмәсәң иде, оста. Олуг оста, мин бу сүзләрне синең авыздан ишетмәдем. Син монда оныгың күрер өчен түгел, ә бәлки грек уты ясау өчен китерелдең. Сиңа, олуг оста, сарайдан иң әйбәт бүлмә бирелер, телисең икән оныгың үз янына ала аласың. Сарайда кавханнарым да булмаган дәрәҗәдә йөрерсең.

Симай ата бер тынга уйга калды. Кубрат ханны аңлавы кыен иде. Бер мәлгә Симай картка куркыныч булып китте. Рум дәүләте гасырлар буена грек уты ясауның серен саклап килә, ә ул, империя алачыгында эшләгән иң хөрмәтле осталарның берсе, утның серен варварларга сатарга тиеш.

— Сиңа да, оста, оныгың Константинга да җил тимәс.

— Җил тимәс, ә минә император Ираклийның кулы җитәр.

— Моңа кадәр Болгар үзе яклы булган берәүне дә рәнҗеттермәде, Симай ата.

— Ярый, хәерле булсын, мин риза, хан. Күрсәт алачыкларыңны.

Хан кул чапты, шундук кече кавхан килеп керде.

— Останы алачыкка озат. Күпме кеше кирәк, шул хәтле һөнәрче бир. Оста сарайның иң яхшы кунак бүлмәсендә яшәргә, хан табынындагын ашарга тиеш. Мин әйттем.

Симай ата чыгып киткәч, Кубрат хан ятим угланы буйтур Илбарыс янына килде, угланны кочагына алды һәм тынып калды.

Күңелендә бер шатлык кайный иде: грек уты булачак! Кешеләр кайгыдан битәр, шатлыктан тизрәк үлүчән булалар. Грек утын күрсә, үлсә дә үкенмәс иде Кубрат хан.

## 18

Далага чыгуга Илбарыс буйтурга һәрчак тынычлану килә иде. Кояш баешка таба тәгәри, кичке дала җиле йомшак кына битне сыйпый. Диңгез буенда калган Фанәгүр артта калды, менә диңгез дә кичке сыек эңгер томанлыгына кереп эреде. Атлар баралар һәм пошкырып куялар. Менә хан болынына җиттеләр, бу болында бары тик яу атлары гына утлыйлар. Вакыт-вакыт көтүчеләр атлар арасыннан иң әйбәтләрен сайлап тоталар һәм иәр-йөгәнгә өйрәтәләр. Иәр-йөгәнгә өйрәткәндә яшь атны кан тире чыкканчы чаптыралар, шуннан хайван сабырлана, башындагы йөгән һәм өстендәге иәргә ияләшә, гадәтләнә башлый, дуламый, чыгымламый. Йөгәнгә һәм иәргә өйрәтелгән атлар хан болынына яңадан әйләнеп кайтмыйлар, шул көннән алып алар кешегә хезмәт итә-

ләр: яу чабалар, сөенче йөртәләр, хәбәр җиткерәләр, җир сукалыйлар. шул көннән алып аларның сыртларыннанияр, башларыннан йөгән төшми. Шушы хан болыны янынннан үткәндә байталлар рәхәт яшәгән чакларын исләренә төшереп, болында гамьсез утлаган яшь атларны, нәсел атларын күреп, сагышланып кешнәп җибәрәләр, каерылып болынга карыйлар. Кешегә яшьлек кире кайтмаган кебек, башларына йөгән кидерелгән атлар да бу болынга кире әйләнеп кайтмыйлар. Аларның күбесе орыш кырында ятып кала, беришесе пычактан китә. Кыскасы, ат үлгәнче кешегә хезмәт итә. Хайван моны беләмедер, кеше белә һәм кулына кергән атны кадерләп карый, вакытында эчерә, ашата, аны кайгыртып яши.

Хан болынын үткәндә Илбарыс буйтурның Кашкасы да каерылып-каерылып карады, сагышланып кешнәп куйды.

Әйләнеп кайтырмы кайчан да булса шушы болынга Кашкасы, әллә соң иясе кебек чит-ят җирләрдә ятып калырмы?..

Вакыт аларга буйсынмый иде, аның үз бизмәне, үз үлчәме.

Кичә иртән буйтур Илбарысны олуг хан чакырып алды. Артыннан ханның җансакчысы килгәч, буйтур сискәнеп киткән иде. Нигә булыр? Әллә соң Чәчкә турында бер-бер нәрсә әйтергә телиме?.. Күңелдә ниндидер өмет чаткысы да җемелдәп куйган булды, шул ук вакытта йөрәккә ниндидер курку да төште.

Олуг хан аны берни булмаган кебек каршы алырга теләде, мәгәр буйтур күрде: хан борчулы, гасабилана, күзләрендә каңгыру галәмәтләре.

«Илбарыс углан,— диде олуг хан, буйтур янына килеп басуга.— Илбарыс углан, сиңа мин янә бер йомыш йөкләргә булдым. Башкарган эшләрең өчен хан башым белән сиңа баш орам, углан. Болгарга игелегең күп булды. Йомышым шуннан гыйбарәттер, углан. Үзең белән Патшакалага барган Камайны ал да көтригурлар ыстанына кит. Көбер хан сиңа бер төмән йырмак алай бирер. Шул алай белән Этилгә юнәл. Этил буйлап каганның уң кулы Җаек бәк җәйли, янында утыз мең алай, ди. Этилнең уң ягына чыкса Җаек бәк — орыш, көчен сынап кара, мәгәр кулына эләгергә тырышма. Көчен сына да кач. Барышың Эске кирмән булыр, торышың янә шунда. Кодрак илханның уң кулына басарсың. Мин әйттем, углан».

Менә алар юлга чыктылар. Бик тиз кояш баеды, күзгә күренеп караңгы төшә башлады. Атларга юл таныш, бертуктаусыз терк-терк юырталар. Буйтур күккә карады. Күк гөмбәзе йолдызлар белән бизәлгән. Күк йөзен икегә ярып йолдыз атылды, шул ук вакытта артта ат тояклары тавышы ишетелде. Илбарыс буйтурның йөрәге кагып куйды, тезгенен җыя төште, тиз генә юл буендагы таллыкларга борылды. Камай сүзсез буйтурга иярде. Таллар арасына кергәч, атларыннан төштеләр, ат башларын кочаклап, тынып калдылар. Чаптырып унлап җайдак үтеп китте. Кайсыдыр: «Ерак китмәгәннәрдер, кояш баер алдыннан гына чыктылар»,— диде. Буйтур кылыч сабына тотынды. Ат тоягы тавышларына тынып калган тартай яңадан кычкыра башлады.

— Буйтур, мин берәүсен тавышыннан таныдым. Сарайда хезмәт итә. Хан җансакчыларымы әллә? Кемне эзлиләр?..

— Юк, болар хан сакчылары түгел, каган шымчылары. Бер нәрсәгә гаҗәпләнәм, кем аларга хәбәр итте икән?

— Фанәгүрдә каган шымчылары!..

— Фанәгүрдә, Камай, Фанәгүрдә. Болгарда да каган яклы кешеләр бар, хәтта илханнар арасында да...

— Әйт, әйтеп бетер, буйтур.

— Атлан атыңа, күп белсәң тиз картаерсың. Киттек, Камай. Икенче юлдан киттек.

Әйе, боларның Батбай илханның кешеләре булуы да бар иде. Хәтерли, Илбарыс, ханның өлкән угланы Батбайны төптәңре Ирсан укытты, укытучы Константин килеп җитмәгән иде әле. Өлкән углан беркайчан да төптәңре сүзеннән чыкмас. Ул аны олуг хан атасыннан да якынрак күрә. «Нигә кирәк булдым икән Батбай илханга? дип уйланды Илбарыс буйтур. Чынын гына әйткәндә, аның илханнар арасында барган бәхәсләргә катнашасы килми иде. Кубрат хан буйтурны Кодрак илханга бирде. Соңнан буйтурга җиткерделәр: Батбай илхан аны үзенә сораган булган икән. Олуг хан аны тыңларга да теләмәгән. Менә хәзер аны Батбай кешеләре куа чыктылар. Җиткән хәлдә ни кыларга тиеш иде ул. Орышырга, яисә аларның теләген үтәргә?.. Юк, орышырга, ул олуг хан йомышы белән бара.

Диңгез яклап җил кузгалды. Далага дымлы һава тарала башлады. Көтүчеләр учак алганнар, берсе җырлап утыра. Элек булса Илбарыс буйтур көтүчеләр янына туктар, алар белән яңа суйган куй ите ашар иде, бүген исә аның берәүгә дә күренәсе килмәде. Ул кичәле-бүгенле генә инанды: илханнар арасында бердәмлек юк. Батбай илхан сиздереп каганны яклый, Чәчкәне каганга биру ягында... Ә Чәчкәне император улы Юстинианга да, Йулыш каганга да бирдерәсе килми буйтурның, ул үзе хан кызын ярата. Юлга чыкканда хан аңа: «Буйтурым, исән-имин әйләнеп кайтсаң, мин сине куандырырмын... Иң зур теләгеңә ирешерсең,— диде. Һәм буйтурның йөзенә чыккан шатлыкны күреп:— Кешегә сиздереп беркайчан да шатланма, углан, балага гына килешә шаулап шатланырга, чын ир-ат кайгысын гына түгел, шатлыгын да яшерә белергә тиеш».

Хан яныннан чыкканда буйтур: «Ул миңа Чәчкәне ышандырды!»— дип уйлады. Хәтта кайтарып сорыйсы килде, әмма укытучысы әйткән мәгънәле сүзләр исенә төшеп, туктап калды. Укытучысы аңа: «Кошны атып, мәхәббәтне яулап алалар, яулап алган мәхәббәт татлырак була»,— дигән иде.

## 20

Чираттагы мәҗлес шуны күрсәтте: илханнар да, кавханнар да икегә аерылдылар. Берәүләре каган белән берләшик дип баралар, икенчеләре империягә йөз тотарга өндиләр. Кубрат хан бу якка да, теге якка да дәшми утырды. Төптәңре Ирсан белән өлкән углан Батбай каганны яклыйлар, алар белән килешеп, кайбер кавханнар баш кагып утырдылар. Мәҗлестән соң Кубрат хан Балкыр илханга куылган олуг кавханына хат язарга булды. Ул аны яңадан сарайга чакырды, олуг кавхан өч-дүрт тел белә, ул хезмәт иткәндә кавханнар арасында ике төрле сөйләүчеләр юк иде. Гаҗәбе шул иде: каганны ханша да яклый сыман тоелды ханга. Әллә тоелды гынамы? Кайнеше Көбер хан да апасын яклап чыкса?.. Дөрес, яшь көтригур ханы аның белән бәхәсләшеп тормады, миңа барыбер дигән кебек, кул селтәп, мәҗлесне ташлап чыгып китте. Мәсьәлә ачык иде: көтригурлар ханы бер якны да якламый. Болгарда ике төркем барлыкка килде. Уйланырлык иде Кубрат ханга. Мәгәр күпме генә уйламасын, ул биргән вәгъдәсеннән кире кайтмас — император Ираклийга тугрылыклы булып калыр. Шул.

Моңа кадәр Кубрат хан кавханнарның берсен дә җәзага тартмады. Хаер, сәбәбе дә юк иде. Хәзер әнә үзенә каршы булган кавханнарны да җәзага тартмый булмастыр. Ул алардан берәм-берәм сорау алыр. Башта төптәңре Ирсанны чакыртыр. Әйе, төптәңре Ирсаннан башларга, дигән фикергә килде ул һәм аның артыннан йомышчысын җибәрде.

Төптәңрене китереп тә җиткерделәр. Килеп керде дә төптәңре, тәхет

янына узды, әмма ханга баш ормады, аяк кенә кагып алды һәм берчиткәрәк барып утырды.

— Сөйлә, төптәңре, ни өчен бирегә китерелүең чамалыйсыңдыр дип уйлыйм?

— Мин сиңа бик күп еллар игелекле хезмәт иттем, хан. Хәзер әнә иң яман дошманыңа әверелеп барам. Син, хан, хаклыкны үзеңдә генә дип барасың. Ә мин — юк дим. Яман яу кардәш хәзәрләр ягыннан түгел, румнардан киләдер. Син, хан, төптәңре сукыр көйгә эш итә, берни күрми дә, белми дә дип уйлыйсың бугай. Төптәңре Ирсан беркайчан да сукыр көйгә эш итмәде. Синең шымчыларың янында минекеләр дә йөри, Биләмжирдә дә кешеләрем бар: каган чынлап та Болгарга яу чабарга җыена. Мәгәр аның Болгарга яу чапмавы да мөмкин... Моның өчен... Күктә — тәңре, җирдә — мин...

— Җирдә — мин,— диде хан, кинаяләп үзалдына сөйләшкәндәй.— Җирдә — мин. Синме хаклы икән, төптәңре, минме? Әйдә, без аны шахмат булмәсендә хәл итик. Син җиңсәң — синеке дөрес, мин җиңсәм — минеке. Кем җиңә, шул тәңредән куәт-зиһен ала булып чыга, шул хаклы булыр, төптәңре. Җиңеләсең икән, төптәңре, мин синең белән ни телим, шуны кылырмын. Мин барысын да беләм, төптәңре. Батбай илханны да, кайбер кавханнарны да котыртучы син. Каганны яклап чыгуыңны мин аңламыйм. Заманында каганның нәселен, Ашин ыруының тамырын кисеп йөрүчеләрнең берсе синең атаң булды. Каган моны белә, кулына килеп керү белән ул аны хәтереңә төшерер һәм сине ат коерыгына тагарга кушар. Күрәсең, төптәңре, телисеңме моны, юкмы, безнең язмышлар бергә бәйләнгән. Батбай илхан бары тик синең коткыга бирелгән, ул үз хатасын бик тиз аңлар. Өлкән илхан буларак ул да каган илханнарын юк итүдә катнашты. Кичерерме илханны каган? Белмим. Каган нәселеннән бер Йулыш илхан исән калды, аны ашинлылар ак ат тиресенә салып каган итеп күтәргәннәр. Аны каган итүче — минем кылычтан котылып калган Җаек бәк. Мин картайдым, төптәңре, ханша Аппакның да миңа каршы булуын телисеңдер. Мәгәр алай булмастыр... Утыр, төптәңре, ал кулыңа ак һәм кара шәкелне... Әйе, сиңа кара шәкелләр белән уйнарга туры килер, каралар чыкты... Йөр, төптәңре. Йөрйөр. Шахмат уены күңелне тынычландыра, шул ук вакытта дошманыңның көчен билгеләргә мөмкинлек бирә. Шахмат өстәле өстендәге ат шәкеле чын ат түгел, йөр, кыю бул, мәҗлестәге кебек. Исеңнән чыгармасаң иде, төптәңре, кешегә үз хыялын тормышка ашыру өчен иң әүвәл тәхет кирәк. Ә Болгар тәхетендә Кубрат хан утыра, син түгел. Минем сараемда егерме төмән алаем бар, һәр илханда унар төмәннән артык, илханнар минем бер сүзем белән яуга кузгалырга торалар. Әмма мин моны эшләмим. Каганның көчен сынау өчен мин Әтилгә йырмак алай җибәрдем, Фанәгүрдән түгел, Фанәгүрдән җибәрсәм, каган шымчылары бу турыда аңа бик тиз җиткерерләр иде, мин аңа йырмак төмәнне Көбер ханнан алырга куштым, буйтурыма, угланыма, Саклаб угланы Илбарыска. Буйтур Җаек бәк алае белән очрашыр, көчләрен сынашырлар. Илбарыс буйтурга мин ышанам, йомышымны йомышлар. Беренче тапкыр гына күзгә-күз дошман белән очрашуы түгел. Аннан исән-имин кайтса, мин аны кече кавхаң Актай урынына куярмын.

Хан сөйләде, төптәңре Ирсан уйланды. Никадәр мәкер бу Кубрат ханда. Аның улы кебек кешене күрә торып үлемгә җибәргән. Җаек бәктә кимендә утыз төмән алай, Илбарыс буйтур аңа каршы бер төмән алай белән бара, имеш. Әйе, тозакны әйбәт корган Кубрат хан. Әмма бернәрсәне уйлап бетермәгән — Болгардагы каганң шымчыларын. Төптәңре алар белән иртәгә үк элемтәгә керер. Керер дә Җаек белән Илбарыс буйтурның йырмак алае очрашканчы каганга хәбәр итәр. Орыш булмый калыр. Буйтур каган ягына күчәр. Менә ни өчен төптәңре Ир-

сан ханга каршы сүз әйтмәде. Аның бирелән исән-имин чыгып китәсе килә иде. Кубрат хан яныннан исән-имин чыгып җитә алса — ул барысына да ирешер — ике туган халыкны орыштырмас. Төптәңре Ирсан өчен кайсы ыру ил башында торса да барыбер, бары тик ике туган халык кына кырышмасыннар. Ике туган халык тату яшәргә тиеш. Дулу белән Ашин ырулары икесе дә төркиләр, дала бүләселәре юк, җәйләүләре Табгачлардан Румнарга кадәр. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, дигән бабаларыбыз. Ә Кубрат хан моны аңламый, бер базилевскаүөз тота. Вәгъдә, имеш, андый вәгъдәләрне мең бирә, мең тапкыр кире ала греклар.

Төптәңре Ирсанның ханга оттырасы килми иде. Кубрат хан элек-электән үк шахматта әйбәт уйный, шуңа күрә аерым бүлмә булдырды. Бу бүлмәгә хан рөхсәтеннән башка хәтта кече кавханның да керергә хакы юк. Бу бүлмәдә хан берничә тапкыр шахмат уеннары уздырды. Уеннарга илханнар, кавханнар, тарханнар катнашты. Уен отканнарны хан олылады, бүләкләр бирде, оттырганнарны мыскыл итте, мүкәләтеп йөртте, үгез, кәҗә итеп кычкыртты. Хан үзе ул хәтле үк көчле уенчылардан түгел иде. Әмма вакыт-вакыт иң көчле уенчыларны да шаккатырып тоташтан откалады, беренче урынга чыккалады. Шахмат шәкелләрен ул да Димәшкъ каласыннан китертте. Һәр шәкелгә алтын белән түләде. Шахмат бүлмәсен саклыйлар, һәрчак унлап алып каравыл тора. Бүлмәгә бары тик хан теләгән кешеләр генә кертелә иде.

Төптәңре уйланды, ханның эче поша башлады, тәрәзәгә карап алды. Көн кичкә авышып килә иде инде. Төптәңре сизде, хан каядыр ашыга, я булмаса кемне дә булса көтә. Моңа кадәр хан һәрвакыт төптәңрене җиңеп килде, ләкин бүген хан таркау уйнады. Гадәт буенча, уен оттырган кеше отучыга бер көмеш дирһәм түләргә тиеш. Үзе кертте бу гадәтне хан һәм барысыннан да карусыз үтәүне таләп итте. Хан үзе дә янчыгында һәрчак алтын-көмеш йөртте. Күптән түгел хан угланы Аспарухка оттырды. Шуннан соң Аспарух илханга сабы зөбәрҗәт ташлар белән бизәлгән тимер хәнҗәрен бүләк итте.

Уен дәвам итте, төптәңре ашыкмады, озын-озак уйлады. Көтмәгәндә төптәңре ике шәкелен югалтты. Хан аркасын терәбрәк утырды, кинаяләп елмайды.

— Бирел, төптәңре, шахмат ул хәрбиләр уены. Шахмат ул орыш кыры. Ә син, төптәңре, тәңре корты.

— Бирелдем, хан.

Төптәңре Ирсан янчыгын чыгарды, ханга бер көмеш дирһәм сузды.

— Булыр-булыр, төптәңре, куй. Бер сүзем бар сиңа, төптәңре. Мин сине бүген сарай төрмәсенә ябарга боерам. Ачуланма. Сабыр, сабыр ит, төптәңре. Шымчыларым җиткерделәр һаман илханнарны котыртасың икән. Минем илханнарны сынап карарга исәбем, төптәңре. Ул-бу булмаса, димәк, аларны котыртучы син, төптәңре. Син югалгач, ни кылырлар... Әйем, кылган эшләренә карап җәзасын бирермен. Мин әйттем.

— Олуг хан?..

Кубрат хан аны тыңламый иде инде, ул кул чапты һәм бүлмәгә шунда ук ике алып килеп керде. Алар төптәңрене култыклап алдылар һәм чыгып та киттеләр.

— Олуг хан, олуг хан, минем сиңа бер сүз әйтәсем бар...

— Туктагыз! Әйт, төптәңре, сүзең!

— Бүген-иртәгә Эске кирмәнне Җаек бәк камап алачак, кызың Чәчкәне әсир итеп Биләмҗиргә алып китәчәк. Син соңга калдың, олуг хан.

— Моны сиңа кем җиткерде, мәкерле җан?

— Дала җилсез, ил хәбәрсез булмый, хан.

Кубрат хан кул селтәде, алыплар төптәңрегә янәдан сөйләргә бирмәделәр, җилтерәтеп алып чыгып киттеләр.

Кубрат хан чапанына төренә төште, шахмат бүлмәсендә ишекле-түрле йөренергә кереште. Каганнан килгән яучыларны ул тоткарларга кушкан иде. Яучылардан күз дә алмый ышанычлы кешеләре йөри. Яучылар ябуда диярлек. Аларны кунак итәләр, ашаталар, эчертәләр, һәр адымнарын күзәтеп торалар. Төптәңре Ирсан яучыларны кайтып киттеләр дип белә, чөнки Кубрат хан аларны капкадан озатып җибәрткән иде, берара юл киткәч, кире кайтартты. Яучылар Фанәгүрдә. Шулай булгач, кем җиткерде икән каганга буйтурның Этилгә китүе турында?..

Кубрат хан ни кылырга белмәде. Эске кирмән камауда. Күпме тора алыр Кодрак илхан? Бит аңарда нибарысы өч төмән алай. Утыз төмән алай белән Эске кирмәнгә килгән Җаек бәк кирмәнне алгандыр да инде, Чәчкәне каганга алып китеп барадыр.

Хан тәхет ягына үтте, кече кавханны чакыртты. Актай килеп тә җитте.

— Мин тыңлыйм, олуг хан.

— Кече кавхан, яучыларның барлык әйберләрен, атларын, дөяләрен биреп, капкадан чыгарып җибәр. Менә бу хатны баш яучыга бир, ә менә бу кылычны,— хан кече кавханга Димәшкъ сәүдәгәрләре китергән кылычны сузды,— Кубрат хан исеменнән Йулыш каганга тапшырсыннар. Мин әйттем.

— Кылыч!— дип аптырый калды кече кавхан.— Йулыш каганга кылыч... Бу бит, олуг хан.

— Кавхан Актай, үтә кушкан боерыкны!

— Баш өсте, олуг хан.

Кече кавхан чыгып киткәч, Кубрат хан каганга язган хатның эчтәлеген исенә төшерде. Хатның эчтәлегеннән ул янә бер тапкыр канәгать калды.

«Тәңре киңәше белән язам мин бу хатны, кече каган. Тәңре үзе иман итте миңа: төрки халкының олуг ханы Кубрат, Йулыш каган, сиңа киңәш итәм: җәйләүләремә, болын-тугайларыма кермә. Мин картайдым, мәгәр минем биш илханым бар, алар белән орышырга туры килер сиңа, кече каган. Чәчкә кызымны сиңа бирмәскә булдым. Төрки вәгъдәсез, кош канатсыз булмас, кызым базилевс угланы Юстинианга ярәшкән. Мин әйттем.

Дулу ыруы Бөек Болгар олуг ханы Кубрат».

Хат эчтәлеген янә бер күңеленнән укып чыгуга, Кубрат хан җансакчысын чакырды.

— Ханшаны дәш!

— Баш өсте, олуг хан.

Ханша озак көттермәде, килеп тә җитте. Ханша өстендә Румнан кайтарылган алсу төстәге бәрхет күлмәк, аякларында укалап эшләнгән болгар читеге, башында кеш тиресе белән уратып каелган энҗеле калфак.

— Ханша,— диде хан, Аппак түргә узуга.— Ханша, авыр көннәр җитте ханыңа. Җаек бәк Эске кирмәнне камаган, Чәчкәне әсир итмәкче. Илбарыс буйтур барып җитә алдымы икән ыстанга, энең Көбер хан бирдеме икән йырмак алай?.. Чәчкәбезне коткарырга кирәк, ханша. Атаң ыстанына кузгал, ханша. Үзең белән минем бер төмән йырмак алаем ал. Алайга үзең баш, ханша. Мин әйттем.

— Соравым өчен кичер, ханым. Илбарыс угланга ни вәгъдә иткән идең?

— Мин аны сарайга кавхан итеп алырым, ханша.

Аппак ханша баш иде, борылып китмәкче булды, мәгәр янәдан туктады.

— Кубрат,— диде ул тыныч кына.— Каган орыш кыры эзли. Фанэгургэ юнэлсэ, бер үзең генэ йолып кала алырсыңмы?
— Фанэгүрне саклармын, ханша. Миндэ грек уты бар. Фанэгүрне ала алмас каган, килэ кала икэн каберен шунда табар.
Аппак хан белэн килешеп ияк какты һэм чыгып китте.
Кубрат хан ачулы иде, үз-үзенэ ачулы иде, хатынын нинди җаваплы йомышка озата, кавханнарына эмер биргэндэй сөйлэште.
— Йомышчы!
— Ни боера хан?
— Кем син, эллэ грекмы?
— Атам болгар, анам грек, олуг хан.
— Туным бир.
Ханга шундук камалы тун китерделэр. Кубрат хан ашыгып сарай алачыгына китте. Алачыкта Симай ата аны елмаеп каршы алды. Алачыкта йөзлэрчэ кеше эшли, бер урында нидер кайнаталар, икенче урында нидер киптерэлэр, һэр җирдэ төбе очлаеп килгэн калын чүлмэклэр, өченче җирдэ шушы чүлмэклэргэ грек утын тутыралар иде.
— Ничэ чүлмэк ясалды инде, оста ата?
— Йөздэн артып китте, хан.
— Ташаткычларга куя торганнары да ясаламы, оста?
— Ясала, хан. Ташаткычларны корабларга да куярга була.
— Корабларга? Эйбэт.
— Базилевсның ташаткычлар куйган меңгэ якын галерасы бар, хан.
Хан дэшмэс булды, тын гына алачыкны карап йөрде, ахыр чыгып китте. Аннан ул кораб осталары янына китте. Кораблар белэн янэ грек эш итэ иде, аның кул астында дистэлэрчэ кеше эшли, яр буендагы комлыкта унлап кораб кынасы корылып ята, алар тирэсендэ кешелэр мэж килэ.
Олуг ханны күрүгэ, оста грек аңа таба ашыкты. Хан аңа эш хакын алтын белэн түли иде, грек акчага хирыс иде.
— Олуг хан, монда килеп безне дэ бэхетле иттең.
— Бэхетең шуннан гына торса, мин килгэлэрмен, төпоста.—Хан ясалып бетеп яткан корабларга күз төшереп алды.— Ничэ кораб суга төшерелде инде?
— Уникe,— дип кабатлады хан.— Эзер корабларга ташаткычлар куйдыр. Һэр ташаткычка өстэмэ хак алырсың.
— Булыр, олуг хан. Ташаткычлар куелган булыр.
— Уникe, олуг хан.

## 21

Төптэңрене аерым төрмэгэ яптылар. Төнлэ белэн ышанычлы кешесе аша ул Саксин кавханны чакыртты. Челтэрле тимер тэрэзэ аша алар озак сөйлэштелэр. Каравыл торучы алып алар янына килеп-килеп китколэде. Хан бу турыда белсэ, каравыл алыпның башын кисэчэклэр. Каравыл борчулы, Саксин кавханның тизрэк китүен тели иде. Фанэгүрдэ төптэңредэн барысы да курка, каршы сүз эйтергэ кыймыйлар. Төптэңре төрмэдэ утырса да, күрер-күзгэ тыныч иде. Саксин кавханга ул Кубрат хан белэн низагы турында сөйлэде бугай, тегесе тизрэк китүягын карады.
Саксин кавхан киткэч, төптэңре уйланып утырды. Кубрат хан барысын да белэм, күреп торам дип уйлый бугай, эмма ахыр чиктэ төптэңре барыбер аны төп башына утыртыр.
Мэгэр Кубрат хан төптэңре уйлаганча ук гамьсез түгел иде. Төптэңрене төрмэгэ утырткач та ул каравылбашны чакыртты һэм төптэңре

янына килергә теләгән бер кешене уздырырга, әмма чыкканда тотып ябарга боерды. Саксин кавханнан соң төптәңре янына тагын бер кеше килде. Төптәңре аның белән дә бик озак сөйләшеп торды һәм бу кешене дә тотып яптылар. Япкан җирдән хан каршына китерелгән Саксин кавханны Кубрат хан кайтарып җибәрде, ә менә икенче кешене тоткарлады.

Чем кара сакаллы, чәчләре иңнәренә хәтле төшкән кеше, каршысында Кубрат ханның үзен күргәч, бөтенләй коелып төште, дер-дер калтыранырга тотынды. Кубрат хан аңа эчемлек салып бирергә кушты, көмеш табакка куеп китерелгән бер җам эчемлек эчкәч кенә ят кешенең куллары калтыраудан туктады. Бераздан ул шактый тынычланды, иркенләбрәк утырды. Әмма куркуы үтмәгән иде әле. Аның күзләре ялтйолт килә, чынлап та хан алдында утыруына ышанып җитми иде кебек.

— Атың әйт, атың ничек?— дип сорады Кубрат хан.

— Атым Карат, олуг хан, көбәче Бакыр угланы Карат.

Кубрат хан чабу астыннан итек башын чыгарыбрак куйды. Ханның хәйләсе шуннан гыйбарәт иде: әгәр дә мәгәр бу адәм каган кешесе булса, ул аның итек башын үбәргә егылачак, инде каган кешесе түгел икән, моны эшләмәс, чөнки ялагайланучыларны ханның җене сөйми иде. Кубрат ханның итек башын күрүгә, кеше баш орды, үрмәләп килеп, ханның итек башын үпте.

— Каган җибәрдеме?

— Сәүдәгәр мин, олуг хан. Фанәгүргә товар алып килдем. Тире, җилем, мамык, бакыр китердем. Киемнәрем дә бар.

— Төптәңрегә нигә килдең, йомышың әйт.

— Олуг хан, ул миннән ике чапан сатып алды, чапаннар алтын жепләр белән тукылган иде, акчасын бирмәгән иде.

— Син ул акчаны хан төрмәсенә килеп алырга булдыңмы?..

— Миңа әйттеләр, олуг хан, иртәгә аның башын кисәчәкләр...

— Башын!— дип гаҗәпләнде Кубрат хан.— Башын?! Кем әйтте?

— Саксин кавхан, олуг хан.

Кубрат хан уйланды. Төптәңренең ябылуы турында бары тик ике кеше белә иде: каравылбаш һәм хан үзе. Димәк, Саксин кавханга да, бу куркак җанга да төптәңренең төрмәдә утыруы турында каравылбаш сүз тараткан.

Кубрат хан төптәңренең өеннән чапаннарны алып килергә кушты. Чапан алырга киткән алып, күп тә үтми әйләнеп тә кайтты. Чапаннар чынлап та төптәңре өендә икән.

— Нигә ала килмәдең?— дип сорады чапан артыннан барган алыпка.— Хәзер үк чапаннарны китереп җиткер. Бер аягың анда, бер аягың монда булсын!

— Чапаннар бәһасез, олуг хан.

— Чапаннарны куеп тор, карендәш. Ни әйтте сиңа төптәңре? Каганга бер-бер хат бирдеме, телдән генә әйтергә куштымы?

— Мин бары тик сәүдәгәр, олуг хан. Сәүдәгәрнең товары алдан, акылы арттан йөри.

— Җәллад, калыбың китер!— дип боерды Кубрат хан.

Бүлмәгә тоташ карадан киенгән, күзләрен генә калдырып йөзенә битлек кигән, башына очларын тырпайтып кара яулык бәйләгән сарай җәлладьı килеп керде. Җәлладны күрде дә сәүдәгәр тәмам телсез калды. Аның янәдән куллары дерелди башлады, иреннәре калтыранды, ул хан ягына йөзтүбән капланырга дип бер адым ясаган иде, ханның җансакчылары аның култык астыннан эләктереп, аякка бастырдылар.

— Калыпка утыртыгыз!— дип боерды хан.

Сәүдәгәрне алып чыгып киткәч, берүзе бер бүлмәдә уйланып утырды хан. Төрле хәлләр күрде ул үз гомерендә, әмма иң яратмаганы, сөймәгәне — ялган иде. Бер тапкыр аңа төптәңре: «Кешегә хәзер агулы ук

кирәкми, кешегә хәзер җылы сүз кирәк»,— дигән иде. Кемгә кирәк синең җылы сүзең? Минә бу сатлык сәүдәгәргәме? Каган йомышы белән Фанәгүргә килеп, ил серен җыеп йөрүчегәме?

Кубрат хан ышана иде, төптәңрене тәмам фаш итү өчен сәүдәгәрләр барысын да сөйләр, сөйләми хәле юк. Шуннан соң хан барлык кавханнарны да җыяр, җыяр да төптәңренең башын кисәргә, яисә ат коерыгына тагарга хөкем чыгарыр... Тик халык аны аңлармы? Төптәңре Ирсанның халык алдында абруе зур, күбесе аны чынлап та тәңре илчесе дип белә. Юк, бу юл белән төптәңрене җиңеп булмастыр.

Кубрат хан бүгенге көнгә кадәр төптәңре белән бәхәсләшеп кенә килгән иде, хәзер эшләр җитдиләнде, икесе ике ярда басып сөйләшә башладылар. Бал корты да үзенә тимәсәләр чакмый ич, бар эше бал җыю, ә инде тияләр икән, ул шундук агулы угын сиңа батыра. Кубрат хан да моннан соң чагар, илгә хыянәт иткәннәрне, кем генә булмасын, кичермәс.

Мәгәр уйлана торгач, Кубрат хан бөтенләй башка бер фикергә килде. Иртәгә үк төптәңрене каганга илче итеп җибәрергә. Аннан исән-имин кайта икән... Юк, болгар алыплары аны юлда ук... Алыплары түгел, җәлладка йөкләр ул бу бурычны. Әйе, җәллад аны юлда ук...

Икенче көнне иртән-иртүк көн тууга дога кылгач, Кубрат хан төрмәдәге төптәңре Ирсанны сарайга китерергә кушты. Ханнан бу боерыкны алган каравылбаш аңламый торды. Нигә дип кичә япкан җинаятьчене бүген чыгарырга да?..

— Төптәңре Ирсаннымы?— дип кайтарып сорады каравылбаш.

— Әйе, төптәңре Ирсанны, каравылбаш.

Каравылбаш чыгып китүгә, хан җәлладны чакыртты. Җәллад хан каршына килеп баскач, хан аңа текәлеп карап алды. Ничәмә ел хезмәт итә инде аңа җәллад, хан аның беркайчан да елмайганын күрмәде, ул бары тик хан боерыгын үтәде.

— Карабаш, син миңа күп еллар хезмәт итәсең. Тугры булдың, сүзем тыңладың, һәр кушкан йомышым җиренә җиткереп башкардың. Тыңла ханың, Карабаш. Бүген өйләдән соң төптәңре Ирсан Биләмҗиргә чыгып китәр, аның янында юлдашлары булыр. Алар Биләмҗиргә барып җитмәскә тиешләр. Кул астыңа ун алып ал. Аңладыңмы ханың?

Җәллад Карабаш гадәттәгечә дәшмәде, карусыз килешеп, боерыгыгыз үтәлер, олуг хан, дигәндәй, баш иде, аннары борылды да чыгып китте.

Җәллад Карабаш чыгып киткәч, Кубрат хан урыныннан кузгалды, йөренеп килде. Барысы да ул уйлаганча барса, кара җылан каганның коерыгына басачак Кубрат хан. Беренчедән, кан дошманына әверелеп барган төптәңре Ирсаннан котылачак, икенчедән, сәүдәгәрдән каганның уй-теләген сөзеп алачак, өченчедән, өлкән угланы Батбайны котыртучыдан аерып алачак. Илхан сукыр тавык кебек, ә сукыр тавыкка сукмак кирәкми. Күрер-белер дә булган хәлләрне, үзе үк атасы алдына килеп баш орыр.

Аяк тавышы ишетелүгә, Кубрат хан тәхетенә утырды. Тынычлану аңа хәтта тәхетенә утыргач та килмәде.

Төптәңре Ирсан килеп керде, бу юлы ул ханга баш ормады, туры ханга карады. Кубрат хан кайнап торган ачуын чак кына эченә йотып җибәрә алды.

— Мин уйладым-уйладым да, төптәңре Ирсан, сине каганга илче итеп җибәрергә булдым. Йомышың шуннан гыйбарәт булыр: каган чынлап та Болгарга яу чабарга уйлыймы? Ничә төмән алае бар? Яу чыгар айлары, көннәре? Каган белән килешү якларын сиңа йөклим, төптәңре Ирсан. Мин әйттем.

Төптәңре Ирсан ханнан һич тә моны көтмәгән иде. Ул бер мәлгә ни

әйтергә белми аптырап калды. Шул мизгел эчендә ул ханның сүз сөрешен анларга теләде. Болгарның олуг ханы каганны яклаган кешене нигә дип Биләмҗиргә җибәрә? Аучының бүрене оясына җибәрүе белән бер бит бу. Вакытны сузу нияте белән төптәңре хан алдына килеп баш орды. Бу аның ышанычыңны акларммын, мин элеккечә үк синең колың дип әйтергә теләве иде, әмма аның кирә-кергәч тә баш ормавы, һәм менә торып-торып маңгаен идәнгә бәрә-бәрә ант итүен олуг хан ошатмады, төптәңренең бу кыланышына авыз чите белән генә елмаеп куйды. Бәхәссез, хан ниятендә ниндидер мәкер корде төптәңре, әмма бу кадәр кыска арада ханның ни теләвен аңлавы кыен иде. Ирсан үзен тәңре кулына тапшырырга булды. Ул үз гомерендә беренче тапкыр диярга була тәңренең булуына ышанды. Аның уенча, төне буена төрмәдә дога кылган Ирсанның моң-зары, ниһаять, тәңрегә барып җиткән һәм ул үз чиратында олуг хан күңелендәге коткыны җуйган, менә хәзер хан янә аның белән дустанә яшәргә тели — Биләмҗиргә илче итеп җибәрмәкче. Болар берсе дә хан теләге түгел, тәңре кодрәте.

— Иә, нигә телең йоттың, төптәңре?

— Тел йотмаслыкмы, олуг хан,— төптәңре Ирсан янә хан каршында баш орды.— Тел йотмаслыкмы,— диде төптәңре, чарасыздан аның күзләре яшь белән тулды.— Ышанычыгызны акларга тырышырмын, олуг хан, гомерем дә кызганмам.

Төптәңре ханга күз төшереп алды. «Иелгән башны кылыч кисми»,— дип уйлады ул.

— Иә, ни әйтерсең, төптәңре.

— Ышанычны ышаныч белән акларммын, олуг хан.— Үзе уйлады: «Каганның төптәңресе Үрәгәйгә картлык килгән, соңгы көннәрен яши икән инде. Каган мине рәнҗетмәс, Үрәгәй урынына төптәңре итеп куяр, менә шуннан соң без синең белән алышып карарбыз, Кубрат хан».

— Сиңа зур йомыш йөклим, төптәңре.

Төптәңре Ирсан янә хан алдына баш орды.

— Коткар мине, олуг хан. Җибәрмә Биләмҗиргә илче итеп. Атам кылган явызлыкларны каган белә, ул мине ат коерыгына тактырыр, мичкәгә салып диңгезгә җибәрер...

Төптәңре әкрен генә башын күтәрде, хан йөзенә күз сирпеп алды. Хәйлә килеп чыга булса кирәк, хан аның сүзенә колак салды, ниятен аңларга теләгәндәй бер мәлгә сүзсез торды.

— Мин сине Биләмҗиргә зур йөк белән җибәрәм, Ирсан. Шул йөкне башкарып кайтканда гына мин сине кичерә алырмын.

— Олуг хан, Болгар өчен мин барысын да эшләрмен.

Хан таягын күтәрде, нидер уйланып идәнгә төшерми торды, ахыр хәл итте — төшерде. Бу аның: алып китегез күз алдымнан бу кешене дигән шартлы хәрәкәте иде.

Шушы көннән Кубрат хан сарайдагы һәр өченче кешегә шикләнеп карый башлады: каган шымчысы түгелме? Хәтта беренче ярдәмчесе Актай кавхан белән сөйләшкәндә дә әйтер сүзен әйтеп бетермәде.

Атна-ун көнгә бер Кубрат хан сарай мәктәбенә бара иде. Ул анда нәниләргә Румнан килгән җимешләр өләшә, әле бер баланың, әле икенче баланың башыннан сыйпый-сыйпый балаларны багучы хатыннан: «Бусы кемнеке, бусы кайсы илханныкы янсә кавханныкы?»— дип сорый, кайберләрендә үз чалымнарын күреп, куанып бетә алмый иде. Сарай мәктәбендә бары тик илханнарның, кавханнарның, тарханнарның, Кубрат ханга аерата якын булган кешеләрнең балалары гына укый иде. Аларны грек Константин укыта, шунда ук аларны орыш уеннарына өйрәтүчеләр дә бар.

Сарай мәктәбенә килеп керү белән ханны балалар сырып алды. Хан аларга биленә таккан күн капчыктан уч-уч җимешләр ташлады. Балалар чыр-чу килеп җимеш җыярга сибелделәр, бары тик арадан берәү

генә үлән арасына сибелгән җимешләргә исе китмәгән кебек басып торды. Хан аны үз янына чакырып алды, капчыктан чыгарып бер җимеш сузды. Малай җимешне алды, ханга баш иеп рәхмәт әйтте, һәм бер читкәрәк китте. Шунда аңа калган балалар берәм-берәм җимеш китереп бирә башладылар. Хан малайны бармак селкеп кенә үз янына чакырып алды.

— Кил әле кил, минем яныма кил!

Ир бала аптырый калды, әле кулындагы җимешләргә, әле аптырап калган малайларга карады, шулай да хан янына килми булдыра алмады.

— Кем угланы буласың, атың ничек?..

— Атам кавхан Савир буладыр, анам...

— Анаңның аты юкмы әллә?

— Анамның аты Артык, олуг хан.

— Олуг хан,— дип кабатлады Кубрат хан.— Кем өйрәтте моны сиңа, миңа олуг хан дип дәшергә?

— Укытучы Константин, олуг хан.

— Җавапка остасың, углан. Тик миңа әйт әле, нигә сиңа иптәшләрең һәрберсе берәр җимеш биреп чыкты?

— Минем атам олуг кавхан, ә аларның...

— Бар, һәрберсенә җимешләрен өләшеп чык. Берсен дә калдырма. Кулыңда ничә бармак синең?— Малай бармакларын тырпайтты.— Дөрес әйтәсең — биш. Ә икенче кулыңда?..— Малай икенче кулының бармакларын тырпайтып җибәрде, кулындагы җимешләре үләнгә сибелде.

— Тагын биш. Ике кулыңда күпме була?..

— Ун, олуг хан.

— Ун, углан, ун,— диде Кубрат хан һәм китеп барды.

Аның кәефе юк иде. Балигъլар укыган бүлеккә китте. Мәктәпләрне укытучы сызымнары буенча эшләткән иде Кубрат хан, үзенә таба килүче укытучыны күргәч, хан әллә нишләп китте. Укытучыны күргән саен Кубрат хан үзе дә аңлап бетермәгән уңайсызлану тоя иде. Укытучы аңа: «Хан, сез минем хатларны укый барасыз икән бит?»— дип әйтер кебек иде.

— Хәерле киләсез, олуг хан!

— Хәерле, хәерле, укытучы! Үзең тазамы соң?

Константин йөрәк турына кулын куеп, баш иде, ханны алдан уздырып җибәрде.

— Сезгә рәхмәтемнең чиге юк, олуг хан. Бабам Симокаттаның башы җиденче күктә.

— Симай ата ул биредә, укытучы, ишетәсеңме, Симай ата. Бабаң сөйкемле карт. Ә син, укытучы, Патшакаланы сагынасыңмы?

— Юк, олуг хан. Кала миңа ят, ә менә калада яшәүчеләр...

«Императрица Мартинаны?»— дип сорарга иткән иде Кубрат хан, укытучы йөзендә сагыш күреп дәшмәде.

— Болгар балалары зиһенлеме, укытучы?

— Аллаһы-тәгалә балаларның барысына да тигез итеп зиһен өләшә, олуг хан. Калганы кешенең үзеннән тора.

— Алай булгач ахмаклар каян килә соң, укытучы?

— Ахмакларны надан дәүләт бирә, олуг хан.

Хан укытучыга сирпелеп алды, әмма дәшмәде, атлавын белде.

— Әйт әле, укытучы, аллаһы-тәгалә адәм дөньяга килгәнче үк аның кем буласын беләме?

— Юк, белмим, олуг хан. Язмышны һәр кеше үзе ясый.

«Син дә үз язмышың үзең ясадыңмы? Император сине хатыны Мартинага гашыйк булганың өчен Фанәгүргә сөрде. Ә син, укытучы, язмыш дисең. Язмыш ул — тәңре сызган юл. Һәр кешегә туганчы ук юл

сыза тәңре, шул юл белән син бара-бара гомер итәсең. Үлемең дә тәңре кулында. Ул аны әллә кайчан беләә, әллә кайчан сызып куйган...»

— Укытучы, менә бездә кара болгарлар һәм ак болгарлар бар. Халык шулай дип йөри. Укыган болгарны белекле, диләр. Тамга танымаганны элек-электән кара болгар, дигәннәр. Белекле, димәк, ак болгар. Аннары, укытучы, язмышны да тәңре бер дә син дигәнчә аңлатмый. Кешенең язмышы ул дөньяга килгәнче үк тәңре тарафыннан язылып куела.

— Кем ул тәңре, олуг хан. Сез инанган алла түгелме?

— Мин табынган алла, укытучы.

— Сәер, олуг хан, каршы әйтергә җөрьәт итәм. Беркем дә дөньяга хан булып тумый. Сезгә Бөек Болгарның олуг ханы булу өчен ун еллар буена ашиннар династиясе белән орышырга туры килә. Әгәр дә мәгәр, сез ул вакытта җиңелгән булсагыз...

— Ярар, укытучы, калдырып торыйк бу бәхәсне. Балигъ угланнар кая?.. Хәрби уеннарда дисең... Укытучы, мин бу сорауны философка да биргән идем: греклар аллаларын адәм заты итеп күз алдына китерәләр. Кеше кеше күңеленә сыя аламы? Төрки тәңресе күк йөзе, кояш. Бар нәрсә дә: яхшысы да, яманы да күк-кояш астында кылына. Күк астында барчабызга да урын җитәрлек, нигә кирәк булды икән акыллы грекларга адәм баласын алла итү?

— Кеше сурәтендәге алламы ул, күк-кояш йөзендәге тәңреме, олуг хан, күңелең инанган нәрсә булыр. Бөтен хикмәт, халкың кабул иткән йоланың дәүләт эчтәлегенә җавап бирүендә. Грекларда ул христос, болгарларда тәңре...

— Атаң Феофан тикмәгә генә сине Болгарда калдырмаган икән, укытучы. Илеңдә булсаң, әллә кайчан башың чапкан булырлар иде.

— Минем башым башка нәрсә өчен чапкан булырлар иде, олуг хан.

— Акыллы кеше — дәүләт терәге, укытучы. Ә син...

Кубрат хан шып туктап калды. «Ни сөйли ул? Акыл сата. Атасы Феофан калдырмады аны, Кубрат хан да алып калмады, укытучы Константинны император Ираклий хатыны Мартинаны яраткан өчен сөргән. Яраткан өчен! Мин ни өчен Балкыр илханга сөрдем кавханым Савирны? Миңа каршы сүз әйткән өчен, түгелме?..

— Мин белекле болгарларны дәүләт терәге булырлар дип укытам, грек Константин.

— Үрнәк дәүләт төзү турында сезгә кадәр меңләгән патшалар, ханнар, шаһлар хыялланган, олуг хан. Әмма әле булса төзи алганнары юк. Башта аларның яшь чактагы хыяллары тормышка ашмаган, шуннан ул дуслары арасыннан дошманнар эзләп таба башлаган, ашмаган хыялларының үчен алардан алган, аннары аңа картаю килгән — үзе турында гына кайгырта, үз-үзен карауга гына күчкән. Әйтик, борынгы Мисыр фиргавеннәре үзләрен таш пирамидалар белән мәңгеләштерергә омтылганнар һәм алар моңа күпмедер күләмдә ирешкәннәр дә. Ассирия патшалары асылма бакча-сарайлар салдырганнар, шуның белән үзләренә бу дөньяда җәннәт ачмакчы булганнар. Грек императорлары исә дөньяда тиңе булмаган храмнар төзегәннәр, ә менә аларның хыялындагы идеаль дәүләт барыбер тумаган. Патшалар, ханнар, шаһлар өчен туса да, халык өчен тумаган.

Кубрат хан туктады, таш эскәмиягә утырды, укытучыга янәшәсеннән урын күрсәтте.

— Нигә син бу хәтле кыю, укытучы?

— Идеаль дәүләткә, идеаль йола кирәк, олуг хан.

— Иң яшь йола кемдә, укытучы?

— Иң яшь йола сарациннарда, олуг хан. Әмма пәйгамбәр титулы алгач, алла илчесе изге Мөхәммәт тә йоласына кылыч белән юл сала.

— Христианнар?

— Алар да ким куймыйлар.
— Болгар нинди йола алырга тиеш, укытучы?
— Дәүләт төзелешендә камил йола, олуг хан.
— Сине тикмәгә генә кумаган икән император, укытучы. Әңгәмәң кызык булды. Уйландыра. Тагын бер сорау сиңа, укытучы. Камил дәүләт өчен әлеге бер йола да ярамый дидең, каян алмак кирәк ул йоланы?
— Болгар нindidер йола алырга соңга калды, яңа йола яңа дәүләт төзелгәндә кирәк, хәзер Болгарда тәңре өстенлек итә.
— Иң камил йоланы булдыру авырмы, укытучы?
— Иң камил йола — гадел хан, гадел император. Дәүләт башлыгы яман кеше икән, аның өчен йола чаршау гына, явызлык кылган эшләрен каплау өчен корылган чаршау. Менә күрәсезме, хан — укытучы бармакларын тырпайтты.— Кулдагы бармаклар да тигез түгел, йолалар ничек тигез булсын, ди. Инде менә хәзер карагыз, хан,— дип йодрыгын йомды укытучы.— Иң камил йола барлык халыклардагы иң гадел гореф-гадәтләрне эченә җыйган йола булыр, олуг хан.
— Әйт әле, укытучы, базилевс алла илчесеме?
— Император Ираклий минем кебек үк гади бер кеше, олуг хан.
Кубрат хан беравык сүзсез утырды, аннары кузгалып китте, укытучы аңа иярде.
— Төптәңре Ирсан: «Тәңре мине хан итеп дөньяга китергән», дип бара. Хакмы ул?
— Мөмкин булса, бу соравыгызга җавап бирмәс идем, олуг хан.
— Нигә?
— Олуг хан, патша яисә хан булып алган һәр кеше дәрәҗәсе үсә барган саен үзендә алла кодрәтләре күрә, иң хәтәре — тора-бара ул моңа үзе дә ышана башлый. Әмма аңа да үлем килә. Бактың исә, ул да гап-гади бер кеше икән: туа, үсә, чәчкә ата, картая, үлә. Үлемсез бары тик мәхәббәт кенә, олуг хан.
— Мәхәббәт?!— дип гаҗәпләнә калды хан.
— Әйе, олуг хан, мәхәббәт. Бары тик ул үлемсез. Кешене чир түгел, көнчелек үтерә. Аллаларның алласы — акыл булыр, олуг хан.
— Мин сине император кууына бөтенләй шаккатмый башладым, укытучы. Синең дусларың бармы? Бар дисең. Мәхәббәттә көчле кеше дуслыкта таркау булыр, диләр. Барысы да тәңредән.
— Алла юк, олуг хан. Күк йөзе без яшәгәнне үзе дә белми.
— Укытучы, бабаң хакына әйтәм, син әйтмәдең миңа бу сүзләреңне, мин ишетмәдем. Эт симерсә, иясен тешләр, ди. Болгарда мин сиңа бөтен булган ирекне бирдем, ышанычым аяк астына салып таптама. Болгарда җәзаланган һәр өченче кеше башсыз күмелә.
— Олуг хан, кешегә хокукны башкарган эше бирә. Болгар дәүләтен дәвам итәрдәй угланнарыбыз бар, аларның күбесен мин укыттым. Мин аларга ышанам, юлларын дөрес сайларлар.
— Укытучы, житеп торыр, арыдым мин синең әңгәмәңнән. Син, Константин, сәүдәгәрләр сараена баргала. Хакыйкать бәхәстә табыла. Бәхәстә белем табылыр, бәхәстә өмет чагылыр, диләр.
— Шулай итәрмен, олуг хан.

* * *

Кояш баеганнан соң диңгез яклап дымлы һава агыла, көндез бик бөркү булгач, Кубрат хан Кызсарайның тәрәзәләрен ачып куярга кушкан иде, кичке салкынча һава килә башлагач, тәрәзәләрне яптырды, берсен генә ачык калдырттты. Кубрат хан диңгез ягыннан күзен дә алмады. Фарсы тимерчеләре ясаган тимергә алтын йөгерткән челтәрләр аша бүлмәгә көннең соңгы кояш нурлары төшә, дымлы диңгез һавасы йомшак ястык булып идәнгә җәелә. Ханга һава җитми кебек иде. Савир кавхан артыннан киткән йомышчы алай һаман кайтмый.

Кубрат хан тәрәзә төбенә утырды. Биредән Фанәгүр уч төбендәгедәй күренә. Кала биек дивар белән уратып алынган, диварларга грек утын ата торган ташаткычлар да куелса?.. Каган Фанәгүр кебек каланы ни тырышса да ала алмас, камап торыр-торыр да китеп барыр. Китеп барыр бер елдан тагын әйләнеп килер. Ни кылырга? Әллә соң тәптәңрене калада калдырырга булганмы? Кан дошманыммы ул минем? Юк. Юк димә, ул минем тәхетемне алырга өндәүче, илханнар күңеленә коткы салучы. Ни генә булмасын, хәзер соң инде. Төптәңре Ирсанны берәү дә коткара алмас. Төптәңре Ирсан юлда, тиздән аларны җәллад Карабаш куып җитәр...

Кыска гына вакыт эчендә үтереш-суеш күз алдына килүгә, Кубрат хан өшеп китте, җиләненә төренә төште. Көтригурлар ханы Көбер ничегрәк кабул итте икән апасын?.. Илбарыс буйтур кайларда, ниләр кылып йөри икән? Нигә Кодрак илханнан хәбәр юк?.. Шулай ук Эске кирмән чыннан да камауда микәнни?.. Әгәр дә мәгәр Эске кирмән камауда икән, буйтур шунда таба кузгалгандыр. Хак анысы, буйтурга хан андый боерык бирмәде, мәгәр буйтур моны үзе эшләр, чөнки Кодрак илхан авыр хәлдә — камауда. Анда Чәчкә, анда Болгарның чиге, анда Болгарның Төн илләре халыклары белән сәүдә итү төбәкләре.

Кубрат хан калада бар биналардан да биек калкып чыккан чиркәү манарасына күз төшереп алды. Әнә нинди мәһабәт, күркәм биналар сала христиан динен өстен чыгару өчен греклар. Нигә без дә тәңрене шулай күтәрмибез икән? Артык ышануданмы, башка бер-бер сәбәп бармы? Төптәңре Ирсан Биләмҗиргә китеп бара, аны тиздән... Үзебезнең тамырны үзебез кисмибезме икән?..

Шул вакыт Кубрат хан янына кече кавхан керде.

— Олуг хан, Илбарыс буйтурдан хәбәрче бар.

— Дәш, керсен!

Кубрат хан кабаланып, хәбәрче кертеп биргән тузны сүтте, хатның тамгасына игътибар итте. Тамга Илбарыс угланныкы иде.

«Олуг хан, менә ике көн инде каган бәге Җаек безне куа килә. Җаек бәк Әтилнең сул ягында, мин уң ягында. Без әкрен генә Эске кирмәнгә таба хәрәкәт итәбез. Җаек бәк безнең якка чыгарга кыймый, миндәге алайның санын белмәүдән дип уйлыйм. Җаек бәкнең төп көче үзе белән түгел кебек. Миңа калса, ул кемнедер көтә. Олуг хан, кыюлыгым җитеп киңәш итәсем килә: Балкыр илхан алае белән Эске кирмәнгә таба хәрәкәт итә башласа, Җаек бәк бу кадәр кыю йөрмәс иде. Җаек бәктә утыз мең алай бар, диләр. Аңарда барлы-юклы ун мең алай, олуг хан.

Илбарыс буйтур».

Кубрат хан өстен алыштырды, сарайга ашыкты. Атын юыртып барганда ул уйланды. Димәк, Көбер кайнеше Илбарыс буйтурга йырмак алып биргән. Бик шәп. Хәзер Балкыр угланга хәбәр салырга булыр. Каганның юл өстенә төшсен. Каганга Фанәгүргә килергә башкача юл юк.

Болай булгач каган Эске кирмәнгә бармаячак, туры бире чыгачак. Йулыш каган Җаек бәгеннән хәбәр көтә бугай. Хәбәр килү белән каган Фанәгүргә кузгалыр. Күпме алай белән килергә исәбе каганның?.. Монысы Кубрат ханга караңгы иде.

Сарайда аны философ көтә иде. Кубрат хан тәхетенә менеп утыругач Иоанн Фасиан аның каршына килеп басты, түбәнчелек белән ханга баш иде.

— Олуг хан, вакытлы-вакытсыз борчуым өчен кичерә күр. Укытучым булган иде, иртәгә балигъ булган оланнар чыга икән, рәхим итсен олуг хан диде.

Кубрат хан философка елмаеп карады.

— Утыр, философ, утырып сөйләш. Укытучыга мең рәхмәт, игелекле кеше. Булырмын мин анда, философ. Минем сиңа киңәшем бар, философ. Мәктәп бетергән угланнарның күбесе һөнәрчеләр. Бәхәссез, һөнәрчеләр дә кирәк. Әмма дәүләт бер һөнәрчеләрдән генә тора алмый. Иң әүвәл аңа, философ, җәйләү-биләмәләрен саклау өчен алай кирәк.

— Олуг хан, болгарлар элек-электән малчылык белән көн күргәннәр. Халкың синең мал үрчетә, иген игә, аларның тынычлыгын саклау — синең эш, балаларыңа белем бирү — минем эш һәм укытучы эше.

Шулай диде дә философ борылып чыгып китте. Кубрат хан аны туктатмады, дәшмәде.

Хан йомышчысын дәште.

— Урыннарыннан кузгатып булса да Алтай белән Култай аксакалларны чакырыгыз! Тиз йөрегез!

Көттеребрәк булса да аксакалларны хан янына алып килделәр. Ураган агасы белән орышта йөргән аксакалларның бөкреләре чыккан, битләрен җыерчыклар баскан, өсләрендәге тире киемнәреннән ят ис килә иде.

— Утырыгыз, аксакаллар.

Аксакаллар Ураган каганның берсе уң кулында, икенчесе сул кулында орышкан. Ураган каган ырубашлар арасында барган чуалышларда һәлак булгач, Култай кавхан көтригурлар ханы Тугрыга ияреп китә, Алтай кавхан исә яшь хан Кубрат янында кала. Башта Тугрыханга ияреп киткән Култайга җан ачулары чыга Кубрат ханның, әмма язмышын Аппак белән бәйләгәч, кавханны кичерә, хәтта аңа Фанәгүргә кайтырга рөхсәт итә.

Аксакаллар бер-берсен яратмыйлар, Тугырханга ияреп киткән өчен Алтай кавхан Култай кавханга ачулы, картаеп киләләр, әмма үзара тыныша алганнары юк.

Аксакаллар хан күрсәткән урыннарга утырыштылар.

— Тәңре үзеңә көч-куәт бирсен, хан!

— Рәхмәт, олуг кавханнар.

— Безгә нинди йомышы төште икән ханның?

— Мин сезнең киңәшегезгә мохтаҗ, аксакаллар.

— Киңәш,— диештеләр кавханнар һәм күзгә-күз карашып алдылар.— Әйе, без ишеттек, хан, игелегең артып төптәңре Ирсанны Биләмҗиргә илче итеп җибәргәнсең икән дип. Хакмы шул?

— Хак, олуг кавханнар. Ил өстенә афәт килгәндә ата-ул — коралга, ана-кыз өметкә ябышыр, ди. Төптәңре Ирсан миңа каршы илханнарны котыртып йөри. Ил эше белән йөрүе игелеккә булыр дип уйладым.

— Шәп иткәнсең, хан. Илче сукмагы суынмаса, ил-илгә суынмас.

— Минем кайгым төптәңре түгел бүген, аксакаллар. Минем кайгым Эске кирмән, Кодрак илхан. Каганның бәге Җаек Эске кирмәнне камаган икән. Йулыш каган Фанәгүргә яу чыкмакчы. Ни кылыйм, аксакаллар, каганны Фанәгүрдә көтимме, каршы чыгыйммы? Киңәшегез әйтегез!

— Киңәш,— диде Алтай кавхан.— Нинди киңәш бирик сиңа, хан Ашин ыруы гомер-гомергә Болгарга яманлык кылды. Фанәгүргә килсә, калабыз ала алмаса да болыннарыбызны, грекларның басуларын гөл-бакчаларын кара җир итәр. Каршы чык каганга, шул булыр минем сиңа киңәшем, хан.

— Хан, тыңлама син Култайны. Гомер-гомергә ялагай булды, бүген берне сөйләсә, иртәгә икенчене сөйли. Ялагай карсак төлке ул.

— Минме карсак төлке, минме ялагай?! Хан, бир кылычың, бәхәсне корал аклар, диләр. Бир, хан, кылычың!

— Шапырынма, калай этәч,— дип күтәрелде Алтай кавхан.— Шапырынма, ялагай карсак.

Картлар чәчрәп торып бер-берсенә килә башлауга, Кубрат хан әмер ...ягы белән дыңк итеп идәнгә төртте. Шундук тәхет бүлмәсенә дүрт ...йбалталы алып килеп керде. Айбалталы алыпларны күрделәр дә олуг ...авханнар уч төпләренә тамак кырып, урыннарына утырыштылар. Куб...ат хан сабырланып калган картларга карап, мыек астыннан гына ел...аеп куйды.

— Киңәшең әйт, Алтай кавхан?

— Минем киңәшем шул булыр, хан. Син үзең аңа яу чап. Дәш уг...аннарың, җый алаең, яу чык.

— Киңәшегез өчен рәхмәт, аксакаллар. Инде хушыгыз!

Аксакаллар дәрәҗәләрен белеп кенә кузгалдылар, кәкре талдан ...исеп алган таякларына таяна-таяна чыгып киттеләр.

«Хак әйтәләр, яшьлек белмәүдән интегер, картлык кыласын кылып ...лгермәүдән интегер дип. Киңәшләре хак, бүген үк Батбай белән Ас...арух угланнарга хәбәр салырга: Маңыч елгасына килсеннәр, үзем ...лаем белән шунда юнәлермен. Грек — калада, төрки — далада ор...шыр. Фанагүрне аксакалларга калдырам, сакласыннар».

Кубрат хан таягын янә идәнгә дөңкеде, шундук каршына алсакчы ...илеп керде.

— Кече кавхан Актайны дәш!

Кече кавхан Актай килеп керүгә, хан тәхетеннән кузгалды.

— Кавхан, Батбай илхан белән Аспарух илханга хәбәрче чаптыр. Бар булган алайларын җыеп, Маныч елгасына таба кузгалсыннар. Ис...тәлекче яз: Сәне алты йөздә кырык икенче язның тычкан елында Бол...гар ханы Кубрат угланнары белән каган алаена каршы Маныч елгасы...на таба кузгалды. Кече кавхан, бу әмерем сиңа: хан болынындагы яу ...атларын иярләп, йөгәнләп алыпларга өләшсеннәр. Мин әйттем.

— Баш өсте, олуг хан. Олуг хан, кыеп әйтергә базам: җәллад Ка...рабаш кайтты, керергә сорый.

— Керсен,— диде хан, йөзен үзгәртеп.

Кубрат ханга кинәт курку килде. Төптәңре Ирсанның үлеме шулай куркыттымы. Җәллад Карабаш беркайчан да аның боерыкларын үтә...мичә калмады, барысын да җиренә җиткереп кайткандыр.

Җәллад Карабаш аның янына кыяр-кыймас кына килеп керде.

— Йә-йә, ни булды?

— Олуг хан, боерыгың үти алмадым, төптәңре Ирсанны Батбай ил...хан аланнар иленә урлап алып киткән.

Кубрат хан иркен сулап алды, эченә җылы йөгерде.

— Төптәңре исән, аны Батбай илхан урлаган. Һәм син аны урлат...тың?

— Олуг хан, Батбай илханда өч йөзләп алай иде, без һични кыла алмадык.

— Бар кит! Кит, югал күземнән! Сыртың каезлыйсы иде дә синең моның өчен... Ярый, оныт ул турыда, Карабаш. Ишетәсеңме, оныт!

Җәллад Карабаш чыгып китүгә, Кубрат тәхетеннән торды, йөренеп китте. «Барсың икән әле, тәңрем, барсың икән,— диде ул, әллә куаныч...тан, әллә ачудан.— Юк, ачудан түгел, куанычтан. Куанычтан да түгел, ...барсәдән соң?..»

— Кече кавхан, миңа каган яучыларын китер. Әйе, әйе, миңа, менә ...монда, тәхетем каршына.

— Яучыларны төптәңре Ирсан белән озаттык бит, олуг хан.

— Шулай бит әле. Вакыт төн инде, олуг хан.

— Каган сәүдәгәре Яматны китер дияргә иткән идем мин, кече кавхан. Соң булса да китер. Менә монда, тәхетем каршына.

Сәүдәгәр кергәндә Кубрат хан тәхетендә утыра иде инде. Каган сәүдәгәре Ямат бәк Кубрат хан янына узды, баш орды. Хан итек ба-

шын чапан чабуы астына яшерде, яратмый иде хан итек башын ялаучыларны.

— Тор, сәүдәгәр, тыңла. Син каган йомышын йомышлый алмадың. Син каган сәүдәгәре, каган сине үзе хөкем итсен. Мин сине Биләмҗиргә кайтарып җибәрергә булдым. Әйе, Ямат бәк, сиңа мин тормыш бүләк итәм. Әмма ул бүләкне минем йомышым йомышласаң гына алырсың: каганга менә бу хатны тапшыр. Киңәш итәм: акылың алдан аягың арттан йөрсен. Хан үтенечен үтәмәсәң, тәңре безне теге дөньяда булса да очраштырыр, тәңренең кодрәте зур.

Сәүдәгәр хатны кулына алды, авырлыгын тойгандай тотып торды, аннары иснәп карады, хаттан дала үләне исе килә иде.

— Кече кавхан Актай, Йулыш сәүдәгәренә ат бир, биш көнлек азык бир.

Ямат бәк янә хан аягына егылырга иткән иде, аны ике яктан ике алып эләктереп алдылар һәм җилтерәтеп алып чыгып киттеләр.

## 22

Илбарыс буйтур Көбер ханнан алган бер төмән алае белән уң як ярдан Эске кирмәнгә күтәрелә, аның һәр адымын күзәтеп, Җаек бәк елганың сул ярыннан бара иде. Икесе дә ашыгалар, атларын бик сирәк ял иттерәләр иде. Җаек бәкнең елга аша чыгарга теләмәвен буйтур аңламый иде. Шуннан буйтур хәйләгә кереште. Ул алаен дүрт төркемгә бүлде һәм Җаек бәк албагучылары күзәткән төбәкләрдә уратып-әйләндереп ике-өч тапкыр уздырды. Буйтурның тизрәк Эске кирмәнгә җитәсе килә иде. Анда Чәчкә, анда Кодрак илхан.

Әле уратыбрак, әле яр буйлап юыртып барганда Илбарыс буйтур аръяктан күзен дә алмады. Кин болынга килеп чыктылар һәм шунда кунарга булдылар. Көтригурлар үзләре белән ерактан күрүче хатыннарын йөртәләр. Буйтур аларны Камай багатырга бирде.

— Багатыр,— дип кычкырды буйтур.— Камай багатыр, аръякта хәзәрләр күренәме? Хатыннарың карасын әле.

Камай багатыр килеп тә җитте.

— Буйтур, Җаек бәкне күрүче юк, әллә монда, әллә юк. Күренми. Минемчә, буйтур, хәзәрләр икегә бүленгәннәрдер. Җаек бәк төп көче белән Эске кирмәнне камауда тотадыр, ә монда йырмак алаен җибәргәндер. Күп булсалар бире чыгарлар иде, орышырлар иде, буйтур.

Шул чак хатын-кызларның берсе кычкырды:

— Аръякта хәзәрләр! Алайның очы күренми. Ял итәргә каршы якка туктадылар!

— Нишлибез, буйтур, кунабызмы, кузгалабызмы?

— Кунабыз, атлар йончыды. Боер: һәр ике якка каравыл алыплар җибәр, ашчылар казан ассыннар.

Шулай диде дә буйтур атыннан төште, сул кулы аның Кашкасын тышаулап җибәрде. Буйтур ияр өстенә утырды, яр кырына килеп җитеп урнаша башлаган хәзәрләргә карап тора башлады.

Ул арада хәзәр алыплары белән болгар-көтригур алыплары уктан алышка керештеләр. Әмма тегеләрнең дә, боларның да уклары ярга җитми иде. Шуннан берсен-берсе мыскыл итү, көлешү китте. Илбарыс буйтурга бу ошамады, алыпларга укларын әрәм итмәскә кушты. Ук йөртүчеләр дә сукраналар, алар да уктан атышкан алыпларны орышалар иде. Кара чәчле, ак тәнле көтригурлар кәҗә сакаллы хәзәрләрдән кәҗә булып кычкырып көләргә тотындылар, тегеләре болгар-көтригурларны бүре булып улап мыскыл иттеләр.

Ук атышып, мыскыл итешеп туйгач, ике як ярдагы алыплар атлар белән әкәмәтләр күрсәтә башладылар. Сул як ярдагы хәзәр кола айгырын ике аягында йөртеп алып китте. Болгар мәргәне дә моны кабатлады. Ул да түгел бер хәзәр думбыра чиртергә тотынды, хәзәрләрнең

ты шул көйгә ауман-тәүмән килә-килә биеп китте. Болгарлар шаккатылар. Мәгәр болгар алыплары арасында да житезләр табылды. Бер алып атка сикереп менде дә ат чабып барганда ат корсагы астыннан әйләнеп кире ияренә менеп атланды. Җавап итеп аръяктагы хәзәр янә үзен атын ике аягында йөртеп алып китте. Хәзәрнең кыланышы буйтурга ошамады, кинәт аның күз алдына мәргән Ташбулат килде. Укларын ул аръякка житкерер, кәпрәеп атын ике аякта йөрткән хәзәрне укка алыр иде. Кайларда йөри икән ул кыю һәм батыр мәргән?.. Көтригур мәргәне угор князенең кияве булды да куйды. Угорлар Болгарга да, Хәзәргә дә, Роська да ясак түләмиләр, әмма өчесе белән дә бик теләп сәүдә итәләр.

Илбарыс буйтур күк йөзенә карады. Биектә-биектә тилгән тибрәлә иде. Үткен күзле тилгән. Аръякта күпме алай, син барысын да күрәсең, ә менә мине билгесезлек борчый. Кая Җаек бәк? Нигә күренми? Тилгән үзенә корбан эзлидер. Җаек бәк кемне эзли микән?.. Җаек бәк кирмәнне алса, Чәчкәне әсир итәр. Бер Чәчкәне генәме?! Юк, Җаек бәк кирмәнне ала алмагандыр. Кирмәнне алган булса, йырмак алаен безнең арттан җибәрмәс иде. Җаек бәкнең бу алае кирмәнне камап торган төп алайның хәбәрчесе. Эске кирмәнгә зур алай килә кала икән, Җаек бәк тиз генә аръякка чыгачак, котылу җаен эзләячәк... Бик ихтимал. Иртәгәдән дә калмый алар Эске кирмәнгә җитәрләр, орышсыз булмас. Илбарыс буйтур көтмәгәндә килеп чыгар һәм хәзәрләрне кисәр-кадар да тагын качып китәр, бераздан тагын килеп чыгар, тагын орышыр.

Шул вакыт аръяктагы хәзәрләр арасында шау-шу купты, бер төркем жайдак елганың югары ягына таба чапты, озак тормастан алар әйләнеп тә кайттылар. Илбарыс буйтур Камайга карады.

— Хатыннарны чакыр, багатыр.— Ераккүрер хатыннар буйтур янына килделәр.— Ни күрәсез, шул турыда сөйли барыгыз.

— Буйтур,— диде кулын маңгаена куеп хатыннарның өлкәнрәге.— Яр буйлап әсир төшкән болгар алыпларын алып киләләр. Ничә алыпмы?.. Жиде. Жиде алып күрәм. Алардан алдарак арбага утырган хатын-кыз күрәм. Арбасы ике көпчәкле...

Буйтур үткер күзле хатын янына ук килеп басты.

— Йә, йә, тагын ни күрәсең?

— Аларга бик күп алыплар иярген. Бик күп, буйтур. Арбадагы хатын-кыз күркәм киемле, түшендәге тәңкәләре ялт-йолт итә. Хәзәрләр атларын атлатып кына, ашыкмый гына киләләр.

Өске яклап төшүче хәзәрләр якынайган саен болгарлар яр кырыена елыша бардылар. Шик юк, хәзәрләрнең кулында болгар әсирләре иде. Ә менә хатын-кызы кем? Үткер күзле хатыннар танымыйлар. Менә арбанык кына якын килде, таллыклар янына туктады. Арбадан...

Илбарыс белән Камай беравыздан диярлек:

— Чәчкә, хан кызы Чәчкә!— дип әйттеләр һәм бер-берсенә карашып алдылар. Бу хәлгә ышану мөмкин түгел иде. Эске кирмән Кодрак илхан кулында... Шулай ук хәзәрләр кирмәнне алдылар микәнни?..

— Алай түгел, алай түгел, буйтур. Кирмәнне хәзәрләр ала алмас!

— Ә Чәчкә, хан кызы Чәчкә ничек хәзәрләр кулына әсир төшкән?!

— Буйтур, алар кирмәнне алганнар. Әнә, Җаек бәк үзе килә. Әнә, күрәсеңме тулпарын...

Бу чынлап та Җаек бәк иде. Җаек бәк килеп житәрәк, аңа каршы чапкан жайдаклар нидер әйттеләр, әмма бәк елганың уң ягына рәтләп күз дә ташламады. Жансакчыларына нидер әйтте һәм алар кәлешеп алдылар.

— Чәчкә Җаек бәк кулында!— дип беравыздан кычкырып җибәрделәр багатыр белән буйтур.

Илбарыс буйтур үзендә багатыр Камайның карашын тойды, ул аңардан сүз көтте, мәгәр буйтур бу мәлдә сүз әйтүдән гаҗиз иде.

— Чынлап та хан кызы Чәчкә бит бу, буйтур,— диде Камай.

— Күрәм,— диде, ниһаять, буйтур.— Исегез китмәгән кебек кыланыгыз. Багатыр, боер, алыплар учак-учак таралсыннар, ашарга утырсыннар.

Таллар артына ике-өч чатыр кордылар. Җаек бәк шунда юнәлде. Күп тә үтми, хәзәрләрнең сөрәнчесе яу кырына килде.

— Илбарыс буйтур, алаең Җаек бәк ягына алып чыксаң, бәк сине уң кулы итәчәк, хан кызын иленә җибәрәчәк.

Илбарыс буйтур яңак итен чәйнәде, дәшмәде, аның янәшәсенә сөрәнче килеп басты, буйтур ни әйтер дип, оран салырга хәзерләнде.

— Сөрәнче, әмер булмаячак. Сабыр итик. Җаек бәк безне тозакка каптырмакчы. Ашыкмыйк.

Аръякта сөрән салучы кычкырды да кычкырды. Шул бер үк сүзләрне кабатлады.

— Әйт, сөрәнче. Юкка тамагың ертма диген. Илбарыс буйтур бәк теләген кабул итми диген.

Болгар сөрәнчесеннән бу сүзләрне ишетүгә, хәзәр сөрәнчесе таллыклар арасындагы чатырларга таба китте. Чатырларны бер-берсеннән шактый ерак куйганнар. Сөрәнче иң арыга куелган чатырга кереп китте. шактый озак торганнан соң әйләнеп килде. Һәм бик озак дәшми торды. Болгарлар да, хәзәрләр дә сабырсызлана башладылар. Берничә хәзәр алыбы тез тиңентен суга кереп, яр башындагы болгарларны укка алмак булдылар, әмма уклар ярга җитәр-җитмәс суга чумдылар. Ниһаять, сөрәнче кулларын авызына куыш итеп куйды. Әмма сөрән салмады, болгарлар ягына уктан аткан алыпларга нәрсәдер әйтте, тегеләре ашыга-ашыга судан чыктылар, яр башына менеп утырдылар.

«Димәк, боларның бирешдән китмәскә исәпләре,— дип уйлады буйтур.— Без дә китә алмыйбыз. Җаек бәк белә, буйтур беркая да китмәячәк, чөнки эсир болгарларны, Кубрат ханның кызы Чәчкәне күреп алды. Аннары буйтурга кирмәнгә баруда ни файда. Иртәме-соңмы кирмән барыбер каганныкы булыр, иң мөһиме — алар кулында хан кызы Чәчкә иде. Җаек бәк нигәдер елга аша чыгарга теләми. Нигә? Әллә бар максаты хан кызы Чәчкәне кулына төшерү идеме?.. Шулай да булуы бик мөмкин ич. Йулыш каган хан кызына өйләнер, телиме моны, юкмы Кубрат хан, тора-бара ризалашыр...

Юк, алай дип уйлыйсы килми иде буйтурның. Йулыш каган Кубрат ханның кан дошманы, ул аңа кызын бирергә беркайчан да риза булмас. Риза булмаса ни, кыз бит инде каган кулында. Бүген-иртәгә хан кызын Биләмҗиргә илтеп җиткерерләр. Каган Кубрат ханга илче җибәрер... Килешер Кубрат хан, килешми кая барсын...

— Буйтур, сөрәнче дәшмәс булды. Иртә кичтән хәерлерәк дип уйлавыдыр Җаек бәкнең.

— Шулайдыр, Камай. Әйдә, ашыйбыз.

Ашап-эчтеләр, һәр ун кешегә учак алдылар. Буйтур һәр ун алыпка өчәр учак куярга кушты. Җаек бәк буйтурда алай аз дип уйламасын.

Кояш баеды. Буйтур һаман ияр өстенә утырып уйланды. Ул бөтен бер Болгар илен, җәйләү-биләмәләрен күз алдына китерергә тырышып карады. Кубрат хан Батбай илхан белән Аспарух илханга хәбәр салгандыр — Маңыч елгасы буена килегез. Балкыр илханның каганның йырмак алайлары белән орышып йөрүе бар. Төп орыш кайда булыр?.. Буйтур белми иде. Хәбәр килү белән Илбарыс төп орыш төбәгенә китәр, әмма ул башта Кодрак илхан янына барыр, аның уң кулына басар. Нинди хәлләрдә кулга төшерделәр икән хәзәрләр хан кызы Чәчкәне?.. Кая Кодрак илхан, кая алае?.. Барысын да кырып бетерделәрме әллә?

Эңгер инде, төн килде, караңгы төште. Ике ярда да учаклар яна.

Буйтур ягында да учаклар шактый. Бәлкем, Җаек бәк төп көчен күрсәтмәс өчен учакларны азрак яктыргандыр?..

Аръяк яры сөзәк, яр буеннан ук таллыклар, болын башлана, бире якка шактый текә һәм биек яр менәсе бар. Хәзәрләрнең күбесе яр астында ятып калыр, болгарлар тиз генә бирешмәс. Әмма барыбер сан хәл итәр. Ни өчен соң әле Җаек бәк бу якка чыгарга тиеш ди? Аның кулында хан кызы. Ул максатына иреште. Ул туры Биләмҗиргә китәр, каганны куандырыр.

Буйтур уйланды, учаклар да сүнә башлады. Уң кулы Камай буйтур янында, ул да буйтурына ни әйтергә белми изалана. Нинди киңәш бирсә дә кабул итмәс кебек буйтуры. Аръякта чатыр тирәли пумала кисәү тотып каравыл йөренә. Чәчкә шул чатырда булса кирәк, үткер күзле хатыннар шулай диделәр. Чатырда Чәчкә булса, Җаек бәк тә андадыр. Чәчкә Җаек бәк кулында Кубрат хан Йулыш каганның яучыларын куып кайтарып җибәрде дияргә була, ә монда хан кызы Чәчкә аның кулында. Хан кызы кулына төшү белән Җаек бәк каганга сөенче җибәргәндер...

Буйтур ияренә кырын ятты. Ике як ярда да каравыллар тора. Болгарларның атлары үз яннарында гына, тезгеннәре аякларына бәйләнгән, сыргы кычкыруга, яисә сөрәнче оран салуга алар сикереп торырга әзер. Алып атка мендеме, аны тиз генә алуы кыен. Төркидә тикмәгә генә: «Атка меңгән — канат элгән»,— димиләр. Буйтурның Кашкасы яр буендагы чирәмне кимерә, аның вакыт-вакыт тынычсызланып, аръяктагы атларның кешнәүләренә колакларын торгызуы буйтурның күңеленә әллә ниткән шомлы уйлар сала иде. Бераздан Кашка тынычланды, янә чирәм кимерә башлады, ахыр ашап туйдымы, буйтурның хәлэтен аңлавы идеме, иясе янына килде, иңенә башын салды, бер тын ни әйтер икән хуҗам дигәндәй, шул рәвештә торды. Буйтур атның йомшак иреннәреннән сыйпады, маңгаеннан сөйде, колак артларын, муен асларын кашыды. Хуҗага рәхмәтен белдерергә теләпме, Кашка иреннәрен кыймылдатып, буйтурның чәчләренә кагылып алды.

— Их, Кашка-Кашка, белсәң икән хуҗаңның хәлләрен,— диде буйтур уфтанып. Ат, иясенең хәлен аңлагандай, башын күтәрде, колакларын торгызып аръякка карады». «Әллә соң атым да беләме минем ник борчылганны?»— дип уйлады буйтур, атның кыланышына аптырый калып.

Каравыл алыплар яр буйлап йөренәләр, кайсы ат өстендә, кайсы тезгенен бил путасына бәйләгән дә тирә-юньне күзәтә-күзәтә атлый бирә, һәрбер каравылның багасы төбәге бар, иң әүвәл ул шул тирәне күзәтә. Ләкин инде караңгы төште, рәтләп күренми башлады. Аръякта учаклар гына җемелди.

Буйтур торып басты, атының башыннан сөйде, уң кулы Камайга дәште.

— Камай, кил әле бире. Киңәшем бар... Мин аръякка чыгарга булдым. Кирмәннең ни хәлдә калуын белеп булмасмы? Юкса Җаек бәк безне юри биредә тота кебек. Әсир болгарлар янына үтә алсам, белермен. Хан кызы Чәчкәне Җаек бәк нык саклыйдыр...

Камай багатыр сикереп торды, каушабрак, мәгәр тавышын тыя төшеп:

— Мөмкин хәлме, буйтурым, хәзәрләр әсирләрне дә, хан кызын да күз карасыдай саклыйлар. Сине тотулары бар!

— Уң кулым Камай, мин шулай хәл иттем. Боерам: мин кире әйләнеп кайтмасам, иртәгә таң беленер-беленмәс йырмак алай белән Эске кирмәнгә юнәләсең. Мин Эске кирмәннең Җаек бәк кулында булуына ышанып җитмим. Миңа калса, Җаек бәк хан кызы Чәчкәне хәйлә белән кулына төшергәндер. Алай белән аръякка чыгып орышсак, алар

бик күп, безне турап ташларлар. Мин үзем генә чыгам, тәңре ярдәмен нән ташламас...

— Чыкмагыз, китик, Эске кирмәнгә, буйтур?

— Юк, багатыр. Мин шулай кылдым.

Буйтур уң кулы Камайны кочагына алды, битләрен-биткә куеп алдылар.

— Мин барысын да син кушканча эшләрмен, буйтур.

— Минем Кашканы үзең белән ал. Кирмәнгә исән-имин барып житсәгез, барысы да сау-таза булсалар, атымны Кодрак илханга бир. Алыпларга иртән генә әйт: буйтур хан кызын коткарырга аръякка чыкты, безгә кирмәнгә кузгалырга боерды диген.

Буйтур ук савытын салды, калканын, өске киемен Камайга бирде. Аннары ике укны сындырды да бил каешына кыстырды, ике хәнҗәрен ике якка такты.

— Әйләнеп кайтмасам, багатыр, кылычым Кодрак илханга тапшыр...

— Буйтурым, юлың тәңрегә тапшыр, аның кодрәте киң...

Буйтур тагын бер ук алды, өчкә сындырды да ике өлешен Камайга бирде, уклы башын үзенә алды.

— Укның урта өлешен төптәңрегә, койрыгын укытучыга бирерсең. Фанәгургә кайта алмасаң, икесен дә Кодрак илханга бир.

Илбарыс буйтур яр буена төште, су янында киемнәрен салды, каешын шәрә биленә такты. Аннары ике камыш кисеп алды, баш-башларын кисеп, өреп карады, шуннан соң гына киемнәрен бау белән бәйләде, баш очына күтәрде.

— Игелекле юл сиңа, буйтур!— дип калды Камай багатыр.

Су буйтурның тезенә житте, биленә, Илбарыс әкрен генә, шыпырдамаска тырышып, аръякка таба йөзеп китте. Буйтур аръяктагы вак таллыкларга чамалады, әмма аны елга агымы түбәнрәк агызып алып китте. Аягы төпкә тигәч, ул ике камышны алды, авызына капты һәм чумып, су төбеннән барды. Сай жиргә житү белән башын судан чыгарды һәм сак кына яр буена чыкты. Яр буенда каравыл йөри. Буйтур судан чыгуга, таллыкка керде, чүгәләп тынып калды. Авыз эченнән жыр мырлый-мырлый каравыл үтеп китте, күп тә үтми янә әйләнеп килде. Каравыл таллык яныннан гына узды, буйтур аның хәтта әчкелтем кием исен тоеп калды. Каравыл алып бертуктаусыз арлы-бирле йөренде.

Каравыл алып, үч иткәндәй, нәкъ буйтур чүгәләгән куак таллар яныннан ике-өч тапкыр узды. Чүгәләп утыра-утыра буйтурның аяклары оеды, ахыр буыны тәмам сүтелде, артына утырды. Арт астында чыбык чыртлап сынды, алып йөгереп таллар куагына килде. Шул мәлдә яр буенда балык чупылдап алды. Каравыл, тирә-ягына карана-карана бер тын басып торды да, үзалдына сөйләнә-сөйләнә китеп барды. Буйтур сынык укларның берсен авызына капты, биленнән каешын салды, тиз-тиз өстенә киенде. Шуннан соң сак кына таллар арасыннан чыкты, куак кырына посып, каравылны көтә башлады.

Буйтур торып басты. Бу юлы яр буеннан ук килә иде каравыл алып. Буйтур таллыккарак чигенде, каравылның үтеп китүенен көтеп торды. Ниһаять, якын-тирәдә аяк тавышлары тынды. Буйтур яр өстенә менде, куактан куакка күчә-күчә чатырларга таба китте. Менә ул жиргә ятты, чатырга таба түшендә шуышып барды. Чатырга ун-унбиш адымнар калгач, әрем куаклары артына посып, бик озак күзәтеп торды. Кисәү тоткан ике алып чатыр, ишеге янында торалар, чатыр арасында беркем дә күренми. Бу чатырдан арырак, куе шомыртлык башлана, анда янә ике чатыр тора. Төн караңгы, әмма күз иялэшә төшкәч, ун-унбиш адымнар кеше гәүдәсен абайларга була иде. Хан кызы Чәчкә кайсы чатырда? Көндезен Чәчкәне менә бу чатырга алып кереп киткәннәр иде. Кисәү тоткан алыплар нидер сөйләшәләр, мәзәк әйтешәләр, көлешәләр. Буйтур әкрен генә чатырга таба шуышты. Аның авызында хәнжәр, итек

кунычына тыккан өч сынык ук очы бар. Менә чатыр. Буйтур чатыр ефәгенә колагын куеп диярлек тын калды. Эчтә һичнинди тавыш юк иде... Каравыл алыплар да мәзәк сөйләүдән туктадылар. Кемнәр бу чатырда?.. Җаек бәк үземе, я булмаса Чәчкәме? Әллә соң үткер күзле хатыннар ялгыштыларммы?.. Чәчкә монда булса, әсир алыплары кая? Үткер күзле хатыннар әсир алыпларны ябулы кибетләр янына алып киттеләр, диделәр. Каравыл алыплар янә пышын-пышын сөйләшә башладылар. Йокламаска тырышалар. Сөйләшүдән туктауга, берсе капчыгыннан кипкән ит чыгарды булса кирәк, икәүләшеп чупыл-чупыл тозлы ит чәйни башладылар.

— Их, монын янына кымыз да булса икән,— диде берсе.

— Биргәнне аша. Кымызы да булыр. Әнә, күрәсеңме болгар әсирләре торган кибетне, шуның күршесендәге кибеттә чүлмәк-чүлмәк кымыз булыр.

— Тансык, алып килим бер чүлмәген чәлеп. Ашчыга ике көмеш дирһәм бирсәң ул бәкнең үзен дә сатачак.

— Һы, бар, тик сак йөр.

— Барысы да йоклый. Таныш ул минем. Ашчыны әйтәм.

— Әйтәм бит, сак бул.

Чатырдан егерме адымнар чамасы җирдә учак яна, учак тирәли алыплар утырганнар. Кайсылары йоклый, кайсылары ярымтавышка сөйләшеп утыра. Берсе йокламый, учакка әледән-әле коры-сары ташлап тора. Буйтур алардан курыкмады, әмма кире әйләнеп киткәндә алар кырыннан үтәргә туры киләчәк. Нишләргә? Көтәргәме, әллә...

Шул вакыт чатыр эчендә нечкә ир-ат тавышы ишетелде.

— Бала, ят, йокла.

Җавап юк, буйтурның йөрәге колак төбенә килеп тибә башлагандай булды. Кемгә дәште? Кем?..

Төн урталарында һаваны болытлар томалады, караңгылык тагы да куерды. Буйтур учакка карамаска тырышты. Учакка караганнан соң караңгыга бик озак күз ияләнми тора иде.

Ярты төннән соң учаклар берәм-берәм сүнә башлады. Буйтур чатырның ефәгенә кагылып алды. Тынлык. Буйтур авызыннан хәнҗәрен алды, сак кына чатыр ефәген тиште. Юк, ишетмәделәр, сизмәделәр. Буйтур сыңар күзен генә тишеккә куеп, эчкә күз ташлады.

Тап чатыр уртасында харәм ага утыра, буйтур аның харәм ага икәнен йөз кыяфәтеннән үк белде, буйтур тишкән тишекнең сул ягында хан кызы Чәчкә. Чәчкәне күргәч, буйтурның йөрәге чабыш атыныкы кебек тибә башлады. Чәчкәнең күлмәк изүе ертылган, күкрәкчәсендә берничә көмеш тәңкә генә калган. Бу ни инде!? Чәчкә әсир! Шулай ук Җаек бәк кирмәнне алган микәнни?.. Чәчкә монда. Кая Кодрак илхан, кая аның алае?!

Чатырның ике ягына ике шәмдәл куелган, җил кергәндә дә куркынып, дерелтәп киткән шәмдәл утларыннан түбә өстендә сәер шәүләләр биешә. Харәм ага шул шәүләләргә караган да каткан, әйтерсең таш сын. Буйтур тишекне зурайта төште, ефәк киселүне ишетепме, харәм ага ялт итеп артына әйләнеп карады. Шул чак Чәчкә торып басты, мендәрен алып, тишек турына ташлады. Күреп эшләдеме ул моны, белмичә генәме, буйтур һичнни аңламады. Харәм ага мыгырданып алды, аннары торды да, ишек яры кучеп утырды. Буйтур тишекне тагы да зурайта төште. Харәм ага тагын шиккә калды. Чәчкәне үз урынына күчәргә кушты. Чәчкә телгә килде.

— Агай, кил әле бире, утыр әле янымга,— диде Чәчкә ягымлы һәм назлы тавыш белән.— Сукранма әле алай, агай. Әйт әле, кемгә шулай хезмәт итәсең?

— Йулыш каганга, кыз олан, Йулыш каганга.

— Утыр әле янымга, агай.— Харәм ага Чәчкә янәшәсенә килеп утыр-

ды, Чәчкә аңа мендәрдән урын бирде.— Мине саклаган өчен Җаек бәк ничә алтын түли агай?

— Алтын юк, кыз олан. Җаек бәк мине ашата-эчертә, йомшак түшәгендә йоклата.

— Коткар мине, агай. Мине коткарсаң, мин сиңа ирек бирер идем. Җирең-ыруың кай җәйләүләрдә?.. Мин сине җәйләвеңә кайтарып җибәрер идем. Ирек алыр идең.

— Нигә ул миңа ирек, кыз олан. Син бирерсең, башка берәү алыр. Юк ирек миңа бу якты дөньяда, кыз олан.

— Алайса мин сиңа җырлыйм, агай. Җырлыйммы?

— Җырла, кыз олан, җырла, җылама гына. Җырла, җыр җанны юата, шәрап канны кузгата, диләр әнә каган җарияләре.

Нидер сизенгән Чәчкә шактый кычкырып җырлап җибәрде.

Этил бит ул, Этил бит ул,
Этил бит ул, киң бит ул,
Этил өсләрендә йөзгән
Аккошларга тиң бит ул...

Чәчкә җырлый башлауга, ишек янында торган каравыл алып чатыр чаршавын күтәреп, эчке якка карады.

— Моңланма, моңланма, хан кызы. Тиздән Биләмҗиргә алып китәләр, каганга биреп туй итәрләр.

Каравылда торучы алып, артына каерылып иптәшенә нидер әйтте, алар гөрләтеп көлешеп алдылар. Шул чакта буйтур чатыр ефәген зур итеп ярып җибәрде. Харәм ага янә як-ягына каранып алды.

— Тагын җырлыйммы, агай?

— Җырлама, кыз олан. Каравылларны котыртма.

— Бичара син, агай, алла бичарасы, тәңре колы...

Чәчкә харәм аганың башыннан сөйде, теге оискәнеп китте, авыз эченнән нидер мыгырданды. Шул чак харәм аганың муенына бау салынды һәм ул эһ дияргә дә өлгермәде берьякка ауды. Җылан кебек шуышып чатыр эченә кергән буйтур, харәм аганың авызына чүпрәк тутырды, кул-аягын бәйләде. Бу хәлгә авыз ачып сүз катырга кыймый торган Чәчкәгә тишеккә таба ымлады.

Бары тик чатырдан китә төшкәч кенә буйтур аңа:

— Елгага таба шуыш, тиз!— диде.

Учаклар сүнгән иде инде, учак тирәләрен узгач, аягүрә бастылар. Чәчкә шунда гына бу хәлнең төшендә түгеллеген абайлады бугай, буйтурның күкрәгенә капланды һәм елап җибәрде.

— Буйтурым, бәгырем...

— Чәчкә, Чәчкә, елама, ашык. Тыңла мине, елга аша йөзеп чык та, Камайга әйт: буйтур Эске кирмәнгә кузгалырга боерды диген. Әйт, Чәчкә, Кирмән кем кулында?..

— Кир-р-мән...

Аларга таба каравыл килә иде, буйтур Чәчкәне елгага таба этебрәк җибәрде.

— Тукталма, йөзеп чык.

— Әй, кем анда?

— Чәчкә, Чәчкә, мин аны тоткарлармын, йөгер, йөгер! Кирмәнгә китегез, чыгу белән. Чәчкә, ишетәсеңме?

— Кем анда дим. Кил әле бире!— диде каравыл.

Каравылга дәшергә кирәк иде, юкса аның оран салуы бар иде. Буйтур җиргә чүгәләде.

— Мин бу. Нигә алай бакырасың... Күрмисең берәү...

— Бире кил,— диде каравыл алып.

— Бик ашыктырма әле син алай, кордаш.

Буйтурның тавышы ошамадымы, каравыл алып шигәя калды, ашыга-кабалана буйтурга таба килә башлады.

— Атың кем, буйсынган багатырың кем?

— Атым сорый бит әле. Атым... Син биргән атмы әллә ул... Менә бетте дә, хәзер киләм.

Каравыл алып бөтенләй шигәя калып, аны көтеп торды. Буйтурга шул мизгел бик җитте, ул каравыл алыпка хәнҗәрен атты. Алып аһ! итте дә йөзтүбән капланды, буйтур ике сикерүдә аның янына җитте, култык астыннан алды да таллар арасына сөйрәп кертте. Ул аны бик тиз чишендерде, өске киемнәрен киеп, елга буена чыкты. Чәчкә елга өстендә күренми иде инде. Диңгез буенда үскән хан кызы суда балыктай йөзә иде. Чәчкә аръякка чыгып киткәндер, Камай багатырны уяткандыр. Юк, багатыр йокламагандыр, су буенда аны көтеп торгандыр. Чәчкә буйтурның боерыгын әйтүгә, алар сак кына, сиздерми генә Эске кирмән ягына юл алырлар. Таллар арасында берничә алып белән атлар калдырырлар. Әсир болгарлар белән исән-имин чыксалар, шул атлар белән буйтур кирмәнгә юнәлер.

Буйтурга каршы каравыл килә башлады. Иптәше, шушы төбәктә очрашырга тиештер, дип уйлады буйтур. Ул аңа тамак кырды.

Буйтур янына килгән каравыл алып:

— Бар, кит!— диде.

Илбарыс буйтур әкрен генә китеп барды, ул аркасы белән тоеп атлады, аңа каравыл алып бик озак, караңгылык эченә кереп эрегәнче карап калды. «Ул миннән шикләнде, шулай да ышанды»,— диде буйтур, адымын тизләтә төшеп, болгар алыплары ябылган кибеткә таба китте. Кибет янында каравыл юк иде, буйтур бераз гаҗәпләнә калды, аңа туктарга да, анда-монда суккаланып йөрергә дә ярамый иде. Ул туры кибеткә юнәлде. Килеп җитәрәк кенә күрде ул, каравыл кибетнең артында икән, учак янында утыра. Икәүләр, берсе учакка чыбык-чабык ташлаштыра, икенчесе иярենә башын куйган да йоклый. Буйтур кибет янына җитте, шунда ук ярымтавышка гына сөйләшүче болгарларны ишетте. Шик юк, нәкъ менә шул кибеттә иде әсир болгарлар. Буйтур кибетнең чүпрәген күтәрде, акрын гына:

— Туганнар, болгарлар. Тавыш чыгара күрмәгез. Бу — мин, Кубрат ханның буйтуры Илбарыс, акрын гына иптәшләрегезне уятыгыз да минем белән шуышыгыз. Туганнар дим, болгарлар...

Әсир болгарлар ышанмый тордылар, шуннан берсе тераләп диярлек буйтурның йөзенә бакты. Аннары әйләнде дә:

— Чынлап та Кубрат хан буйтуры Илбарыс, туганнар. Уят мәргәнне...

Болгарлар кибеттән коелган арада буйтур җиргә чүгәләде, тирә-ягына күз ташлады. Чүгәләгәч тирә-як әйбәтрәк күренә иде. Кибетне боҗрага алганнар икән, тәңре саклаган, ул учак яныннан ук үткән. Каравыл алып дип белгәннәрме? Болгарлар уза башласалар, күрүләре, каравыл кычкырулары бар. Шуышып кына үтәргә:

Буйтур кибеттән төшкән бер алыпка:

— Шуышып кына елга ягына таба кузгалыгыз. Әнә бу арадан узыгыз. Андагылар йоклый кебек.

Хәзәрләргә әсир төшкән болгарлар эшнең асылына шундук төшенделәр, елан кебек берсе артыннан берсе елгага таба түшләрендә шуышып киттеләр. Мәгәр шунда алыплары йоклаган учак яныннан кисәк кенә бер алып күтәрелде һәм ашыга-кабалана таллыкларга таба китте. Болгарлар туктап калдылар. Мәргән алып таллыкка киткән алып артыннан шуышты. Күп тә үтми ул әйләнеп тә килде. Кулында хәнҗәр иде. Ул минем арттан кузгалыгыз дип, торып басты, кул изәде.

Барысы да аңа иярделәр. Елга буена җитәрәк, таллык янына туктадылар.

— Буйтур,— диде кулына хәнҗәр эләктергән мәргән алып.— Җаек бәк безне әсир итмәгән иде. Хан кызы Чәчкә...

Шул чак Чәчкә утырасы чатыр янындагы каравыл оран салды. Ул шул хәтле каты кычкырды ки, бөтен елга буе хәрәкәткә килде.

— Елгага, йөгердек!— диде буйтур.— Өсләрегезне сала-сала йөгерегез!..— Бер алып аларны куып җитеп килә иде инде.— Мин аны тоткарлыйм...

Каравыл алып килеп җитәрәк буйтур аңа хәнҗәрен атты. Иллә шул мәлдә үк икенчесе килеп чыкты, ул әйтерсең җир астыннан калыкты. Буйтур туктады, аны көтеп алды.

— Ни булды!— дип сорады ул, аның өстендә хәзәр киемнәре, алып шикләнмәскә тиеш иде.— Ни булды дим!

— Болгарлар качкан, хан кызы да юк! Әнә алар! Әнә!..

Алып буйтур янына ук килеп җитте, буйтур кисәк борылды да аның корсагына сынык ук белән кадады. Алып аның өстенә капланды, алар яныннан елгага таба кисәүле пумала тоткан каравыл алыплар йөгерәләр иде инде. Буйтур күкрәгенә капланган алыпны берьякка этеп җибәрде дә елгага таба йөгерүче каравыл алыпларга иярде. Әмма аннан шикләнделәр, кайсыдыр куып җитте, йөзен кисәү белән яктыртты. Буйтур аның янтыгына хәнҗәрен тыкты, каравыл алып кулыннан кисәүне алды.

Ул арада аны күреп алдылар.

«Соң, өлгермәдем,— дип уйларга өлгерде буйтур.— Соң! Ятып калганчы, атып кал».

Каршы килгән ике алыпка ике сынык угын атты һәм елгага ташланды, сөзәк яр астына ул йөгереп килгән җайдан сикерде. Әмма аягында тора алмады, суга мәтәлде. Торды, иллә ике адым ясый алмады, артыннан уклар сибелде. Ботына ук кадалды. Буйтурга гүя аркан ташладылар, ул кисәк туктап калды, әмма шул арада аны ике хәзәр алыбы куып җиттеләр, сөйрәп, су читенә чыгардылар.

Буйтурны уратып алдылар, кисәүләр белән йөзен яктырттылар.

— Болгар албагасы,— диештеләр, хәзәр алыплары.— Ике алыпның башына җитте. Их, җаныңны җәһәннәмгә...

— Хан кызы Чәчкә кая?..

Кем?.. Аннан сорыйлармы?.. Буйтурның башын төйгәннәр, ахры, исенә килә алмый торды, битенә су бөркегәч кенә күзләрен ачты, кай тарафта булуын аңларга теләп, тирә-ягына каранып алды. Алдында Җаек бәк утыра иде, буйтур аны кыяфәтеннән үк таныды. Бәкнең өстендә җофар тиресе белән каймалган кыска сырма, сырма изүен ачып җибәргән, сафьян итек кигән аякларын җәебрәк утырган, куллары тезләрендә, иреннәрендә ачулы елмаю. «Итекне Болгарныкын кигән»,— дип уйлады буйтур, күз алдындагы мәхшәрне бер мизгелгә булса да онытып тору теләге белән. Буйтурның карашы Җаек бәк күршесендә утырган кешегә төште. Күрде дә күзләре зураеп китте буйтурның. Үз күзләренә үзе ышанмады: аның каршында сәүдәгәр Ямат бәк утыра иде.

— Таныдыңмы, буйтур,— диде киная белән Ямат бәк.— Тау белән тау очрашмаса да, кеше белән кеше очрашыр, дигәннәр.

— Иске танышмы әллә?— дип сорады Җаек бәк.

— Очрашкан идек бер тапкыр, Патшакала юлында. Белеп тор, Җаек бәк, Кодрак илханның уң кулы булыр бу буйтур, олуг ханның тәрбиягә алган угланы Илбарыс.

Иске таныш буйтурны мыскыл итә. Илбарыс дәшмәде, яңак итен генә чәйнәде. Менә язмыш, кем уйлаган яңадан бу кешене күрермен дип! Ә без менә тагын очраштык. Киң диләр дөньяны, тар икән ул, бик тар. Шик юк, Ямат бәк, ягъни каганның иң ышанычлы баш сәүдәгәре,

Җаек бәккә барысын да түкми-чәчми сөйләр. Аны кичермәсләр. «Кичер, Чәчкәм, кайта алмады Илбарысың...»

Буйтур Илбарыс исемен ишетүгә, Җаек бәкнең йөзе ачылып китте, ул утырган җирендә борсаланып алды, аннары башын Ямат бәккә борды.

— Саклаб кавхан угланы Илбарыс буйтурмы?.. Хуш килдең, буйтур. Минем сине бик күптән күрәсем килгән иде. Чалбай ханның башына җиткән батыр. Ишеткәнем бар, ишеткәнем бар. Әйе, алыпларым, яхшы кошны эләктергәнсез. Төнлә белән оча торган бөркетне.— Җаек бәк ишек яры баскан каравыл алыпларына карады.— Каравылбаш, буйтурны тоткан һәр алыпка бишәр алтын бир!— дип боерды Җаек бәк, кисәүләрен сүндереп кергән алыпларга.— Таң атты, тиздән яктырыр. Боерам: кирмәнгә борылабыз! Хан кызы Чәчкә безнең кулда булыр. Ишетәсеңме, буйтур, безнең кулда!

Ямат бәк Җаек бәкнең колагына үрелеп нидер пышылдады, олуг бәк башын чайкап куйды, гаҗәпләнеп буйтурга күз төшереп алды һәм янә башын чайкады һәм шундук кинаяле елмаю кунды иреннәренә. Тыңлап бетергәч, Җаек бәк аягүрә басты, буйтур янына килеп, ияген алды, башын күтәреп күзләренә карады.

— Саклаб кавхан угланы Илбарыс буйтур, хан кызы Чәчкәне коткаручы синме?

Буйтур башын арткарак ташлап, ияген тартып алды, бер адым артка чикте, шундук каравылбаш аны олуг бәккә табарак этеп җибәрде.

— Телең йоттыңмы әллә, буйтур?

— Юк, бәк, йотмадым.

— Хан кызын...

— Кешенең тәнен әсир итсәгез дә, күңелен әсир итеп булмый, бәк. Син алыпларыңа мине тоткан өчен биш алтын бүләк иттең, ә мин аларның башларын кистерер идем. Хан кызын мин аларның борын асларыннан алып киттем. Әсир төшкән болгарларны да...

— Аларның өчесе елга балыкларына калды. Кинәнмә, буйтур.

— Бәк, кыз урлау төркидә гаеп саналмый иде кебек, каган бозса гына инде бабалар гадәтен...

— Буйтур, буйтур, синең әле шаяртырга да хәлең бар икән бит.— Бәк ишек яры басып торган җәлладына күз кысты.— Җәллад Көркүл, нишли идең әле син үзсүзле әсирләр белән?..

Буйтурның артыннан җәллад килеп тотты, шартлатып кулларын артка каерды, Илбарыс буйтур шундук аңын җуйды, күз аллары караңгыланып, җиргә тезләнде, аннары берьякка авып китте. Буйтур исенә килгәндә аның йөзенә янә су бөркиләр иде. Җаек бәк урынында утыра, янәшәсендә Ямат сәүдәгәр.

— Буйтур, кешегә тәңре бары тик бер гомер генә бирермен дигән. Синең ике гомер яшәргә исәбеңме әллә? Юктыр бит?! Дәшмисең. Ярый, буйтур, инде әйт миңа, нигә сиңа Ашин ыруы каганнары ошамый. Табгач императорына йөз тоткан өченме, я булмаса Йулыш каган үземе?.. Әйдә, дәшмә. Дәшмәү — санлау дигән сүз, санлау — килешү билгесе, диләр. Белеп китсәң иде бу якты дөньядан, Илбарыс буйтур, төрки халкына хыянәт иткән өчен Кубрат хан үз җәзасын алыр. Йулыш каганның олуг бәге Җаек әйтә моны сиңа! Минем синдәй буйтурларны теге дөньяга җибәрәсем килми. Кубрат ханга яшәргә озак калмады, аның җирләре, җәйләү-биләмәләре барыбер каганга күчәр.

— Тәңре әйттеме моны сиңа, бәк?

— Тәңре,— дип мыскыллы елмайды Җаек бәк.— Тәңре болай диде: олуг хан кызын каган алыр, диде. Каһ-каһ-каһ!..

— Тәңре сине моның өчен кичермәс, Җаек бәк.

— Сиңа киңәшем бар, буйтур. Күч каган ягына, ул сине буш итмәс, төрки дөньясында синдәй буйтурлар сирәк була.

— Минем кулларым богауда, тышаулы ат чабалмый.

— Чишегез кулларын!— дип боерды Җаек бәк, ни кушсалар шуны үтәргә торган җансакчыларына.

Буйтурның кулларын чиштеләр, берәүсе аңа утырырга ияр китерде. Җаек бәк үзе дә утырды.

— Син коткарган хан кызы, болгар алыплары миңа әсир төшмәгәннәр иде, буйтур. Хан кызы үзе кирмәннән чыкты, болгар алыплары аны озата чыкканнар иде. Син зур хата ясадың, буйтур. Кодрак илхан сеңлесен янә миңа бирер, хан кызы Чәчкә тиздән барыбер Биләмҗирдә булыр. Мин синең йырмак алаең артыннан кузгалам, сине Биләмҗиргә җибәрәм. Сине исән-имин Биләмҗиргә алып кайтып җиткерерләр, башыңдагы бер чәч тә югалмас. Мәгәр бер шарт белән: алаеңа боер, бирегә чыксын. Тиздән кояш чыгар, алаеңа чыгарга оран сал. Каган рәхмәтен укыр, кичерер. Кирәк икән җәйләвен, кирәк икән алаен бирер, малын да кызганмас. Ашин ыруына баш иеп килгән бер генә дулулылар ыруы да үкенмәс.

— Минем алай түгел иде ул, бәк. Көбер ханның йырмак алае. Алар юлдадыр инде.

— Көбер ханга без тимибез. Килешүебез бар. Каган боерыгы. Алаең анда әле, кузгалмаганнар.

— Юк-к, Җаек бәк,— дип тавышын күтәрә төште буйтур.— Юк, мин аларга боера алмыйм. Мин моны башым киссәң дә эшләмәячәкмен.

— Бу сүзең өчен мин сине ат койрыгына тагар идем, буйтур. Иллә синең башың яшь әле, акылыңа килерсең дип ышанам. Күңелеңә кемдер яман уй салган. Синең болай да каган алдында языгың зур — хан кызын урладың. Хан кызы ни каганга, ни император угланына булмас, Кодрах илхан кирмәннең капкаларын ачмаса, мин кирмәнне алырмын, мәгәр соңыннан берәү дә исән калмас, хәтта хан кызы да. Хан кызын да үтертермен. Син Җаек бәк атын ишеткәнең бардыр, буйтур, теләгем таш яуса да кылырым... Бире ярга үзең генә чыктыңмы?

— Үзем генә дисәм дә, алаем белән дисәм дә син барыбер ышанмас идең, бәк.

— Хак әйтәсең, буйтур. Ышанмас идем. Кеше ышанырлык хәлме. Бер кеше дүрт алыпның башына җиткән, җитмәсә хан кызын, якташларын коткарган. Ярый, килешик, син үзең генә чыктың, ди. Максатың нидән гыйбарәт иде?

— Хан кызын коткару, бәк.

— Бу җинаятең өчен бер атнадан каган алдына басарсың, буйтур. Мин сине каганга җибәрергә булдым.

«Димәк,— дип уйлады буйтур,— каган беркая да яу чыкмаган, бер Җаек бәк Этил буйлап җәйләп йөри».

Бәк ишек яры басып торган каравыл алыпларга ияк какты, ике алып буйтурның кулларын бәйләделәр, чатырдан алып чыгып киттеләр.

— Елга буена!— дип боерды алар артыннан чыккан Җаек бәк.

Буйтурны җилтерәтеп елга буена алып киттеләр. Ул биредән үз алыпларына оран салырга тиеш. Таң аткан, аръяктагы учаклар сүнгән, елга өстенә, яр буйларын ялмап томан төшкән иде.

— Бәк, анда бернәрсә дә күренми, томан,— диде каравылбаш.

— Барыбер кычкырсын,— диде Җаек бәк.

Буйтур янәшәсендә басып торган Җаек бәккә күз ташлады, бәк аръякка караган да аскы иренен чәйни, томан эченә кереп сеңгән ярдан күзен дә алмый иде.

— Томан кояш чыккач кына җәелер, олуг бәк,— диде аның артында басып торучы сәүдәгәр Ямат бәк.

— Оран сал, буйтур!

Ни бу? Ниндидер бер йырмак алай башы берүзе чыгып, ике божра итеп каравылга куелган алыплар аша хан кызы Чәчкәне урлый. Аңа, Жаек бәккә һич тә болгар алыпларының кирәге юк, алар бәк өчен булдылар ни дә булмадылар ни... Ә менә хан кызы Чәчкәгә зур өметләр баглый иде Жаек бәк. Каганга ул хәбәрче чаптырды: тиздән Кубрат хан кызы Биләмжирдә булыр, ә ул юк, кире Эске кирмәнгә китеп бара. Моның өчен аңа каган рәхмәт әйтмәс... Каган Жаек бәккә зур өметләр баглап, үзенең иң якын олуг сәүдәгәрен хан кызын алырга жибәргән. Ямат сәүдәгәр белән килешүләре кыен булыр. Инде нишләргә?..

Жаек бәк уйланды, житмәсә буйтур оран салмый, ялындыра. Буйтурның әле аръякта булмавына Жаек бәк тә ышана, әмма күңелен тынычландырасы килә иде.

— Ишетәсеңме, оран сал, буйтур!

Хан кызы Чәчкә каган кулына кергән хәлдә ул Кубрат ханга шартлар куярга тиеш иде. Кабул итәрме Кубрат хан каган шартларын, юкмы — анысы Жаек бәкне борчымады, иң мөһиме: кулга жиңел генә төшерелгән хан кызы юкка чыкты. Һәм кем аркасында?.. Каравыл алыплар аркасында. Ә бәк аларга житмәсә алтын өләште. Нигә кирәк аңа бу буйтур?.. Хәзер бары тик бер чара кала, Ямат бәк белән буйтурны Биләмжиргә озатырга. Каган үзе хәл итсен Кубрат буйтурының гомерен. Каганның шымчыларына ышанганда Көбер хан каганга каршы чыкмаска сүз биргән икән. Әмма ышанып житеп буламы көтригурларга? Көбер хан Кубрат ханның кайнеше...

— Ямат бәк,— диде артында басып торган сәүдәгәргә Жаек бәк, аръяктан күзен алмыйча.— Син бүген үк Биләмжиргә китәсең. Буйтурны үз кулың белән каганга тапшырасың. Мин Эске кирмәнгә таба кузгалам. Каганга әйт: хан кызы тиздән Биләмжирдә булыр дип әйтте олуг бәк диген: Кубрат хан кызы Чәчкә миннән беркая да китмәс...

— Ихтыярың, олуг бәк. Әмма кыеп әйтәсем килә: мин бирегә Кубрат хан кызы артыннан килгән идем, каган йомышы, бәк.

Жаек бәк беравык дәшми, фикерен туплый торды.

«Бу кеше сатучы каган корты, барыбер мине сатар, әмма каган жизнәсенә берни дә кылмас». Иртәме-соңмы, хан кызы барыбер каганда булыр».

— Боерыгым үтә, Ямат бәк.

— Миңа каган гына боера ала, олуг бәк.

— Хан кызын бу буйтурга син жибәрдең, Ямат бәк,— дип сәүдәгәргә таба борылды Жаек бәк.— Син сатып жибәрдең! Буйтур ат коерыгына тагылыр, синә һичкем ышанмас.

— Баш өсте, олуг бәк. Кайчан кузгалыйм, ниләр алыйм?

— Бер кибет, ун алып сиңа. Этил буйлары минем кулда, сәүдәгәр.

— Тәңре саклаганны саклармын дигән, олуг бәк.

— Каравылбаш, Ямат бәк белән син китәрсең, иң батыр дигән ун алыпларың ал!— диде Жаек бәк, аннары бөтенләй Ямат бәккә таба борылды:— Ишетәсеңме, Ямат бәк, Кубрат хан буйтуры миңа исән кирәк, башыннан бер чәче төшеп калса, жаның-башың белән жавап бирерсең. Без бу буйтур белән франкларга чаклы яу чабарбыз әле.— Жаек бәк буйтур ягына сирпелеп алды.— Тәңре кылган булса...

Буйтурны кабык төпле кибеткә утырттылар. Арба бәргәләнүдән буйтурның бөтен тәне аңырта, куллары ойый башлады. Ул арба артыннан терк-терк юырттырып барган Ямат бәккә карап барды.

Ямышы аларны бу кеше белән тагын очраштырды. Теге вакытта Кубрат хан сәүдәгәрне кайтарып жибәрде, ә ул әнә һаман этлекләр эшләп йөри — хан кызын каганга алып кайтып бирергә ышандырган. Үз чиратында каган бу бурычны — хан кызын Ямат бәк кулына төшереп

бирүне җизнәсе Җаек бәккә йөкләгән. Ни Ямат бәк, ни Җаек бәк каган йомышын үти алмадылар. Җаек бәк бередән Эске кирмәнгә китте, Ямат бәк иске танышы белән каган янына кайтып бара. Ни эшләтер каган Ямат бәкне?.. Нигә миңа бу буйтур, миңа Кубрат хан кызы Чәчкә кирәк диярме, әллә булмаса, җизнәсе сүзенә ышанып көтәргә булырмы?..

— Ямат бәк, кулларым чиштерсәң иде, кулларым ойый.

— Чишегез буйтурның кулларын!— дип боерды Ямат бәк.

— Ат бирсәң, Ямат бәк, ат өстендә кайтыр идем Биләмҗиргә.

— Ат! Төркиләрнең гореф-гадәтләрен белмисең, буйтур. Атка менгән төрки әсир кеше түгел, алып буйтур. Ә син, минем әсирем.

— Кубрат хан сине ат биреп озаткан иде, Ямат бәк.

Ямат бәк буйтурны гүя ишетмәде, атын бәк янәшәсеннән атлатып барган алыпка:

— Нинди халык бу болгарлар,— дип зарлана башлады.— Теге көнне кирмәндәгеләр хан кызын бирми йөдәттеләр, хәзер сөмрәү кошны кулга төшергәч кенә елга аша йөзеп чыгып аны бусы коткара. Моның өчен сине, буйтур, каган ат койрыгына тагар, каганның талканы коры. Җаек бәк тә иманлы, мин булсам елга буенда ук башың кистергән булыр идем. Синең язмышың каган кулында, буйтур. Ул ни әйтер, шул булыр. Мин Кубрат ханга бер ат урынына коралы-ние белән бер кораб калдырдым. Яхшы, каган кичерде. Мин аңа әйттем, уфтанма, каган, дидем, ул кораб барыбер безнеке булыр. Һә-һә-һә!.. Минем каган алдында йөзем ак, буйтур. Җаек бәк уйлансын. Эске кирмәнне алу җиңел булмас, Кодрак илханны юмаларга, хәйлә белән хан кызын кулына төшерергә Ямат бәк бар иде.

Каравылбаш телгә килде.

— Буйтур каганга тере килеш кирәкме, Ямат ага?

— Җаек бәк хан кызы урынына Кубрат ханның асрауга алган угланы белән котылмакчы. Анысын каган үзе хәл итәр.

— Карга күзен карга чукымый, Ямат ага.

— Тик тор, каравылбаш Бүрке,— диде Ямат ачуланып.— Тый телең!

— Телгә йозак салып буламы, Ямат ага. Аннары ул бер миндә генә булса икән.

— Каган телең кискәнне көтәсеңме әллә син, каравылбаш Бүрке?!

— Минекен киссә, башка сөйләр. Болгарлар безнең кардәшләр, икесе бертуган төрки халык. Ни бүләбез!

— Хатының котырттымы, хатының болгар диделәр,—дип сорады кинаялəп Ямат бәк каравылбаш алыптан.

— Болгар, Ямат агай, болгар булыр хатыным. Безгә болгарларга яу чабарга түгел, әнә куәтләнеп килгән сарациннар белән алышырга кирәк. Алар әнә Тимер капка тирәсендә күренә башлаганнар, ди.

— Сарациннан битәр Биләмҗирне яһүд басты, болгарда өч болгарга бер грек булса, Биләмҗирдә өч хәзәргә бер яһүд, каган белән бер табында ашыйлар.

— Хак әйтәсең, Бүрке, хак әйтәсең. Мин үзем дә Кубрат хан белән орыш ягында түгел. Кубрат хан әнә мине исән калдырды, ат биреп җибәрде. Болгарлар белән бүлгән далаларыбыз юк. Яшә тату, сәүдә ит, таңресе бер, теле, гореф-гадәте... Кичә Биләмҗиргә хәбәр юллаучы килде. Кубрат ханның төптәңресе Ирсанны илхан Батбай каганга биреп җибәргән икән. Каганның төптәңресе Үтәгәй картайды, авызында теше, сүзендә ямау юк. Киңәшем әйтимме үзеңә, Бүрке: каганга сүз әйтмә. Җаек бәк, беләсең булса кирәк, каганның җизнәсе... Талашырлар, орышырлар да бер табынга утырып ашарлар. Бер кулына төшкән хан кызын Җаек бәк янә кулына төшерер. Эт авызыннан сөяк алып булмый. Җаек бәккә мин үзем дә ачулы, Бүрке. Ул минем иң сылу кәнизәкләремне

бер дирһәмсез тартып алды, өстеннән дәгъва белән каганга бардым. Ярый, кире алып бирермен, кәнизәкләрең Румга илтеп сатарсың диде, ә үзе кыл да кыймылдатмый. Үзең әйтмешли, карга карганың күзен чукыймы? Моны Җаек бәккә җиткергәннәр, шуннан соң бәк миңа ачу тота, җай чыккан саен әче итеп чеметә. Ишеттеңме, киткәндә ни диде: буйтурның башыннан, имеш, бер чәче дә коелмасын. Күр, ни ди бит! Гарьлегеңнән җир тишегенә кереп китәрсең...

Арба артыннан ат атлатып килгән Ямат бәк белән каравылбаш җилле генә юырттырып, алга киттеләр, аларның урынысын икенчеләре биләде.

Кояш югарыга күтәрелгән саен эсселәнә барды. Җигүле атлар да юыртудан атлауга күчтеләр, койрыклары белән чебен-черкине куып, әкрен генә атлыйлар. Кем дә аларны ашыктырмый, атлар үзләре дә ашыкмыйлар иде. Күрәсең, Ямат бәк үзе дә бик ашыкмый иде. Биләмҗиргә кайтуга, аны каган чакырыр, төпченер, Җаек бәкнең ачуын аңардан алыр. Кем белә, өметләнеп кайтадыр Ямат бәк: бәлкем, Җаек бәк хан кызын бик тиз кулга төшерер һәм, куып ук җитмәсә дә, тиз арада кайтып җитәр.

Атларны куалап алып киттеләр. Арба дыңгырдаудан, сикәлтәләрдә селкетүдән эчләр төшмәле иде. Көн кичкә таба авыша башлады. Көнозын диярлек юлда булдылар. Ахыр, зур булмаган калага тукталдылар, каравыл алып, агач кисмәктән буйтурга су китереп эчерде.

— Эч, буйтур, әйдә, күр күрмәгәнеңне,— диде каравылбаш кинаяле елмаеп, Ямат бәккә күз кысып алды.— Эч-эч, Биләмҗиргә кадәр әллә тия мондый салкын су, әллә юк...

Илбарыс буйтур кипшенгән иреннәрен ялап алды, кисмәк читенә иреннәрен терәде һәм йотлыгып эчә башлады. Ниһаять, ул эчеп туйды, Бүрке алыпка рәхмәт әйтте, аңа игелек теләде.

— Бүрке, Биләмҗиргә еракмы әле?

— Тагын ике тапкыр су эчәрсең әле, буйтур. Эчәргә су тапсак... Ашарыңа мә, тозлы ит кимер, сусауны баса.

Итне чәйнәп бетергәч, буйтурга бер җам кымыз салып китерде каравылбаш Бүрке.

— Игелекле бул, Бүрке.

— Игелек ни ул, буйтур. Әнә кем игелекле бу дөньяда — Ямат ага. Явызлык кылган саен игелеге арта бара.

— Ни сөйлисең син анда?— дип сорады арырак торучы Ямат бәк.— Бетер, кузгалабыз.

Кояш баешка таба тәгәри башлады, атлар бер көйгә генә юырталар. Ямат бәк юыртып барган атлар көенә җырлап җибәрде. Моңлы җырлый иде сәүдәгәр, тавышы моңлы иде, ә менә кылган эшләре бер дә тавышына тәңгәл килми иде. Күп тә үтми, кояш офык читенә кереп батты, ул арада әңгер килде, юлчылар туктамадылар, һаман елга буйлап түбән төштеләр. Бер ара баргач юлчылар диңгезгә җиттеләр. Дымлы диңгез исе күкрәккә тулды, атлар да җиллерәк юырта башладылар.

Кичүне караңгы төшкәндә генә кичтеләр. Кичүне чыгып, бер тын баруга, кичке шәфәкъ әкрен генә эреп юкка чыкты, диңгезгә җиткәндә караңгы төн канатын җәйде. Ай калыкты, ул каяндыр диңгез артыннан килеп чыкты. Хәзәр диңгезе өстенә ярга кадәр көмеш сукмак сузылды. Юл диңгез буеннан бара. Буйтур арбаның әле бер урынына, әле икенче урынына күчеп утырды, ни генә кылмасын, янбашлары авыртуга түзә алмый башлады. Арба артыннан терк-терк атларын юырттырып барган Ямат бәк белән каравылбаш Бүрке тагын сөйләшә башладылар.

— Каган Җаек бәкне яклар дисеңме, Ямат агай?

— Яклар. Төптәңре Үрәгәй дә, аксакаллар да берни дә кыра алмаслар.

— Каган рөхсәт итсә, син бу буйтурны кол итеп сат, Ямат агай. Кимендә ике мең алтын бирәчәкләр. Кубрат ханның ятим угланы дисеңме?!

— Кем алыр, Патшакалада булса икән ул. Румлыларның кол күрделәрме, күзләре тона. Төркидә колларга да алып ирегә бирелә; өйләнә һәм бала үстерә ала, мал-туар тотарга хакы бар.

— Шулмы булды ирек, Ямат агай. Ирек ул әнә... Һавадагы кошлар...

— Кошларны да атып алалар, каравылбаш Бүрке. Бу дөньяда кешегә үлгәч кенә ирек киләдер.

— Яман кеше син, Ямат ага. Әле бер төрле сөйлисең, әле икенче төрле.

— Ә син, каравылбаш Бүрке, артык изге булырга телисең.

— Кеше картая, изгелек кала, Ямат ага.

— Изгелек. Ни ул? Римлеләрнең акылы — аларның миендә, диләр. Һиндларның — мәҗарада, грекларның — күңелләрендә, гарәпләрнең — телләрендә. Болгарның нидә акылы? Изгелектә ди, Кубрат хан. Тик изгелек ни ул, каравылбаш Бүрке? Ни?!

— Хәзәрнең акылы нидә соң, Ямат ага?

— Бөтен хикмәт тә шунда шул, каравылбаш Бүрке. Хәзәрнең акылы соңыннан килүдә. Эш үткәч үкенә хәзәр. Ни өчен хәзәр каганны ефәк җеп белән буып карый дип беләсең?.. Үз-үзен аклар өчен, акылга утырганлыгын исбат итәргә тырышудан. Хәзәр барда — хәтәр бар.

— Моны каган ишетсә ни кылыр иде, Ямат ага.

— Каган ил хуҗасы, ә хуҗа үч тотса ил югалыр, ир үч тотса — гаилә таралыр, диләр. Каганга үч тотарга ярамый, каравылбаш Бүрке. Ә син әйткән иректә ирекне чакта яулыйлар, кул-аягыңа богау салгач түгел. Бу буйтурга ирек килмәс. Аткан укны борып кайтарып булмый.

*Ахыры киләсе санда.*

## Кадыйр Сибгатуллин

### Пошилар

Бик кадерле бер көнебез үтте.
Гади дә көн кебек,
түгел дә.
Әллә нигә генә шушы көнем
бик уелып калды күңелдә.
Чабыш аттай үтте бүген вакыт,
ашыкмаган чагы юк аның.
Һәр көн саен дәресләргә кирәк
сәгатьләрен хәзер дөньяның.
Үзе уйлый,
үзе кыла кеше.
Үз хәлен соң кемнән сорасын?
Һәр көн саен иртән: — Дөньяларга
ни булды икән? — диеп торасың.
Баш бетәрлек хәлләр була торып,
борчылырга сәбәп табыла.
Әллә Җире,
әллә чире шундый —
кешелек тә бик еш абына.

Бик кадерле бер көнебез үтте.
Гомерләргә аны тиңләрлек.
Без бу көнне, җылы учак эзләп,
өйдән-өйгә кереп йөрмәдек.
Бүген Кояш безгә көлеп чыкты,
сандугачлар белән атты таң.
Йөзләребез якты,
еласак та
елаганбыз күбрәк шатлыктан.
Олыларга олы итеп дәштек.
Җылы учны тойды сабыйлар.
Онытылып, эреп, җанга кереп
кочакларда янды җаныйлар.
Уйларыбыз безнең эшкә ашты,
Юлларыбыз булды уңышлы.
Ким дигәндә тагын бер көнгә без
буып тордык әле сугышны.
Шатлыкларны җырлап каршы алдык.
Кайгыларын күрсәк дәшмәдек.
Без бүген дә тагын бер мәртәбә

бер гомерлек итеп яшәдек.
Чәчләребез бераз агаргандыр.
Без картайсак — дөнья яшәрә.
Агармасын имеш, бүгенебез
һәм киләчәк өчен яшә дә!

Бик кадерле бер көнебез үтте.
Һәркайда да аны тойдылар.
Шагыйрьләрдә түгел, компьютерда
сизгеррәк бүген тойгылар.
Күрдек бүген күпне.
Тойдык күпне.
Кемдер яңа корал сынады.
Сукбайлыкка дучар булган гарәп
тагын бер көн ачка чыдады.
Янгын исе, шартлау тавышлары
ишетелә икән ерактан.—
Бу заманда бөегрәк эшләр
көтелә иде, юкса, ир-аттан.
Шаулады Җир бүген зур тавыштан
(Чүкеч тавышларын әйтмим мин).
Үкседеләр яңа каберләрдә,
без аңлыйбыз хәлен ятимнең.
Җир шарыннан төтен исе чыкты,
авыру йөрәк кебек тибеше.
Кешенең бит әле, бер уйласаң,
яңа гына туып килеше.
Кемнәргәдер артык рәхәт Җирдә.
Кулда затлы уен-кораллар.
Ир исемен әләм итеп Җирнең
инде күпме җанын кыйганнар!
Көне буе бүген Җиребезнең
зыңлап торды нерв җепләре.
Кемнәргәдер шартлап үләр өчен
берәр бомба әле җитмәде.
Җитмәгәнен ясап салдык заряд,
ипи бүлгән кебек,
тигезләп...
Һәркемгә дә җитә инде бүген,
барыбыз да Җиргә игезәк!
Бик кадерле бер көнебез үтте.—
Елъязмада урыны зур аның.
Әрнеде җан: әйтерсең лә мине
ташлап китте газиз туганым...
Гайрәтләнеп, гөрләп дөнья шулай
ыгы-зыгы килеп торганда,
кояш баеп барган вакыт иде,
ике поши чыкты урманнан.
Чибәрләнеп, көязләнеп түгел,—
бераз моңсуырак пар иде.
Күзләрендә кешеләрнекеннән
тирәнрәк сагыш бар иде.
Күккә карап озак иснәнделәр,
су эчтеләр төшеп инештән.
...Әллә инде поши урманына
берәр шомлы хәбәр ирешкән.
Пошиларга никтер тыныч түгел,

урманда да дөнья тар сыман.
Китеп барды бүген ике поши
баеп барган Кояш артыннан.

Сүнеп бара безнең тагын бер көн.
Шундый матур...
Шундый кадерле...
Офыклардан бәрә кайнарлыгы —
табигатьнең яна бәгыре.
Күп сораулар туды бүген Җирдә,
күп сорауга җавап табылды.
Минем менә тик бер генә сорау
җәрәхәтләп тора җанымны:
бик борчылып һәм дә бик үпкәләп
китеп баручыга охшыйлар,—
күз бит инде,— кая бара икән,
кая бара икән пошилар?

## Без сугышта һаман

Берөзлексез һаман дәвам итә,
сугышның юк тәмамланганы.
Җиңүләр һәм җиңелүләр булды,
җирдә сугыш тәмамланмады.

Бетте! диде аны минем бабай.
Җиңдек! диде, дошман дөмекте.
Юа-юа канлы кылычларны,
яраларны бәйләп көн үтте.

Хәл алырга яткан җиребездән,
бик арсак та, тордык яңадан.
Сугыш гел шул иде, исеме — бүтән,
ә каныбыз — яңа ярадан.

Бетте! диде аны минем әти.
Җиңдек! диде, соңгы дошманны.
Әти минем, бөтен кеше кебек,
сугыш бетүенә ышанды.

Ул бәхетнең белде ни икәнен.
Тик иминлек кенә юрады.
Бүген менә безнең өйдән үтә
шул сугышның яңа юллары.

Сугыш бара һаман.— Бөтен җирдә.
Көчәп кенә йөри утлары.
Туктап тора икән, аның әле
тын алырга гына туктавы.

Илгә төбәп,
безнең өйгә төбәп
атмаса да туплар корылган.

Мин, атлаган саен, әле һаман
сугыш ярасына орынам.

Кулдан-кулга кала кипә кылыч,
антлар эчеп ала киләбез.
Солдатларның варислары булып,
солдат булып кала киләбез.

Улларыбыз тора бүген чиктә.
Аларның да өзелә сулышы.
Бабасыннан калган шул ук сугыш —
аларның да бүген сугышы.
Буыннардан буыннарга кала,
барыннан да мөһим эш булып.
Кешелеккә даим янап тора,
йөрәгендә яман шеш булып.

Сугыш озын. Аның зәхмәтләре
кешелекнең җанын йөдәтә.
Җир шарының кайтавазы булып
чаң каккандай кага йөрәккә.

Бетте! диеп бүген кем әйтә ала?
Беттеме ул минем оныкка?
Ул да бүген сугыш дигән сүзне
йокысында гына оныта.

Чабатаны күрсә, «бу нәрсә?» ди.
Ишетсә дә, аны күрмәгән.
(Андыйлары онытылды инде,
чабатаны алдык түрләрдән.)

Ә кылычны таный,— автоматны,
пулеметны таный, танкны...
Уенчыгы — сугыш кораллары.
Ул да солдат, сугыш — аныкы.

Унбиш тиен салып сугыш ача,
тешен кысып ата, җимерә!
Тешне кысып куәт биреп торам:
тырыша күр, берүк җиңелмә!

Ирек бирсәң яшәр иде сугыш
киләчәкнең канын эчеп тә.
Тәмамлыйсы иде бу сугышны,
тәмамлыйсы иде ничек тә!..

Бетте! — диеп бүген кем әйтә алсын?
Бер көне юк дошман атмаган...
Без сугышка күптән киткән идек,
без сугыштан әле кайтмаган...

## Сагыш

*Советлар Союзы Герое, очучы М. П. Девятаевка*

Оча алмыйсың, диде аңа врач,—
җирдә генә урының бүгеннән.
Төшерделәр аны бик биектән,
бик биектән — зәңгәр күгеннән.
Бер күкләргә, бер суларга карап,
бер йөрәген баса алмады.
Кая куйыйм бу җанымны, диеп,
дуламыйча чара калмады.
Утырттылар аны «Метеор»га,
Самолеттан, диләр, ким түгел.
Охшаган шул, диде, бераз гына
һәм җилкенеп куйды... И, күңел!
Кыяфәте очкычныкы кебек,
канатлары суда судасын...
Югарыда һава иркен булгач
суларына, бәлки, чыдарсың.
Әйләнде ул Идел киңлекләрен.
Суда йөзде — күккә карады.
Бер сәгатьтә үтеп китәр иде.
Өчәр сәгать үтәр араны.
Кайчакларда аңа бу матур кош
дулкыннарны кисеп үтәр дә,
канатларын җәеп ике якка,
ыргылыр күк тоела күкләргә.—
Баса алмады ләкин ярсуларын.
— Очмый икән,— диде,— кораблар...
Җирдә инде табып булмыйдыр шул,
күктә калса әгәр канатлар.

БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

## Диас Вәлиев

# МӘРХҮМНӘР КОЯШЫ

ХИКӘЯ

*Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,*
*«Ул егылган арып»,— дисәләр,*
*Син ышанма, бәгърем!..*

М. Җәлил.

Якыннан торып карасаң, аның акбурдай ак, кипкән йөзендә еллар буе җыелып килгән арыганлык билгесен — вак җыерчыклар челтәрен күрер идең.

— Әфәнделәр!..

Байтак вакыт хәрәкәтсез утырудан аның аягы оеды, менә ул йөзен чытты, креслосыннан купты, каткан аягын сөйрәбрәк атлап, киңәшмәләр уздыра торган озын өстәлнең теге башына таба китте. Утыртма якалар эчендә кысылган муеннар аңа таба борылдылар. Шунда аның сизгер борын канатлары калтыранып куйды, кипкән йөзендә чак кына сизелерлек җирәнү билгесе хасил булды. Әйе, кабинетка таралып өлгергән бу ис нәкъ менә шушы яка-муеннардан килә иде. Ул кечкенә кулы белән колак тирәсендә ниндидер хәрәкәт ясап алды, баш бармагын тырпайтып, арттагы нәрсәгәдер ымлагандай итте,— ярдәмчесе, өлкән яшьтәге штурмбанфюрер, шундук урыныннан сикереп торды да тәрәзә ачты.

— Менә шулай, әфәнделәр, моңа хәтле бервакытта да бирелмәгән зур вәкаләтләр бирде миңа фюрер. Хәзерге моментта Европаның иң уңдырышлы җирләре безнең кулда. Франция белән Нидерланд кебек илләрнең туфрагы гаҗәеп дәрәҗәдә уңышлы. Бельгия дә алардан калышмый. Хәзер шулай ук Белоруссия белән Украина җирләре дә безнеке. Минем алда сез җыеп тапшырырга тиешле азык-төлек планнары ята. Мин сезгә беркетелгән илләрне карап чыктым. Һәм планнарның киметелгәнлеген күрдем. Узган ел без җир эшкәртү буенча зур үзгәрешләр кертергә тотынгач, андый зур мәйданнарга чәчәр өчен Германиянең яшелчә орлыгы җитмәячәген ачыкладык. Бу орлыкларны безгә шулай ук Голландия белән Франция дә бирмәде. Немецка берәр нәрсә кирәк булганда бу дуслар алдашырга, бәяләрне күтәрергә тотыналар!

СС генералы формасын кигән бу адәм, аякларын элеккечә сөйрәбрәк атлап, креслосы янына килде. Телефоннар тезелешкән өстәл янә-

шәсендә яткан соры овчарка зур башын күтәрде, койрыгы белән паласка сукты. Адәм иелде дә аның башын сыйпап алды.

— Күптән түгел мин бер гобелен сатып алмакчы идем. Аның өчен ике миллион франк сорадылар,— рейхслейтерның йөзендә мыскыллы елмаю чагылып китте.— Ул хатынга: сатып алучының гобеленны үз күзе белән күрәсе килә, дигәннәр. Ә ул: мин аны ят кешегә күрсәтә алмыйм, дип җавап биргән. Алайса, сатып алучы янына үзегезгә барырга туры киләчәк, дигәннәр. Һәм кая барасын әйткәннәр. Минем янга килгәч, хатын гобелены өчен өч миллион франк сорады.— Мундир кигән кешенең йөзендә тагын мыскыллы елмаю күренде.— Элек барысы да гаплади иде. Талап алына иде. Бу исә законлы формага — яулап алганны тартып алуга кайтып кала иде. Хәзер формалар үзгәрде, алар гуманлырак була бара. Шуңа да карамастан, мин таларга кирәк дим, һәм эффектлы итеп таларга! Мин менә нәрсә эшләргә җыенам! Мин сезне, әфәнделәр, билгеләнгән йөкләмәләрегезне үтәргә мәҗбүр итәчәкмен! Әгәр инде кулыгыздан килмәсә, тиешле органнарны аякка бастыру юлы белән беркетелгән илләрегездәге бөтен азык-төлекне барыбер алып бетерәчәкмен. Күп балалы ниндидер француз хатынының, балаларым ач утыра дип, бушап калган кибет тирәсендә елап йөрүе сезне борчымаска тиеш. Әнә, гобеленын кимерсен! Гобелен аңарда калса, әлбәттә! Янсә тамагын фахишәлек белән туйдырсын! Тәэмин итү мәсьәләсендә безне хәзер элекке статистика һич тә канәгатьләндерә алмый.

Мундирлы адәм тынып калды, суынган чәен йотып куйды.

Эңгер-меңгер вакыты килеп җитте, шунлыктан оккупацияләнгән илләрнең рейхскомиссарлары белән азык-төлек киңәшмәсе барган зур һәм иркен кабинетта яктылык кими төште. Кабинет хуҗасы шушы эңгер-меңгер вакытын сөйми иде; ут алырга әле иртә, ә көн яктысы белән электр утының кушылуын ул сөйми, бу аның ачуын китерә, нервысына тия, шуңа да карамастан, люстраларны кабызмыйча кабинетта утыру инде мөмкин түгел иде. Бераз икеләнеп торганнан соң СС генералы формасы кигән адәм кулын күтәрде, шундук кабинетта гөлт итеп ут кабынды, киң тәрәзәләрнең калын шторлары кыштырдашып шуыша башладылар.

Озын өстәлнең урта бер җирендә утырган озын буйлы, тыгыз тәнле рейхскомиссар Бергер, гәүдәсен алгарак күчереп, сөйләргә кереште:

— Франциядәге армия, бу болай да аңлашыла булса кирәк, Франция азык-төлеге белән тәэмин ителәчәк. Шуңа күрә мин бу мәсьәләгә тукталып тормадым...

СС генералы мундиры кигән адәм аңа сүзен әйтеп бетерергә бирмәде:

— Соңгы елны Франция безгә илле мең тонна икмәк тапшырды. Хәзер мин миллион ярым тонна талап итәчәкмен. Һәм бу хакта бернинди дискуссия дә булырга тиеш түгел... Инде Көнчыгыш мәсьәләсенә кайтыйк!.. Бу мәсьәләдә армия белән тулысынча килешенелгән. Андагы армия туган иленнән берникди азык-төлек тә талап итмәячәк. Шулай да бу әле мәсьәләне хәл итү түгел.

Аннан соң сүзне Балтик буе һәм Белоруссия рейхскомиссары Лозе алды.

— Мин зарланмыйм. Балтик буенда безнең эшләр җайланган. Үз вазифаларын үтәгәндә кешеләрнең симерүдән хәтта бераз тыннары да кысыла...— Ә Белоруссиядә, рейхсминистр әфәнде... Миңа кыскача гына үз фикеремне әйтергә ярыйдыр бит?

— Сез монда ни өчен килдегез соң?

— Мин азык-төлекне күбрәк тапшырырга телим. Алай гына да түгел, мин аны күбрәк тапшыра да алам, әмма моның өчен шартлар кирәк. Чыннан да, игеннәр миндә быел уңды. Шул ук вакытта, партизан-

нарны һәм төрле бандитларны юк итмәсәк, Белоруссиянең ярты игенен җыеп алып булмаячак. Менә дүрт ай инде мин ярдәм сорыйм!

— Соң шул шайкалардан саклану чаралары үткәрә алмыйсызмы?

— Моны ничек башкарырга? Бу мөмкин түгел. Территориянең өчтән икесен алар үз контрольләрендә тоталар.

Генерал мундиры кигән адәм арыган һәм битараф кыяфәттә рейхскомиссарга төбәлде:

— Кадерле Лозе, без сезнең белән күптәнге танышлар. Сез гел арттырырга яратасыз.

— Мин бу сыйфаттан баш тартам. Мин беркайчан да арттырмыйм.

СС генералы формасы кигән адәм көлеп алды.

— Фюрерның артып калган кеше материалын адәм күтәрә алмаслык эшләрдә файдаланып юк итәргә, дигән фикере бу очракта төп күрсәтмә булырга тиеш. Ә сез, Лозе, ярдәм кирәк, дип лаф орасыз. Кулыгызда власть. Кулыгызда вермахт бар. Полициягез, эйнзатцкоманда отрядларыгыз бар. Беттән арыну бәхәсләшә торган мәсьәлә түгел, бу сезгә беркетелгән территориядә санитария чаралары үткәрергә кирәк дигән сүз. Инде үз темабызга әйләнеп кайттык. Калган рус өлкәләре нәрсә бирә ала? Минемчә, Рикке, барлык рус территорияләреннән өч миллион тонна икмәк һәм фураж алырга мөмкин.

Рейхскомиссар Рикке башын селекте.

— Бу алыначак.

— Моңа армия өлеше керми.

— Фронт полосасына якын булган икмәк болай да армия файдасына тапшырыла.

— Алайса, ярар. Ике миллион ярым калдырабыз,— дип, көтмәгәндә килешеп куйды рейхсминистр.— Әйе, бер уңайдан әйтегез әле, Лозе, хәзерге көндә сез күпме май җитештерәсез?

— Утыз мең тонна.

— Аз. Алтмыш мең тоннага тәкъдим әзерләгез.

Лозе утырган җирдә кыбырсып куйды, муенын боргалады:

— Әлбәттә, барысы да дөрес. Эйнзатцкоманда отрядлары, санитар чаралар күрү... Әмма бу алтмыш мең тоннаны җитештерү өчен миңа ышанычлы частьлар кирәк. Ә миңа җыен чүп-чарны җибәрәләр!

— Нәрсә?

— Гафу итегез.— Лозе туктап калды.— Гафу итегез, рейхсминистр әфәнде. Мин урынсыз сүз ычкындырдым. Мин бөтен көчемне куячакмын.

Аяк тагын оеды, генералның кабат кәефе китте, ул арыганлыгын сизде, күзләрен йома төшеп, бармагы белән баскалап, аягын массажларга кереште. Нервларның даими киеренкелегеннән килә иде бу. Бер мизгелгә ул хәтта өстәл янына җыелган кешеләрне дә онытып җибәрде, гүя чынбарлыктан арынып торды. Кабинетта тирән һәм авыр тынлык урнашты.

— Әфәнделәр, киңәшмә тәмам,— диде ул шул ук сүлпән тавыш белән.— Бер атнадан азык-төлек буенча тәкъдимнәрегезне көтәм.

Кузгатылган урындык, аяк тавышлары ишетелде. Ул хәрәкәтсез утыра бирде, саубуллашу вакытында әйтелә торган сүзләргә дә игътибар итмәде. Аның кипкән ак йөзе тагын да агарына төшкән, суырылган, үлекнекен хәтерләтә иде.

Рейхскомиссар ычкындырган тотнаксыз сүз аны ярсытты, әмма ул аны, ихтыяр көчен эшкә җигеп, эчкә, күңелнең тирән почмагына куып кертте.

Инде дүрт тулып килә иде. Киңәшмәдән соң ул хәлләрнең торышы хакында берничә доклад тыңлады. Аннан соң, кырыйларына редакцияләү билгеләре куя-куя, үз ведомствосының төрле бүлекләре әзерләгән мөһим документларны карап чыкты.

Инде бераз ял итеп алсаң да була иде.

Менә аның мундиры иркен гардеробындагы башка мундирлар һәм штатский костюмнар янына эленде. Кабинет янәшәсендәге бер бүлмәдә тәбәнәгрәк буйлы, киң җилкәле, кыска аяклы яшь ир-ат аның өстенә йомшак халат кидерде, аннан соң бүлмәгә ике массажист килеп керде. Алар, бик тырышып, унбиш минут дәвамында бүлмә хуҗасының тәнен йомшарттылар. Аннан соң ул душка кереп чыкты, гражданский күлмәк киеп каты чәй эчте дә ике сәгать буе тагын эшләп утырды.

Аны тагын ниндидер йончу басты.

Эш бармый иде. Барырга теләмәде. Аны хәтта ихтыяр көче белән дә алга этәреп булмады. Тәгәрмәчләр туктаган, әйләнмиләр, әйләнергә теләмиләр. Хәрәкәт иткән кебек күренсәләр дә, чынында исә бер урында торалар. Ниндидер чиккә, азакка якынлашу хисе үзен торган саен ныграк сиздерә, әле кичә генә нык булган ихтыярны йомшата, аны эчтән тарката иде шикелле.

Ул күзләрен йома төшеп, кресло аркасына сөялде дә байтак вакыт хәрәкәтсез утырды. Аннан соң язу өстәленең бер бүлемен үзенә тартты, кулдан әмәлләнгән кечкенә бер блокнот алды. Блокнот битләре вак латин һәм гарәп язуы белән сырланган иде.

Менә ул бернәрсәгә дә тукталмаган карашы белән кабинетны айкап чыкты, аннан соң гына кнопкага басты. Шундук ишек ачылды, бусага төбендә ярдәмче күренде.

— Райнерны чакырыгыз.

— Тыңлыйм.

Өч минуттан рейхсминистр кабинетына СС гауптштурмфюреры мундиры кигән кырык яшьләрдәге бер кеше килеп керде. Бу Райнер Ольцша иде. Ул империя иминлек идарәсенең Көнчыгыш Рефератын җитәкли, төрки телләр буенча белгеч, Азия һәм Көнчыгыш буенча специалист санала.

— Утырыгыз, Райнер,— диде кабинет хуҗасы, аның исәнләшүенә җавап итеп.

Хуҗа кеше иңенә мундирын салды да, аягын сөйрәбрәк атлап, шул ук озын өстәл буенча китте.

— Большевизм белән көрәшкә Россия халыкларыннан төзелгән частьларны мобилизацияләү — зур хәрби һәм политик әһәмияте булган эксперимент.— Рейхслейтер өстәл почмагын әйләнеп узды да туктап калды.— Кызганычка каршы, бу мәсьәләдә безнең өметләр акланмады. Миңа еш кына үпкә сүзләре ишетергә туры килә.

Гауптштурмфюрер ирексездән башын кагып куйды, күзләрен аска төбәде.

— Мин инде Россия халыкларын аеру, таркату идеясе гомумән дөрес микән дип тә уйлый башладым. «Идел-Урал» легионы аркасында килеп чыккан шау-шу, мәшәкатьләр, мине нәкъ менә шул ягы белән кызыксындыра.

— Без шушы көнгә кадәр милли хәрәкәтне җитәкләргә лаеклы лидерләр таба алмадык,— диде гауптштурмфюрер.— Көя төшкән кешеләр лидер булырга яраклы түгелләр. Иске эмиграция шуның өстенә пантюркизм идейкалары белән мавыга, ягъни бөтен Советлар Союзы мөселманнарының кардәшлеген алга сөрә. Моның кирәге бар микән? Минемчә, безгә, беренче чиратта, Советларның милли политикасындагы каршылыклардан файдаланырга кирәк, икенче этапта инде дини каршылыклардан да файдаланып булыр иде. Бөек рус империясен бары тик зур-зур милли блоклар төзеп кенә таркатып булачак. Большевизм идеясенә эчтән бары тик милләтчелек идеясе генә каршы тора ала.

Кайдадыр тирәндә, аң эңгер-меңгерендә аның күләгәгә охшаган фикере талпына, шул ук вакытта бу фикер дә түгел кебек, ә ниндидер тотып булмаслык бер хәрәкәтнең зәгыйфь чагылышы гына булып тоела.

Ул шушы кулэгэлэрне ятьмэгэ элэктерергэ азаплана, эмма булдыра алмый, булдыра алмый.

— Безнең эштә төп нәрсә Россия халыкларының милли эгоизмында уйнау булырга тиеш. Минемчә...— гауптштурмфюрер фикерен әйтеп бетермәде, туктап калды.

— Әйе, мин дә шул ук фикердә. Мин дә шул хакта баш ватам... Мин теге кешенең досьесын да, шигырьләрен дә игътибар белән өйрәндем,— рейхслейтерның карашы көтмәгәндә гауптштурмфюрерда тукталды.— Берничә ел бәрелешкәннән соң дөньяның көчләре хәзер тигезләнгәндәй кебек күренә. Алай гына да түгел, безнең уңышлар кайвакытта кимеп тә киткәли... Сез биргән шигырьләрне мин карап чыктым. Каршы якның уй-фикерләрен беләсем килеп, ул идеянең табигатен аңлыйсым килеп карап чыктым!.. Дөньяда камиллеккә ихтыяҗ зур, кадерле Райнер! Мин дөньяның камил булмавын бик авыр кичерәм. Зевс тәгәрмәчкә бәйләп куйган Иктион кебек, без дә туктаусыз хәрәкәттә яшибез. Әмма тәгәрмәч инде әйләнми. Ул тукталды. Ул тик тора. Иманым камил,— рейхслейтерның сөякчел бармаклары блокнотка сугып алдылар,— иманым камил, әгәр дә идея бер пунктта, бер генә пунктта булса да көчсезлек күрсәтә икән, димәк, зур масштабларда да җиңелү мөмкинлеге бар. Димәк, ул бөтен яктан да камил түгел.

— Кешене шартлар формалаштыра, шартлар нинди булса, кеше дә шундый ук,— гауптштурмфюрер үз тавышына күпмедер ризасызлык салырга җөрьәт итте.— Кызганычка каршы, без бу кешегә подполье лидеры булырга мөмкинлек бирдек, аның урынына без аны милли хәрәкәт лидеры итеп файдаланырга тиеш идек. Әмма кешенең капма-каршыга үзгәрүе дә булгалый.

— Ярар, күз күрер. Патшалар да шагыйрьләр белән уйнаганнар,— рейхслейтерның тавышында ачыктан-ачык мыскыл ишетелде.— Сез, Райнер, ни өчендер мине бу кешенең меценаты ролендә күрергә телисез!

— Җирдә яшәүне һәм бәхетне беренче кыллар тәкъдим иткәндә, рейхсминистр әфәнде, моңа бик сирәк кеше каршы тора ала.

— Ярар, ярар, күз күрер. Ул кеше мондамы?

— Әйе, без аны көн дә китерәбез.

— Чакырыгыз,— диде рейхслейтер.

Берничә минуттан рейхсминистр кабинетына кертелгән кешене менә атна буе инде һәр көнне Берлин кырыенда урнашкан һәм кирпеч коймә белән әйләндереп алынган кечкенә особнякташ Гегельплацстагы хөкүмәт бинасына китерәләр иде... Бу кеше инде сугышны, әсирлекне үткән, лагерьдан лагерьга күчеп йөргән, «Идел-Урал» комитетында ике яклы эш алып барган.

1943 елны алар төзегән беренче батальон, офицерларны кырып бетереп, бөтен коралы-ние белән Белоруссия партизаннары ягына чыкты. Карпат тауларына ташланган икенче батальонның язмышы аяныч булып бетте. Алар партизаннар дип белеп кушылган отряд чынлыкта исә бандерачылар бандасы булып чыкты. Коралсызландырылган легионерларны пулемет уты белән юк иттеләр. Ышаныч кимегән өченче батальонны фашистлар Франциягә озаттылар һәм ул шунда таралды; калган өлешен Голландиягә, Остворне утравына күчерделәр. Польшаның Едлино дигән шәһәрчегендә урнашкан дүртенче штаб батальонында әзерләнгән восстание була алмыйча калды: күтәрелергә дүрт көн калды дигәндә кулга алулар башланды. Бер елга сузылган хәтәр уен шулай тәмамланды. Ике ай дәвамында бу кешене җәзаладылар һәм сорау алдылар, әмма бер ай элек, көтмәгәндә, барысы да туктатылды, госпитальгә салдылар, аннан шәһәр читендәге кирпеч стена белән уратып алынган тыныч бер особнякка урнаштырдылар. Янында бер кече офицер калдырдылар.

Ә менә күптән түгел хәлләр ышанып булмас дәрәжәдә үзгәрде. Аны көн саен массажистлар йомшата, сылый, сыйпый башлады. Хәтта йөзенә бераз грим да салалар иде. Көзге каршына килеп баскач, ул үзенең элекке хәленә кайта баруын күрә иде. Менә дигән костюм киертеп, аны көн дә Гегельплацтагы бинага китерәләр, конвой аны буталышып беткән озын коридорлардан алып бара да гостиница номерына охшашлы фәкыйрь генә җиһазландырылган бүлмәгә кертеп бикли. Монда кыска кушетка, урындык һәм язу өстәле бар. Өстәлдә немец газеталары һәм журналлар. Ә кич житкәч, аны шул ук машинада һәм шул ук маршрут белән теге особнякка алып кайталар. Нигә болай итәләр — берәү дә аңлатмый һәм бу хәл аңарда аптырау катыш кызыксыну уята. Шулай да ниндидер уен башлап җибәрелгәнен ул сизенә иде. Уен нинди генә булмасын, ул әлегә аннан канәгать. Бу мәгънәсез, нәтиҗәсез йөрүләр дә әсир тормышына үзенә күрә бер яңалык өсти бит. Иң мөһиме, Гегельплацтагы бүлмәдә кәгазь бар. Миендә кайнаган образларны саклап йөртмичә шундук кәгазьгә төшереп була. Моның нише кара эшне ярата иде ул: көлтәсе белән килгән сүзләр арасыннан иң төгәлләрен, үзенә кирәген генә сайлап аласың, аралыйсың, үзеңнеке итәсең,— бу аңа ләззәт бирә иде. Өстәлендә — кәгазь, аның белән теләсә нишли аласың, кирәксә — сызып ташла, вариантлар эзлә, күчереп тә язарга мөмкин. Монда кәгазь әрәм була дип куркасы юк, кысылып язмыйсың. Язу белән ул кайвакытта шулкадәр мавыгып китә иде ки, үзенең кайда икәнлеген дә онытып җибәрә,— андый чакта калын, нык ишек аркылы коридорга көлү тавышы саркып чыга.

Бүлмәгә нәкъ шундый минутта килеп керделәр. Особнякта яшәүнең һәм бу арлы-бирле йөрүләрнең сере ачылыр чак житкәндер, күрәсең. Аны бу юлы да озын коридорлар буенча алып киттеләр, тик болары үзгә иде.

Бу вакытта рейхслейтер теге блокнотны актаруын дәвам итә иде.

Ишек ачылды һәм озата килгән офицер кабинетка тәбәнәгрәк буйлы, нык гәүдәле теге кешене кертте. Аны күреп, рейхслейтер ашыкмый гына өстәл артыннан торды, башы белән ымлап, офицерга китәргә кушты һәм, йөзенә ягымлы елмаю чыгарып, кунагына кресло тәкъдим итте. Гауптштурмфюрер да салкын кызыксыну белән аңа төбәлде.

— Рәхим итегез,— диде рейхслейтер немец телендә.

Киң күкрәкле, нык, матур аяклы овчарка, өйрәтелгән гадәт буенча, кергән кешенең бер генә хәрәкәтен дә читтә калдырмыйча күзәтә башлады. Рейхслейтер аны муенчасыннан тотып үзенәрәк тартты да җиңелчә генә иркәләп алды.

— Кофе эчәсезме?

Кунак кофедан да, тәкъдим ителгән сигареттан да баш тартмады. Сак кына басып, кабинетка поднос тоткан бер хатын-кыз да кереп чыкты. Кунак шулай ук бер фужер коры шәрабны да ашыкмыйча гына эчеп куйды.

— Күрәм ки, Җәлилов әфәнде, монда чакыртып алуым сезне бераз аптырашта калдырды,— диде рейхслейтер, катнаш төрки телгә күчеп.

— Бу бер дә чакыртып алуга охшамаган шул. Шулай да, ниндидер парадоксны хәтерләтә. Мине атна буе көн дә шушында китерәләр, ләкин моның белән сезгә бурычлы икәнемне белми идем әле.

— Нигә алай? — Кабинет хуҗасы русчага күчте.— Без бит сезнең белән якташлар диярлек. Сез Иделдән, Уралдан, ә мин Балтик буе немецларыннан. Ләкин икебез дә Россиядән,— рейхслейтерның йөзендә кабат теләктәш елмаю күренде.— Өстәвенә без коллегалар да бит әле. Сез Мәскәү университетының гуманитар бүлеген тәмамлагансыз, мин дә шунда ук укыдым. Дөрес, Россиядән мин күптән киттем. Большевиклар оештырган үзгәрештән соң.

— Боларны белми идем. Күңелемә бик хуш килделәр.

Әсир үзен артык иркен тота иде, бу хәл рейхслейтерны ярсыта башласа да, ихтыяр көче белән ул аны бастырып өлгерде.

— Оккупацияләнгән территорияләрдәге политика өчен җаваплы дәүләт кешесе буларак, миңа байтак мәсьәләләр хакында уйланырга туры килә. Сезнеңчә ничек, оккупация политикасы хәрби һәм экономик ихтыяҗлардан гына чыгып билгеләнергә тиешме? Әллә инде безгә бу территориянең киләчәктәге политик фундаменты турында да уйланырга кирәкме?

— Сез мине монда шушы мәсьәләләрне тикшерү өчен чакыртып алдыгызмы? — дип, көлемсерәп куйды кунак.— Кызык. Тормыш чыннан да парадокслардан тора.

— Политик максат — мин торган саен шушы фикергә кушыла барам — ул төп максат,— дип аңлатты рейхслейтер.— СССР үзенең бөтен проблемалары белән (мин бу очракта илнең зурлыгын, халыкларның анархик характерда булуын, илне идарә итүнең кыенлыгын, шул ук вакытта большевизм тудырган шартларны күздә тотам) — Көнбатыш Европадан бик нык аерылып тора. Һәм бу проблемаларны башкача хәл итүне сорый.

Кунак тагы елмайды.

— Мондый реалист булу сезгә сугыш башлаганда кирәгрәк иде!

— Бәлки шулайдыр да. Бу очракта сез хаклы. Әмма реализм сугышның башка этапларында да комачауламый. Мин шушы режимның хәлиткеч операциясен җитәкләүче бер вәкил, ләкин шулай булса да рейх дошманнары белән йөзгә-йөз бик сирәк очрашам.

— Һәм сез, ниһаять, ләззәтләнергә булдыгыз!

Рейхслейтер аягына торып басты, өстәлдән теге блокнотны алып, тагын кунак каршына килеп утырды.

Блокнотны күреп, тоткын агарынып китте.

— Сез бу шигырьләрне иреккә чыгарырга теләдегезме? Төрмә диварлары моның өчен әйберләрне кулга төшерү өчен менә дигән фильтр ул.— Кабинет хуҗасы кабат креслосына килеп утырды, оеый башлаган аягын җайлап урнаштырды.— Моны миңа,— ул тын гына утырган гауптштурмфюрерга ымлады,— кадерле Райнер бүләк итте. Ул минем йомшак якларымны белә. Әйтергә кирәк, сугышның да кайбер яхшы яклары бар. Менә кичә генә минем коллекциям фарсы, абиссин, кытай телендәге кульязмалар белән тулыланды. Шулай ук миндә рус һәм украин елъязмалары да бар. Арада сирәк очрый торган гаҗәеп экземплярлар булгалый. Ләкин мин кайбер безнең заман әйберләрен дә җыям. Миндә, мәсәлән, француз коммунистларының үлем алдыннан язган хатлар коллекциясе саклана.—Рейхслейтер бераз вакыт дәшми торды.— Сезнең шигырьләрне дә җентекләп өйрәндем.

Рейхслейтер бу минутта гаҗәеп бер кызыксыну хисе кичерә иде. Юк, уенны ул бу кешене үз ягына аудару өчен башлап җибәрмәде. Моның белән башка кешеләр шөгыльләнә. Һәм буш шаяру, янсә явыз садизм хисе дә түгел иде бу... Ул утырган олы урынны моның өчен нәрсәләр бизәмәс иде. Рейхслейтерны бөтенләй башка нәрсә ымсындыра иде — берничә ел барган каты сугышлардан соң дөньядагы көчләр тигезләнде, хәтта уңышлар кими дә башлады. Һәм шушы шартларда каршы якның эч серен белергә теләү, үзенә каршы торган идеяне экспериментка куеп, ныклыгын сынап карау теләге белән яна иде ул. Һәм шуның ярдәме белән соңгы вакытта күңелен били башлаган төрле икеләнүләрдән арынаса килә иде аның. Шуңа күрә ул әңгәмәдәшеннән күзен алмый, аның бер генә хәрәкәте дә игътибардан читтә калмый иде. Каршыда аның дошманы утыра. Бу гадәти дошман түгел. Әлбәттә, ул да гильотина пычагы астына ятачак. Әмма гильотина гына рухны җимерә алмый. Рух иректә булып кала. Гильотина дошманны физик як-

тан гына юк итә. Дошманның физик үлеме генә рейхслейтерны канәгатьләндерә алмый. Дошман рухи яктан да җимерелергә, үтерелергә тиеш. Бары шул очракта гына министр үзен борчыган әлеге афәтләрдән, ниндидер хәвефле сизенүләрдән арына алачак.

Ул башын күтәрде, карашында эчтән сызлануы, күңеленең актарылуы ярылып ята иде.

— Миңа сезнең подпольедагы, хәрби әсирләр арасындагы эшчәнлегегез яхшы мәгълүм. Әлбәттә, сез фикердәшләрегез белән бергә үлемгә хөкем ителәчәксез,— дип, дәвам итте ул.— Әмма бер вариант бар. Сез шәхсән бу хөкемнән котылып кала аласыз. Бездә рейх дошманнарына бернинди яклану хокукы да бирелми, шул ук вакытта, Макиавелли әйтмешли, политик әйткән сүзенең колы булырга тиеш түгел. Мин, политик буларак, бу парадоксның дөреслеген исбат итәргә әзер.

— Ни өчен бу кагыйдә миңа кагылмый соң? — дип кызыксынды кунак һәм йөзенә авыр елмаю чыгарды.

— Моны минем бер капризым дип кабул итегез,— рейхслейтер да елмаеп куйды.— Очраклы рәвештә мин сезне олылаучы бер кешегә әвереледем. Һәм мин рейхта сезнең үзегезгә лаеклы урынны алуыгызны телим. Дөресен әйтим, бу минем өчен дә файдалы булачак. Чөнки ул чакта мин хезмәт иткән идея тагын да камилләшә төшәчәк! — Рейхслейтер моны ачылып китеп чын күңелennән әйтте.— Бу мәсьәлә мине күптән борчый. Иске дустым Райнер белән дә бу хакта сөйләшкәнем бар — дөньяның камил булмавы мине газапланырга мәҗбүр итә. Алай гына да түгел, бу хәл мине физик яктан газаплый.

— Сез серле шәхес,— диде кунак, авыр елмаеп.— Сез дә газапланасыз икән бит. Бу очракта мин сезне кызгана да алмыйм.

— Сез бит рус түгел, Җәлилов. Россиягә сезнең ни катнашыгыз бар? — дип, Райнер Ольцша да сүзгә кушылды.— Башка халыклар да, күп вакыт үтүгә карамастан, руслар үзләре дә, өч йөз ел буе кем кул астында яшәгәнлекләрен әле онытмадылар.

— Әйе, ул өч йөз ел булды. Аннан соң дүрт йөз елдан артык вакыт үтте. Һәм шушы җиде-сигез йөз ел вакыт эчендә барысы да буталды. Мин хәзер йөзгә карап та татар белән русны төгәл генә аера алмыйм. Бәлки, мәсьәлә шуның белән аңлатыладыр? — дип, салкын гына елмаеп куйды ул.— Бәлки, аның белән генә дә түгелдер? Хәзер инде кешеләр берсенең немец, икенчесенең рус яисә француз булуы белән генә аерылмыйлар. Бәлки, безне аеручы нәрсә, гауптштурмфюрер, сезнең минә нацист булып, минем...— Ул сүзен әйтеп бетермәде.— Ни өчендер безнең заманны цивилизациянең иң бөек ноктасы дип карыйлар,— дип көлемсерәде ул.— Янәсе, шушы бөек ноктадан без үткән гасырларның кимчелекләренә горур караш ташлый алабыз, чөнки үзебез прогресска ирешкәнбез.

— Көрәшүче ике якның һәрберсенә, үзен фәрештә белән тиңләп, бөтен гаепне иблис өстенә аудару файдалырак. Нацизм белән большевизм хәзер бер-берсеннән шушы иблисне табарга тырышалар.—Рейхслейтер кабат урыныннан торды, кабинет буенча китте.— Бу кызык кына фәлсәфи бәхәс кузгатырлык мәсьәлә. Шулай да әңгәмәне практик юнәлешкә күчерик. «Идел-Урал» комитетында сезгә, шагыйрь буларак, пропаганда һәм культура эше йөкләнгән иде. Бу вак һәм вазифалары ачык булмаган эш... Мин сезгә бу комитетның башлыгы булырга тәкъдим итәм.

— Димәк, мин хәзер иблисне башка җирдән эзләргә тиеш булып чыгам? Шулаймы?

— Кызганычка каршы, без сезгә подпольеның лидеры булырга ирек бирдек,— диде рейхслейтер коры гына.— Мин үз кешеләремнең ялгышын танырга мәҗбүрмен. Шул ук вакытта сезнең ялгышларны күрмәмешкә салышырга да әзермен. «Идел-Урал» комитетында безгә СССРда

яшәүче төрки халыклар арасында абруе булган кеше кирәк.

Кунакның җавабы бу юлы да салкын иде, ул хәтта йөзен дә чытып куйды.

— Гафу итегез, минем инде профессиям бар.

— Нинди профессия?

— Аны сез үзегез атадыгыз. Мин — шагыйрь.

— Сезне бит берәү дә шигърияттән баш тартырга чакырмый! Политика да үзенең табигате белән зур шигърият түгелмени? Бу өлкәдә дә бит гел яңа комбинацияләр иҗат ителеп тора. Дөньяның киләчәген башлыча әнә шул иҗатчы политиклар билгеләячәк!

— Өстәвенә, нәтиҗәсе! — дип, гауптштурмфюрер тагын бер кысылып алды.— Нәтиҗәсе булса иде ичмасам?!

Кунак кисәк аңа борылды:

— Нинди нәтиҗә?

— Сез төзегән оешма тулысынча тар-мар ителде. Югалтуларыгыз акланырмы? Листовкалар? Аларны язган, тараткан кешеләрнең үлемен ничек акларсыз? Сез үз оешмагызга бик күп кешеләрне тарттыгыз. Сез оятсыз рәвештә аларның ышанычын, ашкынуын эксплуатацияләдегез! Сез аларда нәфрәт тәрбияләдегез!

— Без, гауптштурмфюрер, аларның кулына корал бирдек,— диде ул тыныч кына.— Йөз аклыгы һәм ватаннарын кайтарып бирдек. Әсирлек һәм төрле алдау, үгетләү шартларында үз бурычларына һәм интернационализм идеяләренә тугры булып калырга ярдәм иттек. Якташларымнан төзелгән дүрт батальон инде беркайчан да сезнеке булмаячак. Аларга кулыгыз җитмәячәк.

— Сез меңләгән якташларыгызны корбан иттегез! Алар инде барысы да мәетләр! Сезнең киләчәк җиңүегез бу корбаннарга мохтаҗ идеме соң?

— Практик планда карасаң, безнең көрәш бәлки ул кадәр нәтиҗәле дә булмагандыр. Җиңү көне бездән башка да киләчәк. Әмма кеше булган кеше бүтәннәр килеп коткарганны көтеп ята аламыни? Һәрхәлдә, без үзебезнең дөньяда барлыгыбызны исбат итә алдык.

Рейхслейтерның йөзенә мәет төсе йөгерде. Әңгәмә барып чыкмады. Дәвам итүнең мәгънәсе юк иде.

— Дан — мәрхүмнәр кояшы. Элек шулай диләр иде. Бәлки сез дә каберегез өстендә шушы кояш балкыр дип өметләнәсездер? Алтын нурлары белән сезне яктыртыр дип уйлыйсыздыр? Әмма белеп торыгыз, ватаныгыз сезне хыянәтче ролендә генә беләчәк.

Әсир көтмәгәндә көлеп җибәрде.

— Әллә кәрт салып карадыгызмы, министр әфәнде! — Әсир кинәт тупас итеп сүгенү сүзе әйтте.— Сезнеңчә, без эзсез югалачакбыз, исемебез акланмаячак, киләчәк буыннар өчен хыянәтчеләр булып калачакбыз. Без тулысынча сезнең ихтыярыгызда дип уйлыйсыз? Тормыш парадокслардан тора, дип ышанасыз, шулаймы? Әмма иң зур парадокс беләсезме кайчан булачак? Безне юк итәр өчен гильотинага озаткан минутта! Гильотина астына тыгып сез безне мәңгеләштерәчәксез! Һәм безнең үлемебез сезнең үлемегезгә әвереләчәк, сезнең тагын бер җиңелүегез булып яңгыраячак. Шунысы кызык — бу хөкемне сез инде беркайчан да үзгәртә алмаячаксыз...— Ул рейхслейтердан ачыктан-ачык көләргә тотынды.— Мин соңгы елны яшәү һәм үлем турында күп уйландым. Шулай ук үлемсезлек турында да. Кеше ни өчен туа? Яшәвенең мәгънәсе нидән гыйбарәт? Минем әле беркайчан да бу айлардагы кебек киеренке яшәгәнем юк иде! Без көрәштән баш тарткан очракта гына хыянәтчеләр булып калган булыр идек. Әмма без аннан баш тартмадык. Язмышның башка вариантлары юк! Һәм бу хакта сүз озайту мәгънәсез.

Рейхслейтерның йөзе тагын да агарынып китте.
— Сез үз-үзегезгә хөкем карары чыгарасыз,— диде ул гадәттәгечә сүлпән тавыш белән, әмма эчтән ярсуы котырына башлаган иде инде.
Кунак бер мизгел дәшми торды, аннан соң гына йөзенә көлемсерәү чыкты.
— Мин тормышта һәр нәрсәне үзем эшләдем. Һәр нәрсәне.
Рейхслейтер кнопкага басты. Шундук кабинетка сакчылар килеп керде.
— Алып китегез.— Әмер теш арасыннан кысылып чыкты һәм кул хәрәкәте белән ныгытылды.
Менә аны тагын үзәк өзгеч сагыш биләп алды. Бу юлы ул бигрәк тә авыр, котылгысыз булып тоелды. Аның үткен чәнечкеләре җанны үтәли тишкәли, рухны йомшата, өметне өзә иде.
«...Шулай да без оттырдык микәнни?»
Рейхслейтерның фикере логика законнарына буйсынмый башлады.
— Нинди күрсәтмәләр булыр? — Гауптштурмфюрерның тыенкы тавышы кайдандыр ят дөньядан ишетелгәндәй булды.
— Рейх дошманнары өчен закон бер,— диде СС генералы мундиры кигән адәм.

* * *

Оккупацияләнгән җирләр рейхсминистры кунагын шул ук кичне Шпандау төрмәсенә күчерделәр. Ләкин ул аңына берничә көннән соң гына килә алды.
— Кәгазь... Кәгазь бармы?.. Бирегез әле,— дип сорады ул бер көнне кичкә таба. Үзенең ят камерада икәнен ул авырлык белән генә аңлады.
— Сезгә хәзер кәгазь түгел, су кирәк.
Тоткыннарның берсе аның башын күтәрә төште, авызына сулы кружка китерде.
— Менә шулай!.. Судан да шәп дару юк. Аның башы сәламәт түгел, ахрысы. Гел ниндидер кәгазь турында сөйләнә. Шулай да, полковник әфәнде, сез оттырдыгыз.— Су бирүче кемгәдер башка кешегә мөрәҗәгать итә иде.— Бу тернәкләнә башлады шикелле.
— Бүген нинди көн?— дип сорады ятактагы тоткын.
— Сез байтак вакыт аңга килә алмый яттыгыз. Без инде бу турыда полковник әфәнде белән бәхәсләшеп тә алдык. Һәм мин оттым! Әйе, полковник әфәнде, мин бит оттым!
— Сез кем? — дип сорады теге кеше.
— Бу, хөрмәтлем, үлемгә хөкем ителгәннәр камерасы. Без тиздән... Шулай да танышыйк. Мин Мишель Деллатри булам. Бер француз шәһәренең элеккеге мэры. Ә менә бу — барон фон Хайдеггер, генеральный штабның элеккеге полковнигы, 1927 елдан нацистлар партиясе члены. Ә сез Россиядән, ахрысы? Игътибар итегез, полковник әфәнде, бер түбә астында нинди кызык халык җыелган. Мин, мәсәлән, традицион либераль буржуазия тарафдары, сез, полковник әфәнде, СС һәм СД члены, ә яңа танышыбыз коммунисттыр, күрәсең. Шушы компания өчен генә дә монда килеп эләгерлек! Мондый очрашулар, затлы чәчәкләр кебек, тормышка ямь өстиләр.
Полковник дигәннәре ишекле-түрле йөрүен дәвам итте:
— Бу урынсыз шаяртуларыгызны ташлагыз, Деллатри.
— Деллатри әфәнде дип эндәшүегезне үтенәм.
— Ярар, сезнеңчә — Деллатри әфәнде булсын.
— Мин, полковник әфәнде, яңа танышыбызга бары тик ситуацияне генә аңлатам,— дип дәвам итте Мишель Деллатри.— Бомбежка вакытында төрмәнең бер канаты җимерелде. Төрмәгә бомба ташлап, ин-

глизлар үзләренең акыллы баш иканлекләрен күрсәттеләр. Бәлки алар безгә ярдәм итәргә теләгәннәрдер. Әмма барып чыкмады. Шуңа күрә камераның кысанланып китүе өчен администрация исеменнән гафу үтенәм. Ләкин миңа болай ошый! Тугыз ай ялгызым ябылып ятканнан соң кеше белән аралашу бәхетенә ирештем!.. Полковник әфәнде, сез бүген инде егерме километрлап ара үттегез! Әйдәгез, яңа танышыбызны мондарак күчереп куйыйк, уңай булыр... Менә шулай!.. Рәхмәт сезгә, полковник әфәнде! Хөрмәтлем, сезгә су кирәкмиме?

— Юк, кәгазь бирегез... һәм карандаш,— дип катгый рәвештә әйтте теге кеше.— Минем бер генә имгәнмәгән төшем дә юк. Хәтердән башка... Кәгазь кирәк.

— Хәтер? Гафу итегез, мин сезне аңлап җиткермим. Менә бер кәгазь кисәге бар кебек. Рәхим итегез. Болай сезгә җайлырак, шулай бит?.. Мин большевизм яклы түгел, полковник әфәнде.— Мишель Деллатри сөйләшергә ярата иде.— Юк! Әмма нацизмны да хуплый алмыйм. Гомумән без өчебез өч станнан. Шулай булуга да карамастан... Полковник әфәнденең кәефе юк, дускай. Барысыннан да бигрәк аны беләсезме нәрсә борчый? Дошманнар белән бер камерада ятуы һәм язмышының уртак булуы. Ул моны кичерә алмый, чиктән ашкан мыскыллау дип кабул итә. Аның фикеренчә, наци, ә ул үзен Гитлердан да катырак наци дип исәпли... Әйе, полковник әфәнде, сез бәлки нәкъ менә шуның сәбәпле Гитлерга каршы заговорда катнашкансыздыр?

Полковник дигәннәре кинәт йөрүдән туктады:

— Сезнең шәһәрне, Деллатри әфәнде, барон фон Хайдеггер часте алды. Һәм беләсезме мин хәзер нәрсә уйлыйм? Шәһәрне алгач, ул частьның командиры очраган беренче агачка ук сезне асып куярга тиеш иде.

— Әйе, әйе, сез ялгышкансыз! Бер уңайдан сезгә бөтен дөньяны асып куясы калган. Ләкин сез аның муены кая икәнне белмәгәнсез. Эзләп тә таба алмагансыз. Дөнья көлгә әверелсә дә — сезгә барыбер! Солдатларыгыз күп. Бүген сезнең кулда — Европа, иртәгә — бөтен дөнья! Кайда соң сезнең ул солдатларыгыз? Алар инде туфракка әйләнде. Ә сез әле һаман дөнья үлчисез. Менә ул сезнең дөньягыз — таш капчык, төрмә! Йөренегез, әйдә, йөренегез ишекле-түрле, үлчәгез дөньяны! Бүген егерме километр, иртәгә — утыз, ә барыбер моннан чыктым юк. Ха-ха!.. Соңгы наци җир үлчи! Нигә гимннарыгызны җырламыйсыз? Җырлагыз, полковник, җырлагыз шул ахмак гимннарыгызны!.. Кадалып китсен сезне тудырган гасыр! Барысы да кадалып китсен!..

Цемент идән. Штукатурланмаган кирпеч стена.

Берсе акылдан шаша. Икенчесе ишекле-түрле йөрен ә. Ә өченче тоткын, аңын югалта-югалта, кәгазь кисәгенә нидер яза.

Менә кәгазь кисәге аның кулыннан идәнгә очып төшә. Карандаш кисәге дә кулыннан ычкына.

Француз иелеп кәгазь кисәген ала.

— Гарәп хәрефләре. Шигырьгә охшаган... Шигырь? Мондамы? — Француз көлеп җибәрде.

Коридорда аяк тавышлары ишетелә. Шыгырдап ишекләр ачыла...

* * *

Егерме дүрт елдан соң Көнбатыш Берлиндагы Шарлоттенбург округы загсының документларын тикшергәндә бер тарихчы шушындый эчтәлектәге документка тап була:

«2970

Берлин, Шарлоттенбург, 1944 елның 26 августы.

Язучы Муса Гомәров-Җәлил, мөселман, торган урыны Берлин, Хафельштрассе, 9, 1944 елның 25 августында 12 сәгать 18 минутта Берлинның Шарлоттенбург округы, Кенигсдамм 7 йортта вафат булды.

Вафат булучы 1906 елның 2 февралендә Мустафинода (Оренбург) туган. Атасы — Мостафа Гомәров-Җәлил, яшәгән соңгы урыны билгесез. Анасы — Рәхимә Гомәрова-Җәлил, кыз фамилиясе Сәйфуллина, бүтән мәгълүматлар юк. Вафат булучының хатыны Әминә Гомәрова-Җәлил, кыз чагындагы фамилиясе Сәйфуллина.

Берлинның Мантейфельштрассе, 10 йортта яшәүче күзәтүче ярдәмчесе Пауль Дюррхауэрның телдән әйткән мәгълүматларына таянып тутырылды. Бу мәгълүматларны җиткергән кеше үзе билгеле һәм үлемнең шаһиты булган. Кычкырып укылды, расланды һәм кул куелды. Пауль Дюррхауэр.

Төп нөсхә белән тәңгәл булуы расланды. Берлин, Шарлоттенбург, 1944 елның 26 августы. Загс хезмәткәре вазифаларын башкаручы Глюк.

Вафат булуның сәбәбе: башы киселде».

Солтан **ШӘМСИ** тәрҗемәсе

## Зиннур Мансуров

### Акка күчерү

**1**

Кибеттә бер хатын зары
килеп керде колакка:
«Ак буяу,— ди,— таба алмыйм —
әллә кая олаккан...»

Уйлап куйдым: яктылыкка
туйган күңел сирәктер.
Ак буяуның җитмәвенә
сөенергә кирәктер.

**2**

Хәтта Кояш йөзендә дә
кара таплар булгандай,
аккошлар да алай ук ак
булмый икән туганда;
акмы каен үрентесе
җирдән башын сузганда?..

Аккошлар да, каеннар да
яши-яши агара.
Тик бүтәнчә тартышадыр
күңелдәге ак-кара.

Һәрбер кеше күңеле дә
ак-пакь була туганда.
Кайберләре карала шул
үсеп дөнья куганда...

**3**

Мин Женнины күрәм: доктор Маркс
әсәрләрен акка күчерә.
Караламадагы һәрбер сүзгә
ул үзеннән яңа көч бирә.

Кара тап астыннан берәм-берәм
акка чыга сәйлән хәрефләр.

(Сак булмасаң, чиста битләрне дә
кабат пычратырлык хәвеф бар.)

Тагын сызып чыга сызылганны,
себереп ташлагандай тарихтан.
Җирнең якты фал китапларында
Җенниның да нуры бар икән!..

Хакыйкатен күңеленә манып,
«Капитал»ны акка күчерә,
күз аллары караңгылангачы!
Аннан якты-якты төш күрә...

Яшәешнең көрәш әлифбасы —
яктырмаган аннан кем җаны?!
Әле күпме кара кан түгәргә
акка күчерер өчен дөньяны.

## Хәрефләр

Озын-озак сәфәрләрдә йөртә, диләр,
берен хыял, берен нужа, берен мал...
Унлаган пот хәреф төяп, юлга чыккан
Шаһингәрәй, Габделлатыйп, Борынгал.[1]

Зур хәзинә икәнлеген баскыннарга
аңлаталмас хәтта «зирәк» курбашы;
хәрефләрне учка алып, әйтер генә:
«Пугачка да ярамый бит кургашы...»

Ә үзенең, кем әйтмешли, ике аягын
тотып селек — бер хәреф тә төшмәстер.
Кургашынның кайчан көчле икәнлеген
бик тә яхшы аңлап бара өч фәкыйрь.

Кырмыскадай мыжгып яткан хәрефләрдә
китапчылар белә күпме көч барын.

Өч айлык юл газабына түзәрлекме —
кургаш потлар ашый арба күчәрен.

Капчыкларда бихисап сүз кайнап тора —
төрлечә тез буйсынучан хәрефне.

Кибәге дә бардыр, бәлки, борчагы да —
акыл һәм кул башкара бит һәр эшне.

Җан азыгы булса икән һәрберсе дә,—
бар баш ярыр, болгатыры дөньяны...

Иң беренче китаптагы кызыл юлда
җуелмаска сеңеп калган кем каны?..

[1] Казан университеты типографиясендә хәреф җыючы булып эшләгән Ш. Бикқуловның, Г. Яушев белән Б. Биктимеровны ияртеп, 1880 елда Ташкентка сәфәр тотуы искә алына.

...Өч баһадир. Юлда кызып сөйләшәләр:
— Хәрефләрме? Без — иң көчле яу, юләр!
— Исеңдә тот: бу дөньяда көшны — азык,
ә сүз белән кеше җанын аулыйлар...

— Коры кургаш белән генә ни кыларбыз?
— Буяргамы? Бездә әле бар кан да!..

Төрле уйлар килә икән хәреф тулы
капчыкларга башны куеп барганда...

## Хәйретдин Мөҗәй көндәлегеннән юллар яки гомер шәрабы һәм сугыш мунчасы

*1. «Эчтем, бераз үзем дә кыздым...»*

«Сугыш язмалары», 24.11.41

Бераз кыздым, әмма җебеп
мәлҗерәргә чамам юк!

Юк, кыюлык өчен түгел,—
кыз катына ашкынмыйм;
шулай ук җан сызлавын да
хәмер белән басмыйм мин.

Тиредән үк чыга-чыга,
бер сөйләшер өчен дә
эчмәдем мин. Болай да сүз
тоткын түгел эчемдә.

Шундый афәт вакытында
түгел күңел ачуым.
Бу башыма йөз ләззәттән
өстен бер уй баш бүген.

Риза: янып үләргә дә,—
булсын хәерхаһ кына.
Эчтем гомер шәрабымны
Ватанымның
исәнлеге хакына!

Йоттым шул, тахилгә генә
эчкән ди бит тавык та.
Яшәү өчен күтәрдем мин
утырсам да табутта.[1]

Юк, әҗәлгә каршы дару
салып эчмим касәмә...
Сугышта син көн дә үләр
куркак булсаң,— яшәмә!

Халыкларның канын эчеп,
исергәндә паразит,
көн дә үлем исереклеге
белән йөрү — харам бит!

Эчми исерек булырлар ди
мәхшәр-үлем күзендә.
Ә мин аеклыктан гаҗиз,—
Нигә?
Белмим үзем дә.

Шәраб сорап тилмерттеме
җанымдагы хәйямлык?!

*2. «Бүген мунча кердем...»*

28.11.41

Без бит сөттә коенмаган,—
ник яшерим мин аны?!
Юк, үзең дә керләнмичә
пакьләп булмый дөньяны.

Юындырды каен кызы!—
Әйләндем күк сабыйга.
Карт тәнемә төште бугай
себеркенең сабы да.

[1] Җор күңелле сугышчылар землянканы шулай атаганнар.

Пакь су, үзе пычранмыйча,
керне ничек агартсын?!
Дөлдөл түгел,— тапсыз тотып
булмый җирнең ак атын.

Кызу сугыш үзе үк, дим,
кара мунча түгелме?
Йокса йоксын тәнгә корым —
каралтмасын күңелне!

...Ә мин, бәлки, үз мәетен
үзе юган үлемдар?!.

Җирне мунча кертешергә
әле гомер түлем бар!

Пычрануга түзалырмын
ант пакьлеге хакына.
Тик төшмәсен ил алдында
йөзгә нахак тап кына.

Җанга — мунча?
Сафлануның
бардыр башка юлы да.
Халык өчен фида булсаң,
барысы да юыла.

## Мичче

*Туган йортның мичендә бер*
*аркамны тереп торыйм.—*
*Җаным аша ага башлый*
*Гольфстрим!..*

«Кояш батареен ясаучы бар,
мичче табып булмый авылда.
Өйрәнмиләр — борча дагалау күк
катлаулы да түгел, авыр да...»

Тимербае кая, Әхмәтшасы?..
Чынлап, бер очта да юк алар.
Барысы да, кайтмас җиргә китеп,
кем әйтмешли, кирпеч сугалар.

Һөнәрләрен алып калмаганбыз —
«китаплары» белән күмелгән.

...Мичче китә...
Һәм бер җылы нурын
югалтадыр төсле күңел-җан.

## Көтүчесез авылда

Сорап тормый чират:
бармы телек-дертең —
авыл көтүчесе
булып ала һәркем...

Кибетче дә,
бригадир да,
ре җыючы да,
мөгаллим дә,
склад мөдире дә,
председатель хатыны да,
илгә кайткан профессор да...

Чыбыркы һәм курай
өйдән-өйгә йөри.
Көне буе өстә
«чүл кояшы» көйри.

Ваклык, гайбәт, үчтән
монда һәркем өстен.
Бәлзәм итеп сулый
сөтле тузан исен.

Хет бер тапкыр җиргә
яланаяк баса.

Телисеңме: суга
ипи манып аша.

Комга борын төртә
хәтта кәгазь кораб —
күлләр кибеп бара...
Кайта барсын карап.

Малы иясенә
охшый икән чынлап.

Истән чыга монда
«Жигули»га чират.

Акрын йөри сәгать —
кала төсле артка.
Дөрес яшисеңме?—
уйлан шушы хакта.

Чират җиткәч, Феокрит[1]
булып ала һәркем.

Көтүчесез калу
яхшыгадыр, бәлкем...

## Миләш

Чү! Бер песнәк миләш ашый —
ачы тели күңеле...
Бу бит минем зур кайгымны
уртаклашу түгелме?!

Тыныч кына үтә алмыйм
миләшлекләр яныннан.
Тәлгәшләре — хәтер уты —
шул утта мең янылган.

Яна башлыйм, шуларга гел
күзләремне төбим дә...
Минем әнекәем ята
кызыл миләш төбендә.

...Хаста әни. Бит алмасы —
йөткерүдән кан качкан...

Шулай тоям: бу тәлгәшләр
укмашкандыр кан-яшьтән.

Әчтән янам! Котылалмыйм
шул гомерлек җәбердән.
Капмасам да — миләш тәме
китми һаман бәгырьдән.

Чү! Бер песнәк миләш ашый —
ачы тели күңеле...

## Җаваплылык

Минем дә бар гомеремдә
бер парашют төргәнем.
...«Вагон-вагон» уйларымнан
калды бары бер гамем.

«Сәнгатенә төшенмәсәң,
башың белән түләрсең.
Ачылмаса,— биштәр асып
сикергән бер юләр син!..»

«Хыянәтең үзеңә үк
фаҗигале ачыла...»

Нигә кеше һәр эшенә
җавап бирми баш белән?..

---

[1] «Көтүчеләр поэзиясе» вәкиле буларак танылган борынгы грек шагыйре.

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

«Театр яктылыкка — нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.
Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр...»

Г. Тукай. «Театр», 1907.



Хәзер ТЮЗ урнашкан мәгълүм йорт. Монда беренче татар театр труппасы — «Сәйяр» спектакльләре куела. Тукай бу бинада еш булып, артистлар белән якыннан аралашкан.

Татьяна Зуева рәсеме.

# СҮЗЕБЕЗ — МӘКТӘПЛӘР ТУРЫНДА

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**Билгеле булганча, шушы елның беренче көннәрендә ук совет халкы карамагына гомуми белем мәктәбе һәм профессиональ мәктәпләр эшендә тамырдан борылыш ясардай реформаның проекты тәкъдим ителде. Аннан соң айлар буе анда күтәрелгән мәсьәләләр турында илебез кешеләренең фикерләре тупланды. «Реформаның төп юнәлешләре» хәзерләнде, ул КПСС ҮКның апрель Пленумында, СССР Верховный Советы сессиясендә яхшы дип табылды, закон төсенә кертелде.**

**Без, шул гаять мөһим вакыйга турында тәфсилләбрәк сөйләшү өчен, журнал редакциясенең түгәрәк өстәле янына республикабызның мөхтәрәм галимнәрен, педагогларын, мәктәп директорларын, хуҗалык җитәкчеләрен һәм язучыларны чакырдык. Алар арасында СССР педагогия академиясе фәнни-тикшеренү институты директоры, академик Мирза Мәхмүтов; Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан дәүләт педагогия институты ректоры, профессор Мирфатих Зәкиев; ТАССР мәгариф министры Равил Низамов; Казанның 55 мәктәбе директоры, СССР халык укытучысы Әнәс Сәләхов; Сарман районының Рангазар авылы урта мәктәбе директоры Илфат Мәрданов; Актаныш районының «Таулар» колхозы председателе Инсаф Камалетдинов; шагыйрь Сибгат Хәким; прозаик Мөхәммәт Мәһдиев бар иде.**

Әңгәмәне язучы Саимә **ИБРАҺИМОВА** алып барды.

**Я з у ч ы.** Озак еллар буена дәвам итә-итә безнең гадәтебезгә әйләнгән эш ысулларын үзгәртү җәмгыятьтән зур чыгымнар, өстәмә мәшәкатьләр сорый. Яңалык мәктәпләргә, илнең киләчәге булган балалар язмышына кагыла икән, бу очракта хәл бигрәк тә җитди төс ала. Шул җәһәттән караганда, кабул ителгән реформаның зарурлыгын нилә белән аңлатып була? Ул ниндирәк мәсьәләләрне чишүдә ярдәм итәчәк?

**М и р з а  М ә х м ү т о в.** Безнең җәмгыять кебек, нык үскән социалистик җәмгыятьне тагын да камилләштерү чорында халык хуҗалыгының һәр тармагы алдына берсеннән-берсе катлаулырак проблемалар килеп баса. Шулар белән бәйле рәвештә, тормыш яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсендә дә яңадан-яңа бурычлар куэгата. Аларны хәл кылу өчен безгә тәрбия эшләрен тамырдан үзгәртергә кирәк иде. Реформа шул объектив таләпләргә җавап йөзеннән ясалды. Мәктәпләребездә дә, һөнәр училищеларында да, техникумнарда да җитешсезлекләр, «авыру»лар шактый. Врачлар, авыруны дәвалар өчен, иң элек диагноз куялар. Без нәрсә белән авырыйбыз, һәм аны ничек дәваларга мөмкин?

Һөнәр училищеларын гына алыйк. Аларда бик күп төрле һөнәрләргә өйрәтәләр. Шуларның кайсысына кайсы укучы өйрәнергә тиеш? Аларны ничегрәк бүләргә? Бу укучыларны инженерлар укыта. Әмма алар педагог түгел бит. Педагоглыкка кыска вакытлы әзерлек кенә үтәләр. Әле анысына да программаны каян алырга, урынны каян табарга, вакытны ничек җиткерергә?

Профессиональ әзерлекнең дәрәҗәсе дә, ягъни укып чыкканда бирелә торган разряд, үзен акламый. Укучы хезмәт хакын 2 нче разряд буенча түгел, 4 нче разряд буенча аласы килә, ә бу югары разряд эшен башкару исә аның кулыннан килми.

Яшьләрнең шактый өлеше эштән бизә. Хезмәт җитештерүчәнлеге түбәнәя, эш ташлап китүләр башлана. Болар барысы да — безне интектерә торган авырулар, барысы да дәвалау сорый. Шулардан чыгып кына да әйтергә мөмкин: реформа үткәрергә безгә илнең экономикасы кушты.

Партиянең XXVI съездында халыкны экономикага өйрәтергә дигән мәсьәлә куелды, 1983 елгы июнь Пленумы да экономик фикер йөртүгә чакырды. Югыйсә, кеше үз кесәсендәге акчаны гына саный, дәүләтнекен исәпләп тормый башлады. Производствода бер генә процентка экономия ясалса да, миллионнар янга калачак. Еш кына без моны онытып җибәрәбез.

Урта мәктәптән ел саен бер миллионга якын яшьләр производствога китә. Ә берсенең дә һөнәре юк. Училищедан чыккан яшьләрнең ел саен 20 проценты билгеләнгән алмаштыра. Яки мәктәптән чыкканын да, монысын да бер үк эшкә, әйтик, слесарьлыкка өйрәтәләр — аларга 1 нче разряд бирәләр. Яшьләрнең исә югарырак разрядлы эшне башкарасылары килә. Чынында, алар шулай итәләр дә. Әмма күнекмәләре җитмәү сәбәпле, эш коралын, җиһазны куллана белмиләр, ваталар, җимерәләр. Икенче яктан, осталыклары барлы-юклы гына булгач, брак ясап чыгаралар. Менә сиңа план, менә сиңа сан! «Спартак» берләшмәсендә кайбер айлардагы брак 30 процентка җитә.

Эшчеләрнең түбән квалификацияле булуы — җәмгыять проблемасы. Урта белемле һөнәрсез яшүсмерләрдән миллиардлаган зыян килә. Без, шуларны искә алып, тәрбия эшенә реформа ясарга алынганбыз икән, бусы инде экономистларча фикер йөртү була. Без һәр кешене, һәр укытучыны шуңа өйрәтергә тиешбез.

Мисаллар да китерергә мөмкин: берәү училищеда укый, һөнәр ала, аннары икенче эшкә күчеп китә. Яңасына тиз генә урнашмый әле, тәнәфес ясый, янәсе... Эшсез буталып йөрүчеләр шуннан чыга. Болар — һөнәр сайлый алмау нәтиҗәсе. Бездә профессиональ ориентация бик начар куелган. Дәүләт училище укучыларына бик күп акча тота, аларны ашата, киендерә. Аннары шул чыгымнар бары да җилгә оча... Яшьләр һөнәрне үзенең физик һәм акыл сәләтенә карап сайларга тиеш. Һөнәргә ияләшә, яраша алу да — мөһим шарт. Болар барысы да безнең яшүсмерне ничек тәрбияләүгә бәйләнгән.

Мәктәпне политикадан да, экономикадан да һичничек аерып карап булмый. Идеология дә, политика да, экономика да мәгарифкә бәйле. Кешене ничек укытасың, ул шулай яши. Мәгариф системасында авыру бар икән — без аны дәвалыйк! Яңа реформа — менә шул авырулардан арыну өчен безнең кулга тапшырылган көчле корал ул.

**Энәс Сәләхов.** Реформаның әһәмиятенә нисбәтле рәвештә, мин өстәп тагын шуны әйтергә телим: хөкүмәтебез мәктәпкә грандиоз бәя бирде: совет мәктәбенең тарихын, үткән юлын күрсәтте, шушы мәктәпнең беренче бишьеллык батырларын, Бөек Ватан сугышында җиңгән каһарманнарны, космос лачыннарын әзерләвен, аларның барысын да тәрбияләвен ачык итеп күрсәтте. Хөкүмәтебез бөтен ил, бөтен дөнья алдында совет мәктәбенең дәрәҗәсен күтәрде.

Икенчедән, балаларны — илебезнең киләчәген — тәрбияләү бөтен халык эше, партия эше икәнен билгеләде. Монда эшче дә, колхозчы да, партия дә — барысы да бердәй катнаша. Мәктәпне шуннан да ныграк зурлау мөмкин түгелдер.

Халык реформа проектын хуплап каршы алды. Аны тикшергәндә миллионнарча совет кешеләренең фикере тупланды.

Реформа проекты мәсьәләсе КПСС Үзәк Комитетының Политбюросы утырышына гына да ике тапкыр куелды. Бу — партиянең киләчәк буынны тәрбияләүгә гаять игътибарлы булуын раслый.

**Равил Низамов.** Хәзер мәктәптә укучының нәрсәгә сәләтле икәнен ачу зарурияты алга килеп басты. Укучыга сәләтенә карап белем алу мөмкинлеге туачак.

Үзеннән-үзе аңлашыла ки, бу үзгәрешләр яңа дәреслекләр, яңа программалар, яңа методик кулланмалар таләп итә. Без бу юнәлештә эшне башлап та җибәрдек инде. Дәреслекләрне комиссиядә яңа күзлектән карап чыктык. Аларның кайбер-

сен өлешчә генә үзгәртергә, кайберләрен исә әр-яңадан төзергә кирәклеге күренде. Авторлар инде эшкә дә кереште. Югарыда әйтелгән кулланмаларны вакытында өлгертербез дип уйлыйбыз.

Республикада татар мәктәпләренең саны кими бара дигән сүзләр йөри. Бу урында мин ачык итеп әйтергә кирәк саныйм: соңгы мәгълүматларга караганда, киресенчә, татар мәктәпләренең саны арта бара. Республикадагы 2168 мәктәпнең 1180 нән артыгында фәннәр татар телендә укытыла. Безнең ул мәктәпләрдә, партия кушканча, рус телен өйрәнү тиешле югарылыгына куелган. Рус теле безнең районнарда хәтта балалар бакчаларында да өйрәнелә. Татар теле исә хәзер рус мәктәпләрендә укый торган татар балалары өчен I класстан алып X класска кадәр кертелә.

Мирфатих Зәкиев. Мирза Исмәгыйлович әйткәнчә, реформа бөтен совет халкының мәнфәгатьләренә кагыла. Бу очракта минем үзебезнең институт эшчәнлегенә кертеләчәк яңалыклар турында бер-ике сүз әйтәсем килә. Кайчак бездән, ни өчен ул мәктәпләрдә, аеруча авыл мәктәпләрендә, укытучылар җитешми, дип сорыйлар.

Әнәс Сәләхов. Чыннан да, безнең үзебезнең Мәскәү районында гына да башлангыч классларда унбишәр-егермешәр укытучы җитми. Сезнеңчә, моның сәбәбе нәрсәдә? Әллә педагогик вузлар аларны аз әзерлиме?

Мирфатих Зәкиев. Хикмәт институтларда түгел. Төп фәннәрнең укытучылары, минемчә, җитәрлек чыгарыла. Тик, кызганычка каршы, аларның барысы да мәктәптә төпләнеп калмый. Ике-өч ел үтүгә, алар һөнәрләрен алыштыралар. Моның сәбәпләрен «Реформаның төп юнәлешләре» турыдан-туры ачып бирде. Шунлыктан, якын киләчәктә әлеге башбаштаклыкларга чик куелыр дип ышаныйк.

Язучы. Ярый, укытучыларның сан ягын хәл дә иттек, ди. Бөтен мәктәпләр, бөтен класслар укытучылар белән тәэмин дә ителде, ди. Алар барысы да бүгенге көн педагогикасының катлаулы таләпләренә җавап бирерлек итеп тәрбияләнгәнме, тәрбияләнәме? Институтларда педагогик осталыкка өйрәтү мәсьәләсе ничек куелган? Әле бит класска килеп керә белергә дә, беренче сүзеңне әйтә белергә дә, үз-үзеңне тота белергә дә, ягъни укучыга үзеңне укытучы һәм тәрбияче итеп күрсәтә белергә, кирәк.

Латвия дәүләт университетында, мәсәлән, укыту программасына педагогик осталык курсы кертелгән. Бу курска Ян Райнис исемендәге Академия художество театры режиссеры А. Озолс җитәкчелек итә. Ул студентларны дәрес алып бару осталыгына өйрәтә.

Гадәттә, студентларның белеме җитәрлек була. Әмма алар классның игътибарын җәлеп итә алмыйлар. Менә шунда укытучыдан актер осталыгы сорала. Ораторлык сәләтенә дә мохтаҗ буласың, шаян сүз әйтеп, укучыларның күңелен күтәргәләүнең дә җаен табасы бар. Озолс җитәкчелегендәге курс студентлары шушы осталыкларга өйрәнә, класс җитәкчесе булырга җыенган студентлар өчен болар бигрәк тә файдалы.

Реформада укытучылар адресына бер генә тәнкыйть сүзе дә әйтелмәгән. Шулай ук безнең укытучыларның эшендә, аларның үз-үзен тотышында бер генә тел-теш тидерерлек урын да юк мыни, бары да ал да гөл генә мени?

Партиябез укытучыны «җәмгыятьнең ышанычлы кешесе» дип атады, бөтен совет җәмәгатьчелеген мәктәпкә ярдәмгә чакырды: яңа программалар, дәреслекләр төзеләчәк, материаль база ныгытылачак, укытучыларның хезмәт хакы да күтәреләчәк. Болар барысы да бик аңлашыла, болар барысы да — бик кирәкле чаралар. Әмма кайбер укытучыларда кичекмәстән бетерелергә тиешле сыйфатлар юк микән? Укытучы үзе дә үзенең абруен күтәрергә тырышырга тиеш түгел микән?

Әнәс Сәләхов. Еш кына мин менә болай дип уйланам: әгәр дә укытучының хезмәтен икеләләр яисә бишлеләр саны, алар ясаган аллы-гөлле стендлар,

плакатлар белән түгел, ә соңгы нәтиҗә буенча бәяли башласаң, нәрсә килеп чыгар иде икән? Бу нәтиҗә — кеше бит, гражданин! Менә шунда инде синең күз алдыңа урамда очраган исерек хулиган да, итәк астыннан гына мең бәясенә «дефицит» тәкъдим итүче үсмер дә, тиешле хезмәт күрсәткән өчен ришвәт алучы адәм актыгы да килә...

Болар да бит мәктәптә, ягъни, бездә укыган... Җитмәсә әле сочинениеләр язган чакта, совет кешесенең мораль йөзен, иҗади хезмәтнең матурлыгын тасвирлаганнардыр...

Мин сезнең укытучылар адресына нәрсә әйтергә теләгәнегезне чамалыйм, әлбәттә. Кызганычка каршы, кайбер мәктәпләрдә, кайбер укытучыларга төрле бәйрәмнәр уңаеннан, бүләк бирү гадәткә керде. Тора-бара бу бүләкләр бәллүр ваза, күлмәклек кебек кыйммәтле әйберләргә әйләнеп китте. Ата-аналар әлеге ямьсез адымнары белән укытучыларны никадәр түбәнсетүләрен, рәнҗетүләрен, кимсетүләрен дә аңламыйлар. Вак нәрсә диләрдер. Шушындый «вак» нәрсәләр дистәләрчә баланың җанын бозарга җитә.

Әгәр кеше гомере буена үзенең югары әхлагын саклый алмый икән, ул үзендә, мин укытучы була алмыйм, дип әйтерлек көч табарга тиеш.

Сүзнең эштән аерылмавы, намуслылык, укытучының тел тидергесез әхлаклы булуы — болар аның педагогик осталыгының, профессиональ этикасының нигезе. Укытучы «бөтен кеше кебек» түгел, ул барыннан да әйбәтрәк булырга тиеш!

Мәктәпнең материаль базасын ныгыту да — безнең өчен гаять сөенечле хәл. Югыйсә бит без гел сораша идек: шефлардан дисеңме, ата-аналарданмы... Ә алар каян алсын? Алар да шул эшләгән җирләреннән — заводтан, төзелештән, «тегеннән-моннан» алмыйлармыни безгә диган кирәк-яракны! Я буяу, я кадак, я такта... Үзең өчен түгел лә, мәктәп өчен, ни гаебе бар, янәсе...

**Равил Низамов.** Бу документта, игътибар иткәнсездер инде, ата-аналарга җаваплылыкның өр-яңалары йөкләтелде, аларга карата таләп көчәйтелде. Мәктәпнең роле никадәр генә зур булса да, бала тәрбияләүдә ата-ананы, гаиләне бәрәү дә алыштыра алмый. Әмма ата-аналардан бу бурычларны үтәтүдә дә мәктәп катнашырга тиеш.

Без ата-аналарның педагогик культурасын күтәрүгә зур игътибар бирәбез. Шул максаттан чыгып төзелгән махсус программалар мәктәпләргә тартылды да инде.

**Мирза Мәхмүтов.** Бик әйбәт, бик вакытлы чара. Бу кирәк иде, чөнки гаилә тәрбиясендәге чатаклыклар, хаталар яшьләрне әхлакый бозыклыкка, хезмәттән читләшүгә китерә. Хәзерге яшьләр, бигрәк тә шәһәр җирендә, уңайлы, аерым квартиралар алып, өлкән буыннан мөмкин кадәр ерактарак яшәргә тырышалар. Ә элек ничек булган? Яшь ана баланы тапкан да әби-баба кулына тапшырган. Өлкәннәр, халык педагогикасына таянып, баланы тәрбияләгән. Әби кеше, үз җае белән генә, тегеләй итсәң начар була, болай итсәң әйбәт була, дип оныгын әхлак кагыйдәләренә дә өйрәткән; тегене китер, моны алып алып бир, дип, йомыш кушкан, эшкә якынайткан...

Халык педагогикасы буыннан-буынга үстерелгән. Ул бит — халыкның гасырлар буена тупланып килгән байлыгы. Хәзер исә, яшьләрнең өлкәннәрдән ераклашуы аркасында, халык педагогикасының яшь гаиләләргә мирас булып күчмәү куркынычы туды. Мәктәптә дә, югары уку йортында да кешене бала тәрбияләргә өйрәтмибез. Яшүсмерләрнең эштән читләшүләре, әзергә-бәзер яшәргә омтылулары да, бәлки, тәрбия мирасын санга сукмауның ачы нәтиҗәседер. Хезмәттән йөз чөерүче балалар бәрәүгә дә шәфкать күрсәтмәячәк!

Гаиләдәге эчүчелек фактлары да безнең җәмгыятебезгә зур зыян китерә: үзең эчсәң, балаң да эчә, эчкән кешеләрдән гарип балалар туа, һәм аның зарары әллә ничә буынга китә.

**Инсаф Камалетдинов.** Мин ифрат та туры әйтелгән бу сүзләрне куәтләми кала алмыйм. Бала тәрбияләүдә ата-баба тәҗрибәсен санга сукмау, бала-чага-

га тискәре йогынты ясардай яман гадәтләргә бирелү — болар берсе дә яхшылыкка илтми. Моны гомер буе гади халык арасында кайнап яшәвемә таянып та, озак еллар буе берничә авылны берләштергән колхозны җитәкләвемә нигезләнеп тә раслый алам.

Авыл җирендә, мин бала тәрбиялим әле, дип лаф орып йөрмиләр. Күрәсең, безнең мәшәкатьләрнең туп-туры юлдан физик эшкә барып тоташуы үзе үк тәрбиягә йогынты ясыйдыр. Шәһәр кешеләре үпкәли күрмәсен, ни әйтсәң дә, авыл баласы, бәләкәйдән шактый җаваплы эшләргә катнашканлыктан, тормышка яраклашыбрак, шәфкатьлерәк, инсафлырак булып үсә. Олыны олыларга, кечегә ярдәм кулы сузарга өйрәнә. Нидектән бу болай? Чөнки өлкән агасы аңа турырак юлны сайларга, авыр эшне җиңелрәк иттереп башкарырга өйрәткән, ә кечкенәсенең иминлеген көне буена аның үз карамагына калдыргалаганнар. Авылның шактый мәшәкатьле тормышы, табигый рәвештә, хезмәттән башка яшәүнең мәгънәсезлегенә төшендерә.

Аннары, авыл гаиләләренең ишле булуы да — шәһәрдә четерекле мәсьәләгә әйләнгән хәлләрне чагыштырмача җиңелрәк чишәргә этәргеч. Мин үзем — ун бала атасы. Казандагы дус-ишләрем башта гаҗәпләнәләр иде: «Аба-ау! Ничек карап бетерәсез аларны? Әле монда берсе белән дә аптыраган...» — диләр. Мин ялгыз бала белән җәфа чигүче шәһәр ханымнарын яхшы аңлыйм. Кая куясың аны? Нишләтәсең? Кул-аягыңны бәйли ул бердәнбер бала. Икәү-өчәү генә булсыннар — хәл җиңелләшә: алар бер-берсенә күз-колак та була, олысы кечесенә үрнәк тә күрсәтә, ягъни баштагысына тырышып иңдерелгән тәрбия кечеләренә күчә бара. Кабатлап азапланууыңның кирәге дә юк. Унау үсәләр икән, бу — олы бәхет.

Яшьләргә, бала тәрбияләү кагыйдәләрен өйрәткәндә, без ишле гаиләнең аз санлылардан бәхетлерәк икәнен дә кат-кат төкърарларга тиешбез. Бу да — заман таләбе.

Икенчедән, минем «кечкенә һәм зур авыллар» дигән проблемага кагылып үтәсем килә. Без күптән түгел вак авылларны, хуҗалык үзәкләренә күчереп, «отышлы үен» белән мавыгып алдык. Сукыр тиен дә отмадык, әлбәттә, әмма шунда, кечкенә авыллардагы мәктәпләрне ябып, аеруча зур хаталык кылдык. Моның белән шаярырга ярамый. Бүгенге көндә безнең районның колхоз председательләре, егылатора дигәндәй, мәктәпләр санын арттырырга, мөмкиндәйләрен урта мәктәп итәргә тырышалар, чөнки иң өметле яшь көч — мәктәптә. Яшьләр — мәктәбе булмаган авылдан китү ягын карый. Башта син заманга хас шартлар тудыр, аннары эшкә чакыр яшьләрне! Тәрбия чарасымы бу? Һичшиксез!

**Р а в и л  Н и з а м о в.** Авылларыбызда шундый ачык фикерле җитәкчеләр булуына шатланам мин. Чыннан да бездә кечкенә мәктәпләрне ябу тенденциясе башланган иде. Мәктәп беткәч, таркалган авыллар булды. Хәзер бу хатага юл бикле. Татарстанда соңгы ике елда гына да яңадан утызлап мәктәп ачылды, сигезьеллыклар урта мәктәпкә әйләндерелә, колхозларның үзәк усадьбасында урта мәктәп, һичшиксез, булырга тиеш. Инсаф абый әйткән фикерләр яңа документта да чагылыш тапкан: укучыларны хезмәттә тәрбияләү, җитештерүчән хезмәткә әзерләү өчен дәресләр арттырыла. Бездә моңарчы да укучыларның җитештерүче көчен оештыруга әһәмият бирелә иде. Республикада 5 меңнән артык укучылар берләшмәләре бар. 1015 укучылар производство бригадасы эшли. Соңгы елларда укучылар азык-төлек программасын тормышка ашыруда актив катнашалар. Балалар яшелчәне яратып үстерәләр. Узган елда гына да алар 5 мең тоннадан артык суган үстереп тапшырдылар. Мәктәпләрнең ашханәсен яшелчә белән тәэмин итүдә дә укучылар үзләре катнашалар.

**И л ф а т  М ә р д ә н о в.** Балаларның табигате шундый: бурычның зуррагы тапшырылган саен, аларның эшкә мөнәсәбәте җитдиләнә, олыларның ышанычын акларга ихлас күңелдән тырыша башлыйлар. Безнең Рангазар урта мәктәбе укучылары елдан-ел үзебезнең «Җиңүче» колхозының төп таянычына әйләнә баралар. Бәрәңге, чөгендер үстерүдә аларның ярдәме һичнинди көч белән дә алыштыргысыз. Укучылар эштәге яңа ысулларны да үзләре башлап кабул итәләр. Соңгы елларда «бригада подряды» дигән алым мактала. Балалар аны «безнең класс

подряды» дип, үз эшләрендә куллана башладылар. Басуларны класслап-класслап бүлеп алалар да, бик тырышып эшлиләр, хезмәт хакын тигезләп бүләләр. Арттә сөйрәлүчегә дә, ялкауга да, дус-иш өстенә салынырга теләүчегә дә рәхим-шәфкать юк. Чөнки күреп торалар: берәүнең эленке-салынкы йөрүе бөтен классны артка сөйри.

Кечкенәдән гомуми хезмәтнең тәмен татып үскән укучылар, өлгергәнлек аттестаты алгач, бик теләп, колхоздагы даими эшкә киләләр. Колхозга да, ата-анага да, әлбәттә, авыл мәнфәгатен аңлардай кеше тәрбияләүче мәктәпкә дә шатлык бу.

**Мирфатих Зәкиев.** Мин хезмәтне кеше тәрбияләүдә иң зур көч итеп күрәм. Кеше көч сарыф итә, нидер ясый, һәм шушы эшнең аерылгысыз компоненты булып аның хезмәтенә күрә хак алуы торырга тиеш. Түләү булмаса, хезмәт тулы компонентлы булмый. «Карл Маркс» дигән хезмәтендә В. И. Ленин балаларның җитештерүчән хезмәттә катнашырга тиешлеге турында әйтә.

Минемчә, без «Бөтен иң яхшы нәрсә — балаларга» дигән лозунгны тормышка дөрес ашырмыйбыз. «Бөтен иң яхшы нәрсә — балаларга» дигәндә, без азыкның иң тәмлесе, киемнең иң затлысы, киноның иң яхшысы, гомумән, бөтен нәрсәнең иң әйбәте аларга булырга тиеш дип аңлыйбыз. Минемчә, алай гына түгел ул. Иң яхшысы — хезмәткә өйрәтү. Хезмәткә өйрәнгән кешенең генә киләчәге ышанычлы.

**Мирза Мәхмүтов.** Балалар бакчасы, мәктәп һәм училищелардагы тәрбия эшләрен дә тамырдан үзгәртәсе бар. Бу юнәлештә училищеларны хезмәт коллективларына якынайту мөһим. Соңгы елларда 44 нче училище малайлары белән, махсус методика буенча, Түбән Кама нефтехимиклары шөгыльләнә башлады. Берләшмәнең генераль директоры — техник фәннәр докторы Николай Васильевич Лемаев та моңа зур игътибар бирә. Предприятие эшчеләре, остазлар буларак, малайларны шефка алдылар.

Арчадагы 9 нчы авыл хуҗалыгы һөнәр училищесы укучыларын тәрбияләүдә язучылар да якыннан катнашалар. Укытучылар белән бергә язучы Мөхәммәт Мәһдиев һәм Сибгат Хәким хәтта дәресләр бирделәр.

**Мөхәммәт Мәһдиев.** Башта мин Арчадагы училищега үзебезнең университеттагы «Әллүки» түгәрәген алып бардым. Түгәрәк членнары укучылар алдында чыгыш ясадылар, шигырьләр укыдылар. Аннары мин аларга «Бөек Ватан сугышы чорында Татарстан» дигән тема буенча дәрес бирдем. Мин, шушы төбәктә туып-үскәнлектән, әлбәттә, инде дәрес биргәндә җирле материалдан да файдаландым.

Укучылар авыл хуҗалыгының сугыш чоры хәлен, анда кемнәр җитештерелгәнен, Арчаның экономик ягын сораштылар, мин аларга ул вакыттагы кыр батырлары турында, аларның фидакарь хезмәтләре хакында сөйләдем. Эстетик проблемаларга да тукталдык.

Шуннан соң мин бу училищега үземнең Татар дәүләт драма һәм комедия театры репертуарындагы «Борчулы өч көн» дигән спектаклемне алып бардым. Аны укучылар белән бергә карадык һәм спектакль турында фикер алыштык.

**Сибгат Хәким.** Мин дә дәрес бирдем Арча авыл хуҗалыгы училищесы укучыларына. Дәресем В. И. Ленинга багышланган иде. Мин укучыларга бу тема буенча эзләнүләрем, бу теманы өйрәнүләрем, юлбашчыга багышланган әсәрләремнең иҗат итөлү тарихын сөйләдем. Шигырьләр укыдым.

Училище укучылары «Беренче тау» шигыремне аеруча бирелеп тыңладылар кебек.

...Беренче тау...
Җирдә беренче тау...
Торган чакта дөнья уйланып,
Караган шул таудан Идел аша,
Караган яшь батыр, Ульянов.
Беренче тау...

Таулар биек, текә,
Ул менмәгән таулар юк алар...
Беренче тау
Ульяновны кәтә,
Кәтә анда тын, карт юкәләр.
Беренче тау...
Анда ятмый томан,
Үз вакытында шаулый яз анда.
Беренче тау
Беләсеңме кайда?
Без яшәгән данлы Казанда!..

**М и р з а  М ә х м ү т о в.** Бу очрашулар матур әдәбиятның йогынтысын көчәйтә, укучының дөньяга карашын формалаштыра. Менә шушылар нигезендә без методик кулланмалар язабыз.

Фәнни-тикшеренү институтының хезмәт коллективлары, язучылар белән элемтәгә керүе «Правда» газетасында, «Советская педагогика» журналында сөйләнде, СССР Педагогия фәннәре академиясе Президиумы тарафыннан хупланды.

Бу әле эшнең башлангычы гына. Безнең язучылар күп санлы. Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау белән махсус шөгыльләнә торган бюросы бар. Тәрбия эшен ныклы нигезгә бастыруда киләчәктә без язучыларга зур өметләр баглыйбыз.

Укучысыз әдәбият берәүгә дә кирәкми. Бу очрашулар әдәбият сөючеләрне арттыруга да булышачак, файдасы ике яклы булачак.

Бездә композиторларның, рәссамнар, журналистлар, артистлар, архитекторлар, кинематографистларның көчле иҗади гаскәре дә бар, эшкә алар да килеп кушылса, республикабызда тәрбия эшен күршеләрне кызыктырырлык итеп юлга салачакбыз.

**Ә н ә с  С ә л ә х о в.** Сезнең эш алымыгыздагы бу яңалыклар мине бик шатландыра. Ни өчен дисәң, хәзер безнең укучыларның күпчелеге училищелар карамагына барып керәчәк. Реформа профессиональ-техник системада яшьләргә гомуми урта белем бирү мәсьәләсен хәл итте. Димәк, бездә укый башлаган балаларның күбесе шәхес буларак училищеларда формалаша. Бу чорда үсмерләргә үзләренә үрнәк итәр өчен идеал эзләү хас. Училищеларда укытыла торган гуманитар фәннәргә игътибарны арттырырга тиешбез. Димәк, мәсьәлә яңадан кадрларга, ягъни, укытучыларга килеп тоташа.

**Я з у ч ы.** Аның шулай булмый хәле дә юк. Мәктәп турындагы реформа Законы Владимир Ильич Ленинның: «Бездә халык укытучысы буржуаз җәмгыятьтә бервакытта да тормаган һәм тормый һәм тора да алмый торган югарылыкка куелырга тиеш», дигән сүзләрен искә төшерде. Мәктәпләребез техник, методик яктан никадәр генә бай булмасын, киләчәк буынны тәрбияләүнең төп җаваплылыгы, төп авырлыгы укытучы җилкәсендә калачак. Шушы авырлыкны үз иңнәрендә тотарлык яшь һөнәр ияләрен без каян алырга тиеш?

Балаларны мәктәптә үк укытучылыкка әзерләүгә ничек карала?

Менә, мәсәлән, музыка мәктәпләрендә укыта торган укытучылар районнарга, авылларга чыгып, аеруча сәләте булган балаларны эзлиләр. Педагогия институтында да шуңа охшаш берәр эш башкарылмыймы: укытучылыкка сәләте булган балаларны эзләү гадәте юкмы?

**Ә н ә с  С ә л ә х о в.** Хәзерге заманда мәктәп профориентация мәсьәләсе белән күп шөгыльләнә. Ләкин без, укытучылар, әйтик, пешекче һөнәре турында, слесарь янсә врач белгечлеге хакында сөйләгәндә, үз хезмәтебезнең үзенчәлекләренә тукталмыйбыз диярлек. Әңгәмәбезнең журнал битләрендә күренүеннән файдаланып, әйтер идем: килегез сез безгә, кадерле яшьләр, мәктәпкә килегез, безгә яшь көчләр бик кирәк, курыкмыйча, икеләнмичә килегез! Мәктәптә эшләү авыр ул, әлбәттә; әмма кем әйтә әле аны — яшәү җиңел булырга тиеш дип? Мәгънәсез, җиңел тор-

мышның бәхет китергәнен кемнең күргәне бар? Укытучының балаларга багышлаган һәр минутының бәясен санап чыгара алсаң да, аның хакын барыбер түләп бетереп булмас иде, чөнки укытучы һәрвакыт циркулярлар белән билгеләнгәнгә караганда артыграк көч түгә. Безнең хезмәтнең җанга рәхәт китерә торган сере әнә шунда яшеренгән! Минем уемча, кешенең бәхете үзе бәхетле иткән кешеләр санынча арта бара. Шуннан чыгып исәплисең икән, дөньяда укытучыдан да бәхетле кеше юк!

**Мирфатих Зәкиев.** Яшь укытучыларны әзерләү мәсьәләсендә монда миңа да турыдан-туры сорау куелды. Минемчә, педагогик вузлар эшчәнлегенә бик зур, принципиаль үзгәрешләр кертергә туры киләчәк. Бер генә мисал. Безнең институтта төп фәннән саналган — мәктәп педагогикасы өчен нибары 40—50 сәгать вакыт бирелә. Мәсьәләнең мондый куелышы белән берничек тә килешергә мөмкин түгел. Мәктәп тормышы өчен бик кирәкле проблемаларны студентлар бер-ике сәгать эчендә йөгертеп кенә үтәләр. Мәсәлән, «укучының буш вакыты» дигән тема нибары бер сәгать укытыла. Бу бит — проблемаларның да проблемасы! Үзебез укыта торган кешеләрне без киң масштаблы тәрбия эшенә әзерләп чыгарырга тиешбез: класс җитәкчесе буламы ул, озайтылган көн группасында тәрбияче буламы, пионер, комсомол эшләрен, класстан тыш, мәктәптән тыш эшләрне оештыручы буламы — боларның барын да укытучы белергә тиеш.

Хәзер педагогик вузларда практика, медицина институтларындагы кебек, бөтен уку еллары буена алып барылырга тиеш. Яшәп килә торган программа буенча исә дүрт-биш ел дәвамында студент укучы балалар белән нибары дүрт айга якын гына аралаша.

Безнең студентлар авыл мәктәбендә дә практика үтәләр. Авылга җибәрүебезнең сәбәбе — шунда төпләнеп калмаслармы дип өметләнүдән. Күп очракта өметебез аклана да. Студентлар практикада булган мәктәпләренә эшкә китәргә ниятләнеп кайталар. Әммә шунысын да онытмыйк: авылда, район җирендә ул үзен яхшы укытучы итеп күрсәттеме, аны я колхозга, я комсомолга, я районга җитәкче эшкә алалар.

**Язучы.** Шулай да, абитуриентлар җыю мәсьәләсенә якынрак килсәк иде?!

**Мирфатих Зәкиев.** Безнең институтның бөтен факультетларыннан да кешеләр районнарга чыгып абитуриентлар әзлиләр. Без, аларны читтән торып «булачак укытучы мәктәбе»ндә укытабыз, соңгы елда бер ай буе имтиханнар бирүгә әзерлибез.

«Реформаның төп юнәлешләре»ндә педагогик вузларга абитуриентларны мәктәпләрнең һәм һөнәр училищеларының педагогик советлары рекомендациясе белән җыярга тәкъдим ителә. Шуңа өстәп, педагогик советлар үзләре вузларга җибәргән кешеләр өчен җаваплылык тойсыннар иде диясе килә.

Партиябез безнең алга укытучыны әзерләү сыйфатын күтәрү бурычын куя. Белем алу хакына гына белем алу — мәгънәсезлек. Яңа типтагы укытучыны әзерләү мондый юлдан барырга тиеш түгел. Бу — педагогик эшкә сәләте булган яшьләрне сайлап алудан башланырга тиеш. Менә шуңа күрә дә без үзебезнең институттан чыккан белгечләр белән өч ел буена элемтә тотабыз. Һәр кафедрада аларның исемлекләре бар — эшчәнлекләрендә нинди үзгәрешләр булган, нинди үсеш юлы үткәнәр, кем итеп сайланганнар — барысы да теркәлә, киңәшләргә мохтаҗ булса — ярдәм күрсәтелә.

Һәр елны яшь укытучылар слеты үткәрәбез, аларга докладлар, лекцияләр сөйлибез, бирер җибәрергә методик әдәбият әзерлибез.

Укып чыккан студентларыбыз үзләре дә абитуриентлар әзерлиләр.

Безнең институтта һәр кафедра авыл районына беркетелгән. Институтның гыйльми советы һәр районның халык мәгарифе буенча район Советында бергәләп киңәшмә үткәрә. Районда ничә укытучы җитми, ничәсе пенсиягә китә, ничә укытучы кирәк булачагы бергәләп ачыклана. Аннары секцияләрдә занятиеләр үтә. Бу — ике як өчен дә бик файдалы аралашу.

Безнең бу эшләребез РСФСР күләмендә «Казан практикасы» дигән исем астында башка вузларга да тәкъдим ителде.

РСФСР Министрлар Советының карарында: «укытучылар әзерләү; студентларны идея-политик, психологик-педагогик, хезмәт ягыннан әхлакый һәм эстетик яктан укытуның һәм тәрбияләүнең комплекслы системасын төзү;

гыйльми-педагог кадрларны аспирантурада әзерләү; югары һәм урта мәктәп педагогикасы проблемаларын эшләү һәм тормышка кертү өлкәсендә Казан дәүләт педагогия институтының уңай эшен бәяләп үтә»,— дигән сүзләр дә бар.

Шул ук карар РСФСР Мәгариф министрлыгына «...Укытучылар әзерләүдә һәм мәктәпләрдә эшләүче укытучыларның квалификациясен күтәрүдә Казан дәүләт педагогия институтының уңай эш тәҗрибәсен киң җәелдерүне оештырырга» кушты.

«Реформаның төп юнәлешләре»ндә педагогик кадрларның квалификациясен күтәрү системасы тагын да камилләштерүгә мохтаҗ», диелгән. Шуңа бәйле рәвештә, безнең институт галимнәре укытучыларның белемен күтәрү институтында да укыталар. Алай гына да түгел, без үзебезнең институт күләмендә мәктәп директорлары, уку-укыту бүлеге мөдирләре һәм роно хезмәткәрләре өчен ике айлык квалификация күтәрү факультеты оештырдык. Бу эш һәр ике як өчен дә бик файдалы.

**Равил Низамов.** Мирфатих Зәкиевич, сез бит әле үзегезнең тагын бер матур эшне әйтми калдырдыгыз: Казан дәүләт педагогия институты Татарстанны гына түгел, тагын 24 өлкәне милли кадрлар белән тәэмин итә.

**Мирфатих Зәкиев.** Әйе шул, без аларга ел саен егерме биш белгеч урынына җитмеш бишне озатабыз.

**Язучы.** Бүгенге көн таләпләренә тулысынча җавап бирердәй яшь укытучы бигрәк тә кайсы ягы белән аерылып торырга тиеш?

**Равил Низамов.** Без укытучының бөтен эш артыннан да үзененең йөгерүен, барысын да үзе эшләвен хупламыйбыз. Ул укытучыларга, пионер, комсомол оешмаларына таяна белсен, аларга педагогик-фәнни юнәлеш күрсәтеп бирсен. Без менә шундый укытучыларны мактыйбыз, шундыйлар белән горурланабыз.

Тәрбиянең шул якларын күздә тотып, безнең мәктәпләрдә үзидарәгә игътибар арттырылды, комсомол, пионер, укучылар оешмаларына ныграк ышаныч белдерелде. Безнең министрлык каршында махсус лаборатория оештырылды. Ул укучылар үзидарәсен камилләштерүнең педагогик нигезләрен өйрәнә, хәтта мәктәпкәчә яшьтән үк уку процессында дәрестән тыш эшләрне дә эченә ала.

РСФСР Мәгариф министрлыгы бригадасы килеп безнең бу тәҗрибәне өйрәнеп китте. Бу хакта Коллегиядә дә сөйләдек.

**Язучы.** Без бер төп фикергә якынлаштык бугай: мәктәпләр тормышына гаять мөһим яңалык кертәчәк реформа халык мәнфәгатьләрен, җәмгыятьнең алга китешен күздә тотып чыгарылган. Төп мәсьәлә шунда: без барыбыз да — ата-аналар да, педагоглар да — мәктәпкә җәмгыятьнең киләчәге итеп карарга тиешбез. Мәктәп юл башы, чишмә! Ул — иң изге башлангычларга старт! Икмәктән кала, халык өчен иң әһәмиятлесе — мәктәп! Әгәр шулай итеп аңлыйбыз икән — без алдыбызга Партия куйган бурычларны җиренә җиткереп үтәрбез.

Салих Маннапов

# ЧЫНЛАП ТА ШУЛАЙМЫ СОҢ?

## КҮЗӘТҮЛӘР ҺӘМ УЙЛАНУЛАР

*Суын алмаган кое тиз корый...*

Халык сүзе

Алдымда — ике шагыйрьнең күптән түгел бер-бер артлы басылып чыккан цикллары. Икесе ике буыннан, бер-берсенә һич охшамаган авторлар. Ләкин... укыйсың— бер төсле үк сәер халәт били бара... Ничегрәк аңлатып булыр икән ул халәтне... «Ан-2» самолетына утырып очкандагы кебегрәк дипме соң...

Ару-талуны белмәс мәшһүр «кукурузник» бу чагыштыруга үпкәләмәс, шәт. Чыннан да, әлеге шигырьләрне укыганда, самолетка утыру кебек үк, матавыклы әзерлек эшләре үтәргә кирәк. Анда да тавыш һәм «һава упкыннары», күтәрелә һәм төшә алмый интегү... Самолетта очуның тагын бер җайсыз ягы бар — үзеңне иркле хис итә алмау: бәйлелек — ниндидер кагыйдәләргә, билетта күрсәтелгән урынга, расписаниегә, һава шартларына, тагын әллә ниләргә. Менә шул хәлләргә һәрвакыт шактый авырсынып кына риза булган шикелле, ул шигырьләрне укыганда да ниндидер вакытлы мәҗбүриятне тоясың: бу мәҗбүриятнең вакытлы булуын белү генә шул шартларга түзәргә, хәтта шулай тиештер дип, эчтән тынарга күндерә... Әлеге биеклекнең һәрвакыт җирдән бәйлелеген, җиргә нисбәтле булуын тоеп барасың. Җирнең кадере арта, җәяү йөрисе килү теләге көчәя...

Әдәби орбитага күчкәндә, шундый чакларда, йөрәкне урынына утырту өчен, җитдирәк шагыйрьләребез иҗатын, классикларның китапларын кулга алырга мәҗбүр буласың.

Юк, бу — бериш шигырьләрне, стильләрне башкаларына каршы куярга җыену түгел. Кешенең кискен, көчле тойгылар, тизлек, биеклек халәтен кичерәсе килүе дә, тынычлык, тотрыклылык, җиргә нык басып торуны теләве дә вакыт, кәеф, зәвык һ. б. шартлар белән бәйләнгән. «Ан-2» дә дә, бәлки, бик күпләр ваннада яткан кебек рәхәтлек кичерәләрдер.

Шигырьдә канатланып очу, баш әйләнерлек тизлекләр дә булырга тиеш. Шуңа сусау бар адәм баласында! Сүз — канатларны кисеп, җирдән мүкәләп бару турында, янсә шуңа чакыру максаты белән түгел. Сүз — күңелнең чын тизлек, биеклек һәм табигый киеренкелеккә сусавы, нәкъ әнә шундый чакта ниндидер таяну ноктасы, ныклык, җирне тоясы килү халәте уянуы турында.

Адәм баласы, менә шулай, ике арада талпына, каршылыклы кичерешләр утында яна инде ул... Укыйсың, аңлый барасың — күге биек әсәрләр җирне нык тою аркасында гына иҗат ителә. Тормышка, кеше язмышына якынрак булган саен, тормышны ямьлерәк, кешене матуррак, бөегрәк итүче әсәрләр языла.

Шагыйрьләребезнең заман агышын аңлап, көн таләбен тоеп, мөһим иҗтимагый-политик, социаль-әхлак темаларына алынуы аларның гомуми активлыгы үсүе турында сөйли. Кешенең аңына, йөрәгенә үтеп керү өчен барган катлау-

лы идеологик көрәш шартларында чын кичерешләр бүләк итә алырлык әсәрләргә ихтыяҗ зур. Кеше күңеленең яңа тирәнлекләрен ачу, заманча фикер сөрешенә ия булу, заман проблемаларын чорга лаек итеп күтәрү өчен яңа мөмкинлекләр эзли бүгенге поэзия. Күрәсең, бу юлда «чыгымнар»ның байтак булуы да табигыйдер.

Шигырьнең кайчак укучыны бик күп шартлар, шартлылыклар аша үтәргә мәҗбүр итүе әле бер хәл... Кайвакыт шушы бәла-казаларны кичеп тә без, гүләүдән башка, берни дә ала алмыйбыз. Шигырь ничек башланса ахыргача шулай дәвам итә. Ә бит үзе шатыр-шотыр килә, әллә кайсы төшләре кубып төшәрдәй булып калтырый, шау-шуы колакны саңгыраулата... Шигырьнең, асылда бер ноктадан кузгалмаган килеш, гүләп-дерелдәп утыруы һәм «техник сәбәпләр аркасында» укучыны күтәреп, вакыт һәм пространствода күчерә алмавы кызганыч.

Рифмалы сүзнең, ясалма канатларга таянып, техника исәбенә генә күтәрелергә азаплануы да шаккатырлык хәлмени! Нормаль хәлмени! Поэзиядән тимер салкыны гына килеп торуы мактаныч була алмый. Яңа сүз әйтергә омтылуны бөтән юнәлешкә алып китеп, кайбер авторлар әнә шул якка хәтта махсус басым ясал, техника белән алдырырга тырышалар кебек.

Әлбәттә, төп тенденция буларак, шигырьләрдә табигый сулыш һәм тормышчанлык кимеми. Үзенә якын күренешләр һәм кичерешләр турында язганда, күңелендә бөялеп торган тирән хисләренә юл ачканда, төрле буын шагыйрьләр ихлас һәм табигый булып калалар.

Билгеле бер даирәдә судагы балык кебек табигый яшәешкә ия булган шигъри әсәрләр языла. Әмма зуррак, җитдирәк тема-проблемаларга алыну белән, шактый гына очракларда, мәгълүм мәсәлдәге Баканың үгез кадәр булып кабарырга азаплануы кебегрәк, көчәнү килеп чыга... Шагыйрьнең күтәрә алмастайны күтәрергә тырышуы һәм аннан шуны таләп итү (көчкә туры килми торган таләп), изге омтылыш хәлендә калган әйбер — җитди темаларны ваклау, халтура тегермәненә су кою, укучыны биздерү булып кына кайта.

Шигърият, үзенең асыл үрнәкләре белән, без еш кына истән чыгара торган хакыйкатьне кабат-кабат раслап яши: тышкы накал, зурдан кубу үзеннән-үзе генә уңай нәтиҗә бирми. Әйдә, күбәләк кебек кенә булсын — канат җилпенеше дә зәгыйфьрәк тоелсын, «түшәме»дә үзенә тиң булсын ул шигырьнең, хәтта күбәләк гомерен генә яшәсен...— әмма шул гомер эчендә ул безнең тормышны аз гына булса да ямьлерәк итәргә, табигый кичерешләр белән янып алырга, ниһаять, таш кебек күңелләрдә дә үзенең җылы сурәте-эзен калдырып китәргә сәләтле!

Тыштан һичнинди хәйләсез, самими генә кайбер әсәрләрнең җисемендә, тукымасында, һәр күзәнәгендә беленеп тоелып торган шундый табигыйлек күңелнең әллә нинди тирәнлекләрен айкап чыгара,— җырлыйсы да килә, елыйсы да килә... Андый шигырьләрне укыганнан соң, дөньяның бөтенлегенә, кешенең матурлыгына ышаныч арта, шул бөтенлекне, матурлыкны үзеңнең дә арттырасы килү теләге уяна...

* * *

...Бу язмаларны, шигырь китапларының ак калган төшләренә язылган сүзләр, дип атап булыр иде, бәлки...

Китапка кечкенә кәгазь кисәкләре кыстырып, фикереңне юл уңаенда, кайнар көе, ачыктан-ачык язып бару — тәнкыйтьче халкының профессиональ гадәте. Соңыннан ул язмаларның күбесе мәкаләләргә керми дә кала. Кагыйдә буларак — аерым киңәш-тәкъдим өлешләре, кимчелекләргә төртелеп узган урыннары. Аларны еш кына мәкаләнең тоны, төзелеше, максаты сыйдырмый: шагыйрь иҗатына гомуми бәяне төшерер дип, фикер сөрешен чарпаландырыр, дип уйлыйсың...

Бу юлы мин мәкалә язмаска булдым. Әлеге шул «китап читенә язылган» сүзләрнең кайберләренә кире кайтып, шулар хакында бераз уйлану иде исәп. Мәкалә яза башласаң, чыннан да, исемнәр, гомуми бәяләр, хәтта тарихи чигенешләр...— юк, бөтенләй башка үзәнгә алып кереп китәчәк. Ә бу юлы әле миңа бәләкәй генә эксперимент ясап карау мөмкинлеге дә күренеп тора. («Эксперимент» дигәч тә, аның хикмәтен-серен, күрәсең, бераз соңынтынрак ачу дөрес булыр...)

Мәгълүм булганча, һәр тәнкыйтьченең эчендә тагын бер тәнкыйтьче утыра бит

әле. «Личный», «лирик» тәнкыйтьче дигәндәй. Кулыңа каләм алганда ул гел кисәтеп тора: җитешсез якларны ипләбрәк әйт, тамырына балта чабу булмасын, төп тонны берүк басып китмәсен! Алга таба сүзләр «түгәрәкләнә», шомара, димәк, тагын бераз йомшара. Укучыга тәкъдим ителгәндә инде мәкалә кулдан тере балык кебек шуып чыга. Тәнкыйтьче үзе дә аптырап кала. Юк, һәр ноктасы үзенеке, сүз сөреше нәкъ аныңча, фикеренең дөреслегенә шикләнми. Әмма... Шагыйрь иҗатына тулаем бәядә күпмедер перспектива калдыру, җитешсез якларны «түгәрәк» сүзләр белән, басым ясамыйча гына әйтеп китү... Бу — укучыны ялгыштырмасмы, шагыйрьнең үз-үзенә хилаф мөнәсәбәт тудырмасмы... Чынлап та шулаймы соң барысы да? Аерым очрак, хәтта бер карашка вак деталь булып тоелса да, асылда җитди һәм каршылыклы хәлләргә күз йомып, аларны сыйпап-сырлап үтә килү тора-бара зуррак, катлаулырак әйберләр, кимчелекләр булып җыелмасмы?

Яисә шулай да була. Игътибар итә киләсең: берәү артык күзгә чалынмыйча гына шигырь язып маташа, ара-тирә басылгалый да. Язганнарының төп өлеше — балаларның кибеттән «Конструктор» тартмасын сатып алып, әзер детальләрдән радио җыюы шикелле үк, яңа сүз түгел... Җитдигә санамыйсың: андый әйберләр басылгалый инде, мондый шаярулар поэзиядән ерак тора,— кыскасы, гонаһсыз мавыгу... Ләкин җитә бер вакыт,— әзер өлге-конструкцияләр белән эш итәргә остарып өлгергән автор инде үз юлында берникинди тоткарлык күрми кебек. Әдәбиятта вакыйга булырдай күренешләр турында да сүз әйтелми тора, ә аны мактап язылган «тәнкыйть» күзгә керә. Хөрмәтле генә кешеләр гаҗәп җиңеллек белән зур-зур сүзләр ычкындыралар. Яңа исем, табыш, ачыш, диләр. Аптырап каласың: чынлап та шулаймы соң?!

Әлбәттә, поэзиягә карата абсолют фикер була алмый, ул һәр заманда төрле карашлар, зәвыклар бәрелешенең кайнар ноктасы булган. Соңгы елларда беркадәр сүрелү-тынычлану, академик тонга күчү — әйбәт фал, дип раслаучылар да күп. Һәрвакытта да шулаймы икән соң? Безнең шигъри цех тоташтан сыйфат билгесе куярлык продукция генә бирә башладымы, әллә, иң гадәти газета мәкаләсе кебек,— укысаң-укымасаң да ярарга әйләнеп барамы? Поэзия уңаеннан әллә ни ис китмичәрәк сөйләшү җәмәгатьчелекнең аңа игътибары кими төшү турында кисәтмиме?

Хәер, бу фикер үзе шактый ук каршылыклы, чөнки шул ук «соңгы елларда» матбугатта шигъри хәрәкәт турында күзәтү, фараз һәм бәхәсләр аз булмады. «Алдамы, арттамы? Хисме, акылмы? Тынычмы, шартлаулымы?» һ. б. лар, һ. б. лар. Моннан берничә ел элек оештырылган зур сөйләшү вакытында поэзиянең гражданлык йөзе турында җитди фикерләр әйтелде. Кызыклы күзәтүләргә бай, иҗатчы шәхесе һәм анык гражданлык позициясе җәһәтеннән олы таләпләр куеп фикер алышу иде ул.

Әлеге сөйләшүләрдә көн тәртибенә үк куелмаса да, миңа калса, гел игътибар үзәгендә торган бер мәсьәлә бар иде. Ул — бүгенге әдәбиятның үз укучысы белән уртак тел таба алу-алмавы мәсьәләсе. Юл уңаенда гына килеп чыгу аркасындамыдыр, әллә бераз төшенкерәк һәм субъективрак тонга күчүләре ошап җитмәдеме,— бу хакта сүз кузгатучыларның еш кына уңайсыз хәлдә калуы сизелә иде. Андый чакларда әлеге проблема үзе дә җитдилеген югалткан кебек тоела башламадымы икән әле? Юктыр, мөгаен. Алай булырга тиеш түгел. Чөнки без — телибезме, теләмибезме — әдәбиятның кыйммәтен һәрвакыт укучы буларак бәялибез.

«Китап читендәге язулар» да — укучының шигырьгә беренче, турыдан-туры мөнәсәбәте. Әмма... ни өчен анда бөтенләй ак калган (димәк, «сөт»кә киткән) битләр һәм сорау билгеләре (ягъни аңлашылмаучылыклар) ешрак күзгә чалына?..

Менә шул сорау билгеләрен яңадан карап чыгасы — бүгенге поэзия белән анык укучысы арасындагы бәйләнешләрнең өзелгән яисә урнаша алмый калган очракларына тагын бер кат игътибарны юнәлтәсе, шул уңайдан кайбер күзәтүләр белән уртаклашасы иде.

Әйе, авырткан җирдән кул китми, дигәндәй, бүгенге поэзиянең казанышларына ихлас сөенгән хәлдә, бу юлы мин үземне (һәм, ихтимал, нинидер дәрәҗәдә башка укучыларны да) борчып йөргән мәсьәләләргә басым ясый төшәргә, аларга якынрак килеп карарга уйлыйм. Якыннан караганда алай ук вак булып тоелмыйлар алар.

* * *

Шундый бер риваять бар.

Имештер, көннәрнең берендә булачак пәйгамбәрне атасы базарга агач пот (мәҗүси тәңре сыны) сатарга җибәрә... Дәресен әйтергә кирәк, товар үтемле түгел. Шунлыктан Мөхәммәтнең дә күңеле тартмый: көнозын базарда утырасы, ә соңыннан сатылмаган товарны кире төяп кайтасы... Ләкин ата сүзеннән дә узып булмый. Иң соңгы юлны сайлый — хәйләгә керешә малай. Иртән бер кочак сынны бау белән бәйли дә, җирдән сөйрәп тузан туздырып базарга чыгып китә. Үзе юл уңаенда ук сөрән салып бара: «Пот сатам! Алып калыгыз! Һич югы ясагыз — мичегезне җылытыр,— агачы бик шәп бит!» — дип кычкыра икән. Шәһәр халкы бу тамашаны күреп: «Бу ни хәл, нинди башбаштаклык бу?! Безнең тәңрене мыскыл итә бит бу малай актыгы!» — диешәләр һәм, әлбәттә, алар да шушы хәлдән чыгуның бердәнбер юлын табалар: базарга барып җиткәнче үк, зирәк Мөхәммәтнең бөтен товарын сатып алып бетерәләр...

Малай чакта колакка кереп калган бу риваятьнең сөземтәсе, гыйбрәте ачыклап торуга да мохтаҗ түгел: булган байлыгыңны тәкъдим итә белү дә зур сәнгать, ди ул. Синең алтын кулыңнан үтеп, көмеш тир тамчыларың белән сугарылган җитди хезмәтең икенче берәүнең һәйбәт кәгазьгә төрелгән түбән сыйфатлы «товары» янында югалып калса — менә бусы үкенечлерәк, рәнҗешлерәк.

Бәлки, кайвакыт әнә шул күрсәтеп җиткерә белмәү дә безнең эшне, дәрәҗә-кимәлне,— әйтик, поэзиябез ирешкән биеклекләрнең зурлыгын ерактан ук танырлык-күрерлек итә алмыйдыр әлегә?

Бәлки, гомумән, җитди, тирән шигырьгә караганда буш ритмнар, затлы эчемлек этикеткалары һәм чалбар «фирма»ларының күбрәк игътибар үзәгендә булуы шуннан киләдер?

Аннары, шунысы да яшерен-батырын түгел, кайчакта этикеткага, ярлыкка кайсыбер шигырьләргә караганда күбрәк мәгълүмат салынган була! Алар бүгенге көн тизлекләреннән калышмаска тырышып дөнья куучы кешегә ныграк кирәк булып чыга! Ә безнең җир гаменнән аерылган фикер-фаразлар, әзер детальләрдән җыелган шигырьләргә «мич кабызырга ярар әле» дип тә күз салучы табылмый башларга мөмкин...

Әсәр укыламы?— бу беренче карашка гына җитди сорау булып тоелмый. Синең шигыреңә, бәлки, дәрьяларның агышын кирегә борырлык фикер салынгандыр. Ләкин... иң әүвәл аны укыйсы бар, аны әле укырга кирәк. Шигырь нәрсә ул!..— Ара-тирә роман хәтле романны «укый алмадым» дигән сүзләр дә ишетелеп китә. Ә бит ул «укый алмаган» әсәрдә кызыклы образлар, фикерләр, язмышлар, әлегәчә берәү дә күтәрмәгән катламнар бар. Шулай дип әйтеп карагыз— ышанмый. «Мин аны укый алмадым,— ди.— Мин ни өчен азапланырга тиеш»,— ди.

Мондый очракларда иң җиңеле — укучыны үшәнлектә, тармаңгайлыкта гаепләү. Фикер җегәре артамы, эстетик информация байыймы тел көрмәкләндерүдән, ясалма катлауландыру-боргалаудан,— менә шул гади генә нәрсәләр хакында, гаҗәп,— кайвакыт талантлы гына автор да башкача уй йөртә. Ә көнлекче автор шулай боргаланулар артына үзенең бушлыгын яшерергә азаплана. Тыштан бер үк нәтиҗә. Хәтта мондый очракта талымсыз, әмма борыны сизгеррәк «уртакул» отучы булып чыга. Ул җиңел укылыш, вакыйга-интрига кору исәбенә укучыны яулап бара. Укучыларның бер өлеше шундый җимгә каба, шул рухта тәрбияләнә. Асылда фикер һәм образ яңалыгы булмаган андый әйберләр чыгып өлгергәнче үк: «тәҗрибә җитми — анысы факт, әмма укыла бит...» — дип яклау, «әдәбиятның йөзен билгеләми торган әсәр бит бу,— тимәгез инде!» — дип тәнкыйтьтән аралау сүзләре ишетелә башлый... Әлеге авторларга: «мондый сүзләргә алданмагыз, туктап-юанып калмагыз; киеменә карап каршы алу, акылына карап озату кагыйдәсен әле әдәбиятта да һичкемнең урап уза алганы юк»,— дип әйтәсе иде кана...

Әдәби осталык ягына игътибар иткәндә, кайвакыт тәнкыйть тә укучыны әнә шулай ялгыш юлга кертеп җибәргәли, ахрысы.

Без уңга-сулга «эзләнә», «үзенчәлекле» кебек сүз-бәяләрне юмартрак сибә башладык, аларны беркадәр норматив тәшенчәгә әйләндереп киләбез булса кирәк. Бөтенесе үзенчәлекле, бөтенесе эзләнә... Без инде кайвакыт яхшы белән яманны аера алмый торган хәлгә килеп җиттек кебек тәэсир кала башлый...

• • •

Бу тигезләү-буталышның сәбәпләрен эзли китсәң, кайбер нәрсәләрне бүгенге поэзиядәге «тигезлек», «алтын урталык»тан да күрә башлыйсың. Төрле стильләр, төрле буын әдипләренең янәшә торып, кулга-кул тотынышып эшләве мәгънәсендә түгел бу «тигезлек». Уртакул белән чын ачышның янәшә, бер рангта йөрүе, уртача югарылыктагы әсәрләр, уртача геройлар, уртача тел булуы мәгънәсендә ул. Хәтта, кемнәрнедер даими рәвештә аерып куюю рәвешендә яманаты чыккан «обойма» да шушы шартларда бөтенесен соры төскә буяу белән алдыра башлады: хәзер «обойма»ларга бөтенләй билгесез исемнәрне дә кушып җибәрү яңалык һәм кыюлык дип санала, имеш. Эңгер вакытында бөтен мәче соры, дигән күк килеп чыга...

Шулай да соңгы егерме елда поэзиядә зур давыллар уйнап узуы мәгълүм. Гомум яңарыш процессы барлык буын шагыйрьләренең иҗатын тетрәндереп, сугарып чыкты. Өлкәннәрдә ул сабыр-тынычрак барды. Әлеге дулкында аеруча шул чактагы яшьләр күтәрелде, бу аларның иҗатында да тирән үзгәрешләр булып чагылды. Шушы яңарыш рухында укучыларның һәм иҗатчы яшьләрнең дә яңа бер буыны тәрбияләнеп үсеп җитте. Алар өчен әлеге хәлләр бигрәк тә тәэсирле булды — шигырьнең базары бер яктан төште, икенче яктан күтәрелде. Тышкы билгеләренә генә карап та бу үзгәрешләргә табынуы, яки аларны сәбәреп түгүе җиңел иде. Кайберәүләр шуны эшләделәр дә.

Тасвир-хикәяләүгә күнеккән укучылар катламы бу давылны шактый авырсынып кабул итте шикелле. Чәйнәп салуның, киң тасвир өлешенең кыскаруы, нигездә, әнә шундый укучылар арасыннан бер өлешнең «кыскаруы»нда да сәбәпче булгандыр. Шигырь төшенең тыгызлануы аның эчке җегәрен, сыйдырышлылыгын арттырды. Ә кайбер очракта — андый парчаларны чыра яндырып эзлисе юк — шигырь концентрат хәленә килә, тәрәзәсе-ишеге булмаган өйне хәтерләтә башлады.

Менә шундый вакытта әдәбиятка аяк баскан «икенче дулкын» яшь шагыйрьләргә уңышлары һәм каршылыклары яхшы ук бергә буталган, кискен аерылып тормаган шартлар белән очрашырга туры килә. Алар мондый очракта нинди юлны сайлыйлар соң?

Тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе җитмәү үзен сиздерә, күрәсең: кызганычка каршы, әлегә безнең күбебездә иң соңгы әдәби агымнарның көчле йогынтысын җиңә алмау, хәтта аларны күпмедер дәрәҗәдә канунлаштыру өстенлек ала кебек. Якын үткәнгә анык мөнәсәбәт сизелмәве, гомуми хорда үз тавышыңны ишеттерүдән шикләнү, «башлап биргән җыр»ны гына дәвам итү белән канәгать булу поэзиягә якты исемнәр-йолдызларның шактый аз кабынуы булып кайта.

Бермәл әлеге бөлгавырда аптырашып калган авторларның бер өлеше хәзер генә ис-акыл алып, «ничек язарга икәнен» (?!) чамалап, берәм-берәм мәйданга чыга башладылар. Шуның нәтиҗәсе буларак, багана кебек юнган дөрес-шома шигырьләр күбәйгән төсле. Шигырьләрдә икенчеллек, «китап сүзе» көчәю күзгә ешрак ташлана. Шигырь халык тормышыннан, җанлы телдән аерыла бармыймы дигән шөбһәле сорау туарга җирлек барлыкка килде. Бүген цитата, исемнәр, астөшермәләр поэзиясе дип әйтерлек язмаларны шактый күп укырга туры килүе, алардагы эстетик информациянең кайчак эпиграф итеп китерелгән газета хәбәреннән генә гыйбарәт булуы күңелне бик борчый торган хәл.

Кайбер шигырьләргә әле болай гына якын килеп тә булмый: аларны уку төрле исемнәрдән торган кроссвордны чишү, билгеле бер (еш кына уртачадан түбән) дәрәҗәдә эрудицияне тикшерү булып тоела башлый. Ә кроссвордның язмышы һәрвакыт бер үк финал белән тәгәлләнә, бу мәгълүм: шакмаклары тулуга ул кирәксез бер нәрсә булып кала, бүтән кызыксыну уятмый.

Ясалма катлауландыру, күзгә төтен җибәрү, мөгез чыгарырга азаплану h. б. төрле эстетик кыланулар кайбер яшь, җегәрле прозаиклар өчен дә «әйбәт тон» булып санала башлады бугай. Тәмәке тартканда төтенне боҗраландырып чыгарудан тәм табучы малайлар кебек, без хәзер тәкәббер геройлар, «интеллектуаллар», аларның көяз сөйләшүе, «даһи» парадокслары һәм ак якалы фәлсәфә ташкыны белән мавыга төшәбез. Тормышчан конфликтлар урынына — ясалма фәлсәфи бәрелешләр, тормышчан проблемалар урынына эчке күлмәкләр турында сөйләшү күбәя төште. Шуның нә-

тиҗәсе рәвешендә, алардагы геройлар күзгә күренеп кечерәя, конфликтлар ваклана, кайбер әсәрләрдә, «тормышта шулай да була бит» дигән сылтау белән, рухи тотнаксызлыкны аклаган хәлләр тәкъдим ителә. Ниһаять, соңгы елларда укучыларның үзләре үк мондый әсәрләргә, изге хисләрне тупас куллар белән капшауга каршы чыга башлавы тикмәгә генә түгел.

* * *

Тормышчанлыкны — «тормышта да шулай була», гомуми сүз куертуны — «публицистик кайнарлык» дигән булып, абстракт төшенчәләр, сүзләр артында яткан анык мәгънәләрне, гомуми картина-күренешләр эчендә аларга бигүк туры килеп бетми торган детальләр, нюанс-төсмерләр булуын онытмыйк әле... Югыйсә, шушы логика буенча, китабы ешрак чыга торган шагыйрьне — сирәгрәк, азрак басылучы шагыйрьдән күренеклерәк, ә тора-бара талантлырак та дип уйлый башлыйбыз... Хәтта кайвакыт китап калынрак, шигырь шомарак булса, яхшырактыр кебек тоела, шулай кабул ителә...

Гөнаһсыз сабыйлар логикасы түгелмени бу? Бала-чага белән булган күпсанлы вакыйгаларның берсе искә төшә...

...Авылга кунакка кайтканда, балаларга очып куна торган усал әтәчнең муенына кызыл тасма салу турында сүз чыга. Нәни кызыбыз сүз сөрешен чамалап, әле генә үзенең котын алган «хулиган»ны яклап калырга азаплана: «Әтәч йомырка салмыймы соң ул?» — дип сорый. «Юк»,— дигән җавапны ишеткәч: «Элегрәк тә йомырка салмый идеме?» — дип карый. «Беркайчан да салмый»,— ди дәү әнисе. «Алайса син ул әтәчне ник алдың соң?!» — дип аптырый кызчык. Бераздан, янә әйләнеп килә: «Ник ул әтәч берәү генә; әгәр икәү булсалар да йомырка салмас идеме?» — дип, төпченүне шул рухта дәвам итә...

Без дә шулай түгелме соң? Әтәчләр икәү булса, берсе йомырка салыр иде, дип өметләнмибезме?.. Сан һәм форма әдәби иҗатта үзеннән-үзе генә сыйфат һәм эчтәлеккә күчә дип ышанып йөрмибезме? Югыйсә нигә әле «хәзерге яшьләрдә форма камил, тик менә эчтәлек кенә...» дигән нәтиҗәләр ясарга ашыгабыз,— үзебез дә сизмәстән, форманы эчтәлектән аерабыз түгелме?

Форма камиллеге җимәктән, шагыйрьләр болай ук «вваклану»ны яратмасалар да, соңгы елларда шигырьдә шапшаклык көчәя баруына күз йомарга мөмкин түгел. Әйтик, рифманы рифмага чагып ут чыгарудан бигрәк, «ялкау рифмалар» — шигырь үрә генә башлаган, әле поэзия кануннарын яхшылап белеп бетерми торган өйрәнчекләрдәге кебек, ярым-йорты яңгырашка корылган сүз кайтавазларына таяну күзгә күбрәк ташлана. Аларда бербөтен сурәт хасил итүе мөмкин булмаган, бер максатка буйсындырылмаган һәм бер-берсе белән бәйланышка керә алмый торган детальләр сибелеп ята...

Шигырь — гармония баласы. Анда гармония эзләү тормыштагы кебек үк, көрәш аша бара. Әсәрнең төзелешендә үк — шул көрәшнең чагылышы. Шигырь — тыелгысыз омтылыш. Шигырь — көтү. Авазның, сүзнең, образның, мәгънәнең кайтавазын көтү. Асылда аның көтелмәгән булуы!

Без, шигырь акмы, «кара»мы — аның әйтергә теләгән сүзе мөһим, дияргә яратабыз. Әмма укучының көткәне акланмау — нәрсәдер сөйләп чыгу һәм аның хикмәтен таба алмау, ниндидер ачышка алып килердәй булып талпынып та, сүз уйнатудан ары уза алмыйча калу—шигърият кораллары белән эш итә белмәүдән дә башлана.

Мөгез чыгарудан сөзәрлек булса, һавага менүдән — караш киңлеге артса, бу — сөенерлек кенә. Шуңа күрә тулаем алганда, яшь язучының «мөгез чыгарып» каравы табигый хәл. Булачак язучының беренче адымнары ук кеше күз алдында; аның һәр абынып китүе, йөрергә өйрәнүе ярдәмгә, яклауга, хуплауга мохтаҗ. Сүз әлеге аякка басуны тизләтү, баш белән йөрергә өйрәнеп гомерен сарыф итүгә юл куймау турында бара. Мәсьәлә шул ягы белән катлаулы да: без икенче чиккә ташланып, артыгын кайгыртып, кайчакта бераз таркүңеллелек тә күрсәтеп булса кирәк, экспериментлар ясаучы, үзен авыррак жанрларда сынаучы, кыскасы, үз мөмкинлекләреннән зуррак йөк күтәреп караучы (яшьлеге аркасында!) авторларны бер чыбыктан сөреп, мөгезсезләрне, ботак-чатаксызларны гына үткәреп җибәрергә яратабыз шикелле. Әдәбиятта мөгезсезләр, шомалар күбәю — яхшыракмыни?

«Алтын урталык»ны чамалап алган авторларга «яшел дулкын» ачу, эстетик куәтсез, эчтәлек ягыннан җитди булмаган әйберләрнең зур тираж белән пропагандалануы, тәнкыйтьтә һәм чыгышларда өстән-өстән генә: я тема уңаенлы, я фамилия-сан өчен, я болай, җае килгәнгә генә сыйпап-мактап үтелүе борчый. Бу хәл җәмәгатьчелектә хата фикер формалашуга, яшь һәм башлап язучыларга ялгыш юнәлеш бирелүгә дә нигез тудыра, минемчә.

* * *

Шигырьгә мөнәсәбәт җитдилеген киметүче, шигырьнең дәрәҗәсен төшерүче сәбәпләр күп һәм катлаулы булырга тиеш. Без, ихтимал, аларның кайберләрен, иң өстә ятканнарын гына күрәбездер әле. Чынлап та, тулы бер китаптан, зур шигырь бәйләменнән ни өчен санаулысына, аерым юлларга гына тукталасың, игътибар итәсең, истә калдырасың? Ни өчен бусы тәэсир итә, ә тегесе юк? Күңел халәте, вакыт, укучының әзерлеге, зәвыгы һ. б. нәрсәләр бар — анысы мәгълүм, аны алдан программалаштырып-салып куеп булмый... Ләкин бер үк шигырь күпләрнең күңелен били ала икән, димәк, анда «программаланган» да нидер бар?! Җыр — сер, ди халык, һәм һәр шагыйрь ул сергә үз ачкычын эзли. Очын-очка ялгау, шома-тигез итеп үреп чыгу турында гына кайгырткан автор беркайчан да бу серне, бу ачкычны табып җиткерә алмый. Укучыга тертеп күрсәтү, теркәү, сөйләп бирү генә түгел, күз алдында тамырлану, үсү, яфрак яру кирәк...

Без прозадан да хисләр чынлыгы, хәрәкәтләр чынлыгы эзлибез. Шуңа күрә бүген популярлык таҗы документаль нигезле әсәрләр ягына баса кебек.

Укучыга авторның үз-үзенә соклануы белән тулы, үзенә генә мөһим тоелган мәнфәгатьләр, һәртөрле шәхси очраклар турында сөйләү, багышлаулар белән тулы китаплар нигә кирәк? Җыр язмышы өчен җаваплылык турында күкрәк кагу төсендәге купшы юлларга кем мохтаҗ?

Штамп, әнә шулай, формадан эчтәлеккә үтеп керә: темада яңа чишелеш такъдим итмәү, фикер учагының бер шигырь эчендә генә сүнеп калуы рәвешендә чагыла. Темада даими, үзгәрешсез бер даирә-орбита билгеләнүе сагайта. «Мин һәм минем шигырьләрем», «Сагындым сине, туган авыл», «Яшьлектә сөйгән яр» темалары төрле вариацияләрдә, асылда бер үк чишелеш белән йөзләрчә шигырьдә кабатлана. Соңгы елларда табигатьне саклау, тынычлыкны саклау кебек изге, глобаль темаларны да аерым очракларда үтемле товар итеп ваклау, бер өлге буенча «тиражлау» эчне пошыра. Гонаһсын кая куярбыз, егетләр? — дип әйтәсе килә башлый. Шундый язмалар аркасында шигъри сүз язучы сүзенең кадере төшүкимү куркынычы яный.

Шундый мөмкинлекләр калдырылганда, бер яктан, сөякчел язмалар — әзер идея кабыргасына ит кундыра алмый газапланучы авторлар иҗаты үзен яхшы хис итә. Икенче яктан, пружинасы йомшак шигырьләр: гомуми сүз, беренче тәэсирдән тирәнгәрәк үтеп керә алмаган, проблеманың төшенә төш үтмәгән очраклар ишәя.

Һәр ике төрдә дә — кеше язмышына чыга алмау, тоташып яна алмау.

Минемчә, бу хәл сүзгә талымсызлыкта ук чагыла — аның зур җегәренә таяна белмәүдә, темага тиң яңгыраш таба алмауда, җиңел-җилбәзәк булып уйнауда... Тагын да тирәнгәрәк карасаң — җаваплылык, эчке яну җитми, күңел тәҗрибәсе кечкенә, шуңа күрә шәхес буларак әйтер сүзебез дә зур түгел. Андый шигырьләрдәге (һәм прозадагы) тәкәббер бушлык, күңел ярлылыгы, рия һәм штампны күреп, укучы да йөз чөерә.

...Шигырь арты шигырь укыйсың: барысы да дөрес, барысы да мәгълүм... Һич аңлашылмый: нинди максат белән? — автор Кояш системасы өчен кайгыртучы фәйләсуф булып күренергә тырыша, үзенең «абразаумый» булуы белән мактана кебек, хәтта хисләнгән булып кылана! Авторның чын йөзе, тормыш позициясе урынын тышкы кыяфәт-поза ала бара. Бер табылган алымнар, темалар, образларны ахыргача сыгу, ниһаять, бармактан суырырга тотыну иҗатлары белән танылып өлгергән шагыйрьләрнең дә кызыклы дөньясын кызганыч хәлгә китерә — ахыр чиктә бер даирә эченә бикли бара. Аларда шигырь — карт кыз шикелле — үзе өчен генә яши башлый, кайчакта тәкә мөгезе кебек — үз эченә бөтерелеп, башына кайтарылып үсә, сөзәргә яраксыз, гарипләккә әйләнә. Шундый заманда!

Дөрес, безнең көннәрдә, әйтик, Се-

ләйман утрауларының генерал-губернаторын бөтен нәсел-нәсәбе белән өйрәнгән кайбер яшьләр икенче буын бабаларының да исемен белмиләр. Бер мәйданчыкта яшәүче күршеләр бер-берсен танымыйлар. Якын туганнар хат язышу түгел, бәйрәм белән дә котлашмыйлар... Коммуникабельлек җитми, диләр...

Бәлки, поэзиядә, юк, поэзиядә генә түгел — прозада, драматургиядә һәм тәнкыйтьтә дә дөньякүләм әйберләр турында сүз куертып, аяк астындагы туфракны онытып җибәргәләү, туфрактан аерылу, аралану, ниндидер бер божрага бикләнү, йомылу менә шундый — тормышның үзендәге сәер хәлләргә иш булып чыкмыйммы икән...

Әнә, сәхнәдә нидер хәл итәләр, шаулашалар, гөж киләләр,— тик, әйтерсең лә, башка телдә сөйләшәләр...— тамаша залына «ут» күчми. Бу хәлне кайбер авторлар һәм артистлар үзләренчә аңлыйлар: кинәт сәхнәдә арзанлы трюк, кылану, тамашачыны көлдерергә тырышу башлана. Ләкин, кем әйтмешли, «егылып көлә халык... автордан һәм актерлардан көлә, җәмәгать». Сәхнәдәге вакыйга хәтта тормышчан булганда, үзалдына яшәгәндә дә нәкъ менә тамашачының килеп кушылуына, аның бер почмактан килеп күтәрешүенә мохтаҗ! Әҗәлдән улын яклап калганда, Әлмәндәр картның ихласлыгын һәм гаҗизлеген тоюдан елап утырабыз бит әле...

Минемчә, кайчакта шигырьгә әнә шундый яклауга мохтаҗлык, гаҗизлек җитеп бетми. Яхшы шигырьдә әнә шундый табигый мохтаҗлык, укучыны үзе дә сизмәстән катнашып китәргә «котырту» хикмәте бар.

Югарыда әйтелгән күзәтү — үз эченә бикләнү, йомылу күренеше үзе үк шуңа каршы хәрәкәт башлануга сәбәпче булып тора. Шушы хәлдән чыгу юлын әдәбият үзе эзли. Поэзиядә, көчле бер агым булып, сурәт, проблема һәм фикер колачы ягыннан прозага һәм драматургиягә тартылу, якынаю бара. Проза һәм драматургиядә исә лирик башлангыч, моң, укучы-тамашачы белән эчкерсез бәйланышка омтылу, ачылу тенденциясе көчәя кебек. Замандашның күңел төпкеленә карау, аңа турыдан-туры мөрәҗәгать итү, һич югы юри каршы чыгу, үртәү укучыны, хәтта кайсыдыр чаты белән аны электереп, бераз тәнен эрттырып алу — битарафлыктан уяту, эшкә-хәрәкәткә чакыру... **Шигырь тәэсир итсен, укылсын өчен — җиңел укылмаска тиеш!**

* * *

Поэзия һәм укучы, шигырьнең замандаш күңеленә юл эзләве мәсьәләләренә кагылганда, «иң әзерлекле укучы» дип аты чыккан тәнкыйтьчене, тәнкыйть базарындагы бәяләрне читләтеп үтеп булмый. Соңгы елларда гына да татар поэзиясенең үсеш тенденцияләрен күзаллаган җитди хезмәтләр дөнья күрде. «Дежур» рецензентлар һәм кайбер шагыйрьләрнең үзара макташу рухындагы язмаларына юл бермә-бер чикләнде. Шулай да баштан ук танырга кирәк: киң катлам укучыга чын поэзияне аеру мәсьәләсендә һәрвакыттa да ныклы юнәлеш бирә алганыбыз юк әле. Бездә, ни язылса,— шул әйбәт, дигән рецензияләр һаман да байтак басылып тора. Рецензия,— билгеле булганча, киң катлам укучыга барып ирешә торган, аңа монографик хезмәтләрдән тизрәк һәм үтемлерәк тәэсир итә торган, укучы фикерен һәм ихтыяҗын формалаштыру көче зур булган өлгер, сугышчан жанр. Без еш кына шушы гади хакыйкатьне онытабыз шикелле һәм китап күзәтүне вакыты булган теләсә кем язса да ярый дигән караш урнашуына юл куябыз. Газета-журналлардагы шундый рецензияләр буенча хөкем йөрткәндә, безнең поэзия тулысы белән үзенчәлекле, «кабатланмас йөзе булган» шагыйрьләрдән һәм «коеп куйган» шигырьләрдән генә тора.

Чынлап та шулаймы соң?

Икенче яктан, соңгы елларда шагыйрьләрнең төрле чыгышларына, шул исәптән тәнкыйтьчеләргә «багышлап» язылган парчаларына карасаң, поэзиянең уңышларын һаман да күрми икән безнең тәнкыйть, һәм аның бөтен гөнаһларында, кимчелекләрендә торганы шул тәнкыйтьчеләр генә гаепле икән. Шигырь теле белән тәнкыйтькә ук ату әдәби модага әверелеп бара шикелле. Тәнкыйть белән тарткалашучы шигырьләр антологиясе төзесәң, шәт, күләме ягыннан кулга тотарлык бер китап килеп чыгар иде... Һәр очракта классиклар белән генә авызны томалап куярга яратучылар, әлбәттә, бу юлы да шул тарафка бармак төртеп күрсәтерләр. Әнә бит, янәсе, алар да... Классиклар, әлбәттә, ялган тән-

кыйтьчеләргә дә, шул ук вакытта мөтәшагыйрьләргә дә кискен фикер белдергәннәр, ләкин алар иң әүвәл «тәнкыйть—кирәкле шәйдер» дигән принциптан чыгып, аны вульгарлаштыруга каршы торганнар. Алар үз иҗатларын гомумән тәнкыйть фикереннән, ачы булса да туры сүздән аралау-гарантияләү өчен тырышмаганнардыр. Аннары тарих шаһит: әдәби-эстетик фикер үсешенә үзләре җиң сызганып өлеш керткән әдипләр дә һәр заманда булган. Әле дә бар.

Әйе, поэзияне бәяләүдә мәгълүм штамп яши, һәм ул, миңа калса, өлешчә поэзиянең үзеннән дә килә — бумеранг булып, игезәк образлы, «дөрес» фикерле төссез шигырьләрнең кайтавазы булып. Шигърият һәм укучы файдасына тәнкыйтьнең беркадәр «тенденциоз» булуы (ягъни күңелендәген уеп әйтүе — скальпель белән!) шифалы гына булыр иде. Бу сүзләр беренче тапкыр яңгырамый, ләкин...

...Минем бер танышым, эшкә килү белән, башкаларга да йоктырырга, көннең увертюрасын билгеләргә теләгәндәй, иртәнге тәэсирләрен, күргән-белгәнен ачылып сөйләргә ярата. Аның әйләнә-тирәсендә — шактый китап укыган егетләр-кызлар, җае чыкса-чыкмаса югары материяләр хакында фәлсәфә куертырга яратучылар да бар араларында. Ә танышымның хикәяте гади нәрсәләрдән, җир хәлләреннән башлана. Мәсәлән, менә болайрак:

— Бүген ишегалдында Караборын елап калды әле, егетләр,— ди ул.— Кайдандыр килеп, иялänеп калган иде, ничәнче ел инде безнең подъездда яши... Бала китергәндә генә югалып тора да, иртәгә кайтып керә үзләрен... Матур була аның көчекләре! Тик, күзләре елтырый башлауга, әнкәләре каядыр чыккан арада, урлап бетерәләр үзләрен берәм-берәм. Шуннан соң шыңшып йөрүенә түзәть юк...

Нидер әйтеп бетерми, барысы да шуны көтеп торалар. Бу тынлык — аның файдасына...

— Көчекләргә, бәлки, безнең подъездга керел-чыгып йөрүче күршеләр үк кул суза торгандыр. Караборын юаш, ышанучан, аларга игътибар да итми... Тик үз ишләре өчен мондый көннәрдә аннан да усалрак җанвар юк: ишегалдыннан узып баручы бер кәкрекойрыкка да көн күрсәтми. Аларны күрү белән, зур тавыш чыгара, пыр туздырып, әллә кая кадәр куып китә. Күрәсең, караклыкны үз ишләреннән күрә, бәбкәләрен шулар иярте киткән дип беләдер...

Тыңлап торучылар әкрен генә таралышалар. Әллә, чынлап та, шушы хикәят тәэсир итте инде аларга?

Әлеге очраклы гына мисалда, минемчә, катлаулы бәйләнеш-мөнәсәбәтләрне гадиләштереп аңлаудан, сәбәп белән нәтиҗәне бутаудан кисәтеп тору да бар кебек...

Бер яктан, теге яки бу шагыйрьнең тәнкыйтькә, «минем уңышларымны гына, ә башкаларның кимчелекләрен генә күрсен иде» дигән кебек, үпкәләп яшәве, икенче яктан, «тигезләүче» тәнкыйтьнең җавапсыз чыгышлары укучыда һәм яшь авторларда ялгыш фикер тудыра, поэзиянең дә, тәнкыйтьче сүзенең дә абруен төшерә. Һәрхәлдә, бүгенге шигырьләрдәге аерым кимчелекле яклар вакытвакыт өстенлек, модель, ким дигәндә табигый хәл дип кабул ителә икән, бу хәлләрнең тагын да тирәнрәк тамыр җәюенә генә юл ачыла бара.

Сер түгел, җитешсезлекләр турында сүз чыкса, һәркайсыбыз күбрәк яшьләрне генә телгә алырга тырышабыз. Беренчедән, яшьләр иҗатында чор әдәбиятының төп эзләнүләре һәм төп «авырткан төшләре» ярылып, ачык булып ятканга күрә. Икенчедән, яшьләр әле эзләну чорында,— тәнкыйть сүзенең аларга файдасы ныграк тияр дип. Ләкин таләпне кешесенә карап берничә төрле кую, өлкәннәргә хөрмәтне, ә яшьләр турында кайгыртуны бәяләү шкаласындагы ташламалар белән алыштыру мөмкинме?

* * *

Безнең поэзиянең якты исемнәре, биек орбитасы, кабатланмас дөньясы булганлыктан, җитди, зур проблемалары да шактый. Әнә шул проблемалар үзләре янындагы кечерәк мәсьәләләрдән җыела-укмашалар.

Укучы белән бәйләнешкә керү — үзеннән-үзе аңлашылган кебек тоелучы шундый «гадәти» мәсьәләләрнең берсе. Әлбәттә, беркем дә, фәләнчә язсаң гына укыла, дип канунлаштыра алмый: укучы күптөрле — аңа күп төрле шигырьләр дә кирәк. Әлбәттә, сүз ерак плане-

талардагы ят цивилизацияләр, хәтта Яңа Гвинеядәге «куку-куку» кабиләләре белән контактка керү турында да бармый. Ләкин укучы үзебезнеке, ул гаеп итмәс дип, артык җиңел уйламыйбызмы? Ул җитәрлек дәрәҗәдә әзерлекле, үзе аралап укыр әле дип, ачыктан-ачык йомшак әсәрләр тәкъдим иткәләү — галиҗәнап укучыга илтифатсызлык күрсәтү түгелме?

Нишләп әле без һәрвакыт җиңел юлга исәп тотабыз: «талантлы укучы»га, «үз укучыбыз»га гына өметләнеп язабыз? Мин укучыга җайлашмыйм дигән хак сүз, турысын әйткәндә, кайвакыт үз-үзеңне тынычландыру гына булып аңлашылмыймы?

Әдәбиятның тормышка тәэсире, билгеле ки, укучы-замандаш күңеле аша бара. Шуңа күрә бәйләнеш, контактлылык дигән нәрсәләр — бу мәсьәлә, гомумән, киң, тирән, катлаулы. Шигырьне укучы хөкеменә, к е ш е  а р а с ы н а чыгарып җибәргәндә аның өчен җаваплылык хисе дә зур булырга тиеш.

P. S. ...Язылган кадәресенә нокта куйгач, кире кайтып укып барганда (тәнкыйтьчегә дә «үҗәт укучы» булу җиңел түгел), уйлап-икеләнеп куйдым: әгәр дә кемдер, бу сүзләр фәлән шигырьләр уңаеннан гына әйтелгән икән,— шул кирәк аларга, дисә? Бигрәк тә күздә тотылган шигырьләр басылып чыкмаган тәкъдирдә, менә бу мәкалә язылмый да калыр иде әле, дип уйласа?

Чынлап та шулаймы соң: фәлән шигырьләр уңаеннан күңелгә килсә дә, ул берничә шигырьне сызып ташлау белән, мәсьәлә хәл ителер идеме?

Шуннан соң, мин башта ук әйтеп куелган «эксперимент»ны эшләргә — бирелгән бөтен фамилияләрне, шигырьләрдән өземтәләрне сызып чыгарга булдым. Әлеге «операция»дән соң мәсьәләнең асылы үзгәрү-үзгәрмәвен укучы үзе күрер (һәм, әлбәттә, мисалларны да җитәрлек табар). Ә безнең кыскарту әле, уйлап карасаң, аерым исемнәр тирәсендә сүз куертудан аралап, шуның өстенә, уңышсыз парчаларның янә бер кабат дөнья күрүенә дә юл куймау булып чыга түгелме соң?

Әй... бер цитата барыбер онытылып калган икән: эпиграфтагы сүзләр. Күңелсез уйлар уятып торса да, аларны сызмыйк инде. Соң бит чынлап та шулай: ил-көн һәм замандаш белән рухи бәйләнештә яшәмәсәң, тагын нәрсәгә өметләнергә мөмкин?! С у ы н  а л м а г а н  к о е  т и з  к о р ы й.

# ИХЛАС ХИСЛӘР ГӘҮДӘЛӘНЕШЕ

Мөхәммәт Мәһдиев белән бергә юлга чыгарга туры килгәләгәне бар. Шуныңсын яратам, аның белән озын юллар кыска була. Ни өчен дигәндә, әңгәмәдәшләрен җор сүз белән авызына каратып тоту сәләтенә ия ул. Бер караганда, бик гади генә әйберләр турында сөйли кебек, ә чынлыкта исә шул гадәтилек сине тирән уйга сала, тәэсирләндерә, көлдерә, гыйбрәт алдыра. Аның күзәтүчәнлегенә, детальләрне бертекләп хәтерләвенә, тел бизәкләрен гаять нечкәләп тоюына сокланмый мөмкин түгел. Миңа калса, Мөхәммәт Мәһдиев язасы әйберләренең башкаларга тәэсирен башта әнә шулай кешеләр белән аралашканда сынап карыйдыр шикелле. Мин шунысына да игътибар иттем: поезд Курса тирәләренә килеп җиткәч, ул җитдиләнеп кала, үрелеп-үрелеп тәрәзәдән карый, хәтта аягына ук басып, тәрәзәгә каплана. Әйтерсең лә юл буйларындагы агач һәм үләннәрне беренче тапкыр күрүе. «Менә бу сукмакны күрәсезме,— ди ул бераз баргач,— Курсапочмак булыр. Мәктәптә укытып йөргән елларда бу сукмакларны ай-һай күп таптарга туры килде».

Үзем аны күзәтәм, үзем уйлыйм: туган як кемгә дә газиз шул! Күңел кыллары киерелгән җәядәй тартылып торган, шылт иткән тавышка да аваз бирергә әзер торган нәкъ кешесе өчен аның газизлеген тою хисе тагын да көчледер. Әдипнең «Торналар төшкән җирдә» дигән лирик-документаль повестен укыгач, мин моңа кабат инандым.

*Туган җирне сагыну дәрте*
*бер вакытта да бетми икән...*

Әбелмәних Каргалының әнә шундый юллары белән башланып киткән әсәр «Бу — минем туган җирем...» дигән сүзләр, горурлануны да, сагышны да белдерүче сүзләр белән тәмамлана. Шушы ике арада никадәр язмышлар, характерлар, тормыш вакыйгалары турында тасвир итәргә өлгерә язучы. Сүз җай гына, табигый бара. Каләм бер урында да төртелеп калмый. Укучы автор артыннан ияреп бара да бара. Гөберчәк авылы кешеләре синең өчен дә якын, үз булып әверелә.

Мәрхүм Мирсәй Әмирнең мондый сүзләре хәтердә калган: «Чын тормышны, әдәби әсәргә герой булырлык кешеләрне ерактан эзләргә өйрәнелгән. Ә туганнан бирле үзең үткән юл? Сиңа якын торган агай-эне, туган-тумачаларың? Дус-ишләрең? Алар турында язу үзенә күрә кода-кодагыйлык шикелле, ярамый торган эш исәпләнгән». М. Мәһдиевнең бу мәсьәләгә карашы күптән ачыкланган: үзең яхшы белгән, тирәнтен төшенгән, алай гына да түгел, аерылмас язмышың булып әверелгән тормыш даирәсе турында язу гына каләмнең ышандыру көчен билгели. Ә ныклы җирлеге булмаган, уйлап чыгарылган әйбердә кайчан да булса фальшь чыгасын көт тә тор. Бу очракта язучы әти-әнисе, туганнары, дус-ишләре, гомумән, авылдашлары турында горурланып та, сагышланып та, ачынып та, уенкөлке катыш мәзәк итеп тә сөйли. Кешеләрнең үзләренә генә хас гаять үзенчәлекле якларын тотып ала, шул сыйфатларны калкытып кую өчен гаҗәп төгәл детальләр таба. Шул рәвешле, гадәти генә кешеләрнең сүз белән тасвирланган үтә индивидуаль портретлары пәйда була. Андый кызык холыклы кешеләр бер Гөберчәктә генә түгел, әлбәттә. «Безнең авылдан бер генә герой да, бер генә космонавт та, бер генә академик та чыкмаган. Анда зур сулар, таулар, иркен болыннар юк, кыялар юк. Тагын бик күп нәрсә юк. Бөтен булган байлыгы — урман, чишмәләр һәм кешеләр. Мин менә шулар турында сөйләргә те-

лим»,— дип башлап алып китә әдип хикәяләүне. Бөтен хикмәт тә әнә шул гадилектә инде, үзенчәлекле хасиятләрне тотып ала белүендә.

Кеше — үзе бер дөнья. Аның күңеле хәзинә белән тулы. Ул үткәннәр турында уйлый, көндәлек мәшәкатьләре белән яши, киләчәкне күз алдына китерә, ярата, нәфрәтләнә, сагышлана. Бигрәк тә табигать белән күзгә-күз калган мизгелләрдә ул аеруча каршылыклы хисләр кичерә. Беренчесе — син бөтен дөньясында бәрдәнбер акыллы тереклек ияседер, бу урман-басулар, таулар, офыклар, ай-кояш — барысы да синең ихтыярыңа буйсыналардыр кебек, алар синеке генә сыман. Мондый хисләр кешене көчле, олы итә. Икенчесе — табигатьнең бөеклеге, мәһабәтлеге, көче алдында кеше үзен тары бөртегедәй бик кечкенә, көчсез бер җан иясе итеп сизә. Мондый капма-каршы уйларның күңелгә килүенә нәрсә сәбәпче була икән? Моңа җавап бер — кешенең әлеге мизгелдәге халәте. Дөньяны кабул итүнең башлангыч инстенктив этабы әнә шуның белән бәйләнгән. М. Мәһдиевнең әлеге әсәрендә исә кешеләр нигездә оптимистлар буларак гәүдәләндерелә. Оптимистлык әсәрнең бөтен тукымасына сеңгән.

«Шундый тын, дөньяның зыңлаган тавышы ишетелә, дөнья сабырлык, акыл чәчә, кызыл шар инде күмелеп бара, җир әйләнә, ә мин шушы мәһабәт тынлык уртасында торналар төшкән җирдә басып торам». Хис итү — кешене кеше итә торган иң көчле сыйфатларның берсе. Кеше, канатлары булмаса да, ераграк, биегрәк, тизрәк оча. Димәк, ул хис белән генә түгел, акыл белән көчле. «Торналар төшкән җирдә» әсәрен укыганда да кешенең әнә шулай күпкырлы булуына сокланасың. Игелеклелек тә, юмартлык та, йомшак күңеллелек тә, тапкырлык та, зирәк акыллылык та, хәйләкәрлек тә, усаллык та, мәкерлелек тә — һәммәсе дә бар кешедә. Тик бу сыйфатларның уңайлары өстенлек алган очракта гына җәмгыять сау-сәламәт, таза әхлаклы була. Торналар төшкән җирдә шигъри матурлык күреп, аны изге итеп тою сәләтенә ия кеше үзе дә чын мәгънәсендә олы рухлы, зур зат булып күзаллана. Кешеләр әнә шундый матурлыкны күрә белүдән мәхрүм булмасалар, тормыш ямьле, дөнья имин, тыныч булыр. Мондый сәләтне кадерләп сакларга, үстерергә, аны яңа буыннарга тапшыра барырга кирәк. Бу — яшәеш таләбе.

Әлеге уйлар М. Мәһдиев повестен укып чыккач сине дә биләп алалар икән, димәк, әдип иң олы максатына — үзе борчылган нәрсәләр турында укучының да шулай нечкәләп уйлануына, хис-кичерешләр дөньясында яшәвенә ирешкән. Әдәби әсәрнең төп бурычы да шул бит. Димәк, әсәр уңышлы килеп чыккан.

Повестьның әһәмияте әйтелгәннәр белән генә чикләнми. Татар халкы күп гасырлык тарихында гаять катлаулы юл үтте. Бу юлда ул үзенең гореф-гадәтләрен, рухи дөньясын, эстетик фикерләвен, яшәү рәвешен иҗат итте. Һәр буын боларның кайсыдыр якларын инкарь итә килде, үзеннән яңаларын өстәде. Хәзер бу байлыкны өйрәнү, туплау буенча тулы бер фәнни оешмалар эшли. Әмма М. Мәһдиев бу эшкә үзенчә якын килә. Ул сәнгать чаралары ярдәмендә, укучыларны мавыктырырлык итеп, әнә шул затлы әйберләрне күрсәтеп бирә, күңеленә ошап бетмәгәннәрен аяусыз фаш итә. Килер буыннарга изге дә, олы да, тирән мәгънәле дә булган халык рухын исән-имин килеш тапшырырга тели. Автор болай уйлана: «Боларны инде һич тә кире кайтарып булмый. Сүз ул турыда бармый. Сүз — әнә шул җырларны, шул гадәтләрне тарихи материал буларак кәгазьгә төшереп калдыруның, аларны сәхнәдә, халык күңелендә саклап калуның кирәклеге турында гына бара». Бу исә язучының максаты булып әверелә. Изге максат!

Бер тамчы суда кояш кадәр кояш чагыла алган кебек, кечкенә генә бер авылның тормыш-көнкүреше турында сөйләгәндә халыкның рухы ачыла. Язучы урыны-урыны белән тәфтишләп аңлатып бирүдән дә курыкмый, теге яки бу уңай белән үз хөкемен дә чыгара бара. Повестьны, шул рәвешле, халкыбызның рухи дөньясы турында сөйләүче билгеле бер күләмдәге энциклопедия дип санарга була. Бу яктан ул күренекле әдибебез Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәренә охшаш. «Кереш сүз» үзенә бер әһәмиятле роль үти. Автор туган халкыбызның яшәү рәвешендәге теге яки бу фактларны чит ил кешеләренең гореф-гадәтләре белән янәшә куеп карый. Һәм алардагы уртаклыкны ачып сала. Ә бу исә бик тирәндә яткан мәгънәләргә төшенү мөмкинлеген тудыра.

Башка барлык халыклар кебек үк, болгар-татар халкы да үзенә аерым бер

утрау булып кына яшәмәгән. Ул, күршеләреннән тормыш тәҗрибәсе алу белән бергә, үзе дә бу мәсьәләдә юмартлык күрсәткән. Теләсә кайсы халык үткән үсеш этаплары аңа да ят булмаган. Аның көнкүрешендәге, акыл хәзинәсендәге асыл якларында диңгез артларында яшәүчеләрнеке белән уртаклыклар бар икән. Моңа һич гаҗәпләнергә ярамый. Без дә кешелек дигән гаять зур океанның бер өлеше ләбаса.

Шунысы бәхәссез, халыктагы иң матур сыйфатларны хезмәт иярә ижат итә. Безнең төбәкләрнең хезмәт сөючән, эш рәтен һәм тәмен белгән талантлы халкы элек-электән күп төрле һөнәр белән көн күргән. Хезмәтчел халкыбызның иң зур казанышы, ди язучы, әхлакый югарылык. Әнә шул иң зур байлык — әхлакый сафлыкның эчтәлеген ул бүлектән-бүлеккә ача бара, аерым кешеләр образларында гәүдәләндерә. «Алай да чишмә бар әле...» бүлегендәге Сафый абзыйны гына алыйк. Әхлакый сафлык үрнәгенең үзе бу. Авыл кырыендагы киртә-койма белән әйләндереп алынган үз хуҗалыгында дөньядан аерылып яшәүче кешедер бу дип уйлыйсың башта. Бакчасында ниләр генә үсми! Бүтәннәр бәрәңгедән гайрене үстерергә кулларыннан килмәгәндә, ул авыл читендәге җирендә «оҗмах бакчасы» барлыкка китергән. Яшәү рәвеше, холкы белән башкалардан аерылыбрак торган шул Сафый абзыйның олы җанлы булуын язучы зур осталык белән күрсәтеп бирә. Әлеге игелекле җан бакча артындагы мул, тәмле сулы чишмәне карап-чистартып тора икән. Юк, кемдер кушканга түгел, үзе теләп. Авылдашларының җәйге челләдә чишмәдән су эчеп хәл алулары, биредәге шигъри матурлык аның күңелен кинәндерә. Авылдашларына шундый игелек кыла алуына чиксез куана. «Алай да чишмә бар әле», дип, шөкер итәргә ярата. Башкаларга игелек кылудан ләззәт алу кебек югары әхлакый хистән дә матуррак нәрсәнең булуы мөмкинме? Сафый абзый әнә шул матурлыкның үзе булып гомерлеккә хәтердә кала. Чишмә янындагы чирәмгә кырын ятып, аның шифалы суыннан ләззәтләнүче авылдашларына карап сөенүче Сафый абзый образ-портреты ничек хәтердән уелсын?! Бигрәк тә чын, матур сурәт! Моны язучының тылсымлы каләме шулай төгәл ясаган.

Әсәр традицион повестьлардан шактый аерылып тора. Ләкин без соңгы вакытларда жанрларның аеруча хәрәкәтчән булуларын күзәтә килабез. Шуңа күрә әсәрнең жанр ягыннан билгеләнүен шик астына алырга җыенмыйбыз. Әсәр нинди дә булса сюжетка корылмаган. Ул егермедән артык аерым хикәя-эпизодлардан тора. Әмма аларның һәрберсендә халык вәкилләре образларын, аларның рухын күрсәтү алгы планга чыгарыла. Шул рәвешле әсәр бер бөтенгә әверелә. Авторның лирик образы да үзәк җепләрнең берсе буларак, әсәрнең буеннан-буена үткәрелә. Әдипнең үз образын ачуга багышланган урыннар да укучы өчен кызыклы. Димәк, без әлеге повестьны бер үк вакытта автобиографик планда да карый алабыз. Тик шунысын искәртик: повестьны чын мәгънәсендә мемуар әсәрләр рәтендә карамаска кирәктер. Чөнки автор башка геройларны ничек сурәтләсә, үзенә дә шундыйрак кына өлеш чыгара, ягъни автор образы башкалардан аерылып тормый, ул әсәр тукымасына табигый керешә. Шулай да язучының теге яки бу вакыйгага, геройга карата мөнәсәбәте ачык белдерелеп барыла, серле елмайган автор образының зирәклеген, кешелеклелеген укучы даими сизеп тора.

Гади генә итеп җыеп әйткәндә, кешенең сагынырлык үткәне, үзәкне өзгән моңнары, яраткан туган ягы булырга тиеш икән. Туган ягы белән аерылгысыз бәйләнеш аның үз яшәешен дә мәгънәле итә. Шундый кеше генә чын-чыннан олы хисләр кичерергә сәләтле. «Торналар төшкән җирдә» әсәрендә исә бу хакыйкать аеруча көчле раслана.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

# ӘСӘРНЕ ЧЫН ИТКӘН НӘРСӘ...

*Укучы фикере*

Берничә дистә ел «Казан утлары»н укып баручы буларак, миңа да бер-ике сүз әйтергә рөхсәт итсәгез иде. Әйтәсе килгән фикер Альберт Хәсәновның күптән түгел басылып чыккан «Әбкәм ядкәре» исемле повесте турында. Мин төгәл булмаган детальләргә кагылачакмын. Әдәби әсәрне чын иткән нәрсә дә деталь бит инде.

Иң әүвәл шуны искәртәсе килә: кушамат белән сөйләшү безнең халыкка хас түгел. Яңсә шаярып, яисә ачуланып искә төшергәндә генә кушамат белән дәшүчән халык. Ә бу әсәрдә рәттән һәм нинди дер тәм табып саный аларны автор. Тыйнак һәм кешелекле (автор сүзе) әби дә «бар әле, саесканнарга кертеп чык», дип сөйләшә. Татар халкында мондый тәрбиясезлекне белерлек кенә чама бар, ямьсезләмәсен иде автор безнең күркәм гадәтләрне. Гомумән, кушаматны әдәби әсәрдә нинди дә булса вакыйгага ачыклык кертердәй булса гына искә алу ярый дип уйлыйм. Ул кушаматның әсәрдә керәге юк икән, чүп итеп тутырасы да түгел.

Чабатаны шакмаклы яулыкка төрү дә хак сүз түгел. Чабата хәзер генә сувенирга әверелде, элек чабата чабата иде инде ул, башка кием юклыктан, аптыраганнан киелә иде һәм дәрәҗәсе дә зур түгел иде.

Аннары, ни сәбәптән әтисен сугышка юртак белән озатканнар? Узышка бармыйлар, сугышка китәләр ич. Автор һәр даим матур сүз әйтергә, шаккатырырга кажырып тора: кызлар уймак авыз, бил — нечкә, атлар юртак булу фарыз аңа. Оста язучыларныкы шулай тиеш дип аңлый бугай ул. Ә минем укучы буларак шаккатасы килми: купшыга киттеме өметне өзәм инде: көчсез кеше сугышыр алдыннан нык шаулый, кулыннан эш килмәгән — мактанчык була. Бу — тормыш тәҗрибәсе.

Янә бер деталь: Әби апара бутый да, төче коймак пешерә. Апара — әче камыр ул. Мондый элементар нәрсәләрне истән чыгарырга ярамый.

Мәгариф бүлеге мөдирләре чабата кимәделәр. Алар халык күз алдындагы кешеләр, вазифалары ук арурак киенеп йөрүне таләп итә иде. Чана тартып җылы оекбаш-бияләй җыеп йөрүе дә чамасызрак арттыру. Эшлекле итеп күрсәтү өчен бүтән детальләр табарга кирәк иде. Оекбаш-бияләй җыючылар булды, әмма мәгариф бүлеге мөдире белән авыл советы председателе бәләкәй чана тартып йөреп җыймады аны. Алар ул заманда да җитәкче ролен башкардылар.

Мондый арттыруларны санап бетерерлек түгел. Мәсәлән, шунда ук: «Фронтка дигәндә халык инде җанын кызганмый... тик алсыннанр гына» дию чын сүз түгел. Ул чорда сандык тулы әйбер юк иде, сораганнарын көтеп, чыгарып кына бушатырга. Халык үзенә юкны бирде, үзе ялангач булса да. Ә авторның бик җиңел килеп чыга.

Фронтка бүләк дигәннән, тагы бер бүләкне әйтми мөмкин түгел. Өч ел сугыш барышында йончыган, таланган, ачлыктан шешенгән кешеләр ике-өч танк төзетмәкчеләр. Нәрсә бу? Автор танкның бәһасен белмиме, яки яшь язучы буларак ул заманны күз алдына китерә алмаганмы? Сугышның беренче елларында булды андый җыюлар. Тик соңгыларында... Тормыш ул театр түгел. Аның үз законнары. Без ул елларны бик хәтерлибез. Бирә алганны биреп бетергән идек инде ул елларда. Мин автор өчен повесть язарга җыенмыйм, әмма язган кеше ул елларны уен итеп кенә тасвирламасын иде.

Укучыны ни тоттырсаң шуңа канәгать һәм талымсыз итеп күз алдына китермәгез инде сез, зинһар. Хәзер безнең әдәбият нык үсте. Әдәбият белән бергә укучысы да үсте.

М. Горький әйткән: «Цель литературы помогать человеку понимать самого себя, поднять его веру в себя и развить в нем стремление к истине».

Әнә бит хакыйкатькә омтылыш тәрбияләү дигән. Шулай булгач, чынбарлыкка һәм аның детальләренә зур игътибар кирәк. Алар — әсәрне чын иткән нәрсәләр.

**З. ГАЗИЗҖАНОВ.**
*Азнакай.*

# Г. КАНДАЛЫЙНЫҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН ӘСӘРЛӘРЕ

Габделҗаббар Кандалый (1797—1860) XIX гасыр татар поэзиясенең зур таланты. Аның исеме һәм иҗаты бүгенге укучыларыбызга мәктәп дәреслекләре битләреннән үк таныш. Шагыйрь үзе исән вакытта аның әсәрләре бергә тупланып, аерым китап итеп, чыгарылмаган. Ләкин Кандалый үлеменнән соң берничә еллар үткәч Казан университеты нәшриятында 1881 елда чыккан «Мәгъшукнамә» һәм 1884 елда К. Насыйри тарафыннан чыгарылган «Фәвакиһелҗәласә» китапларында аның шигырьләреннән байтак үрнәкләр басылган. Һәм, ниһаять, 1960 елда, шагыйрьнең мирасы профессор Х. Госман тарафыннан аерым китап итеп туплап чыгарылды. (Г. Кандалый. Шигырьләр. Казан, 1960, 186 б.).

Бу җыентыкның чыгуы Кандалый мирасын барлау һәм өйрәнү юлында яхшы нигез булды. Шуннан соңгы елларда да «Казан утлары», «Совет мәктәбе» журналлары битләрендә әледән-әле Г. Кандалыйның яңа әсәрләре табылу турында хәбәрләр күренгәләп тора. Бу табышлар киләчәктә Г. Кандалый әсәрләренең тулырак җыелмасын төзүчеләр тарафыннан онытылып калмас, дөнья күрерләр дип көтәргә кала.

Соңгы елларда, археографик экспедицияләр вакытында, бу юлларның авторына да Г. Кандалый иҗатына бәйләнешле материаллар күрергә туры килде һәм аларның кайберләре Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивына алып кайтып тапшырылды. («Сәхипҗамал» поэмасыннан өзекләр һәм башкалар).

1978—79 елларда археографик эзләнүләр вакытында иске кульязма битләрендә һәм архив кишттәләрендә Г. Кандалыйның әлегәчә тулы килеш билгеле булмаган яңа ике шигыре табылды. Түбәндә шуларны укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ.**

## Хат

Шигырь Казанда яшәүче пенсионер М. Хәмитов кулында саклануч иске кульязма китап битенә теркәлгән. Кульязма Татарстан АССР, Апас районы авылларының берсеннән табылган. Бу шигырьнең дүрт юлы Х. Госман чыгарган җыентыкның 81 битендә «Оялу» исеме белән басылган. Шигырьнең кульязма варианты белән танышып чыгу аның бу исемгә ярашмаганын күрсәтә. Кульязма вариант хат рәвешендә язылып, хатның баштагы өлеше билгесез бер кызга, калган өлеше кызның туганнарына адресланган.

Хатның язылу техникасында һәм композициясендә Кандалыйга хас булмаган кытыршылыклар бар.

Текст белән танышып чыккач, аны күчерүче шигырьне кыскартмадымы икән дигән фикер кала. Бу шулай булган булса кирәк тә. Шигырьдә Г. Кандалыйның үз торышында булган вакыйгаларга якынлык сизелә. Ихтимал, киләчәктә шигырьнең тулырак текстлары да табылыр әле.

Оялып, икеләнеп кыйлган эшләр —
Сүреләдер, сүтеләдер димешләр.

Биреңез дик, дигел, бер дә оялма,
Сүзем будыр сиңа, җаным, багалма.

Китапларда бу сүзне күргәнем бар,
«Оялган кемсәнең ризкы булыр тар».

Синеңчүн нидәкле әйләдем зар,
Әгәр, ялган, дисәң, бер ходаем бар.

Бу инәлүләрем таш та белерде,
Урыс кызы динен ташлап килерде.

Ишетмәдең, җаным фәрьяды-зары,
Йитәр инде, инәлмәм мондыйн ары.

Күп иде лә, язсам хатка тагы да,
Туласы булды ла ике ягы да.

Йитәр, сүзне йибәрмә күп озынга,
Дәхи инәлдермәм диеп кызынма.

Ая җаным, вая җаным, җәмалым,
Синең өчен өзеләдер бу җаным.

Әдәпле диделәр, әһле инсаф,
Тәнеңә кул тимәгән, диделәр, саф.

Ни хурлыктыр синең кебек матурга,
Надан астында мыймылдап ятырга.

Карарым калмаен яздым сәлам,
Мөганыйб әйлә, бән дәхи киләм.

Җиһан — зольмәт ирүр бәнем күземә,
Көенмәктән фәләнага — җаныма.

Зәхи хале, зәһи хале, зәһи хале,
Бән егълармын, һәммә галәм сер исем.

Минем сез бакмаңызлар сүрәтемә,
Йөрәгем кан, ирүр мәхзүн җаныма.

Ая абзый вә абыстай сүземнән,
Нәбиләр хакы чүн, бәни исәргәң.

Мөдаль улың, кабул итеп сүземнән,
Бәни, чыннан, җәфаларга төшермәң.

Нәбинең хак хезмәте, гыйззәте чүн,
Фирак идең төнемне көндеземнән.

---

Мөганыйб әйлә — соңыннан чакыр.
Дәхи — тагы.
Зольмәт — караңгылык.
Бәнем — минем.
Зәһи халь — яхшы хәл.
Мәхзүн — моңлы, хәсрәтле.
Нәбиләр хакы чүн — пәйгамбәрләр хакы өчен.
Мөдаль улың — юл күрсәтүче бул.
Фирак идең — аерып бир.

Әгәр, тәзвиҗ идәрсәм кардәшеңне,
Хәлегъ итәм хәлалемне соңыннан.

Гаҗәп хәйран ирермен бу эшемнән,
Берәр ләхза китә белмәс исемнән.

Тәфәххыс әйләнгән хәлем-әхвәлемнән,
Йөрәгем аерылырдай сагышымнан.
Гаҗәеп каты исәргең бу сүземнән
Хәҗәр йомшар иде йомшак күңелдән.

Фи нәһар, сөммә нәһар, бәгъдән нәһар.
Мөдаль улың; аерма мәгъшукымнан,
Сәбәп улың висаля ба чынанә.
Колыңызмын сезә (мин) җану дилдән.

Ая абзый вә абыстай.белеңләр,
Ки, гяһ-гяһ, еглып китәм һушымнан.
Нитәк былбыл гашыйктыр җөмлә гөлгә,
Чынаникә гашыйкмын сеңлегезгә.

## Аерма

Шигырьнең баштагы ике дүртьюллыгы Х. Госман төзегән җыентыкта югарыдагы исем белән бирелгән (78 бит). Бу шигырьнең тулырак тексты Уфаның Тарих, тел һәм әдәбият институты архивында өченче археографик экспедиция материаллары арасыннан табылды. Уфа тексты БАССР, Бүздәк районы Канны Төркәй авылында яшәүче Габдерәфикъ Балгузиннан күчереп алынган.

«Аерма» шигыре Г. Кандалыйның башка шигырьләреннән үзенең шигырь үлчәме белән аерылып тора. Ихтимал, яңа табылган текст Кандалый шигыренең бүтән билгесез шагыйрьләр тарафыннан тулыландырылган варианты булуы бар.

Суда үскән камышларның,
Аслы бер дә, нәсле бер.
Бәгъзесеннән кандь алырлар,
Бәгъзесеннән бурия.

Һәм ушандак адәмнәрнең,
Аслы бер дә, нәсле бер.
Бәгъзесе башка агрыкдыр,
Бәгъзесеннән күзгә тутия.

Аслы, нәсле бер булса да,
Җисме, гаклы — бер түгел.
Аермалары нинди икәнен,
Әйтәем мин сезгә, бел.

Бәгъзеләрнең җисме күркәм,
Гаклы якты — шәм-чырак.

Бәгъзеләре шундый ахмак,
Хайван андыйн яхшырак.

Адәмнең бар сәтдин ак
Һәм карадыйн карасы.
Бу икәүнең аралары,
Мисле көн-төн арасы.

Бәгъзеләре шундый яхшы,
Барча адәм дус күрә.
Бәгъзеләре шундый усал
Күбесе дошман күрә.

Күп адәмнең бар гамәле
Үзенә мал җыюда.
Бәгъзе көн-төн иҗтиһадта,
Халыкка ярдәм кыйлуда.

---

Тәзвиҗ идәрсәм — өйләнсәм.
Хәлегъ итәм — аерам.
Хәлалем — хатыным.
Берәр ләхза — һич тә.
Тәфәххыс әйләнгән — нечкәләп тикшерелгән.
Хәҗәр — таш.
Фи нәһар, сөммә нәһар, бәгъдән нәһар — көн артыннан көн үтә (гарәпчәдән Мөнир Юсупов тәрҗемәсе).
Мәгъшукымнан — сөйгәнемнән.
Висаля — кавышуга.
Ба — кабат.
Гяһ-гяһ — вакыт-вакыт.
Җөмлә — барлык.
Бәгъзе — кайсыбер (се).
Кандь — шикәр.
Бурия (фарсыча) — чыпта.
Ушандак — шулай ук.
Тутия — матурлык өчен күзгә сөртә торган матдә.
Мисле — нәкъ.



## Резеда Вәлиева

Резеда Тәфкалүн кызы Вәлиева (Хәлилова) 1930 елның 1 маенда Башкортстанның Кыйгы районы Дүшәмбикә авылында туа. Урта мәктәп һәм В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлагач, Татарстан китап нәшриятына эшкә билгеләнә һәм бүгенге көнгәчә анда яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә редактор булып эшли.

Шагыйрәнең балалар өчен беренче китабы («Минем дусларым») 1960 елда басылып чыкты. Хәзер ул — уналты шигырь китабы авторы. Шагыйрә проза өлкәсендә дә көчен сыный: «Яшь ленинчы» газетасында аның «Якты яр» исемле повесте басылып чыкты.



## Газиз Кашапов

Газизҗан Салих улы Кашапов 1942 елның 21 августында Аксубай районы, Яңа Үзи авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, колхозда тракторчы һәм клуб мөдире булып эшли. 1962 елда Совет Армиясенә чакырыла һәм рядовой, хәрби училище курсанты, кадровый офицер булып хезмәт итә. 1973 елда Казан дәүләт университетына читтән торып укырга керә. Китап нәшриятында кадрлар бүлеге мөдире, Әлмәттә чыга торган «Хезмәт байрагы» газетасында, КамАЗ радиосында эшли. 1978 елдан — «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе. КПСС члены.

«Казан утлары» журналында Г. Кашаповның «Сәмум җиле», «Солдат иртә ир була», «Җир җылысы» исемле повестьлары дөнья күрде. «Сәмум җиле» (1978) һәм «Еллар тыныч иде» (1983) исемле китаплары бар.



## Хәйдәр

Хәйдәр Гайфетдин улы Гайнетдинов 1952 елның 27 ноябрендә Зәй районының Дүрт Мунча авылында туган. Мәктәп бетергәннән соң бер ел колхозда эшли. Аннары 1976 елда Казан дәүләт университетын тәмамлый. «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли. Хәзер ул — «Ялкын»ның җаваплы секретаре.

1982 елда Татарстан китап нәшрияты яшь шагыйрьнең «Ут теле» исемле беренче китабын бастырып чыгарды.

## Читлектәге акчарлак

Атаклы рус жырчысы Федор Иванович Шаляпин чит илдә композитор Антон Эйхенвальд белән кафеда сөйләшеп утыралар икән. Федор Иванович, үз алдына сөйләнгәндәй:

— Казанда мин гаҗәеп бер кеше очраткан идем...— ди.— Моннан егерме, егерме биш еллар элекме? Хәзер дә мин аны шулкадәр ачык итеп күз алдына китерәм...— дип, Шаляпин кинәт кенә менюны әләктереп ала да, шунда ук карандаш белән яшь татар егетенең рәсемен ясап куя.

— Ул шундый шәп шигырьләр яза иде,— дип дәвам итә Шаляпин.— Безнең Михаил Юрьевич кебек үк, бөтенләй малай чагында диярлек үлеп китте... Юк, мин аның бөтенләй балаларча саф йөзен тулысынча охшатып ясый алмадым. Ә аның күзләре, Антон, күзләре! Акыллылар... һәм бөтенләй олыларныкы кебек... Мин кайчакта тимер читлектәге акчарлакны күз алдына китерәм: инде беркайчан да диңгез өстендә оча алмас микәнни?! Әлеге татар шагыйре миңа әнә шундый акчарлак булып тоела. Сагыш аның күңеленә авыр таш булып яткан кебек иде. Кызганыч, мин аның исемен онытканмын...

— Тукай ул!— ди Эйхенвальд.

— Тукай? Тукай! Дөрес!— ди Шаляпин.

Шуннан соң Эйхенвальд Шаляпинга Тукайның «Су анасы» шигырен укып күрсәтә.

— Беләсеңме, Антон,— ди Федор Иванович.— Син бу шигырьгә нигезләп опера яз!

Чыннан да А. Эйхенвальд, аның киңәшен тотып, «Су анасы» операсын яза башлый. Бу операның партитурасы, композитор вафат булганнан соң, Глинка исемендәге музейга тапшырылган.

...Димәк, мәшһүр Шаляпин белән Тукай очрашкан?!

## Уку

Әстерханда яшәгәндә Сәгыйть Рәмиев Давыт Мөхәммәтов исемле кешедә фатирда тора. Фатир хуҗасының хатыны Һәҗәр ханым да, нәни кызлары да С. Рәмиевне бик яраталар. Газета һәм театр эшләреннән арып кайткач, С. Рәмиев хуҗа хатынга:

— Һәҗәр апа, теге зур самоварыңны кайнатып җибәр әле, рәхәтләнеп бер чәй эчик!— дип әйтә торган була.

Һәҗәр ханым идәндәге келәм өстенә табын әзерләп, самовар китерә икән; аннан соң С. Рәмиев хуҗаның нәни кызларын үз янына чакырып чәй эчә торган була. Чәй эчкән арада С. Рәмиев кызларга сораулар бирә:

— Гайшә, син бүген ни сәбәпле сабакка бармадың, ә?

Гайшә хәйләли башлый:

— Башым авыртты...— ди.

— Алай ярамый, Гайшә!— ди С. Рәмиев.— Уку калдырырга һич ярамый... Ә син нишләдең, Өммегөлсем, ә?

— Менә сабакка җибәрмиләр,— ди Гөлсем.— Үскәч мин дәрес калдырмаячакмын!

Рәмиев бәләкәй Гөлсемне күтәреп алып:

— Менә дөрес! Уку ул бөек нәрсә, кызлар. Уку юлында үлеп калырлык булса да, уку кирәк! — дип, шагыйрь шигырь сөйли:

Ирләргә дә фарыз уку,
Кызларга да фарыз уку,
Фарыз эшнең барсы уку,
Уку, уку, уку.

Вакытлар узу белән әлеге Өммегөлсем бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимовның тормыш иптәше була һәм үзе дә язучылык эшенә бирелеп китә, китаплар бастырып чыгара.

## Сәгыйть Рәмиев — актер

Шагыйрь Сәгыйть Рәмиев газета хезмәткәре генә түгел, һәвәскәр артист буларак та спектакльләрдә еш катнаша торган була. Ул вакытта хатын-кыз рольләрен уйнарга артисткалар булмый, шул сәбәпле хатын-кыз рольләрен ир-егетләр уйный. С. Рәмиевкә күбесенчә хатынкызлар ролен бирәләр икән. Тукай Әстерханга килгәч, аның шәрәфенә спектакль куела. Сәгыйть Рәмиев зур күкрәкле, уң аягы аксый торган бер хатынны уйнарга тиеш икән. Уен барышында Рәмиевнең күкрәк урынына куелган йомгаклары төшеп, сәхнә буйлап тәгәрәп китә. Рәмиев йомгакларны куып тота да берәм-берәм урыннарына куя. Бу күренеш уйнаучыларны да, тамашачыны да чыгырдан чыгара: озакка сузылган көлү тамашаны туктатып тора...

Уеннан соң Тукай сәхнә артына, артистлар янына керә.

— Я, ничек?— дип сорый Рәмиев Тукайдан.

— Кызык булды,— ди Тукай, көлә башлап.

— Ә-ә, теге каһәр суккан йомгакларны әйтәсеңме?— ди С. Рәмиев.

— Юк,— ди Тукай.— Анысы бер хәл. Мин аннан көлмимен. Син, Сәгыйть, уң аякка аксап сәхнәгә кердең, сул аягыңа аксап чыгып киттең. Шуннан көләм!

## Сызгыру бушка китмәгән

Композитор Мансур Мозаффаровны гаять тыныч табигатьле, тыйнак һәм аз сүзле кеше буларак хәтерлиләр. Кайчан карама, ул ялгызы гына, үзенә ишетелерлек кенә сызгырынып, нидер көйләп йөри торган була. Җыелышларда тик утыра, тәнәфескә чыккач, тагын читкә китеп моңлана икән.

Бик тавышлы бер җыелыштан соң, Мозаффаровка әйткәннәр:

— Мансур абый, сез нигә бер сүз дә әйтмисез?

М. Мозаффаров иңбашын сикертеп куя да, бер сүз дә әйтмәстән, матур гына бер көй сызгырып, читкә китә.

Бераз вакытлар узгач, ул үзенең атаклы, матур, моңлы «Симфоньетта»сын язып китерә.

*«Кызыклы хәлләр»не журнал өчен Батулла әзерләде.*



## ИГЕНЧЕЛӘР ЯНЫНА

23 июльдә очерк һәм публицистика секциясенең киңәйтелгән утырышына урак өстендә республикабыз районнарында эшләячәк «Урак-84» язучылар бригадасы членнары җыелды.

Игенчеләр янына китәчәк әлеге бригада алдында торган кичектергесез бурычлар турында Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе Т. Миннуллин, секция житәкчесе М. Зарипов сөйләде. Фикер алышуларда язучылар А. Гыйләжев, Г. Ахунов, М. Хәсәнов, Л. Хәмидуллин, М. Хәбибуллин, Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев һ. б. чыгыш ясап, быелгы иген уңышын җыеп алуда игенчеләргә ярдәм итүнең яңа формаларын гамәлгә кертү турында сөйләделәр.

## ЧУВАШСТАНДА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

18—22 июньдә Чувашстан автономияле республикасында татар әдәбияты көннәре булып узды. ЧАССР Язучылар союзы һәм Культура министрлыгы тарафыннан оештырылган әлеге әдәбият бәйрәмендә Татарстаннан язучылар Әмирхан Еники, Илдар Юзеев, Аяз Гыйләжев, Шәүкәт Галиев, Ренат Харис, Кави Латыйп, Рөстәм Мингалим, Зиннур Мансуров, Камил Кәримов, ТАССРның атказанган артисты баянчы Ганс Сәйфуллин, җырчы Люция Хәсәнова һәм яшь композитор Риф Гатауллин катнашты.

Әдәбият көннәрендә катнашучылар бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин һәйкәленә, шулай ук чуваш әдәбиятына нигез салган демократ-шагыйрь Константин Иванов бюстына чәчәкләр куйдылар.

Көннең икенче яртысында татар язучылары делегациясен КПССның Чувашстан өлкә комитеты беренче секретаре И. П. Прокопьев кабул итте. Кунакларны ул өч орденлы республиканың экономик һәм культура тормышы казанышлары белән таныштырды, авырым алганда, халык хуҗалыгы планнары һәм социалистик йөкләмәләрнең үтәлеше, Чувашстан хезмәт ияләре алдында торган мөһим бурычлар турында сөйләде.

Кичен «Почет билгесе» орденлы республика рус драма театры бинасында Чувашстанда татар әдәбияты көннәрен ачуга багышланган тантана булды. Аны кереш сүз белән КПСС өлкә комитеты секретаре А. П. Петров ачты. Үзенең чыгышында ул кунакларны партия өлкә комитеты, Чувашстан Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы, шулай ук республика хезмәт ияләре исеменнән кайнар тәбрикләде, тугандаш татар һәм чуваш халыклары арасындагы бай традицияле тарихи дуслык, экономик һәм культура элемтәләре турында горурланып сөйләде, Казанны чуваш культурасының бишеге дип атады.

Әдәбият көннәре ачу тантанасында шулай ук ЧАССР Язучылар союзы идарәсе председателе А. Емельянов, Чабаксар машина төзелеше заводы эшчесе, Социалистик Хезмәт Герое А. Александров, Чабаксар районының «За коммунизм» колхозы председателе В. Яруткин, университет студенткасы Т. Ильина, чуваш шагыйрьләре В. Давыдов-Анатри, П. Афанасьев, Р. Сарби, татар әдипләре И. Юзеев, Ә. Еники, А. Гыйләжев, Ш. Галиев, Р. Харис, К. Латыйп һ. б. лар чыгыш ясады.

Соңыннан сәнгать осталары һәм үзешчән коллективлар концерты булды. «Безнең дуслык гомерлек» исемле вокаль-бию сюитасы белән тәмамланган әлеге концертта татар халык җырлары да, шулай ук Б. Мулюковның Чувашстан телевидение һәм радиосы Дәүләт комитетының хоры башкаруында «Казан» ораториясеннән (Р. Харис либреттосы) бер бүлек тә яңгырады.

Икенче көнне Татарстаннан килгән кунаклар, И. Юзеев һәм Р. Харис җитәкчелегендәге ике бригадага бүленеп, Комсомол һәм Яльчик районнарына юл тоттылар. Аларны һәркайда да ипи-тоз һәм якты йөз белән хөрмәтләп каршыладылар. Әдәбият көннәрендә катнашучылар, район үзәкләрендәге очрашулардан соң, татар авылларына чыгып, көндезен фермалардагы терлекчелек йортларында, ә кичен культура сарайларында әдәби-музыкаль чыгышлар ясадылар.

Күңелләргә тирән уелып калган шундый ук очрашулар республиканың Батыр һәм Шемурша районнарында да оештырылды.

Әдәбият көннәре барышында Татарстан вәкилләре Чабаксар шәһәренең истәлекле урыннарын карадылар, машина төзелеше, электр аппаратлары заводлары цехларында булдылар, хезмәт коллективларын үзләренең иҗат үрнәкләре белән таныштырдылар.

Югары дәрәҗәдә һәм эшлекле төстә үткәрелгән әдәбият көннәре күпмилләтле Ватаныбызның тигез хокуклы тугандаш вәкилләре — чуваш һәм татар культураларының туктаусыз үсүен, әдәбиятлар дуслыгының халыклар дуслыгын ныгытуга хезмәт итүен тагын бер мәртәбә ачык итеп раслады.

# ЯШӘҮ АГАЧЫ

«Сабан туе»... Яшь рәссам Шамил Шәйдуллин үзе өчен беренче җитди күргәзмәдә әнә шундый әсәре белән катнашты. Сәнгать сөючеләр һәм белгечләр тарафыннан яратып кабул ителгән әлеге картина, эстетик ләззәт бирү белән берләттән, шул хакта да «сөйләде»: нәкышчеләребез сафына үзенчәлекле талант килә.

Алдан ук шуны әйтергә кирәк: «Сабан туе» («Авылым бәйрәме») полотносында без, беренче чиратта, традицион теманың гадәти булмаган гәүдәләнешен күрәбез. Картинаның үзәгендә — курай уйнаучы малай. Бөтен тарафка агылучы көй-моң, әйтерсең, авыл бәйрәменең аерым-аерым күренешләрен үзара бәйли. Курайчы малай булмаса, бөтенесе дә таралып китәр шикелле. Менә шул рәвешле автор сабан туеның төп аһәңен, хезмәт туенда катнашучы авыл эшчәннәренең рухи күтәренкелеген кабатланмас төсләрдә бирүгә ирешкән.

Үзенең балачак елларын Ш. Шәйдуллин авылда үткәргән. Рәссамның авыл баласы булуы, рухи тамырлары белән авыл җирлегендә берегеп торуы аның һәрбер картинасында да ачык төсмерләнә. Сайлап алынган тема әсәрдән-әсәргә тирәнәя. Рәссам авылдагы социаль һәм культура үзгәрешләрен нечкәләп тотып алырга омтыла, авылның үткәне һәм киләчәге, аерым алганда, традицияләребез язмышы турында уйлана. Мәсәлән, «Шомырт», «Күки авылындагы дусларым», «Рәссам авылда», «Икмәк турында баллада» кебек картиналарда аның шушы юнәлештәге эзләнүләре чагыла.

Яраткан тема тирәнәйгәннән-тирәнәя, димәк ки, рәссамның осталыгы да арткаңнан-арта бара. Ышанып әйтергә мөмкин: Ш. Шәйдуллинның профессиональ әзерлеге югары. Казан художество училищесын тәмамлагач, ул И. Репин исемендәге художество институтында күренекле рәссам Е. Моисеенко җитәкчелегендә белемен арттыра, аннары СССР Художество академиясе член-корреспонденты Х. Якуповның иҗат мастерскоенда осталыгын камилләштерә. «Зур Идел-80» зона күргәзмәсендә һәм шулай ук Бөтенроссия экспозициясендә югары бәя алган «Карт алмагач төбендә» исемле картинасы аның шактый ук бай иҗат тәҗрибәсенә ия булуын һәм профессиональ яктан туктаусыз үсә баруын күрсәтә. Әлеге әсәрнең Татарстан сынлы сәнгате турындагы яңа китап тышлыгында бирелүе дә авторның уңышка ирешүен янә бер мәртәбә раслый.

«Карт алмагач төбендә» картинасының сере нидән гыйбарәт? Барысы да идея эчтәлегенең тирәнлегеннән киләдер. Рәссам кешелек тормышының асылын билгеләүче олы төшенчәләр — буыннар арасындагы рухи бәйләнешләр, зирәк картлык һәм хыялый яшьлек, үлем һәм яшәү кебек төшенчәләр турында сөйли. Картинада өч буын вәкиле сурәтләнгән: картлар, балалар, оныклар... Шулай да мул җимеш бирүче учарланып үскән карт алмагач әсәрнең төп герое буларак кабул ителә. Алмагач образы — тормыш символы. Әлеге яшәү агачы дус һәм тату гаиләдәге кешеләрнең йөрәкләрен үзара бәйли һәм аларны җил-давылдан ышыклап тора шикелле. Киң гомумиләштерүләргә ия булган бу әсәр авылны яратырга, халык традицияләрен баета-баета дәвам иттерергә чакыра, һәм шуның белән ул публицистик яңгыраш та ала.

**Вера ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның бүлек мөдире.

Тышлыкның дүртенче битендә: РСФСРның халык артисты, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Рөстәм Яхин. Рөстәм МАНСУРОВ фотолары.

# «КАЗАН УТЛАРЫ» 1985 ЕЛДА

Татар совет әдәбиятының иң күренекле әсәрләре, гадәттә, укучыларыбызга иң элек «Казан утлары» аша барып ирешә. Журнал сәхифәләре шаһит: СССР һәм РСФСР дәүләт премияләре һәм Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган әсәрләр үз вакытында иң беренче журнал битләрендә басылып чыккан. Социаль һәм әхлакый проблемаларга багышланган, заманча яңгырашлы роман һәм повестьларга, пьеса һәм хикәяләргә, поэма һәм шигырьләргә журнал киләчәктә дә киң урын бирәчәк.

1985 елда совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенә 40 ел тула. Әлеге тарихи вакыйга уңаеннан да күп кенә материаллар, фронтовик әдипләрнең истәлекләре биреләчәк. Журнал битләрендә иң яхшы хикәяләргә «Батырлык дәвам итә» конкурсы бара. Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышланган әлеге конкурска май аенда йомгак ясалачак.

Әлбәттә, журналның йөзен иң беренче чиратта күләмле проза әсәрләре билгели. Алдагы ел нинди яңа әсәрләр белән сөендерер соң? 1985 елда «Казан утлары» үзенең укучыларына берничә роман тәкъдим итәчәк. Алар арасында, мәсәлән, Хисам Камаловның «Безне өйдә көтәләр», Гөлсем Мөхәммәдованың «Эзләнүләр», Чиләбедә яшәүче язучы Рөстәм Вәлиевнең Габдулла Тукай турындагы «Дөнья гаме» дип исемләнгән романнары бар. Алдагы ел өчен повестьларыбыз киштәсе дә буш тормый. Шундый әсәрләрдән Аяз Гыйләҗевнең «Тәмәкене ташладык, рәхәт чигә башладык», Нәби Дәүлинең «Без дөньяга килдек», Гамил Афзалның «Юл башы», Сәет Шәкуровның «Артист» исемле повестьларын әйтеп китәргә мөмкин. Гариф Ахунов, Вакыйф Нуруллин һ. б. язучылар безнең өчен яңа роман-повестьларын тәмамлап киләләр.

Драма әсәрләре белән кызыксынучылар киләсе елда Туфан Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр», Әхәт Гаффарның «Мулланур Вахитов» исемле пьесалары белән таныша алачаклар.

Билгеле булганча, 1986 елда сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 100 ел тула. Бу олы юбилейга әзерлекне журнал быел ук башлаган иде. Киләсе ел саннарында да, алда әйтелгән романнан тыш, халык шагыйре турындагы истәлекләр, әсәрләр урын алачак. Күренекле революционер Мулланур Вахитовның тууына 100 ел тулу уңаеннан, шулай ук Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлына кагылышлы эзләнүләр, Х. Туфан, Ш. Маннур һ. б. турында биреләчәк истәлекләр укучыларыбызда зур кызыксыну уятыр.

«Бүгенге татар поэзиясе һәм аның илкүләм яңгырашы» дип исемләнгән түгәрәк өстәл янындагы сөйләшү дә күпсанлы укучыларыбыз күңелендә теләктәшлек табар дип ышанабыз.

Журнал киләсе елда да татар халкының килеп чыгышы һәм культура тарихыннан кызыклы яңа материаллар бирүне дәвам итәчәк.

«Казан утлары»ның Бөтенсоюз каталогындагы индексы — 73210. Аңа Советлар Союзының барлык почта бүлекчәләрендә язылырга мөмкин. Язылу бәясе бер елга 10 сум 80 тиен.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и об…
ОРГАН